ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**Ә. М. Закирҗанов**

# ТУФАН МИҢНУЛЛИН ДРАМАТУРГИЯСЕ

Казан
2022

**УДК 82.091**
**ББК 83.3(=632.3)**
**З 18**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

**Фәнни мөхәррир**
*филология фәннәре докторы, доцент* ***Н.М. Йосыпова***

**Рецензентлар**
*филология фәннәре кандидаты* ***А.С. Шәрипова****,*
*филология фәннәре кандидаты, доцент* ***Ф.И. Габидуллина***

**Закирҗанов Ә.М.**
**З 18 Туфан Миңнуллин драматургиясе:** монография. – Казан: ТӘһСИ, 2022. – 252 б.
ISBN 978-5-93091-421-4

Монографиядә чорыбызның танылган драматургы Туфан Миңнуллин иҗатының үсеш-үзгәреш этаплары, әдәби-эстетик эзләнүләре, шул исәптән тема-проблема һәм жанр формалары төрлелеге, сәнгати алым-чаралар байлыгы, традицияләр дәвамчанлыгы һәм табышяңалыклары әдәби процесс үзенчәлекләренә нисбәтле тикшерелә.

Хезмәт татар әдәбияты тарихы һәм театры белән кызыксынучыларга, укытучыларга, студентларга һәм мәктәп укучыларына тәкъдим ителә.

УДК 82.091
ББК 83.3(632.3)

**ISBN 978-5-93091-421-4**

© ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2022
© Закирҗанов Ә.М., 2022

## КЕРЕШ

XX гасырның икенче яртысы – XXI гасыр башы татар драматургиясенең үсеш-үзгәрешен, сәнгати эзләнүләр юнәлешен, тормышчанлык һәм халыкчанлык белән сугарылуын билгеләгән әдипләрнең берсе – Туфан Миңнуллин (1935–2012). Татар драматургиясе һәм театры башлангычында торган Г. Камал һәм Г. Исхакый, Ф. Әмирхан һәм М. Фәйзи, К. Тинчурин һәм Ф. Бурнаш кебек классиклар традицияләрен уңышлы дәвам итеп, шулай ук Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт, аларга килеп кушылган Х. Вахит, А. Гыйләҗев, Ш. Хөсәенов һ.б. эзләнүләрен үстерә барып, ул татар сәхнә әдәбиятын үзенчәлекле тема-мотивлар, кабатланмас образлар, сәнгати алымнар белән баета. Татар яшәешенә караган әхлакый һәм фәлсәфи мәсьәләләрне гомумкешелек кыйммәтләре яссылыгында сурәтләве белән татар әдәбиятын ил күләмендә, күпсанлы халыклар арасында танытуга зур өлеш кертә.

Т. Миңнуллин иҗаты – чын мәгънәсендә милли байлыгыбыз. Аның күпсанлы әсәрләрендә татарның борынгыдан алып бүгенгесенә кадәрге гаять катлаулы, каршылыклы тарихы, үзенчәлекле шәхесләре чагылыш таба. Әдип шулар аша татар яшәешенә күз сала, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында фикерләре белән уртаклаша. Яшәешнең төрле якларын гыйбрәтле сурәтләү аша күңелгә үтеп керә, битарафлыктан чыгара, үзеңнең, якыннарыңның, милләтнең язмышы турында уйлануга китерә. Пьесаларында «дөньяда яшәүнең тирән фәлсәфи мәгънәсен Туфан Миңнуллин әхлакый чисталык, пакь намус

белән бәйләп, эмоциональ-тәэсирле, үтемле, гыйбрәтле, тормышчан итеп тасвирлый»[1].

Туфан Габдулла улы Миңнуллин 1935 елның 25 августында хәзерге Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында туа. Үзенең истәлек-хатирәләрендә әти-әнисенең үзенә йогынтысын, аларның тәрбия мәсьәләсенә карашын, балачагының аерым сәхифләрен, мәктәп елларын, чорның авырлык-кыенлыкларын, шатлык-куанычларын сагыш тулы сагыну белән искә ала. Әти-әнисенең әдәби иҗатка ихтирамы малайга Туфан исеме кушудан башлап (атаклы шагыйрь Хәсән Туфан исеменнән алынган бит!), олыгайгач та дәвам иткән. «Диләфрүзгә дүрт кияү» пьесасының язылу тарихын болай дип искә ала: *«Иң рәхәт язылганы әлеге комедия булды. Чөнки аны миңа әти белән әни язышты, аларның миңа, бер-берсенә карата булган кайгыртучан мөнәсәбәте яздырды»*[2] Бу, бер яктан, әти-әнисенең үзара гаять җылы мөнәсәбәте, бер-берсенә булган тирән ихтирам хисен гомер буе саклауларын аңлатса, икенче яктан, аларның балаларына зур йогынтылары булуга ишарә итә. Кайчандыр Казанда Г. Коләхмәтов шәкерте булган әтисе Габдулла гомере буе китап яраткан, үзе өчен генә шигырьләр дә язган. Характерына хас төп сыйфатлар буларак, Т. Миңнуллин аның юаш, әмма үзсүзле һәм принципиаль булуын, намусына каршы бармавын билгеләп үтә истәлегендә: *«Дөньяда намуслы кешеләр бик күп. Ләкин әти кебек чиста, намуслы кешене үз күзләрем белән күргәнем юк, дисәм, ялган булмастыр»*[3]. Әнисе, җиде ир бала арасында бер кыз булып үскәнгә, ирләр холкына, тәвәккәллегенә ия була. Тормышның авыр вакытларында, бигрәк тә сугыш елларында әлеге ныклыгы аркасында балаларын ач итми, хәер сорашырга чыгармый, өсләреннән кием-салымны өзми. Үз шәхесен яклый белә торган горур хатын була ул. Туфан ага истәлегендә әнисе һәм туганнарының горур булуын, әз генә кимсетүгә дә түзә ал-

---

[1] *Шәймиев М.* Иң зур бәхет – халык мәхәббәтенә ия булу // Туфан Миңнуллин: фәнни-публицистик, документаль-биографик җыентык / төз. Г. Рәхим. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 3.

[2] *Миңнуллин Т.* Пьеса ничек языла? // Татарстан. – 1993. – № 1. – Б. 118.

[3] *Миңнуллин Т.* Әти // Татарның бер баласы. – Казан: Рухият, 2003. – Б. 17.

мауларын билгеләп үтә һәм *«ул горурлык хисенең үземдә булуына сөенеп бетә алмыйм»*[1], дип яза. Икейөзлелекне, һәртөр төчеләнүне яратмаган әнисе үзенең эш-гамәле белән балаларына яхшылык эшләү, изге күңелле булуның үрнәген бирә. Аның бала тәрбияләү фәлсәфәсе дә *«Ил алдында хур булма, кеше көлдермә, яманатың дөньяга чыкмасын»*[2], дигәнгә нигезләнә.

Т. Миңнуллинның балачагы сугыш елларына һәм сугыштан соңгы авыр вакытларга туры килә. Әтиләре сугышта булып, әниләренең авыр тормыш арбасын үзе генә тартып баруын балалар да күрә, аңлый, ярдәм итү, булышу, үзеннән өлеш кертү теләгеннән үстерә. Туфан ага истәлегендә авыл хатыннары белән бергә әнисенең Идел аръягындагы җиде-сигез чакрым ераклыктагы урманнан бәләкәй чана белән утын ташуы турында яза. Бервакыт ул, 8–9 яшьлек малай, әнисенә булышырга дип, кышкы салкында чана эзе буйлап аңа каршы китә. Хәле беткән малайны чанадагы утын өстенә утыртып кайталар. Файдасыннан бигрәк мәшәкате күбрәк булса да, әнисе бу вакыйганы һәрвакыт рәхмәт хисе белән искә ала, ул бит ярдәм кирәклеген аңлап, үзен зур егеткә санап юлга чыккан. Бала характеры әнә шулай формалашкан, күрәсең.

Әнисеннән килгән горур табигать, үҗәтлек аңа, ачлы-туклы яшәүгә карамастан, үз авылларында башлангыч, күрше Олы Салтык авылында җидееллык, Олы Карамалыда унъеллык мәктәпне уңышлы тәмамларга мөмкинлек бирә. Шул елларда ул беренче шигырьләрен язып, уй-фикерләрен, хис-кичерешләрен кәгазьгә төшерү тәҗрибәсе ясый. Урта белем алгач, университетта уку теләге булса да, тормыш яшь егетне үз көнен үзе күрергә мәҗбүр итә. Ул бухгалтерлык курсларында укып кайта һәм кибетче, счетовод булып эшли, бераздан Казакъстан якларында чирәм җирләрне эшкәртүдә катнаша. Монысы да Туфан ага өчен үзгә бер тормыш мәктәбе була. Беркатлы авыл егете ялган һәм дөреслек, намус һәм түбәнлек, егетлек һәм ваклык төшенчәләренең мисаллары белән очрашып, кешеләрне таный,

---

[1] *Миңнуллин Т.* Әни // Татарның бер баласы. – Казан: Рухият, 2003. – Б. 27.

[2] Шунда ук. – Б. 28.

өйрәнә. Җирле казакъ халкы хәл-торышы белән танышу, аларга карата гаделсез күренешләр белән очрашу да характерын ныгыта. Шуңа да өстән төшкән күрсәтмәне бозып, җирле халыкка шикәр комы сатарга рөхсәт бирүе аркасында җитәкчеләр белән каршылыкка керсә дә, бу «егетлеге» өчен халык хөрмәтенә лаек була. Үзе истәлегендә язганча, *«...тауарны теләсә кемгә сатарга рөхсәт бирәм. Шуның аркасында казакълар арасында авторитетым да зур, "нугайдың жаксы баласы" булып йөрим»*[1].

1956 елны ул Казан дәүләт университетына укырга керә, әмма бераздан Мәскәүдәге Щепкин исемендәге театр училищесында уку өчен сәләтле кызлар-егетләр төркеме җыела, дигән хәбәрне ишетә. Конкурсны уңышлы үтеп, укырга кабул ителә һәм 1956 – 1961 елларда әлеге уку йортында белем ала. Мәскәүдә уку елларында Т. Миңнуллин үзе өчен театр сәнгате дигән олы дөньяны ача. Танылган шәхесләрден белем алу, төрле милләт кешеләре белән якыннан аралашу, даими рәвештә спектакльләр карау, аларны бәяләүдә катнашу, күренекле артистлар, режиссерлар белән аралашу – болар барысы да аның дөньяга карашын үстерә, сәхнә закончалыкларын тирәнрәк аңлау, артист булуның, әдәби текст белән эшләүнең үзенчәлекләрен ачу мөмкинлеге бирә.

Татар театр тормышына яңа сулыш өргән Р. Таҗетдинов, Н. Ихсанова, Ә. Шакиров, Н. Дунаев, Г. Исәнгулова, Р. Шәрәфиев һ.б. белән бергә, ул Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында артист булып эшли башлый. Шулай да Т. Миңнуллинның күңеле әдәби иҗатка тартыла һәм ул үзен журналистикада сынап карый. 1964 – 1967 елларда Казан телевидениесендә мөхәррир, соңрак «Чаян» журналында әдәби хезмәткәр вазифасында. Күңелендәге уй-фикерләрен, күргән-белгәннәрен кәгазьгә төшерү теләге, аны әдәби иҗатка алып килә. Шул елларда хикәяләре, юморескалары, фельетоннары, кече күләмле сәхнә әсәрләре дөнья күрә, балалар өчен язылган

[1] *Миңнуллин Т.* Казах кызы // Татарның бер баласы. – Казан: Рухият, 2003. – Б. 122.

«Азат», «Айга сәяхәт» кебек әкият-пьесалары, өлкәннәр өчен «Безнең авыл кешеләре» (1962), «Очканда-кагынганда» (1965) драмалары языла, кайберләре сәхнәгә куела. Әлеге әсәрләр булачак драматургка үзен сынап карау, сәхнә закончалыкларына төшенү мөмкинлеге һәм тәҗрибәсе бирә. 1967 елдан башлап Т. Миңнуллин профессиональ язучы сыйфатында иҗат итә.

Әлмәт театры сәхнәсенә менгән «Күрше кызы» (1967), Казанда Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелган «Миләүшәнең туган көне» (1968), Драма һәм комедия театрында (хәзер К. Тинчурин исемендә) сәхнәләштерелгән «Нигез ташлары» (1968) пьесалары драматургиягә талантлы, үзенчәлекле каләм остасы килүен хәбәр итә. 1970–1980 елларда Т. Миңнуллин иҗаты тулысынча ачылып, дистәләгән пьесасы сәхнәләргә менә, китап җыентыклары басылып чыга. Әдипнең төрле тормыш материалына, гыйбрәтле хәл-күренешләргә, вакыйгаларга мөрәҗәгать итеп язылган пьесалары тиз арада үз тамашачысын табып, озак еллар сәхнәләрдә уңыш белән уйнала.

XX гасырның 80 еллары уртасында башланып киткән үзгәрешләр йогынтысында Т. Миңнуллин иҗатында яңа бер этап башлана. Милләт гаме белән яшәгән әдип актив рәвештә республиканың иҗтимагый-сәяси тормышына катнашып китә, җәмәгать эшлеклесе буларак танылу ала. Т. Миңнуллин 1984–1989 елларда Татарстан Язучылар берлеген җитәкли, 1997–2008 елларда ул Халыкара ПЕН-клубның Татар ПЕН-үзәге рәисе вазифаларын башкара, 1984–1989 елларда Татарстан Югары Советы депутаты һәм 1989–1991 елларда элеккеге СССР Югары Советының Татарстаннан сайланган депутаты булып эшли, 1995 елдан вафатына кадәр (2012) – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты. Тормышның төрле якларына караган, киң җәмәгатьчелекне борчыган мәсьәләләр буенча әдипнең үткен, беркемне дә битараф калдырмый торган фикерләре трибуналардан яңгырый, язмалары газета-журналларда басылып чыга. Публицистик эчтәлек белән сугарылган мәкаләләре «Утырып уйлар уйладым» (1998, 2001, 2005, 2010), «Татарның бер баласы» (2003) һ.б. җыентыкларда дөнья күрә.

Иҗат гомерендә Т. Миңнуллинның өч дистәдән артык китабы басылып чыга, 50 гә якын әсәре сәхнәгә куела, йөзләгән мәкалә-язмалары дөнья күрә. Аларның һәрберсе сәнгатьчә югарылыкта язылып, әдәби процесска зур йогынты ясый, укучы-тамашачы ихтирамын казана. Әдипнең байтак әсәрләре башка телләргә тәрҗемә ителеп, Татарстаннан читтә дә танылу ала. Иң уңышлы пьесалары Башкортстан, Мари Эл, Удмуртия, Бурятия, Калмыкия, Дагстан, Осетия, Ичкерия, Казакъстан, Кыргызстан, Таҗикстан республикалары, шулай ук Таллин, Рига, Вильнюс кебек чит башкала милли театрлары, Россиянең Омск, Воронеж, Әстерхан, Мичурин, Мурманск, Түбән Новгород, Новокузнецк шәһәрләре рус театрлары сәхнәләрендә зур уңыш казана. Әдипнең әсәрләре белән чит ил театр сөючеләре дә таныша. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының Германия, Финляндия, Төркиядәге гастрольләре вакытында драматургның «Әлдермештән Әлмәндәр» (Финляндия, 1996; Төркия, 1999), «Җанкисәккәем» (Германия, 1996; Финляндия, 2000), «Йөрәк маем» (Финляндия, 1997) спектакльләре тәкъдим ителеп, белгечләр һәм җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнә. Т. Миңнуллин пьесалары инглиз, төрек һ.б. телләргә тәрҗемә ителә.

Т. Миңнуллин «Нигез ташлары» комедиясе һәм «Үзебез сайлаган язмыш» драматик хикәясе өчен 1974 елда Республика яшьләр оешмасының М. Җәлил исемендәге премиясенә, «Ай булмаса, йолдыз бар» әсәре буенча Әлмәт драма театрында куелган спектакль өчен 1979 елда Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә һәм Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле өчен, режиссеры М. Сәлимҗанов һәм баш рольне башкаручы Ш. Биктимеров белән берлектә, 1979 елда Россиянең К. Станиславский исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. Татар театр сәнгатен үстерүдәге аеруча хезмәтләре өчен аңа 1978 елда Татарстанның һәм 1984 елда «Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе», 2005 елда «Башкортстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр бирелә. 1984 елда ул «Почет Билгесе» ордены белән

бүләкләнә. 2005 елда Татарстан Республикасы Президенты Указы белән Т. Миңнуллин «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән шәрәфле исемгә лаек була һәм шул ук елда «Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен» ордены белән бүләкләнә.

Татарстанның Халык язучысы Туфан Миңнуллин 2012 елның 2 маенда вафат була һәм Казанның Яңа бистә зиратына җирләнә.

* * *

Т. Миңнуллинның күпкырлы бай иҗаты драматургия, публицистика, проза, әдәби тәнкыйтьне үз эченә ала. Аларны үзара тыгыз бәйләнештә, бөтенлектә өйрәнү, әдипнең сәнгатьле дөньясын, фикерләү үзенчәлекләрен аңларга ярдәм итә. Иҗатта беренче адымнарын ул хикәяләр, юморескалар язудан башлый. Моңа «Чаян» журналында эшләве дә йогынты ясый, билгеле. Алар тормыштан алынган булулары, укучыга бик тә якын хәл-күренешләр турында артык көчәнми генә бәян иткән, әмма эзлекле, мәгънәле булулары, куелган мәсьәләнең ачык-аңлаешлы чишелүе белән укучыга якын була.

Т. Миңнуллинның күзәтүчәнлеге, заман рухы белән яшәве аеруча публицистиксында тулы чагыла. «Утырып уйлар уйладым» (1998, 2001, 2005, 2010), «Татарның бер баласы» (2003) кебек җыентыклардагы горур табигатьле, үткен телле публицист тарафыннан иҗат ителгән язмалар кемне генә битараф калдырыр икән. Аларда Туфан аганың әрнүе, борчу-шатлыклары, теләк-омтылышлары чагылыш таба. Аның яшәеш фәлсәфәсе белән тулы фикер-карашлары синең җаныңа үтеп керә, башкаларга түгел, үзеңә дә әйтергә куркып йөргән уйларыңны тартып чыгара. Әдипнең табигыйлеге, авылчанлыгы әлеге мәкалә-очеркларда да чагылыш таба. Авылчанлык ул – гадилек, әмма беркатлылык түгел, сабырлык, әмма мокытлык түгел, тыйнаклык, әмма куркаклык түгел, горурлык, әмма тәкәбберлек түгел, кызу канлылык, әмма дуамаллык түгел. Авылчанлыкның җыелма образын драматургның күпсанлы әсәрләреннән табып була.

Т. Миңнуллин көндәлекләрендә төрле елларда илдә, республикада, аерым төбәкләрдә яисә үзенең шәхси тормышында булган вакыйга-хәлләргә мөнәсәбәтле эчтәлекләре белән дә, язылу формалары белән дә төрле булган язмалары туплап бирелгән. Аларда тынгысыз җанлы әдипнең сәяси, иҗтимагый, мәдәни хәл-күренешләргә нисбәтле уй-фикерләре чагыла. Арада мәкалә, очерк, юмореска, истәлек, хәтта мәзәк жанрына караганнары да бар. Автор өчен китап укучы күңелендә теге яки бу мәсьәләгә караш булдыру һәм нindидер нәтиҗәләр ясарга этәрү әһәмиятле. Шулар аша ул җитди гомумиләштерүләргә килә.

Күпсанлы язмалар артында без халкыбызның бүгенгесе һәм киләчәге өчен җан атучы, матур сыйфатларына шатланучы, ямьсез якларына тирәнтен борчылучы, шулай да (кайчандыр Йосыф Акчура татарның олы шәхесе Фатих Кәрими турында әйткән сүзләрне кулланганда) «милләтен чеметеп сөюче» шәхесне күрәбез. Т. Миңнуллин үткәне данлыклы һәм фаҗигалы булган татар халкының матур киләчәгенә ышана. Шуңа да данлы һәм фаҗигалы үткәнебез яисә бүгенгебезнең авыр, борчулы күренешләре турында сүз алып барганда да күңел төшенкелегенә бирелми. Бу урында әдипнең бөтен иҗаты оптимизм белән сугарылуын әйтеп үтәргә кирәк.

Милләт язмышы мәсьәләсе аның публицистик мәкаләләрен күптөрле тема-сораулар аша үзара бәйләп тора. Бу да – аның публицистикасына хас бер үзенчәлек. Язучы укучысы белән ихластан сөйләшү алып бара. Ул купшы сүзләрне, төчелекне кабул итми. Шуңа да җәмгыятьтә әхлакый һәм милли кыйммәтләрнең үзгәрүе, намуслы, әхлаклы кешеләргә яшәүнең һәрвакыт авыр булуы, алардан рухи көч таләп итүе турында да, татар язмышына янаган куркыныч хакында да ачыктан-ачык һәм гыйбрәтле мисалларга нигезләнеп яза.

Туган җир кадере турындагы язмалар тулы бер циклны тәшкил итә. Үзен һәрвакыт авыл кешесе итеп хис иткән язучы татар авылының гасырлар дәвамында үзенә генә хас сыйфатларны саклавын, ә инде үзгәртеп корулардан соң, язылмаган кануннардан читләшә башлавын билгели («Барып җиттек», «Хуш, авылым?»). Авылда урлашуның гадәти күренешкә әйләнүен,

кешеләрдә оялу хисе бетә баруын да яшереп кала алмый. *«Җир бүген гомерен җиргә багышлаган авыл кешесенә дә кирәкми. Аны, атна саен реформа ясап, җирдән биздереп бетерделәр»*[1], диюе ил башында утыручылар сәясәтенә бәя булып яңгыраса да, автор авыл халкының ваемсызга, битарафка әйләнүе өчен дә әрни.

Т. Миңнуллин көндәлекләренә хас тагын бер үзенчәлек – публицистик аһәңнең лиризм белән үрелеп баруы. Бу бигрәк тә аның остазлары, каләмдәшләре, үзе белгән һәм аралашкан кешеләр турындагы язмаларында чагыла. Гомумән, ул остазларының бай, мәгънәви образларын тудыра, үзләренә генә хас характер сыйфатларын ача («Риза абый», «Празат абый», «Сара апа», «Сибгат абый»). Мондый истәлекләр өлкәннәргә ихтирам билгесе генә түгел (анысы да бик мөһим), аларда чын шәхесләрдә генә була торган сыйфатлар калкытып куела. Бүгенге тормышыбызда шуларның кимүе өчен борчылу, сәбәпләре турында уйланып, *«буыннар шулай хәерхаһлык белән алмашынып барса гына, кешелек дөньясы камил буладыр»,* дип нәтиҗә ясый.

Әдип замандашларыннан кемнәргә мөрәҗәгать итә һәм алар аның игътибарын нәрсә белән җәлеп итә соң? Т. Миңнуллин тормышта үзе булып кала алган, горур табигатьле, үзен, якыннарын, халкын яклый белә торган һәм, иң мөһиме, шәхес булып формалашкан, һәр нәрсәгә үз караш-мөнәсәбәте булган кешеләр турында яза. Татары өчен теләсә кемнең якасыннан алырга әзер Зәки Зәйнуллинның «теләсәң-теләмәсәң дә уйларга мәҗбүр итә» торган әсәрләр язуын, «кешеләрне яратуын», «мескеннәрне, икейөзлеләрне яратмавын», «татар йөзенә тап төшермәвен» («Кылчыклы Зәки»), Марсель Сәлимҗановның һәр эшне уйлап эшләвен, «беркем алдында да шәхесен түбән төшереп мескенләнмәвен», шәхес булып калуын («Сагыну»), Марсель Галиевнең туган телгә хас серлелекне, матурлыкны, шигъри аһәңне, «берничә җөмлә, кайчакта берничә сүз белән кеше характерын

---

[1] *Миңнуллин Т.* Барып җиттек // Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б. 95.

күрсәтә» алуын («Көлә белеп көлү»), якташы Рафаэль Гыймадиевның көчле рухын («Рух»), Нурихан Фәттахның туры сүзлелеген, горур табигатен («Киребеткән»), Мөхәммәт Мәһдиевнең проза остазы буларак детальләр белән оста эш итүен («Кеше китә – җыры кала...»), Нурлат районы һәм шәһәре хакимияте башлыгы Фатыйх Сибгатуллинның көчле характерын, эш кешесе булуын («Шундый кеше»), Фасил Әхмәтовның татар милли көйләрен саклау өчен зур хезмәт куюын («Яшьтәш») күреп ала һәм әлеге кешеләрнең матур портретларын аерым штрихлар белән, истә калырлык итеп сурәтли. Аларның эш-гамәле, уйфикере белән авторның, үзе язганча, «пәрие» туры килә.

Т. Миңнуллин – язучы буларак, тормышны гаять оста күзәтүче. Ул яшәештәге вакыйга-күренешләрне сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә карый. Бу исә аңа үткәнне, бүгенгене һәм киләчәкне фәлсәфи яссылыкта бәяләү мөмкинлеге бирә. Бу публицистик язмаларының тагын бер үзенчәлеге булып тора. Яшәү мәгънәсе... Автор өчен әлеге төшенчәнең асылы ачык һәм бернинди икеләнүләргә урын калдырмый: үз язмышыңны милләт язмышы белән тыгыз бәйләп, аның гаме белән яшәү. Моның өчен һәр кешедә милли үзаң уятырга, чын шәхес тәрбияләргә кирәк. Иң мөһиме – *«ул рухыңның, җаныңның ирегеН саклау. Җаны ирекле кешене бер генә тупас көч тә буйсындыра алмый»*[1]. Автор Балтач районы кешеләренең горурлыгы булган, калын урман уртасындагы түгәрәк аланда үскән гаҗәеп матур, чын мәгънәсендә табигать бизәге булган чыршыга бәйле тирән фәлсәфә таба: беренчедән, кеше ирекле булганда гына бәхеткә ирешә; икенчедән, *«матур, мәһабәт булсаң да, синнән ерак түгел, сине саклап торган, сине гүзәл итеп күрсәткән бүтән “агачлар” барын онытмыйк»*[2].

Әдипнең публицистик язмаларында дистәләгән кеше язмышы чагылыш таба. Аларның күбесе – гыйбрәтле язмыш булып, бәхет, гаилә, нәсел, бүгенге һәм киләчәк төшенчәләренә

---

[1] *Миңнуллин Т.* Җавап // *Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. –Б. 121.

[2] *Миңнуллин Т.* Чыршы // Туфан Миңнуллин: фәнни-публицистик, документаль-биографик җыентык / төз. Г. Рәхим. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 197.

барып тоташа. Татар милләтенең рухи көчсезлеге чагылышы булган, аның киләчәк язмышына зур йогынты ясаган катнаш никахлар мәсьәләсенә автор әледән-әле әйләнеп кайта. Бу сорауга ул «Илгизәр плюс Вера» пьесасы белән ачык һәм аңлаешлы итеп җавап биргән иде инде. Шунысы игътибарга лаек: аерым мәкаләләрендә башка милләт кешеләре белән никахлашып, соңыннан бәхетсез язмышка дучар булучыларны аңларга тырышса, рус мәкале белән әйткәндә, «не их вина, а беда» дип бәяләсә, икенче бер язмаларда язучының бәясе катгый. Башка милләт кешесе белән тормышын бәйләүчеләрнең шул милләт кешесенә, бик еш кына балалары өчен дә «татарин» гына булган кызганыч язмышларга әверелүен күрә. Ә инде «Зар» исемле язмада ике малаеның да марҗа кызларына өйләнүен, килённәренең өйдә татарча сөйләшергә дә рөхсәт итмәвен сөйләүче апа язмышына нисбәтле усал, кискен нәтиҗә ясый: *«Мин бу апа зарланып сөйләгән ише кыйссаларны мең тапкыр тыңладым инде, әллә ни исем китмәде, апаны кызганмадым да. Үзләре үстергән балалар бит, кемгә өйләнсә дә, барыбер, әйбәт кеше генә булсыннар, дип сөйләнеп яшәгәннәрнең картайгач зарлануы гына ул. Андыйларга татар, ни чәчсәң, шуны урырсың, ди. Бигайбә»*[1].

Татар язмышына, үткәненә һәм бүгенгесенә кагылышлы мәсьәләләрдә Т. Миңнуллин ваемсызлыкны, «ярар инде», дип кул селтәүне, эндәшми калуны кабул итми. Аның актив гражданлык позициясе күбебезгә үрнәк булып тора («Ялган», «Кто портит погоду в России», «Әйтәсен әйтәм»). Туган тел язмышы һәрдаим авторның игътибар үзәгендә. Ул аңа аралашу чарасы итеп кенә карамый, ә милләт яшәешен, хәлен, көчегәрен билгеләүче фактор буларак бәяли. *«Ул күңелдә җыелган изге сүзләрне аңлатучы ата-бабалар васыяте дә икән. Үзебез дә аңлап бетермәгән кайтавазларны сиземләү чарасы икән»*[2], – дип яза ул. Әдәбиятка, аерым алганда драматургиягә

---

[1] *Миңнуллин Т.* Зар // *Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. –Б. 177.

[2] *Миңнуллин Т.* И туган тел! // Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б. 148.

кагылышлы язмаларда күтәрелгән мәсьәләләр да телгә бәйле яктыртыла. Телсез әдәбият була алмый – Т. Миңнуллин өчен язылмаган закон бу. Шуңа да әдип соңгы елларда театрларыбызда да татар теленең нәфислеге, көче, аһәңе кимүе өчен борчыла һәм бу сорауда бернинди килешүләргә барырга ярамавын аңлатып, нәтиҗә ясый: милли театрыбыз бетсә, татар да бетә («Телсез әдәбият буламы?»).

Әдип публицистикасында иҗтимагый-социаль мәсьәләләрдән дә читләшми. Гадәттә, дәрәҗәле, хөрмәткә лаеклы, күптөрле бүләкләр лауреаты булган кешеләр ил, республика җитәкчеләрен мактау белән мавыга. Т. Миңнуллинда бу юк. Ул җитәкчеләрнең эшчәнлегенә салкын акыл белән бәя бирә. Язмаларда бер фикер һәрдаим кабатлана: аерым сорауларда республика җитәкчеләре белән килешеп бетмәсәм дә, алар алып барган сәясәтне яклыйм, дөрес дип табам, ди. Шуның белән бергә, язучы республика җитәкчеләре игътибар итәргә тиешле мәсьәләләрне кабыргасы белән куюдан читләшми. Миллионнарга төшереп спорт клублары тотуны, чит ил спортчылары сатып алуны һәм шул ук вакытта мәктәпләрдә спорт инвентарьләре булмауны, балалар белән эшләүче тренерларга бик аз хезмәт хакы түләүне дә якламый ул («Нигә?»). Бу сорауларга карашын образлы итеп болай белдерә: *«Озаграк карап торсам, елмаеп куям: республикабызны көяз бер егеткә охшатам. Әнә ул, муенына мең тәңкәлек галстук тагып, Бауман урамыннан узып бара. Галстук гаҗәеп килешә үзенә, тик бер нәрсә генә кәефне боза – көязебезнең ыштан төбе тишек. Шул тишектән шәрә тән ялт-йолт күренеп бара»*[1].

Гаять катлаулы һәм каршылыклы, татар милләте язмышына бәйле җитди сораулар алда торганда Т. Миңнуллин драматург, прозаик, публицист булып кына кала алмый. Бүген язучыга зур, кичектергесез вазифалар йөкләнүен тирәнтен аңлый ул. Шуңа да Татарстан Дәүләт Советы трибунасыннан ясаган чыгышларында без тәҗрибәле сәясәтчене, «Татарның әхлакый кодек-

---

[1] *Миңнуллин Т.* Бер сөенәм, бер көенәм // Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б. 79.

сы»н иҗат иткән акыллы фәлсәфәчене күрәбез. Т. Миңнуллинның бөтен язганнары кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәте турында булып, аларда татарның яшәү рәвеше, тормыш мәгънәсе, иң матур хыял-омтылышлары чагылыш таба. «Татарның әхлакый кодексы» – ул халкыбызны милләт итеп саклап калуда таяныч ноктасы булган фикер-карашлар тупланмасы. Аның нигезен әдип, беренче чиратта, рухи ныклыкта, җан азатлыгында таба. Унике пункт рәвешендә татар кешесендә канун буларак урын алырга тиешле өндәмәләр билгеләнә. Иң мөһимнәре буларак түбәндәгеләр аерып чыгарыла: дәүләтчелеккә омтылу; бердәмлекне саклау; туган телне яклау һәм үстерү; горур булып үз кадереңне белеп яшәү; үз хокукларыбызны яклау; гыйлембелемле булу; әхлакый камиллеккә омтылу; туган җирне кадерләп яшәү; нәселеңнең сәламәт булуы; милли үзаң булдырып, татарлыкны якларга әзер булу; дөнья казанышларын үзләштерү һәм файдалану[1].

* * *

Т. Миңнуллин әсәрләре тематик төрлелеге, жанр һәм жанр формалары байлыгы белән чын мәгънәсендә соклану уята. Шулай да әдип иҗатының үзенчәлеге аеруча тулы Кеше шәхесен өйрәнүендәге, аның яңадан-яңа сыйфат-төсмерләрен, каршылыклы рухи дөньясын ачу белән бәйле. Драматургны кешенең шәхес буларак формалашуы, тормышта үз урынын табу юллары, җан-рухына нигез итеп нәрсәне алуы һ.б. кызыксындыра. Шуңа да аның геройлары гаять тормышчан һәм үзләренә генә хас характерга ия булулары белән аерылып тора, аларның рухи дөньясын ачуда әдип психологизм алымнарына нигезләнә, хис-кичерешләрен укучы-тамашачыга җиткерүнең яңадан-яңа юлларын, алым-формаларын таба.

Т. Миңнуллинның бай иҗаты үз вакытында ук тәнкыйтьчеләрнең, әдәбият-сәнгать белгечләренең игътибарын җәлеп

---

[1] *Миңнуллин Т.* Татарның әхлакый кодексы // Туфан Миңнуллин: фәннипублицистик, документаль-биографик җыентык / төз. Г. Рәхим. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 64–66.

итә. Баштагы елларда әсәрләренә нигезләнеп куелган спектакльләргә бәяләмәләр урын алса, бераз соңрак драматург иҗатын максатчан тикшергән язмалар дөнья күрә. Аның тормыш һәм иҗат юлын, сәнгати эзләнүләрен эзлекле күзәтеп килгән авторларның берсе булган А. Әхмәдуллинның төрле елларда газета-журналларда басылып чыккан мәкаләләре туплап бирелгән «Ничек сурәтләргә сине, замандаш?»[1], Сәхнә әдәбияты һәм тормыш»[2], «Горизонты татарской драмы»[3], «Дөреслеккә ирешү юлында»[4], «Офыклар киңәйгәндә»[5] тәнкыйть җыентыкларында урын алган язмаларында драматург пьесаларына этрафлы бәя бирелеп, тема-проблема киңлеге, жанрлар байлыгы, образ-характерлар бирелеше ачыклана. Ә инде галимнең «Күңелләрне уятыр»[6], «Татарская драматургия»[7] монографияләрендә XX–XXI гасырлар чиге сәхнә әдәбиятына нисбәтле драматургның шул елларда язылган, сәхнәләрдә куелган күпсанлы пьесалары тикшереп бәяләнә, алып килгән яңалыгы, яңа тенденцияләргә нигез салуы, үз чоры әдәби процессында тоткан урыны һәм әсәрләренең заманчалыгы ачыклана. А. Әхмәдуллин драматургның сәхнәгә куелган беренче пьесаларыннан башлап вафатына кадәр дип әйтерлек иҗатына игътибарлы була, һәрдаим этрафлы сүзен әйтеп, иҗат серләрен киң җәмәгатьчелеккә күрсәтеп бара. Т. Миңнуллинның иҗат үзенчәлеген билгеләячәк үзенчәлекләр буларак, пьесаларында «төп игътибар кешенең эчке дөньясы-

---

[1] *Әхмәдуллин А.* Ничек сурәтләргә сине, замандаш? – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 151 б.

[2] *Әхмәдуллин А.* Сәхнә әдәбияты һәм тормыш: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 304 б.

[3] *Ахмадуллин А.* Горизонты татарской драмы: Лит.-критич. статьи. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. – 216 с.

[4] *Әхмәдуллин А.* Дөреслеккә ирешү юлында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 255 б.

[5] *Әхмәдуллин А.* Офыклар киңәйгәндә. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 239 б.

[6] *Әхмәдуллин А.* Күңелләрне уятыр: Монография. – Казан: Мәгариф, 2007. – 223 б.

[7] *Ахмадуллин А.* Татарская драматургия: история и проблемы. – Казан: Татар. кн. изд-во, 2012. – 511 с.

на, аның рухи халәтен тирән анализлауга юнәлтелгән»[1] булуны, «геройларының психологик кичерешләрендәге нечкә борылмаларга гаять сизгерлеген»[2] аерып куя. Галим фикеренчә, Т. Миңнуллин – көтелмәгән ситуацияләр корып, шунда образны көтелмәгәнчә ачу остасы. Тематика һәм проблематика ягыннан да, художестволылык җәһәтеннән дә күп тармаклы, жанрлар системасы да төрле, бай булып, аңарда комедия һәм драма жанрларының байтак төрләрен күрергә мөмкин. А. Әхмәдуллин драматургның сәнгати эзләнүләрендә мондый мөһим сыйфатларны аерып чыгара: кешенең шәхес буларак формалашуы; яшәешнең асылын тәшкил иткән әдәп-әхлак кануннарының сакланышы; образ-характерның җанлылыгы һәм тормышчанлыгы; яңадан-яңа тема-мотивларга мөрәҗәгать итү; сурәтләнгән материалга нисбәтле яңа жанр формалары табу; замандаш образларын сәхнәгә менгерү; шартлы-аллегорик образлардан файдалану[3]. Тәнкыйтьче Т. Миңнуллин драмаларына хас иң характерлы стиль үзенчәлеге буларак, «аларны якты һәм күтәренке оптимистик рухлы иткән мул бизәклелек, сүз-сурәтләү чараларына байлык, төсләр күплеге»н[4] аерып чыгара.

Н. Ханзафаровның «Татарская комедия»[5] монографиясендә, күпсанлы мәкаләләрендә Т. Миңнуллин пьесаларының жанр һәм жанр формалары, көлкелелек аша яшәешнең мөһим проблемаларын чагылдыру юллары, чор драматургиясендәге эзләнүләрне әйдәп баруы ассызыклана. Й. Нигъмәтуллинаның «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве»[6] китабында «Хушыгыз» драмасы модернизм эстетикасына нисбәтле өйрәнелә. А. Саттарованың

---

[1] *Әхмәдуллин А.* 1968 елда татар драматургиясе // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б. 19.

[2] Шунда ук. – Б. 21

[3] *Әхмәдуллин А.* Үзе сайлаган язмыш // Дөреслеккә ирешү юлында. Мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – Б. 55–69.

[4] Шунда ук. – Б. 71.

[5] *Ханзафаров Н.*Татарская комедия. – Казань: Фэн, 1996. – 228 с.

[6] *Нигматуллина Ю.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. – Казань: Фэн, 2002. – 176 с.

«Современная татарская драматургия: 1985–2000 гг.»[1] хезмәтендә, башка авторлар белән бергә, Т. Миңнуллин драмалары чор тенденцияләре һәм шулар аша заман героен сурәтләү үзенчәлекләренә нисбәтле тикшерелә. Ф. Миңнуллинаның «Жанр драмы в татарской драматургии рубежа XX–XXI веков»[2] китабында драматургның унга якын пьесасы жанр һәм жанр формасын ачыклаучы алым-чаралар яссылыгында бәяләнү белән игътибарга лаек.

А. Батталованың «Татар драматургиясендә йорт образының үсеш-үзгәреше (1960–2000 еллар)»[3] монографиясендә куелган проблемага нисбәтле Т. Миңнуллинның байтак пьесасы өйрәнелә. Әдәби процесс белән тыгыз бәйләнештә, драматургның сәнгати фикерләү үзенчәлеге, тема-мотивлар аша яшәеш кыйммәтләрен, шул исәптән туган авыл, туган йорт кадерен ачу алымнары тикшерелә. Төрле чорларда «йорт» мотивы чагылышының билгеле бер үзгәреш кичерүе, тормыштагы үзгәрешләрне ачуга, бәяләүгә хезмәт итүе билгеләнә. Автор билгеләп үткәнчә, «Т. Миңнуллин драматургиясендә йорт эш-хәрәкәт мәйданын тудыруда, чынбарлык картинасын формалаштыруда катнаша[4].

А. Шәрипованың «Татарская драматургия XX – начала XXI в.: проблема инварианта»[5] монографиясендә «инвариант» төшенчәсенә нисбәтле сәхнә әдәбияты үсешенең төп этаплары билгеләнеп, аерым чорга хас үзенчәлекләр аеруча тулы чагылган пьесаларга анализ ясала. Автор Т. Миңнуллинның драматургиягә алып килгән яңалыгын классик инвариантны, байтак вакыттан соң, беренче булып халыкчан проблемаларга нисбәтле һәм дөньяның сурәтле картинасы рәвешендә чагылдыруда[6], дип билгели.

---

[1] *Саттарова А.* Современная татарская драматургия 1985–2000 гг.: Концепция эпохи и героя. – Казань: Гуманитария, 2003. – 152 с.

[2] *Миннуллина Ф.Х.* Жанр драмы в татарской драматургии рубежа XX–XXI веков. – Казань: ИЯЛИ, 2019. – 144 с.

[3] *Батталова А.* Татар драматургиясендә йорт образының үсеш-үзгәреше (1960–2000 еллар). – Казан, 2009. – 132 б.

[4] Шунда ук. – Б. 60.

[5] *Шарипова А.С.* Татарская драматургия XX – начала XXI в.: проблема инварианта: монография. – Казань: ИЯЛИ, 2022. – 336 с.

[6] Шунда ук. – Б. 133.

Т. Миңнуллин иҗаты буенча М. Шәрипов «Туфан Миңнуллин драматургиясе. Герой проблемасы һәм аның сәнгати гәүдәләнеше»[1] һәм Г. Шакирова «Туфан Миңнуллинның 1980–1990 еллар драматургиясе»[2] темасына тикшеренүләр алып бара. Аларда драматург иҗатында образлар системасы, аларның алым-чаралар аша сурәтләнеше, шулай ук аерым чорга караган әсәрләренең идея-проблематикасы һәм сәнгатьчә эшләнеше чагылыш таба.

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан чыгарылган алты томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның 6 нчы томында[3] урын алган А. Әхмәдуллин язмасында Т. Миңнуллинның иҗат портреты бирелә. Хезмәттә драматургның тормыш һәм иҗат юлы үзара бәйләнештә бирелеп, эзлекле рәвештә сәнгати эзләнүләре, табышлары барлана, чор үзгәрешләре белән бергә, татар сәхнә әдәбиятына алып килгән яңалыгы, әсәрләренең әдәби процесстагы урыны билгеләнә. Ә инде сигез томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның 7 нче томында[4] Ә. Закирҗанов драматург иҗатын үз чоры әдәби процессы белән тыгыз бәйләнештә өйрәнә. Сигезтомлыкның 6, 7 һәм 8 нче томнарында[5] урын алган XX гасырның икенче яртысы – XXI гасыр башы татар драматургиясенә күзәтүләрдә Т. Миңнуллин пьесалары да өйрәнелеп, кызыклы һәм җитди нәтиҗәләр ясала.

---

[1] *Шарипов М.* Драматургия Туфана Миннуллина. Проблемы героя и его художественное воплощение: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Уфа, 1989. – 20 с.

[2] *Шакирова Г.* Драматургия Туфана Миннуллина 1980–90-х г.: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1999. – 19 с.

[3] *Әхмәдуллин А*. Туфан Миңнуллин // Татар әдәбияты тарихы: алты томда: 6 т.: 60–90 еллар әдәбияты. – Казан: «Раннур» нәшр., 2001. – Б. 405–429.

[4] *Закирҗанов Ә.* Туфан Миңнуллин // Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. 7 т.: 1985–2000 еллар. – Казан: Фолиант, 2019. – Б. 263–274.

[5] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда: 6 т. / фән. мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 676 б.; Татар әдәбияты тарихы: сигез томда: 7 т. / фән. мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. – Казан: Фолиант, 2019. – 567 б.; Татар әдәбияты тарихы: сигез томда: 8 т. / фән. мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. – Казан: Фолиант, 2021. – 740 б.

И. Иляллованың «Театр имени Камала. Очерк истории: исследование»[1], М. Арслановның «Татарское режиссерское искусство (1941–1956)»[2], «Татарское режиссерское искусство (1957–1990)»[3], «Тылсым. Татар театры: режиссерлар һәм драматурглар»[4], Р. Солтанованың «История татарского театра в плакатном искусстве»[5], «Сценография татарского театра: основные этапы и закономерности развития (XX – нач. XXI вв.)»[6], А. Салихованың (Габәши) «Особенности формирования и развития татарского сценического искусства»[7] хезмәтләрендә татар театры тарихы, танылган режиссерлар, артистлар, музыкантлар, рәссамнәр эшчәнлеге белән бергә, куелган пьесалар, шул исәптән Т. Миңнуллин әсәрләренә дә бәя бирелә, спектакльләрдә чагылыш тапкан үзенчәлекләр аерып чыгарыла.

Т. Миңнуллинның җыентыклары, аерым журналларда басылып чыккан пьесалары турында йөзләрчә мәкалә язылган, арада А. Гыйләҗев[8], Р. Мөхәммәдиев[9], Р. Мостафин[10], Н. Хан-

---

[1] *Илялова И.* Театр имени Камала. Очерк истории: исследование. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 328 с.

[2] *Арсланов М.Г.* Татарское режиссерское искусство (1941–1956). – Казань, 1996. – 224 с.

[3] *Арсланов М.Г.* Татарское режиссерское искусство (1957–1990). – Казань, 2002. – 272 с.

[4] *Арсланов М.Г.* Тылсым. Татар театры: режиссерлар һәм драматурглар. – Казан: Мәгариф, 2008. – 287 б.

[5] *Султанова Р.Р.* История татарского театра в плакатном искусстве. – Казань, 2017. – 352 с.

[6] *Султанова Р.Р.* Сценография татарского театра: основные этапы и закономерности развития (XX – нач. XXI вв.). – Казань, 2020. – 592 с.

[7] *Салихова А.Р.* Особенности формирования и развития татарского сценического искусства. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – 360 с.

[8] *Гыйләҗев А.* Замандашыбыз Әлмәндәр // Соц. Татарстан. – 1978. – 18 апр.; аныкы ук: Притяжение сцены (К 50-летию Туфана Миннуллина) // Вечерняя Казань. – 1985. – 25 авг.

[9] *Мөхәммәдиев Р.* Тормыш дәвам итә // *Мөхәммәдиев Р.* Якутлар табыладыр вакыт белән. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – Б. 181–197.

[10] *Мустафин Р.* Факел внутренней свободы // Татарстан. – 1997. – № 5. – С. 6–7.

зафаров[1], М. Арсланов[2], Ә. Закирҗанов[3], Н. Йосыпова[4], А. Габәши-Салихова[5], Ф. Миңнуллина[6] һ.б. мәкаләләре фәнни нигезе, уңышлы гомумиләштерүләр аша Т. Миңнуллинның иҗат серләрен, сәнгати табыш-яңалыкларын ачу ягыннан аеруча игътибарга лаек.

Т. Миңнуллинның төрле театрларда сәхнәгә куелган һәрбер пьесасы һәм тамашачыларда, һәм театр белгечләрендә зур кызыксыну уятып, алар буенча күпсанлы бәяләмәләр, күзәтүләр языла. Танылган театр белгечләре И. Илялова[7], Д. Гыймранова[8],

---

[1] *Ханзафаров Н.* Драмаларда – күңел дөньябыз (хәзерге драматургиягә бер караш) // Мәдәни җомга. – 2002. – 15 март.

[2] *Арсланов М.* Туфан Миңнуллин драматургиясе // Казан утлары. – 2015. – № 8. – Б. 177–178.

[3] *Закирҗанов Ә.* Заман белән бергә // Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – Б. 16–45; *Закирҗанов Ә.* Әдипнең иҗат дөньясы // Рухи таяныч. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – Б. 73–93; анык ук: Туфан Миңнуллинның иҗат дөньясы (соңгы еллар иҗатына бер караш) // Мәйдан. – 2010. – № 9. – Б. 112–123. һ.б.

[4] *Йосыпова Н.* Соңгы еллар татар драматургиясе // Хәзерге татар әдәбияты / төз.: Г.Р. Закирова, Л.Ә. Гыйззәтуллина. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 436–443.

[5] *Габәши-Салихова А.* Иҗатында – ил гаме // Миңнуллин Т. Пьесалар.– Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.– Б. 5–13.

[6] *Миңнуллина Ф.* XX гасыр ахыры татар драматургиясендә шәхес фаҗигасе (Т. Миңнуллин, Р. Хәмид, З. Хәким әсәрләре мисалында) // Тюркский мир и исламская цивилизация: проблемы языка, литературы, истории и религии: материалы IX Международной тюркологической конференции (Россия, Республика Татарстан, г. Елабуга, 13–14 апреля 2018 г.) / отв. ред. Р.Б. Камаева. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. – С. 171–174; анык ук: *Миннуллина Ф.Х.* Новые явления в татарской драматургии конца XX – начала XXI вв. // Научный Татарстан. – 2021. – № 2. – С. 78–89 һ.б.

[7] *Илялова И.* «Ир-егетләр» (Г. Камал исем. ТДАТта куелу уңае белән) // Соц. Татарстан. – 1971. – 30 май; анык ук: Плечо товарища: («Мужчины». К постановке в ТГАТе им. Г. Камала) // Театральная жизнь. – 1971. – № 21. – С. 28; анык ук: Переходный возраст. Заметки о состоянии современной татарской драматургии // Советская культура. – 1985. – 24 декабря.

[8] *Гимранова Д.* Улыбка – это тоже важно... («Четыре жениха Диляфруз» на сцене ТГАТа им. Г. Камала) // Советская Татария. – 1972. – 23 апр.; анык ук: Театрга гашыйк булыгыз!: драматургларыбызның соңгы еллардагы иҗаты // Казан утлары. – 2003. – № 2. – Б. 124–129; анык ук: Җиде елдан соң күрешү (Казанда Чаллы Татар дәүләт театры гастрольләре) // Мәдәни җомга. – 2008. – 27 июнь.

Һ. Мәхмүтов[1], М. Арсланов[2], Н.Ханзафаров[3], Р. Игъламов[4], Р. Солтанова[5], А. Салихова[6], М. Хәбетдинова[7], Р. Әхмәтов[8], Ә. Закирҗанов[9] һ.б. язмаларында Т. Миңнуллин пьесаларының театр сәхнәләренә куелу үзенчәлекләре ачыла.

Д. Заһидуллина һәм Н. Йосыпованың югары уку йортлары студентлары өчен чыгарылган «XX гасыр татар әдәбияты

[1] *Мәхмүтов Һ.* «Үзебез сайлаган язмыш» (Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә) // Соц. Татарстан. – 1974. – 23 апр.; аныкы ук: «Канкай углы Бәхтияр» (Г. Камал исем. ТДАТ сәхнәсендә) // Соц. Татарстан. – 1975. – 25 февр.; аныкы ук: Иң актив иҗат чоры // Татарстан яшьләре. – 1978. – 30 март

[2] *Арсланов М.Г.* Драматург белән театр дуслыгы // Татарстан яшьләре. – 1976. – 19 окт.; аныкы ук: Пафос жизнеутверждения («Старик из деревни Альдермеш». К постановке на сцене ТГАТа им. Г. Камала) // Комсомолец Татарии. – 1976. – 5 дек.

[3] *Ханзафаров Н.* Бишек җырын беләсезме? («Әниләр һәм бәбиләр». Г. Камал исем. ТДАТ сәхнәсендә) // Соц. Татарстан. – 1984. – 18 март;

[4] *Игламов Р.* Рассказать о своем народе (гастроли ТГАТа им. Г. Камала в Свердловске) // Уральский рабочий (Свердловск) . – 1982. – 1 авг.; аныкы ук: Не забывайте колыбельную («Колыбельная». К постановке в ТГАТе им. Г. Камала) // Советская Татария. – 1984. – 15 апр.

[5] *Султанова Р.Р.* Исламская эстетика и сценография татарского театра // Театр XXI века и вызовы нового времени: материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 110-летию татарского театра / под ред. Э.М. Галимовой. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – С. 138–150.

[6] *Габаши А.* Сотворение чудо («Искал тебя, любимая», ТГАТ им. Г. Камала) // Время и деньги. – 2001 – 9 нояб.; аныкы ук: Новые открытия Туфана Миннуллина // Казань. – 2008. – № 7. – С. 42–52; аныкы ук: Татар драматургиясенең киләчәге өметле («Мулла», «Дивана» спектакльләре турында) // Сәхнә. – 2008. – № 10. – Б. 6–7.

[7] *Хәбетдинова М.М.* «Төш»тәге серләр (Т. Миңнуллинның «Төш» спектакленнән соң уйланулар) // Казан утлары. – 2015. – № 8. – Б. 169–176; *Хабутдинова М.* Талантом обретенное бессмертие: итоги театральной декады в честь 80-летия Туфана Миннуллина // Татарика. – 2020. – № 2 (12). – С. 91–102.

[8] *Ахметов Р.* Мулла // Звезда Поволжья. – 2012. – 15 ноября.

[9] *Закирҗанов Ә.* Нәрсә ул гөнаһ? (Әлмәт Татар дәүләт драма театрында «Гөнаһсыз гөнаһлылар») // Шәһри Казан. – 1999. – 12 нояб.; *Закирзянов А.М., Хабутдинова М.М.* Новое прочтение женской темы в спектакле «Без луны, звезда нам светит» по одноименной пьесе Т. Миннуллина (2015) (реж. Р.Р. Фазлыев) // Филология и культура. Philology and culture. – 2016. – № 1 (43). – С. 198–204.

тарихы»[1]дәреслегендә XX гасырның икенче яртысында татар драматургиясе үсеше мәсьәләләренә киң урын бирелә. Авторлар бу чорны татар әдәбиятының милли нигезләргә кайту дәвере итеп бәялиләр. Т. Миңнуллин иҗаты исә татар сәхнә әдәбиятының иң уңышлы традицияләрен дәвам итеп, милли яшәеш мәсьәләләрен яңа аспектта сурәтләве белән җитди яңалык алып килү ягыннан ачыла.

Т. Миңнуллинның замандашлары истәлекләре[2] дә олы әдипне төрле яклап ачу мөмкинлеге бирә. Ә инде шәхесе һәм иҗаты турындагы күпсанлы язмалар арасыннан Р. Вәлиев[3], М. Галиев[4], Р. Миңнуллин[5] мәкаләләре аерым игътибарга лаек. Халык язучысы исеменә лаек булган әлеге танылган әдипләр Т. Миңнуллинны каләмдәш, фикердәш, остаз һәм, аеруча мөһиме, «олпат Ил агасы, милләт язмышы өчен кайгырып, ил борчуы белән борчылып яшәүче һәм иҗат итүче олуг зат, фидакяр шәхес»[6] буларак бәялиләр. Шуңа да Р. Вәлиевнең «Туфан Миңнуллин дигән язучының таланты, иҗат үзенчәлеге – кешеләрне, табигатьне, тормышны, гомумән, бар дөньяны ярата белүендә»[7], дигән фикере әдипнең бөтен иҗатына ачкыч ролен үти.

Әлеге хезмәттә Т. Миңнуллин драматургиясе XX гасырның икенче яртысы һәм XXI гасыр башы сәхнә әдәбияты үзенчәлекләренә нисбәтле тикшереп бәяләнә. Билгеле инде, әдипнең гаҗәеп бай иҗатын бер хезмәттә тулысынча иңләп алу мөмкин түгел, без драматург иҗатының төп этапларын аерып чыгару, аларга хас сыйфат үзгәрешләрен билгеләү өчен, сәнгати

---

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

[2] Дуслар җыелган җирдә: Т. Миңнуллин турында замандашлары. – Казан: «Идел» журналы китапханәсе, 1995. – 160 б.

[3] *Вәлиев Р.* Уйлый торган йөрәк // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда: 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 7–12.

[4] *Галиев М.* Туфан булып кара син! // Мәдәни җомга. – 2005. – 19 авг.

[5] *Миңнуллин Р.* Бәләкәй чагын сагынучы олы әдип // *Миңнуллин Р.* Шагыйрь генә булып калалмадым. – Казань: Матбугат йорты, 1998. – Б. 189–190.

[6] *Вәлиев Р.* Уйлый торган йөрәк // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда: 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 8.

[7] Шунда ук. – Б. 12.

үзенчәлекләр аеруча тулы чагылган пьесаларына бәя бирү максатын куйдык. Шуңа нисбәтле әсәрләрендәге тема-проблематика төрлелеген, жанр формалары байлыгын, бу өлкәдәге табышларын, сюжет-конфликт кору остасы булуын, үз йөзләре белән аерылып торган геройлар һәм аларны ачу, укучыга җиткерү юлларын, заман рухын чагылдыруга хезмәт иткән бай алым-чараларны, гомумән сәнгати фикерләү үзенчәлеген ачу кебек бурычлар куелды.

XX гасырның икенче яртысы – XXI гасыр башында сәхнә әдәбияты, берничә этап аша үтеп, җәмгыятьтәге демократик үзгәрешләр тәэсирендә сан һәм сыйфат үзгәреше кичерә. Ул, беренче чиратта, чынбарлык мәсьәләләренә мөрәҗәгать итеп, яшәеш үзәгенә тормышта үз урынын эзләүче кешене куюда, аны бөтен каршылыклары белән бирүдә, конфликтның яшәеш белән бәйле төрләнүендә, яңа дөнья сурәте тудыруда чагылыш таба. Драматурглар татар кешесе образын милли йөзе, үзенә хас сыйфатлары белән ачуга килә. Алгы планга авыл тормышы һәм шунда гомер кичерүче герой чыга. Бу елларда драматургия тема һәм жанр ягыннан бик нык байый, төрләнә. Т. Миңнуллин әлеге үзгәрешләрнең уртасында булып, еш кына аларны әйдәп бара, җитди казанышларга ирешә. Аның пьесалары татар яшәешен бөтен байлыгында һәм каршылыгында традицион һәм яңа сәнгать чаралары ярдәмендә тасвирлавы белән киң яңгыраш ала.

**1 БҮЛЕК**

# 1960–1980 ЕЛЛАР ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ЯҢА ТЕНДЕНЦИЯЛӘР ҺӘМ Т. МИҢНУЛЛИН ИҖАТЫ

## 1.1. 1960–1980 еллар драматургиясендә яңарыш дулкыны

Драма төренең төрле чорлардагы үсеш-үзгәреше җәмгыятьтәге шартлар, традицияләр дәвамчанлыгы һәм әдәби процессның эчке үзенчәлекләре белән билгеләнә. 1950 елларның икенче яртысында, бигрәк тә партиянең X съездыннан соң (1956), тарихка «җепшеклек чоры» исеме белән кереп калган демократик үзгәрешләр сәхнә әдәбияты өлкәсендә иҗат итүчеләргә дә зур йогынты ясый. Сүз һәм матбугат ирекге бирелү, ерактагы һәм якындагы тарихның фаҗигалы һәм гыйбрәтле сәхифәләре билгеле булу, репрессияләнгән әдипләр иҗаты кайту һ.б. иҗтимагый-мәдәни яңалыклар драматургларның дөньяга карашын, әдәби-эстетик күзаллауларын киңәйтә, аларны бермә-бер активлаштыра. Нәтиҗәдә әдәби иҗатта укучы-тамашачының рухи ихтыяҗларына җавап бирердәй пьесалар дөнья күрә. Әнә шундый шартларда татар драматургиясе сыйфат үзгәрешләре юлына чыга.

Шактый вакытны үз эченә алган дәвердә сәхнә әдәбиятының үсеш-үзгәреше бертөрле түгел. Бигрәк тә 1950–1960 еллар чигендә сәнгати эзләнүләр авырлык белән бара. Озак еллар бер төрле генә уйларга күнектерелгән халәттән арыну җиңел булмый. Тормыштагы үзгәрешләрне кабул итү, аңлау һәм бәяләү өчен билгеле бер вакыт кирәк була. «Без барыбыз да

диярлек совет власте тирбәткән татлы йокыда идек әле, – дип яза А. Гыйләҗев, XX гасыр ахырыннан торып, ул чор турында. – (…) Без халкыбызны алдап, аның күзенә төтен җибәреп, колагын балавызлап яшәдек»[1]. Шуңа да яңарыш җитди каршылыклар аша юл яра. «Совет әдәбияты» журналы, «Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә сәхнә әдәбияты һәм театрның торышы, аларны үзгәртү юллары турындагы К. Гыйззәт, Ш. Сарымсаков, И. Нуруллин, М. Әмир һ.б. тәнкыйтьчеләр һәм язучылар мәкаләләрендә, мәсьәләнең мөһимлеген аңлау белән бергә, аны хәл итү, драматургиянең үсеш юлларын билгеләүдә капма-каршы фикерләр булу да шул хакта сөйли[2]. Бу урында шуны да искәртеп китәргә кирәк, «җепшеклек» чорында билгеле бер демократик күренешләр урын алса да, алар җәмгыятьне, бигрәк тә системаны үзгәртеп коруны күздә тотмый. Шуңа да совет дәүләте алып барган төп сәясәт саклана, идеология йогынтысы да көчле була. Т. Миңнуллин «Чирәм җирдә» дигән истәлегендә әлеге чор турында болай дип яза: *«…Хрущев заманын мин инде үз күзләрем белән күреп беләм. Шуңа күрә ул заман турында үз фикерем бар. Ул фикерем бер дә аллы-гөлле түгел. Милләтләрне бер-берсенә каршы куеп, сортларга аерып, кайберләрен илләреннән кууны Сталин башкарса, милли культураларның тамырына балта чабу Хрущев вакытында булды. Милли мәктәпләрне аллы-артлы ябып тордылар. Милли матбугатны бетерделәр диярлек. Безнең "Социалистик Татарстан" газетасын дубляж итеп кенә калдырырга тырышу шул чакта булды. Милләтне яклап сүз әйтүчеләргә ярлыклар ябыштырылып кына торды»*[3].

---

[1] *Гыйләҗев А.* Көндәлекләр (1992–1993) // Сайланма әсәрләр: 6 томда. 6 т.: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, язылып бетмәгән роман, көндәлекләр, хатлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – Б. 89.

[2] *Гыйззәт К.* Бүгенге драматургиябез турында // Совет әдәбияты. – 1961. – № 9. – Б. 138–143; *Сарымсаков Ш.* Уйланмыйча мөмкин түгел // Совет әдәбияты. – 1963. – № 7. – Б. 3–4; *Нуруллин И.* Идея сафлыгы һәм сәнгать камиллеге өчен // Совет әдәбияты. – 1963. – № 10. – Б. 141–146; *Әмир М.* Иҗат дәрте // Казан утлары. – 1968. – № 5. – Б. 107–122.

[3] *Миңнуллин Т.* Чирәм җирдә // *Миңнуллин Т.* Татарның бер баласы. – Казан: Рухият, 2003. – Б. 111.

1950 еллар ахыры – 1960 еллар драматургиясендә Н. Исәнбәт, Г. Насрый, Р. Ишморат, Ю. Әминев, З. Шаһиморатов, С. Шәкүров, шулай ук проза өлкәсендә танылу алып, сәхнә әдәбиятына да билгеле бер өлеш керткән М. Әмир, Ш. Бикчурин, Ә. Баян, Ф. Хөсни кебек әдипләр актив эшли. Алар янәшәсендә киләчәктә сәхнә әдәбиятының йөзен билгеләячәк Х. Вахит, Ш. Хөсәенов, А. Гыйләҗев, Т. Миңнуллин һ.б.лар беренче адымнарын ясый. Драматургиядәге сәнгати эзләнүләр гомуми әдәби процесс белән тыгыз бәйле булып, анда ике юнәлеш ачык сиземләнә. Берсе – партия күрсәтмәләренә, идеологик таләпләргә нигезләнеп иҗат итү, бу төр әсәрләрдә авторлар тормыш күренешләрен шомартып күрсәтү, каршылыкларны беркатлы һәм бертөрле итеп кору, конфликтны җиңел, нигездә, коммунист образына яисә партия күрсәтмәләренә бәйле хәл итү белән мавыга. Шуңа да Г. Насрый, З. Шаһиморатов, С. Шәкүров, Ә. Камал кебек драматургларның гына түгел, бәлки танылу алган Р. Ишморат, Ю. Әминев, Х. Вахит һ.б.ның аерым пьесалары да, вакыт сынавын үтә алмыйча, чор күренеше генә булып кала. Икенчесенең нигезен күпгасырлык татар әдәбиятының иң яхшы традицияләрен дәвам итү, милли һәм гомумкешелек кыйммәтләрен яклау, халыкның яшәү рәвешен, традицияләрен, гореф-гадәтләрен саклау һәм шулар аша чорның актуаль мәсьәләләрен киң җәмәгатьчелек алдына кую һәм аларны сәнгати алымнар ярдәмендә сурәтләү омтылышы билгели. «XX гасырның икенче яртысы татар әдәбиятында көчле әдәби-эстетик үзгәрешләр пәйда була. Алар татар әдәбиятының, советчыл идеология сызган чикләрдән үтеп чыгып, милли традицияләрне яңартуын тәэмин итәләр»[1].

Әлеге күренеш, билгеле, буш урында барлыкка килми. Бердән, нахак гаеп белән репрессияләнгән К. Тинчурин, Ф. Бурнаш, Ш. Усманов, Ф.С.-Казанлы, Г. Ибраһимов кебек драматургларның пьесалары сәхнәләргә менә һәм драматургия офыкларын бермә-бер киңәйтеп җибәрә. Икенчедән, сәхнә

---

[1] *Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр: монография. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – Б. 368.

әдәбиятының башлангычына, аеруча XX йөз башына игътибар арту, «алтын чор»да урын алган эчтәлек-форма табышларыннан, әдәби алым-чаралардан актив файдалана башлауга китерә. Өченчедән, демократик үзгәреш шартларында дөнья әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре һәм әдәбият фәне казанышлары белән танышу мөмкинлеге туу да драматурглар иҗатына уңай йогынты ясый.

Татар драматургиясендә традиция буларак реализм юнәлеше әйдәп бара. Җәмгыятьтә өстенлек иткән коммунистик идеологиягә нисбәтле социалистик реализм әдипләр өчен төп иҗат методы булып кала. Әмма бу мәсьәләдә җитди бәхәсләр урын алып, ул үзгәрешләргә дучар була. Аеруча мөһиме, талантлы драматурглар рәсми идеологик таләпләрдән читләшеп, чынбарлыкны мөмкин кадәр тулы һәм каршылыклары белән сурәтләргә омтыла, ягъни классик реализмга йөз белән борылу күзәтелә. Бу исә сәхнә әдәбиятында чор проблемаларын объектив бәяләүгә, тематик төрлелеккә, кеше шәхесенә игътибар артуга, чор типларын мәйданга чыгаруга, конфликтларның төрләнүенә һәм әдәби алым-чараларның байый баруына юл ача.

1960 елларда татар сәхнә әдәбиятының яңарышы, аның тормышчанлык, заманның җитди мәсьәләләрен сәхнәгә чыгару юнәлешендә үсеп китүенең беренче карлыгачлары булып Х. Вахитның «Беренче мәхәббәт» (1960), «Рәхим итегез!» (1961), А. Гыйләҗевнең «Җиз кыңгырау» (1960), «Киек Каз Юлы» (1960), «Көзге ачы җилләрдә» (1961), Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы» (1961) пьесалары санала. Хәй Вахит пьесалары хис-кичерешләр байлыгы, заманның характерлы билгеләрен үзләрендә чагылдырган геройлары белән үзенчәлекле. А. Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә, бу чор сәхнә сәнгатенә яңа агым өстәп, тамашачыны театрга кайтаруга зур өлеш керткән драматург[1] художестволы форма һәм стиль өлкәсендә җитди эзләнүләр алып бара, мөһим сорауларны кыю рәвештә сәхнәгә чыгара, пьесаларында сюжеттан тыш элементларга, комедиячел ситуацияләргә, лирик чигенешләргә, фәлсәфи уйлануларга, уры-

[1] *Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: история и проблемы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С. 315.

ны белән хикәяләп аңлатуга, мөрәҗәгать итә, пролог һәм эпилог кебек композицион алымнардан уңышлы файдалана. Аның «Беренче мәхәббәт» (1960), «Рәхим итегез» (1961), «Карлыгач канат җәя» (1965), «Соңгы хат» (1966), «Илһамия» (1968), «Туй алдыннан» (1969), «Мәхәббәтең чын булса» (1972), «Онытa алмасаң, нишләрсең» (1977) пьесалары конфликтның тормышчанлыгы, әхлакый һәм фәлсәфи мәсьәләләрнең әдәби-эстетик яңгырашы белән аерылып тора. Җыр-музыка еш кына пьесаларының лейтмотивы булып килә һәм геройларның эш-хәрәкәтен, рухи халәтләрен, күңел дөньяларын ачарга, аңларга ярдәм итә. Шуңа да Х. Вахит әлеге мелодрама жанрын яңадан сәхнәгә кайтаручы буларак бәяләнә[1]. Драматургны, нигездә, тәрбия, әхлак мәсьәләләре кызыксындыра, әсәрләрендә ул кешелек кыйммәтләрен, матур рухи башлангычларны яклый, тормыштагы ямьсез күренешләрне, кешеләрдәге һәртөр кимчелекләрне тәнкыйтьли.

1960 еллар драматургиясендә яңарыш билгеләре яшәеш кыйммәтләрен, кешедәге рухи башлангычларны яклау һәм саклау омтылышын алга чыгара. Н. Ханзафаров фикеренчә, «алтмышынчы еллар драматургиясе һәм төп проблемасы, һәм стиль үзенчәлеге буенча (аеруча 60 нчы елларның икенче яртысы) җитмешенче елларның аналитик фикерләү һәм тирән фәлсәфи, сәнгати гомумиләштерүләргә омтылыш белән характерлана торган *интеллектуаль драматургиясен* үстерү өчен нигез булды. Алга таба татар драматургиясе катлаулы әхлакый-этик проблемаларга, замандашның аз өйрәнелгән психологик дөньясына кыюрак мөрәҗәгать итәчәк»[2]. Әлеге мәсьәләләр теге яисә бу дәрәҗәдә барлык әсәрләрдә дип әйтерлек урын алса да, аеруча тулы һәм гыйбрәтле булып, олы тормышка беренче адымнарын атлаучы яшьләрнең эш-гамәлләре чагылыш тапкан әсәрләрдә күзәтелә. Яшь геройның характер сыйфатлары формалашу, аның үз-үзен табудагы каршылыклары, гаиләдәге якыннары һәм чит кешеләр белән мөнәсәбәтләр урнаштыру кыенлыклары

---

[1] *Ибрагимов М.И.* Предисловие // Вахит Х. Первая любовь: пьесы / Хай Вахит; [сост., авт. аналит. ст. М.И. Ибрагимов]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С. 6.

[2] Ханзафаров Н.Г. Татарская комедия. – Казань: Фэн, 1996. – С. 161.

кебек мәсьәләләр А. Гыйләҗевнең «Җиз кыңгырау» (1960), «Яланаяклы кыз» (1964), Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы» (1961), Х. Вахитның «Кайда соң син?» (1963), «Карлыгач канат кага» (1965) пьесаларында үзәккә куела.

Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы» трагикомедиясе замандаш яшь геройның эчке дөньясын, рухи кичерешләрен әдәп-әхлак мәсьәләләре белән бәйләнештә тасвирлый. Зөбәйдәнең үз-үзен эзләве әтисе һәм абыйсының әхлаксызлыгы, башкаларга карата битарафлыгы белән каршылыкка керә. Әлеге конфликт буыннар арасындагы каршылык, хезмәткә төрлечә караш, мәхәббәт-дуслык, бәхетле булу, яшәеш мәгънәсе кебек җитди мәсьәләләр белән үрелеп китә. Пьесага бәя биреп, А. Гыйләҗев болай дип яза: «Яп-яшь Зөбәйдәнең җаны талпынуларына игътибар итик. (...) Зөбәйдә кеше булырга тели, чын кешеләрчә яшәргә омтыла. Аның гадел, хак буласы килә. Ләкин теләк – бер нәрсә, ә үзең яшәгән мохит, аның туктаусыз аяусызлыгы, хаксызлыгы синең аягыңа богау булып урала, таш булып иярә. Зөбәйдәгә яшәү җиңел түгел, алда да җиңел булырга охшамаган»[1].

Татар драматургиясе 1960 еллар дәвамында тәҗрибә туплап, сәнгать чаралары ярдәмендә яшәешнең яңадан-яңа якларын чагылдыруга килә. Нәтиҗәдә драматургия тарихында урын алачак бер төркем пьесалар язылa: Х. Вахитның «Соңгы хат» (1965), «Туй алдыннан» (1969), Ш. Хөсәеновның «Әни килде» («Әниемнең ак күлмәге», 1968), Т. Миңнуллинның «Нигез ташлары» (1968), «Миләүшәнең туган көне» (1968), «Диләфрүзгә дүрт кияү» (1968). Шулар арасында дуслык, мәхәббәт, үз-үзең һәм бер-берең алдындагы җаваплылык кебек мәңгелек сорауларга мөрәҗәгать итеп, аларны уңышлы сәнгать чаралары аша чагылдырган «Туй алдыннан» драмасы аеруча киң яңгыраш ала.

Татар әдәбиятында ата-ананы, бигрәк тә Ананы изгеләштергән дистәләгән әсәрләр арасында Ш. Хөсәеновның «Әниемнең ак күлмәге» драмасы үзгә урын ала. Шикләнмичә әйтер-

---

[1] *Гыйләҗев А.М.* Көндәлекләр (1992–1993) // Сайланма әсәрләр: 6 томда. Т. 6. : Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, язылып бетмәгән роман, көндәлекләр, хатлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – Б. 90.

гә мөмкин: әлеге пьеса – татар сәхнә әдәбиятының зурлыгын билгеләүче әсәрләрдән. Гаять мөһим идея эчтәлегенә ия пьеса үзенең сәнгатьчә эшләнеше белән дә игътибарга лаек. Уңышлы композициясе, образларның эш-гамәле аша тудырылган кискен фикер каршылыклары, конфликның максатчан үстерелүе, проблемаларның һәр чор өчен актуаль булуы һәм аларның сәнгатьчә хәл ителүе кебек сыйфатлар әсәрнең заманчалыгын, төрле буыннар өчен кызыклы һәм әһәмиятле булуын тәэмин итә.

Ана һәм бала мөнәсәбәтенә драматурглар соңрак та мөрәҗәгать итә. Ялгыз ана, ятим бала тормышы Р. Батулланың «Кичер мине, әнкәй» (1984) пьесасында үзенчәлекле чагылыш таба. Алгы планга әнисе белән генә яшәүче 16 яшьлек Миргаянның характеры, психологик үзенчәлекләре формалашу куелып, егетнең хыял-максатларын, дөньяга карашын тулырак ачу өчен, автор кычыткан арасыннан табылган көндәлекне файдалана. Драматург яшәешебездәге күңел катылыгы, миһербансызлык күренешләренең тирәнәя баруы өчен борчыла, үзенең әдәбиэстетик карашларын ана белән улны яклап раслый.

1970–1980 еллар татар драматургиясе милли яшәешнең яңа хасиятләрен ачуда җитди уңышларга ирешә. Аның танып белү диапазоны киңәя, шәхес һәм җәмгыять бәйләнешенең иҗтимагый, әхлакый, фәлсәфи аспектлары әдипләр тарафыннан игътибарга алына. Әлеге чор сәхнә әдәбиятының үсеш-үзгәрешенә китергән сәбәпләр турында уйланып, үзе дә танылган драматург Р. Хәмид күренекле сәнгать белгече И.Л. Вишневскаяга сөйләгәннәрен хәтерендә яңарта: «хәзер без үз тамырларыбызны эзли башладык, татар менталитетын, татарның милли хисләрен кыюрак файдалануга күчтек, әсәрләребезне «мәңгелек» сюжетларга корганда да милли үзенчәлекләребезгә өстенлек бирергә омтылабыз, әмма шул ук вакытта бар халыкларны да тирән борчыган уртак зур проблемаларны да онытмыйбыз»[1]. Тематика киңәю белән бергә, яңа жанр формалары пәйда була. Яңалыкның аеруча зурысы заман геройларын чагылдыру һәм сәхнә закончалыкларына тәңгәл рәвештә яңа сәнгати сурәтләү алымнарын эзләү

[1] *Хәмид Р.* Татар драматургиясе миллиме? // Казан утлары. – 2002. – № 4. – Б. 155.

белән бәйле. А. Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә, «үсеш характерларны декларатив сурәтләүдән кеше күңеленең бай һәм катлаулы булуын күрсәтүгә күчү юнәлешендә бара»[1].

Әдәби-эстетик эзләнүләрнең җитди нәтиҗәсе буларак халыкчан образ-характерлар, замандаш сыйфатларын йөрткән типлар мәйданга чыга. Ш. Хөсәеновның «Әни килде»сендә Ана, Т. Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар»ында Мәдинә, «Әлдермештән Әлмәндәр»ендә Әлмәндәр, И. Юзеевнең «Сандугачлар килгән безгә»сендә Хәмзин кебекләр халыкның күпгасырлык тәҗрибәсен, иманын үзенә туплаган, ил кайгысын үз кайгысы иткән, башкаларның шатлык-сөенечләрен дә бүлешергә әзер геройлар буларак сурәтләнә.

Әлеге чор сәхнә әдәбияты татар драматургиясенең моңа кадәр тупланган традицияләрен үстерү юлына чыга. Классик драматурглар иҗатында урын алган, вакыйгаларны композицион яктан «оялап» урнаштыру (Г. Камал. «Безнең шәһәрнең серләре»); үзе күренгәнче үк герой белән таныштыру (Г. Камал. «Беренче театр»); символ дәрәҗәсенә күтәрелгән әдәби детальләр аша герой характерын ачу (Г. Исхакый. «Кыямәт»; И. Богданов. «Помада мәсьәләсе»); метафора булып килгән күренешләрдән файдалану (К. Тинчурин. «Беренче чәчәкләр»); шартлы алымнарга мөрәҗәгать итү (Г. Коләхмәтов. «Ике фикер») һ.б. үзенчәлекләр тагы да калкулана, яңа сыйфатлар алып, образларны ачуга, төп идеяне аерып куюга хезмәт итә. Т. Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар», А. Гыйләҗевнең «Сары чәчәк ата көнбагыш», И. Юзеевнең «Мәңгелек белән очрашу», Р. Мингалимнең «Тау астында илле бүре», Р. Хәмиднең «Иске йорт кешеләре» кебек әсәрләрендә символик образлар, шартлылык алымнары әхлакый һәм фәлсәфи фикерләрне тулырак ачарга, укучы-тамашачы игътибарын җәлеп итәргә мөмкинлек бирә.

Җәмгыятьтә билгеле бер дәрәҗәдә урын алган демократик үзгәрешләр, әдәбиятта чынбарлык күренешләренә игътибар арту һәм милли яшәешнең үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйлану драматургиядә тәнкыйди башлангычны көчәйтә. Аерым

[1] *Әхмәдуллин А.* Хәзерге татар драматургиясенең жанр һәм стиль үзенчәлекләре // Метод, стиль, жанр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – Б. 105.

әдипләр үз чоры җәмгыятенә тирәнтен бәя биреп, аның гаделсез якларын тәнкыйтьләүгә киләләр. Халык тормышы белән бәйле булып, җәмәгатьчелектә кызыксыну уяткан хәл-вакыйгаларны гыйбрәтле геройлар язмышы аша сурәтләгән авторларның берсе – Аяз Гыйләҗев. Әсәрләре арасында XIX йөздәге крестьян чуалышларын («Син – минеке, мин – синеке»), гражданнар сугышы күренешләрен («Сары чәчәк ата көнбагыш»), күмәк хуҗалыклар төзү вакыйгалары тудырган фаҗигалы язмышларны («Өч аршын җир»), Бөек Ватан сугышы чорын («Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз»), нефть чыгаруны («Җан җылысы»), «торгынлык еллары» каршылыкларын («Югалган көн»), кешенең үз-үзен эзләвен («Киек Каз Юлы», «Әгәр бик сагынсаң...») сурәтләгән пьесалар бар. Тематик төрлелек үзе үк әһәмиятле булса да, әдип өчен үзмаксат түгел. Аның өчен иң мөһиме – тарихи вакыйгалар фонында кеше язмышларын, аларның уй-борчуларын, хыял-омтылышларын ачу. Бер-бер артлы дөнья күргән пьесаларында иҗат юнәлеше, стиль үзенчәлекләре, сәнгати сурәтләр байлыгы ачык сиземләнә: тормыш дөреслегенә тугры калып, яшәештәге гаделсезлекләргә каршы чыгу, ә ул исә яшәү мәгънәсе, чын һәм ялган кыйммәтләр, рухи һәм матди байлык турында уйлану булып үсә.

А. Гыйләҗев 1960–1970 елларда сүз сәнгатендә герой турында барган бәхәскә кушылып китә һәм пьесаларының үзәгенә язмыш тарафыннан бәрелгән-сугылган, тормышта үз урынын таба алмый аптыраган, бертөрле генә аңлап та, бәяләп тә булмый торган геройларны куя. Әйтергә кирәк, үз вакытында драматург әсәрләренең тиешенчә кабул ителмәве, тәнкыйтькә дучар булуы да шуның белән аңлатыла. Әмма драматург актив герой яклы, үз язмышын ил, халык язмышы белән бәйләгән кешеләр генә җәмгыятьне үзгәртергә әзер дип саный. «Җиргә тапшырылган серләр»дәге (1967) Кәрим Хәернасов, «Җан җылысы»ндагы (1969) Таймас Шабанов, «Югалган көн»дәге (1976) Йосыф, Карт, «Әгәр бик сагынсаң...»дагы (1980) Фәүзия, Әсфан, «Китмәгез, тургайлар»дагы (1982) Наза, «Ефәк баулы былбыл кош»тагы (1984) Мияссәр карт кебекләр – безнең әйләнә-тирәбездә яши торган гади-гадәти кешеләр. Әмма алар

тормышның асылын аңлап, мәгънәле яшәргә омтыла. Үзләренең эш-гамәлләре белән җәмгыятьнең әхлакый нигезе какшавын, рухи кыйммәтләрнең кимүен искәртә. Туган туфракка һәм мәхәббәткә үзенчәлекле мөнәсәбәт А. Гыйләҗевнең иң яхшы пьесаларыннан берсе булган «Өч аршын җир» трагедиясендә аеруча тулы чыгылыш таба.

Әдип әсәрләрен берләштерүче, үзара бәйләп торучы төп мәсьәлә – милләт язмышы. Әлеге киң, катлаулы төшенчә төрле яклап ачыла: туган тел сакланышы, гореф-гадәтләргә тугрылык, туган як табигатен саклау, халкыбызга хас иң матур әхлакый сыйфатларны алдагы буыннарга җиткерү һ.б. Ә бит әлеге пьесалар «торгынлык чоры»нда, ягъни интернационализм маскасы артында милләтләрнең ассимиляцияләшүе яклanган, шәһәрләрдә татар мәктәпләре бетүгә барган, Татарстан табигатенә әйтеп бетергесез зыян-афәт салынган, катнаш никахлар төрлечә хупланган елларда язылган. 1980 еллар уртасындагы үзгәртеп коруларга халыкны нәкъ менә шундый әсәрләр әзерли. А. Гыйләҗевнең күпсанлы әсәрләрендә социалистик системаның гаделсез яклары фаш ителә, рухи-әхлакый кыйммәтләре яклана, укучыларда милли үзаң, милли горурлык тәрбияләп, укучы-тамашачыларны киләчәк үзгәрешләргә әзерләү күзәтелә. Милләт турында борчылу, аның иң матур сыйфатларын яклау һәм саклау һич тә текстлардагы аерым фикерләргә кайтып калмый. Аның эчтәлеген милли характерлар билгели, ә эш-гамәлләре исә автор позициясе, карашлары белән тыгыз бәйләнештә булып, әсәрнең төп идеясендә чагылыш таба. А. Гыйләҗев фикеренчә, кеше яшәешендә, аның характеры формалашуда, киләчәк язмышында аеруча җитди урынны гаилә алып тора. Шуңа да драматургның барлык пьесаларында диярлек ата-ана һәм бала, туганлык, нәсел җебе, аны дәвам итү, буыннар арасында рухи бәйләнешне саклау кебек мәсьәләләр төрле яссылыкта сурәтләнә. Ата-ана һәм бала каршылыгы да А. Гыйләҗев әсәрләрендә яңа фәлсәфи югарылыкка күтәрелә, гаилә, нәсел традицияләре, әхлакый кыйммәтләр сакланышы, милли яшәеш рәвеше белән үрелеп китә.

Бу чорда драматургларның яшәештәге күп кенә мәсьәләләргә мөрәҗәгать итүе тематик төрлелеккә, еш кына моңа кадәр

читтә калып килгән тема-проблемаларны калкытып куюга китерә. Аларның күбесе әхлакый кыйммәтләрне саклау һәм хезмәткә җылы мөнәсәбәт формалаштырудан гыйбарәт булган ике мөһим тенденция тирәсенә туплана. Совет җәмгыяте кеше бәхетен, тормышны яхшырту юлларын беренче чиратта хезмәт белән бәйләп карый. Шуңа әдәбиятта, шул исәптән драматургиядә хезмәт темасы киң чагылыш таба. С. Шәкүровның «Туган туфрак» (1968), Т. Миңнуллинның «Кырларым-тугайларым» (1978), «Адәм баласына ял кирәк» (1979), А. Гыйләҗевнең «Хушыгыз, тургайлар» (1978), Г. Ахуновның «Чикләвек төше» (1978), Р. Хәмиднең «Синең урыныңа кайттым» (1978), «Китәм инде» (1982) кебек әсәрләрендә Туган җиргә мөнәсәбәт кешеләр арасындагы җылы хисләр, дуслык-туганлык билгеләре чагылышын билгели.

Драматургиядә производство темасын, хезмәт процессын сәхнәдә чагылдыруның билгеле бер кыенлыгы бар. Авылда туып үскән язучыдан завод-фабрикаларга, төзелешләргә бәйле яңа мәгълүматларны үзләштерү һәм аны әдәби формаларда укучы-тамашачыга җиткерү җитди әзерлек сорый. Әлеге кыен мәсьәләгә бу чорда беренчеләрдән булып А. Гыйләҗев «Киек Каз Юлы»нда мөрәҗәгать итә. Бераздан Ә. Баянның производство темасына язылган «Күзләре нинди иде...» (1966) драмасы дөнья күрә. Әсәрләрдә яшәешнең әхлакый, фәлсәфи сораулары, аерым алганда, яшәү мәгънәсе, бәхет төшенчәсе, мәхәббәт, кешенең рухи дөньясы һ.б. мәсьәләләр гомумкешелек кыйммәтләре дәрәҗәсендә яңгыраш ала. Боларны бер үзәккә яшәеш хакыйкатен эзләү проблемасы туплый. Ә. Баянның сәхнә әсәрләрен, нигездә, ике тема берләштерә, берсе – үз чоры вакыйгалары аша кешенең рухи-әхлакый асылын аңларга омтылу, икенчесе – ерак тарих белән бүгенгенең рухи бәйләнешен тасвирлап, үткәннәр аша заманга бәя бирү. Аның бу өлкәдәге эзләнүләре «Зәңгәр кыңгыраулар» (1972–1983) драмасында дәвам итә. Романтик рухта, әмма иҗтимагый күренешләрне дә төрле яклап күрсәтеп-бәяләп язылган пьесада торгынлык елларына хас катлаулы тормыш материалы – әхлак проблемасы үзәккә куела.

Торгынлык елларының тынчу атмосферасына сыеша алмыйча, шәхес иregeнә омтылу, төрле буыннар арасындагы рухи бәйләнешне саклау, халыкның бүгенгесен һәм киләчәген татар авылы, аның үзенә хас яшәү рәвеше белән бәйләп карау Ризван Хәмид драмаларында күзәтелә. Ул сайлап алган тормыш вакыйгалары, конфликт характеры сискәндереп җибәрә, үзенә җәлеп итә, геройлары язмышы белән яшәтә. Драматург иҗатында туган ягының, якыннарының, якташларының бөтенлекле образы тудырыла, чор-заман кырыслыгы, үзгә холыклы характерлар, гомумән, үзенә хас алым-чаралар, сурәтләр ачык тоемлана. Г. Камал исемендәге ТДАТда 1978 елны Марсель Сәлимҗанов сәхнәләштергән «Синең урыныңа кайттым...» пьесасы татар сәхнә әдәбиятына үз стиле күренеп торган драматург килүен хәбәр итә. Әлеге уңышы артыннан яңа әсәрләре бер-бер артлы дөнья күрә: «Иске йорт кешеләре» (1979), «Кайтыр идем» (1980), «Каен җиле» (1982), «Китәм инде» (1983), «Майның унбишләрендә» (1984), «Диде кардәш...» (1985) һ.б.

Беренче әсәрендә үк Р. Хәмид тормышның гаять четерекле якларын кыю рәвештә сәхнәгә чыгара. Әсәрдә катнашучыларның барысы да диярлек үзара туганлык мөнәсәбәтендәге кешеләр булу каршылыкка керүче якларның эш-гамәлен кискенләштерә, рухи дөньясын тулырак ача. Р. Хәмид геройлары моңа кадәр авыл-колхоз темасына язылган әсәрләрдә катнашучылардан аерылып тора. Алар берсе дә без күнеккән уңай герой идеалы түгел, әмма һәрберсенең үз яшәү фәлсәфәсе бар.

Р. Хәмид тематик киңлеккә, проблемалар төрлелегенә, жанрлар байлыгына омтылмый. Әмма гаилә-көнкүреш вакыйгалары, шуларда хәрәкәт итүче геройлар артында укучы-тамашачы үзен һәм чолгап алган әйләнә-тирәсен күрә. «Кайтыр идем» (1980) лирик драмасында ярату һәм дуслык, ир һәм хатын, ана һәм бала мөнәсәбәтләре гадәти булмаган шартларда сынала. Гади көнкүреш вакыйгасы яшәеш фәлсәфәсенә үстерелә. Драматург үзенчәлекле, бераз сәер, дуамал геройларны алга чыгара. Алар кылган эш-гамәлләр дә шундый ук. Бер үк вакытта вакыйга-күренешләр тормышчанлыгы, кырыс дөреслеге белән сискәндерә. Алар тукталып уйланырга, үзеңә һәм башкалар

тормышына игътибар белән карарга мәҗбүр итә. «Китәм инде» (1980) драмасында да бер бәхетле кеше дә юк, аны сызлану фәлсәфәсе иңләп үтә. Геройлар җан тынычлыгы, үзара аңлашу таба алмый, сәбәпләре исә ата-ана, әби-бабай язмышы аша 1930 елларның кырыс вакыйгаларына барып тоташа. Р. Хәмид тарихка «шәхес культы» исеме белән кереп калган әлеге дәверне сурәтләргә, мөнәсәбәт белдерергә алына. Автор җиңел генә берәүне аклау, икенчене каралту юлыннан китми: аның өчен хакыйкатьнең асылына төшенү мөһим. Ул исә һәркем күңелендә үткән, бүгенге, киләчәк турында уйлану булып калка. Бер әсәреннән икенче әсәренә күчеп, драматург шәхес һәм халык мөнәсәбәте турында да уйлана. Торгынлык елларында аеруча көчәеп киткән битарафлык, кешенең, Инсафетдин әйткәнчә, «телсез мәхлук»ка әйләнүенең башлангычы да тоталитар системаның кешене бер винтикка әверелдерүе, куркыту хисен мәҗбүриләп тагуы, ихтыярын юкка чыгаруы белән аңлатыла. Шул рәвешле, драматург эзоп теле белән җәмгыятьнең гаделсез якларына каршы чыга, укучы-тамашачы күңелендә хөр рух, шәхес бөтенлеге тәрбияли.

Татар сәхнә әдәбияты даими мөрәҗәгать итеп килгән темалар арасында Бөек Ватан сугышы кырларында, тылда сыналу үткән кешеләр тормышы аерым урын тота. Сугыш алып килгән яралар тирән булып, алар озак еллар дәвамында үзләрен сиздереп тора. Бик күпләрне тән ярасы гына түгел, бәлки якын кешесен югалтудан туган җан яралары гомере буе озата бара. Тыл күренешләрен һәм сугыштан кайткан кичәге солдат тормышының төрле якларын сурәтләүгә Х. Вахит, С. Шәкүров. Ә. Гаффар, Р. Ишморат һ.б. алына. А. Гыйләҗевнең «Шикәрем син, балым син» (1981) драмасы ирләрен сугышка озатып, гомере буе шуларны көтеп, аларга тугры калган, тол булып гомер кичергән хатын-кызларга багышлана. А. Гыйләҗев үзенең геройларын сокланып сурәтли. С. Шәкүровның сугыштан соңгы татар авылын сурәтләгән «Туган туфрак» әсәрендә Арслан, Гариф кебек кичәге солдатлар көтелмәгән каршылык белән очраша. Авыл бик авыр хәлдә калган, колхоз председателе Күркә Сөләйман күбрәк үз мәнфәгатен кайгырта. Тол калган балалы

хатыннар, ялгыз карт-карчыкларның хәле бигрәк тә авыр. Шундый хәлдә Арслан читкә китү нияте белән йөри. Әмма аңа Украинадан алып кайткан хатыны Галина (Галия) таяныч булып тора. Сугыш елларында яраланган хәлдә «туган авыл» дип саташып яткан Арслан, ниһаять, үз бәхетенең туган туфракта булуын аңлауга килә. Автор карашларын ачуда Галина образы әһәмиятле. Гомере буе Днепр буйларын сагынып яшәвенә карамастан, ул ире Арслан туып-үскән җирне үзенеке кебек кабул итә. Һәртөр авырлыкны җиңеп, укытучы, мәктәп директоры булган хатын, гомере ахырында күңелен ачып сала: *«Бу туфракта минем тирем, кайнар яшьләрем тамды. Бу туфракта минем татлы хыялларым тормышка ашты. Шулай булгач, бу – минем туган туфрагым! Мин моннан беркая да китмим инде»*[1]. Драма, вакыйгалардан бигрәк, сугыш һәм сугыштан соңгы еллардагы авырлыкларны үз җилкәләренә салган авыл кешеләренең җанлы образлары белән таныла.

1970–1980 елларда драматургларның төрле пландагы эзләнүләре тарихи тематиканың үсеп, яңа төсмерләр алуына китерә. Тарихи теманы яктыртуда проза төрендә уңышка ирешкән Н. Фәттах «Кол Гали» (1972) трагедиясендә Болгар дәүләтенең фаҗигалы чорларын тасвирлый. Үзенең эчтәлеге белән аңа якын «Алтын кашбау» шигъри трагедиясендә Ә. Баянов үткәннәрне бүгенге көн югарылыгыннан бәяләү омтылышы ясый. Бөек Тукайның әдәби образы Н. Исәнбәтнең «Кырлай егете» (1967), Р. Ишморатның «И мөкатдәс моңлы сазым», И. Юзеевнең «Очты дөнья читлегеннән», Т. Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» пьесаларында чагылыш таба.

Ә. Баянның үткән тарих сәхифәләрен җанлы картиналарда, образларда чагылдырган пьесалары шигъри формада язылган. Бу, бердән, аның шагыйрьлек рухы чагылышы булса, икенчедән, сурәтләнгән вакыйгаларның романтик пафосын, халык Хәтере мотивын тирән хис-кичерешләр, көчле драматизм, фаҗигалы каршылыклар аша бирүгә хезмәт итә. Әдипнең «Һәйкәл» (1970) драмасы гражданнар сугышы вакыйгаларын күз алдында тор-

---

[1] *Шәкүров С.* Туган туфрак // С. Шәкүров. Пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – Б. 120.

гызып, ил-Ватан, Туган җир, тарихи Хәтер, кешенең рухи көче кебек төшенчәләрне калкуландыра. Бүген, Гражданнар сугышы вакыйгаларын берьяклы гына бәяләүдән китеп, бөтен тулылыгында, ил-халык фаҗигасы буларак аңларга омтылганда да әдипнең явызлык-мәкергә нәфрәте, ирек-азатлык омтылышын югары күтәрүе – заманча яңгырый. Ә. Баян кулланган символлар, аллегорик, шартлы образлар, күренешләр моны тагы да үткенәйтә. «Алтын кашбау» (1986) шигъри трагедиясе – әдип иҗатындагы заман сынауларын уңышлы узган, бүгенге һәм киләчәк буын һәрдаим мөрәҗәгать итәчәк әсәрләрдән. XIII гасыр урталарында Батый ханның Болгар илен басып алуына бәйле вакыйгалар үзәгендә яшәү – үлем – үлемсезлек турында фәлсәфи уйлану ята. Фаҗигалы пафос өстенлек иткән пьесада кеше рухы сынала. Туган ил язмышын үз язмышы иткән Баян, Җикү кебек геройларның эш-гамәле Бөеклек символына әверелсә, үзләренең куркак җаннарын саклап калу өчен һәртөр әшәкелеккә, хыянәткә баручы Балтамар һәм Изух Түбәнлек билгесе итеп сурәтләнә. Әдип яшәү мәгънәсен Ватан азатлыгы өчен көрәш белән бәйли һәм шул юлда һәлак булу үлемсезлек китерә дигән фикерне яклый. Алтын кашбау – ярәшелгән кызның баш киеме – символ буларак, моны тагы да үстерә.

Татар драматургиясендә эзләнүләрнең, үзгәрешләрнең бер чагылышы булып романтик юнәлешнең яңаруы тора. 1960 еллардан башлап сәхнә әдәбиятында гади кеше тормышына, аның рухи дөньясына, шәхси теләк-омтылышларына игътибар арту, романтик хыял дөньясы, мәхәббәт хисе белән бәйле купшы башлангычларның торган саен киңрәк урын алуына юл ача. Бу исә әсәрләрдә романтизмның рухи камиллеккә омтылыш, идеалга мөрәҗәгать итү, шартлылыкка, символларга урын бирү, җыр-музыка белән үрелеп бару һ.б. алым-чаралары активлашуга китерә. Бу юнәлештә И. Юзеев аеруча уңышлы эшли, аның янәшәсендә Ә. Баян, Т. Миңнуллин, С. Шәкүров, Р. Ишморатова, Ә. Гаффар кебек драматургларның пьесаларында чынбарлык сурәте еш кына романтик пафос белән үрелеп, геройларның хыялый омтылышларына, идеаллаштырылган сурәткә урын бирелә.

И. Юзеев – «драматургиядә дә шагыйрь булып калган, ягъни шагыйрьлеген саклаган, бу ике төрне һич тә аерып карамый торган, сәхнәне шигърият белән баеткан иҗатчыларның берсе»[1]. Аның күпчелек пьесаларында («Соңгы сынау» («Соңгы төн», 1972), «Янар чәчәк» («Сандугачлар килгән безгә», 1974), «Кыр казлары артыннан» (1976), «Бәхетемнән узып барышлый» (1979), «Онытылмас бәет» (1980), «Очты дөнья читлегеннән» (1981)) романтик пафос өстенлек итә. Геройлары – еш кына көнкүреш ыгы-зыгысы белән каршылыкка кергән, хыялында туган идеалга омтылып яшәүче шәхесләр. Әдип шигырь-поэмаларындагы яшьлек дәртен, мәхәббәт идеалын, саф хисләр дулкынын пьесаларына да алып килә. Ул заман һәм кеше арасындагы каршылыкларны үзгә бер моң, җан хәрәкәте, хисләр муллыгы аша тасвирлап, идеалларына тугры калган геройларны сәхнәгә менгерә. Аның вакыт сынавын уңышлы үткән әсәрләре арасында «Кыр казлары артыннан» драмасы да бар. Драматург тормыштагы әхлакый кыйммәтләр турында уйланып, Яхшылык һәм Матурлыкның мәңгелек булуын раслауга килә. Вакыйгалар бертуган Малик һәм Халик Бикташевлар каршылыгына нигезләнеп, туган җир кадере, кешегә кешелекле мөнәсәбәт, олы мәхәббәт кебек төшенчәләргә кагыла. Бәхәс предметы булган көмеш битлек – символ, үткән белән бүгенгене тоташтыручы изге ядкяр. Тексттагы шартлы борынгы кеше образы әнә шуны җиткерә: *«Ерак бабаларыбызның рухын саклаган көмеш битлек. Аны кигән кешене бер дошман да җиңә алмаган, чөнки халык аңа әллә ничә гасырлар җыелган байлыгын, җан матурлыгын салган»*[2]. Вакыйгалар барышында «*мал артыннан куып, җан матурлыгын югалткан*» Маликның шактый тар, үзен генә кайгырткан яшәеш фәлсәфәсе кире кагылып, Халикның: *«Бабаларыбыз, аталарыбыз безгә җир-туфрак кына калдырмый, шуның өстенә алар безгә кул белән тотып булмый торган иң*

[1] *Әхмәдуллин А.Г.* Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе: монография. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 114.

[2] *Юзеев И.* Кыр казлары артыннан // Сайланма әсәрләр. 5 томда. 3 т.: поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр. 2002. – Б. 215.

*изге орлык – мәхәббәт, матурлык рухы калдырганнар»[1],* дигән сүзләре төп фикер-идея ролен уйный. Ясминә образына бәйле, кеше күңелендәге хыял, омтылыш, мәхәббәт хисе, «Кыр казлары артыннан» җыры белән кушылып, рухи матурлыкка мәдхия булып яңгырый.

Чынбарлык күренешләренең романтик сурәтлелек аша бирелешенең үзенчәлекле үрнәге дип Ә. Гаффарның «Язлар моңы» драмасы күрсәтелә ала. Сугыш темасын яңача яңгыраткан әсәрдә саф мәхәббәткә соклану, буыннан-буынга күчеп барган Хәтер аша киләчәккә ирешү мөмкинлеге ассызыклана. Сәгыйдулла образы бу чор әдәбиятында яңалык буларак кабул ителә. Яраткан хатынының башка кеше белән яшәвен аның акылы аңласа да, йөрәге кабул итә алмый. Һәр яз саен күңелендә ярату бөреләре яшәрә, ир кулына гармун алып, язгы пычракны ера-ера, урам әйләнә. Аның уйнавында сөйгәненнән аерган өчен сугышка нәфрәт тә, дөньяны яшәртүче, нурлаучы мәхәббәтнең ялкынланып януы да чагыла. Үзенең яратуын җыр итеп тараткан Сәгыйдулла, ниһаять, хисләрен акылына буйсындырырга тиешлеген аңлауга килә. Фәрдәнәгә булган сөюен йөрәгенең ерак почмагына яшереп, гармунын сандыкка сала, калган күңел җылысын Сарага биреп, матур гомер итә. Әлеге ике гаилә, бигрәк тә Сәгыйдулла белән Ярми арасында каршылык тирән булса да, алар үзара аңлашып, килешеп яшәргә көч таба. Шуңа автор геройларының күңел матурлыгына, рухи көчләренә, кирәк вакытта бер-берсенә юл куя белүләренә соклануын яшерми.

Драматургиядә сурәтләү объектының киңәюе, тематик төрлелек, конфликт характеры драма жанрларының эчтәлеге баюга, яңа жанр формалары мәйданга килүгә юл ача. Чынбарлыкның җитди мәсьәләләрен сәхнәгә чыгаруга нисбәтле бу чор сәхнә әдәбиятында тарихи-биографик драма (Р. Ишморат. «И мөкатдәс моңлы сазым»; Ә. Гаффар. «Соңгы сәгать»), социаль-психологик драма (Ш. Хөсәнов. «Әни килде»; Х. Вахит. «Туй алдыннан»), социаль драма (Х. Вахит. «Оныта алмасаң, нишләрсең»;

---

[1] *Юзеев И.* Кыр казлары артыннан // Сайланма әсәрләр. 5 томда. 3 т.: поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр. 2002. – Б. 218.

Т. Миңнуллин. «Әниләр һәм бәбиләр»), фәлсәфи-публицистик драма (Т. Миңнуллин. «Моңлы бер җыр»), публицистик драма (Ә. Гаффар. «Килер бер көн»), интеллектуаль драма (Т. Миңнуллин. «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә»), мелодрама (Р. Батулла. «Кичер мине, әнкәй»), лирик драма (Т. Миңнуллин. «Кырларым-тугайларым»; Р. Хәмид. «Кайтыр идем») һ.б. жанр формалары урын ала.

Иҗтимагый тормыштагы шартлар комедиографиянең халыкчанлык традицияләренә кайтуына этәргеч бирә. Заман героена игътибар арту тормышчан конфликтларга йөз тотуга китерә. Идея-эстетик эзләнүләр жанрлар синтезында, психологик аспектның тирәнәюендә күренә. Көнкүрештәге кимчелекләр, әхлакый түбәнлек, гаделсезлеккә түзеп тормау, иҗтимагый тормышта яңалыкның акрын юл яруы кебек мәсьәләләр комедияләрдә көлү объекты буларак күтәрелә. Әхлак проблемалары еш кына гомумкешелек кыйммәтләре яссылыгында бирелә. Бу чор комедияләре водевиль (Х. Вахит. «Күк капусы ачылса»; Т. Миңнуллин. «Диләфрүзгә дүрт кияү»), көнкүреш комедиясе (Ю. Әминев. «Әй, әшнәләр, әшнәләр»; Ф. Садриев. «Оҗмах ишеге төбендә»), җитди комедия (Х. Вахит. «Карлыгач канат җәя»; И. Юзеев. «Сандугачлар килгән безгә»), моңсу комедия (Т. Миңнуллин. «Әлдермештән Әлмәндәр»), лирик комедия (Р. Мингалим. «Кунак кызы гел килмәс»), сатирик комедия (Р. Вәлиев. «Әй машина, машина»), музыкаль комедия (Х. Вахит. «Кияүләр»; Р. Батулла. «Сөйгән ярым ятка кала»), трагикомедия (Ш. Хөсәенов. «Зөбәйдә – адәм баласы»; Ф. Садриев. «Кондырлы кодачасы») кебек жанр формалары белән байый. Шул ук вакытта, үзенчәлек буларак, аларның (мисал өчен, көнкүреш комедиясенең көнкүреш драмасы белән) үзара керешеп китүе күзәтелә (Т. Миңнуллин. «Нигез ташлары»; Ю. Әминев. «Сатучылар» һ.б.). Мәсәлән, Х. Вахитның «Күк капусы ачылса»сы – кешеләр характерындагы кимчелекләрдән көлеп, җыр-музыка белән үрелеп барган водевиль. Төп вакыйга яшь уйлап табучы Газиз белән тормыштагы яңалыкларны авыр кабул итүче завод директоры Госман Ганиевич арасындагы каршылыкка нигезләнеп үстерелә. Җитештерүне конвейерга куеп,

хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга бәйле Газиз тәкъдимнәре директор тарафыннан һәрдаим кире кагыла. Шул сәбәптән, егет хәйләгә бара – соңгы тәкъдимен башка кеше исеменнән комиссиягә тапшыра. Әлеге инженерны ачыклау гыйбрәтле сюжет борылышларына китерә. Шактый таныш производство темасы юмор, сүз уйнату, көтелмәгәнлек һәм аеруча җыр-музыка ярдәмендә аңлашу рәвешендә уңышлы яңгыраш ала.

Халыкчан көлүнең яңа алым-формалары Р. Вәлиевнең «Әйдә барыйк, кызлар карыйк!» комедиясендә тәкъдим ителә. Пьеса беренче күренештә үк уңышлы интрига тудыруы белән игътибарны җәлеп итә: бүлмәдә яшәүче егетләрнең берсе мәхәббәт уены белән мавыгучы, чорыбызның «дон-жуаны» буларак сурәтләнсә, калганнары – киресенчә, әлегәчә кызлар кулы да тотып карамаган «мәми авызлар». Әлеге каршылык үзара мөнәсәбәтләр чисталыгы, мәхәббәткә тугрылык, рухи байлык кебек мәсьәләләргә карашлар төрлелеге рәвешендә үстерелә һәм төп геройның тәүбә итүе белән тәмамлана. Мәзәкчән хәл-күренешләр аша драматург җитди мәсьәләләргә килеп чыга һәм юмор-сатира алымнары белән укучы-тамашачыны алар турында җитди уйланырга этәрә, кирәк урында сайлау алдына куя. Егетләр һәм кызларның үзара мөнәсәбәтенә җиңел карау, мәктәпләрнең һәм авылларның бетүе, шәһәргә киткән яшьләрнең еш кына үзләрен таба алмавы, мәдәният өлкәсенә игътибар җитмәү – шундыйлардан. Драматургның тагын бер табышы көлү алымнары белән бәйле. Әфләтунның үз-үзен фаш итүе күренештән-күренешкә арта барып, пьеса ахырында иң югары ноктасына җитә һәм егетнең тәүбәгә килүе булып яңгырый. Татар теленең бөтен байлыгыннан файдалану, мәкаль-әйтемнәргә, гыйбарәләргә мөрәҗәгать итү, сүз уйнату, җорлык, берсен-берсе инкяр итә торган төшенчәләрне янәшә кую кебек алымнар пьесадагы карнавал көлүне тагы да баета.

Бу еллар драматургиясендә трагедия жанрының активлашуы күзәтелә. С. Шәкүровның «Зөһрә йолдыз» (1968), И. Юзеевнең «Соңгы төн» (1972), «Мәңгелек белән очрашу» (1982), А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» (1972), Ә. Баянның «Алтын кашбау» (1986) һ.б. пьесалар языла. Шигъри трагедия жанрын

үстерүгә, «уртак идеаллар белән янган һәм барысын да фаҗигалы язмыш берләштергән татар халкының тарихи шәхесләрен, милли каһарманнарыбызның үлемсез образларын»[1] иҗат итүгә И. Юзеев зур өлеш кертә. Аның «Соңгы сынау», «Очты дөнья читлегеннән», «Мәңгелек белән очрашу» әсәрләрендә яшәеш идеаллары романтик сурәтләр аша фәлсәфи планда бирелә. Тарихи шәхес М. Җәлил образын үзәккә алган «Соңгы сынау» трагедия-легендасында конфликт матурлык-явызлык каршылыгына нигезләнә. Реалистик һәм романтик тасвир үзара кушылып барган «Очты дөнья читлегеннән» трагедиясендә Г. Тукай язмышы яшәү-үлем каршылыгында ачыла. Рухи коллыкны кабул итмәгән Тукай дөнья-читлектән күкләргә аша. Аның үлеме ирек өчен көрәшнең мәңгелек булуын раслый һәм шуңа чакыру булып яңгырый. «Мәңгелек белән очрашу»да исә, автор «...мифик-фантастик образлар, ситуацияләр ярдәмендә явызлыкка каршы чыга, җирне, кешелекне катастрофадан саклауны яклап күтәрелә»[2].

Шулай итеп, милли тормыш-яшәешне чагылдыруга, кеше һәм җәмгыять бәйләнешенең төрле аспектларын ачуга нисбәтле татар драматургиясе җитди әдәби-эстетик эзләнүләр юлына чыга: драматурглар сюжет һәм композиция, тема һәм жанр, тел һәм стиль чараларының, форма-алымнарының яңадан-яңа төрләренә мөрәҗәгать итәләр. Чынбарлык күренешләренә караган мәсьәләләр, милли, әхлакый, социаль төсмер алып, гомумкешелек кыйммәтләре белән тыгыз бәйләнештә күтәрелә. Драматурглар халык яшәешенең тирән катламнарына, тарихи сәхифәләренә кагылып, шулай ук көндәлек тормыш күренешләре аша фәлсәфи гомумиләштерүләр ясый.

---

[1] *Шәехов Л.М.* Татар шигъри трагедиясе: монография. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – Б. 146.

[2] *Галиуллин Т.* Дәвамлылык: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – Б. 103.

## 1.2. Т. Миңнуллинның драматургиядә беренче тәҗрибәләре

Т. Миңнуллин әдәби иҗатка килгән 1960 еллар ил-халык тормышында җитди үзгәрешләр белән характерлана. Татар әдәбияты да милли яшәешкә йөз белән борылып, тормышчанлык юнәлешендә һәм сәнгатьчә эшләнештә яңа баскычка күтәрелә. Драматургиядә Н. Исәнбәт, Р. Ишморат, М. Әмир, Ю. Әминев һ.б. янәшәсендә Х. Вахит, А. Гыйләҗев, Ш. Хөсәенов, И. Юзеев кебек авторлар үсеп чыга, театр дөньясы җанлана. Т. Миңнуллин әнә шундый шартларда үзенең шигырьләрен, юмористик хикәяләрен, скетчларын яза башлый. Аларда яшь авторның тормышны оста күзәтүче булуы, аерым детальләрне уңышлы тотып алуы, яшәеш мәсьәләләрен каршылыклар бәрелеше рәвешендә чишүгә килүе ачык күренә. Шуларга таянып, ул «Безнең авыл кешеләре» (1962), «Комиссия» (1966), «Күрше кызы» (1967), «Бәхетле кияү» (1967), «Исеме кем?» (1969) кебек пьесалар язуга килә. Әлеге әсәрләр, тәҗрибә туплау белән бергә, авторның башлангыч чор эзләнүләрен тоемларга ярдәм итә. Ә инде үзенең пьесалар язарга алынуын Т. Миңнуллин болай аңлата: *«Минем театр өчен яза башлавым, театрда уйнау белән бәйле. Барысы да хәтта уеннан башланды кебек. Язылган рольне уйныйм, ә эчемнән генә уйлыйм, ә бит бу күренештә бөтенләй башка сүзләр әйтергә мөмкин. Әлеге сүзләрне уйлап таба идем. Сүзләр генә дә түгел, сюжетның башкача дәвам ителешен дә уйлап табам. Күбрәк уйнаган саен, күбрәк язасы килә...»*[1]

Бу елларда әдәбиятта, шул исәптән драматургиядә әдәп-әхлак мәсьәләләре өстенлек итә. А. Шәрипова билгеләп үткәнчә, татар драматургиясенең төп сурәтләү предметы булып, милли һәм гомумкешелек әхлакый кыйммәтләре яктылыгында ачылган чынбарлык тора[2]. 1950 еллардагы бертөрлелектән, «конфликтсызлык теориясе»ннән арына барган сәхнә әдәбиятында кеше шәхесенә игътибар арта. Бу аны һәм гаиләдә, һәм

---

[1] Миңнуллин Туфан: фәнни-публицистик, документаль-биографик җыентык / төз. Г. Рәхим. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 467.

[2] *Шарипова А.С.* Татарская драматургия XX – начала XXI вв.: проблема инварианта: монография. – Казань: ИЯЛИ, 2022. – С. 125.

хезмәттә сурәтләп, эчке дөньясын мөмкин кадәр тулырак ачу омтылышында күзәтелә. Күп әсәрләрдә урын алган әхлакый конфликтта, герой характерына бәйле, намус, изгелек, бурыч мәсьәләләре алга чыга[1]. Чор рухына бәйле рәвештә, Т. Миңнуллин кешенең тормышта үз урынын табуы, бәхете-язмышы халык тормышы белән тыгыз бәйлелектә һәм әдәп-әхлак кануннарына нигезләнеп яшәгәндә генә була ала, дигән принципка таянып иҗат итә. Драматург «өчен иҗаты башлангычында ук төп максат булып татар халкының җанына үтеп керү тора»[2]. Билгеле, беренче әсәрләре сәнгати планда шактый йомшак була. Тәүге пьесаларыннан булган «Безнең авыл кешесе» әсәренең Минзәлә театрында куелуы уңаеннан, режиссер Сабир Өметбаев сүзләрен исенә төшерә: *«Синең йомшак пьесаңны куйдым. Йомшак икәнен белеп куйдым. Үз ялгышларын үзе сәхнәдә күрсен, дип куйдым. Чөнки үз ялгышларын драматург сәхнәдә күрмәсә, ялгышларын икенче әсәрендә дә кабатлый. Менә хәзер сине алтынчы рәткә утыртам һәм тамашачыларга синең кайда утырганыңны алдан әйтеп куям. Тотып кыйнасыннар, икенче тапкыр мондый пьеса язмассың*»[3].

Т. Миңнуллинның «Бәхетле кияү» (1967) пьесасы сәхнә телен, сәхнә закончалыкларын үзләштерү-өйрәнү юлында бер адым булып тора. Көнкүреш комедиясе авыл кешеләре психологиясен, тормышка карашын аңлау ягыннан кызыклы. Сюжет бик гади булып, анда ниндидер җитди мәсьәләләр күтәрелми. Авылдагы əти-əни янына кызлары ире белән кайтып төшә. Әмма авыл кешеләре аларны төксе йөз белән каршы ала, әйтерсең аларны алыштырып куйганнар. Кыз да, кияү дә моны аңлый алмый аптырый. Икенче көнне иртәдән хәл үзгәрә: һәрберсенең телендә «кияү» дә «кияү». Ниһаять, моның сәбәбе ачыклана: төнлә яңгыр явып үткән икән. Җир-ана, икмәк өчен борчылу

[1] *Илялова И.* Театр имени Камала. Очерк истории: исследование. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – С. 194.

[2] *Хабутдинова М.* Талантом обретенное бессмертие: итоги театральной декады в честь 80-летия Туфана Миннуллина // Татарика. – 2020. – № 2 (12). – С. 92.

[3] *Миңнуллин Т.* Сабир абый фәлсәфәсе // *Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – Б. 48.

авыл кешеләренең – картмы ул, яшьме – канында, ди автор. Иген басуы эсседән көеп ятканда, янәсе, нинди кияү кайгысы булсын? *«Игеннәр генә түгел, үзебез дә кара көя башлаган идек. Яшәүнең кызыгы бетә башлаган иде. Хәтта сез дә күзгә күренмәдегез кичә. Кайгыбыз бик зур иде шул»*[1], – ди Харис. Күптән көткән яңгырны алып килгән кияү нинди булсын, билгеле инде, «бәхетле кияү». Әсәр сәхнә әдәбиятына яңалык алып килми, әмма ул интрига тудырылып, аның чишелеше белән кызыклы. Автор диалоглары хәтердә уелып кала. Халыкчан сөйләм, җор тел, сүз уйнату, урынлы мәкаль-әйтемнәр аша авыл кешеләренең аерым штрихлар белән бирелгән мөлаем образлары калка.

Драматургның беренче әсәрләреннән булган «Күрше кызы» дуслык-мәхәббәт хисенең төсмерләрен һәм аның яшь кеше рухына тәэсирен ачуга юнәлтелгән булуы белән игътибарга лаек. Пьесада шәхес формалашу процессы мәхәббәт, хезмәт, әдәп-әхлак, буыннар бәйләнеше кебек яшәеш проблемалары белән үрелеп бара. Алгы планда яңа гына мәктәпне тәмамлаган 18 яшьлек Фәния исемле кыз тора. Дөрес, бу образ өр-яңа түгел. Алдарак яшьләрнең олы тормыштагы беренче адымнары, аның җитди каршылыклар аша баруы Х. Вахит, Ш. Хөсәенов, А. Гыйләҗев пьесаларында урын ала. Х. Вахитның «Беренче мәхәббәт» (1960) драмасында Рәхилә беренче ярату хисләрендә һәм этисенә мөнәсәбәттә сынала, ә инде Ш. Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы» (1961) трагикомедиясендә Зөбәйдә үзенең шәхси хокуклары өчен көрәшергә әзер кыз буларак сурәтләнә. А. Гыйләҗевнең «Киек Каз Юлы»ндагы Бәллүр исә киләчәгенә зур, матур омтылышлар белән атлаучы, аны ачык күзаллаучы буларак ачыла.

Т. Миңнуллин герое беренче күренешләрдә үк үзсүзле, тиктормас һәм гашыйклык халәте бөтен барлыгын биләп алган кыз булып алга килеп баса. Ул 12 яшендә күршедә яшәүче Хәлим абыйсына гашыйк булган, хәзер әлеге беренче тойгылары чын ярату булып үскән дип саный. Үзен ошатып йөрүче Вахитны кире кага, сөйләшергә дә теләми. Ә менә аның гармунда

[1] *Миңнуллин Т.* Бәхетле кияү // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 5 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 19.

уйнаганын ярата. Бу да кыз күңелендәге романтик халәткә, матурлыкка омтылышка ишарә итә. Авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, инженер-механик сыйфатында авылга кайткан Хәлимнең зоотехник булып эшләүче Әминә белән якын дуслыгын белү, Фәниягә гаять көчле тәэсир итә. Тормышта беренче каршылыкка очраган кыз чарасызлык алдында кала.

Фәния – Хәлим – Әминә традицион мәхәббәт «өчпочмагы»н автор тагы да тыгызландыра төшә: әйтелгәнчә, Фәнияне классташ егете ошатып йөрсә, Әминәгә колхозның алдынгы механизаторы Хәйдәр күз салып йөри. Төп геройларның мәхәббәткә хокукы хезмәттә һәм әхлакый чисталыкта сынау үтә. Югары белемле инженер Хәлим авылдашлары тарафыннан хөрмәт ителә. Дөрес, яңа гына колхозда эшли башлаган егетне ни өчен хөрмәт итү сәбәбе ачыкланмый, шулай да моны аның әти-әнисенә булган зурлау чагылышы дип кабул итәргә кирәктер. Автор егетне авылны, җирне яратып, эшен җиренә җиткереп башкаручы буларак ача. Шул ук вакытта Хәлим тәҗрибәсез, кешеләрне дә тиз генә танып-белә алмаучы булып күзаллана. Аңа ныклык, сүзен сүз итү, үз позициясен төгәл, ачык белдерү җитми. Әминәгә шактый битараф булса да, моны үзенә бик соңарып кына аңлата. Күрше кызы Фәниянең хис-кичерешләрен, үзенә мөнәсәбәтен дә сизми, хәтта бөтен кешедән соң белә һәм шуның белән кызны озак вакыт икеләнүле халәттә тота, күңел газаплары китерә. Автор егетнең Әминәгә капма-каршы позициядә торуына аерым басым ясый. Тормышка, хезмәткә мөнәсәбәттә икесе ике төрле кеше булуын кызга ачык итеп әйтә: *«Ул хыялларың синең өчен чүп кенә икән. (...) Синең өчен җир дә, кешеләр дә кирәкми. (...) Фәния әйткәндәй, мәхәббәт мәхәббәт белән, тик ул намуска тап төшерерлек булмасын. Мещан буласым килми минем, Әминә»*[1].

Пьесада авторның нәфрәте Әминәгә юнәлгән. Ул шактый тупас, аны авылында да, күрше авылда да яратмыйлар, үзе алдында ук бу турыда ачыктан-ачык әйтәләр. Әдәп-әхлак сыйфатларын үзләштермәве, аның хезмәткә мөнәсәбәтендә дә чагыла.

---

[1] *Миңнуллин Т.* Күрше кызы // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 151.

Пьесада төрле буын вәкилләре урын алып, автор билгеле бер схемага нигезләнә. Карт кеше икән, димәк, тәҗрибәле, акыллы, яшьләргә бик тә кирәкле сабак бирүче. Яшь кеше исә – ялгышлар аша киләчәккә баручы. Автор үзенең геройларына бәяне дә яшьләрдән бирдерә. Әгәр Вахит Хәлимне әйбәт кеше дип зурласа, Әминәнең җирне яратмавын әйтә. Ятим малай да Хәлим белән шактый тиз уртак тел тапса, Әминәне тупаслыкта гаепли. Болар шактый ясалма булып, әсәрнең гомуми яңгырашын киметә.

Хәлимнең күршесе Фәния әлегә олы тормышка әзер түгел, ул юктан гына кызып китә, әнисе белән дә килешеп бетми. Әмма аның саф күңеле, олы йөрәге бар. Шуңа да ул авыл бөтенлеген саклаучы булып күзалланган Хәйретдин картка тартыла, аның янында тынычлык таба. Гашыйклык халәтен дә беркемнән яшереп тормый. Мәхәббәт хисен китаплардагы кебек күз алдына китерә: *«Ярату ул сиңа ошаган кешегә ышану, аңа табыну, аны үзеңнең идеалың итеп күрә белү, хөрмәт итү, серләреңне аңардан яшермәү, авыр чакларда чын күңелдән ярдәм итү, кайгысын-шатлыгын уртаклашу, ул кешене күргән саен күрәсе килеп тору...»*[1] Алдагы күренешләрдә колхозда эшли башлаган кызның рухи үсеше бирелеп, ул үзенең гашыйклык халәтендә булуын, өлкән яшьтәге егетне үзе күрергә теләгән идеал дип кабул итүен аңлауга килә. Билгеле инде, бу алай җиңел генә бармый. Вакыйгаларда кызның борчылуы, икеләнүе, күңел кичерешләре психологик яктан шактый уңышлы нигезләнә. Беренче хисләрендә алданган кыз, авылны ташлап, Казанга китмәкче була. Әмма аны Вахит бу ялгыш адымыннан туктата. *«Качарга җыенасыңмы?* – ди егет кызга. – *Үз-үзеңнән качып котылып буламыни? (...) Кайда синең горурлыгың? (...) Нәрсә, мәхәббәт гаепле дип исәплисеңме? Мәхәббәт – ул изге нәрсә! Җүләр хисләр түгел ул. Мәхәббәт ул олы, аны юл тузанына гына күмеп булмый. (...) Адашуыңны теләмим мин синең»*[2]. Әлеге фикерләр Вахитныкыннан бигрәк, автор карашы булып тора. Чынлап торып яратып карамаган Вахит та мәхәббәт турында «дөрес» сүзләр

---

[1] *Миңнуллин Т.* Күрше кызы // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 124.

[2] Шунда ук. – Б. 155.

сөйли, урынлы-урынсыз «акыл» сата. Гомумән, Т. Миңнуллин ул чорда җитди бәхәсләр уяткан мәсьәләләрне укучы-тамашачы алдына куеп, фикер алышуга китерә. Пьеса билгеле бер кимчелекләрдән азат булмаса да, ул заманчалыгы, акцентларның куелышы, сюжет төзеклеге, бер төрле генә бәяләнми торган үзенчәлекле геройлары, аеруча идея эчтәлегенең ачыклыгы белән кызыксыну уята, байтак еллар төрле сәхнәләрдә куелып килә.

Шул рәвешле, драматургның беренче тәҗрибәләре уңышлы туфракка төшә. Ул, белеп һәм яратып, авыл турында, аның гаҗәеп кешеләре турында яза, сәхнәгә характерлары белән аерылып торган образларны чыгара. А. Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә, «беренче пьесаларына ук заманны һәм кешеләрне аңлау, тормышны белү, көн сорауларына һәм ихтыяҗларына сизгерлек хас»[1]. Әсәрләрендә иҗат тәҗрибәсе җитенкерәмәү, сәхнә закончалыкларын тоеп бетермәү, образлар эшләнешендә туры сызыклылык үзен сиздерсә дә, драма һәм комедия жанрларының эчке хасиятләрен ачык тоемлап язуы һәм конфликтның ачык-аңлаешлы булуы һәм аның эзлекле чишелеше аларның укучы-тамашачы тарафыннан уңай кабул ителүенә китерә.

## 1.3. Тормышчан конфликт һәм яңа геройлар

Драматург заман үзгәрешен оста сиземләп, тамашачының рухи ихтыяҗларына йөз тотып, тормыштагы актуаль, җитди, төрле буын кешеләрен борчыган мәсьәләләрне алга куеп иҗат итә. Шунлыктан аның әсәрләре укучы-тамашачыда һәрвакыт теләктәшлек таба. Чор мәсьәләләрен яктыртуны әдип табигый рәвештә кешенең уй-хыялларын, яшәү максатын, кешелек сыйфатын ачуга бәйли. Т. Миңнуллинны киң җәмәгатьчелеккә драматург буларак таныткан «Нигез ташлары» (1968), «Миләүшәнең туган көне» (1968) пьесалары шәхеснең каршылыклы рухи дөньясын чор билге-төсмерләре контекстында күрсәтәләр.

Драматургны татар гаиләсендә буыннар бәйләнеше, кешенең туган җире, туган йорты каршындагы җаваплылыгы, буын-

[1] *Әхмәдуллин А.* Үзе сайлаган язмыш // Дөреслеккә ирешү юлында. Мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – Б. 51.

нардан буыннарга күчеп килгән әдәп-әхлак – намус, горурлык, миһербанлылык, хезмәт ярату һ.б. сыйфатлар – сакланышы борчый. Татарны татар итеп яшәтә торган урын дип Т. Миңнуллин авылны саный, шуңа да татар авылының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән бәйле вакыйгалар, уй-фикерләр, аның бөтен иҗатын иңләп үтәчәк «туган җир», «туган нигез», «туган йорт» мотивы бу дәвер әсәрләрендә киң яңгыраш табып, образ-символ дәрәҗәсенә күтәрелә. «Татар драматургиясендә милли проблематиканың алгы планга чыгуы, халык тормышы белән бәйле мәсьәләләрнең көн тәртибенә куелышы, милли сурәтлелек өстенлек алу турында сөйләгәндә, йорт образына кагылышлы үзгәрешләрне урап узу мөмкин түгел, – дип яза бу мәсьәләне махсус өйрәнгән А. Батталова. – Аның әдәбиятта яңа югарылыкка күтәрелүе, һичшиксез, иҗат мәйданына килгән яшь драматурглар, бигрәк тә Т. Миңнуллин әсәрләре белән бәйле»[1].

«Нигез ташлары» пьесасы тормышта гадел яшәү, ата-бабадан килгән әхлак сыйфатларын саклау, аларга тугры калып, яшь буынга җиткерү мәсьәләсен үз эченә ала. Аның ата-ана һәм балалар мөнәсәбәтенә бәйле һәм йорт-нигез төшенчәсе аша ачылуы аеруча зур кызыксыну тудыра. Әсәрнең төп идеясе дә кешенең ата-бабадан килгән нәселенә тугры калуы, аңа тап төшерми яшәве белән бәйле. Автор карашлары гаҗәеп уңышлы табылган «нигез ташы» символы аша чагыла.

Җитмеш яшьлек Гарифулла карт дүрт малай үстергән, мәгънәле, матур гомер итеп, авылдашлары каршында хөрмәт казанган. Намуслы, үзсүзле, принципиаль картны елның елында икмәк кабул итү комиссиясе җитәкчесе итеп куялар. Соңгы вакытта ул кәефсез йөри, хатыны Гөлҗиһан белән дә әйткәләшеп ала. Ә инде авыл бригадиры Нурәхмәтнең иске йортны, нигезне җимереп, *«менә дигән яңа өй салып бирәбез бит үзегезгә»*[2] дигән сүзләре аны чыгарыннан чыгара. Тиздән Гарифулланың телеграмма белән улларын чакырып кайтаруы билгеле була.

[1] *Батталова А.Д.* Татар драматургиясендә йорт образының үсеш-үзгәреше (1960–2000 еллар): монография. – Казан, 2009. – Б. 44.

[2] *Миңнуллин Т.* Нигез ташлары // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 14.

Аның борчылуы әкренләп улларының яшәү рәвешенә бәйле туган каршылыкка барып тоташа. Аларның авылдан китүләренә бер борчылса *(«Дүртесенә дүрт тиенлек акыллары юк. Җыен зимагур»[1]),* Әхмәдиша нәселенә тап төшерә торган эш-гамәлләре өчен икенче борчыла ул. Шуңа да җитди сөйләшү алдыннан нәсел турындагы риваятьне искә төшерә. Хәмидулла, Әхмәдиша бабайлардан килә торган намуслы яшәү рәвешенең Гарифулла балаларында дәвам итәргә тиешлеген дә искәртә. Әңгәмә юнәлешен билгеләп, сорауны да ачык куя: *«Гарифулланың нигез ташлары ничегрәк икән, мүкләнеп, череп бетмәгәннәрме?»* Олы улы Хәниф Себердә яшәп, заводта эшли. Үз тормышыннан канәгать ул, әнә улы Флорид та акыллы, тәрбияле булып үсә, бабасына тартыла. Әмма Хәниф бөтен нәрсәгә битарафка әйләнгән. Туганнары белән аралашмый диярлек, әти-әнисе янына да бик сирәк кайта. Министр урынбасары булып эшләүче улы Хәмиткә дә борчулы уйларын турыдан-туры җиткерә карт. Колхоз рәисенә әйтеп, яңа йорт салдыру мәсьәләсен дә ул күтәргән икән. Гарифулла моңа каршы түгел, әмма бит авылда тагын да начаррак шартларда яшәүче ялгыз карчыклар бар. Нигә башта шуларны кайгыртмаска? Әнә авылда Хәмитнең «влач» яратуы турында сүз ишетелә икән. Шуның өстенә Казан урамында очраган авылдашларына сәлам бирми узып киткән. Бергә укыган төркемдәшен «танымаган», йомыш белән кабинетына кергән авылдашы Гайнетдин абзый белән сөйләшмәгән улын Гарифулла карт гамьсезлектә, гади кешеләргә игътибарсызлыкта гаепли. М. Хәбетдинова билгеләп үткәнчә, автор авылдан чыгып та, туган җире – «кендеге» белән бәйләнешен югалткан кешеләрнең йөрәгенә барып җитәргә, туган җирдә барган һәрнәрсә өчен һәркемнең шәхси җаваплылык тоюын тели[2].

Шулай да атаны аеруча зур борчуга салган улы – Хәлил. Ул әхлакый кануннарны гына түгел, бәлки хокукый законнарны

[1] *Миңнуллин Т.* Нигез ташлары // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 23.

[2] *Хабутдинова М.М.* Талантом обретенное бессмертие: итоги театральной декады в честь 80-летия Туфана Миннуллина // Tatarica. – 2015. – № 2 (5). – С. 96.

да бозып эш итә икән. Ата улына әрнүле күңеленнән чыккан бәяне бирә: *«Карак син, белдеңме! Бур! Кешенең шырпысына да тимәгән Әхмәдиша нәселеннән карак килеп чыккан»*[1]. Склад мөдире булып эшләүче Хәлилнең төрле юллар белән әйбер үзләштереп, аны танышларына сатуы беленгән. Капка төбендә ята торган түбә калаен да ул «тапкан», ә бер өлешен бригадир Нурәхмәткә саткан. Шуңа да урланган материаллар белән яңа йорт салу фикере Гарифулланың җан ачуын кузгаткан. Дөрес, Хәлил башта бу гаепкә каршы торып карый. *«Урлыйм, законный итеп урлыйм. Мин генә түгел. Сезнең кебек җүләр буласым килми минем. Яшәп каласым килә. Бүтәннәр яшәгәндә, нигә миңа каршы торырга?»*[2] – ди ул, урлашуның җәмгыятьтә тирән урын алуына ишарәләп. Әмма соңыннан ул гаебен танырга мәҗбүр була. Хәлилнең әхлакый һәм хокукый кануннарны бозуы барысын да кузгатып җибәрә һәм җитди сөйләшүгә китерә. Әлеге бәхәскә ирләр генә түгел, хатыннар да кушылып, ул нәсел, ата-ана һәм үзең каршындагы җаваплылык кебек мәсьәләнең бөтен кискенлегендә куелуына китерә. Вакыйга барышында Хәлилгә хатыны Фәрдиянең тискәре йогынтысы булу да ачыла. Ул – татар әдәбиятында киң таралган усал килен образының яңа шартларда бирелеше. Ире Хәлилдән көнләшә, шактый комсыз итеп тә сурәтләнә, яңа йортка дип кайтарылган түбә калае өчен акча таләп иттерә. Автор берничә штрих белән бу хатынның татар милли йола-гадәтләрендә тәрбияләнмәвен билгеләп үтә. Чәй өстәле әзерләнгәч, ул ирләрдән генә түгел, кайнатасыннан да оялмыйча, түр башына кереп утыра. Фәрдиягә капма-каршы буларак шәфкать туташы Сәрия бирелә. Чын татар кызларына хас булганча, ул тыныч, сабыр, өлкәннәргә хөрмәт белән карый. Иң мөһиме, әдәп-әхлак кануннарын саклап яшәргә омтыла.

Драмада Гарифулла карт халкыбызга хас иң матур сыйфатларны саклаучы, заманны сылтау итеп гореф-гадәтләрдән, нәсел традицияләреннән читләшүче улларын «акылга китерүче» булып сурәтләнә. Авылда гаделлеге белән танылган ата

---

[1] *Миңнуллин Т.* Нигез ташлары // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 48.

[2] Шунда ук. – Б. 57.

шәһәрдә яшәүче улларына әхлакый суд ясый, нәсел традицияләренә тугрылык, намуслы хезмәт, туган йорт кадере турында җитди бәхәс алып бара. Ата белән уллары арасындагы каршылык, туган йорт, нигез турындагы сөйләшүдән, һәркемнең яшәү рәвеше, кылган эш-гамәлләре өчен җаваплы булуы турындагы фәлсәфи нәтиҗәгә үсә. Карт яши торган йорт «нәселенең йөзе. Аның нигезе (...) шактый нык. Гарифулланың улларын гаилә хөкеменә тартуы – әнә шул ташлар өстенә утырган мүкләрне кыргалап тору ул»[1]. Йортның озак сакланышы өчен нигезнең ныклыгы кирәк булган кебек, нәсел гомере, димәк ки, милләтнең киләчәге дә өлкәннәрдән килә торган яшәү рәвешенә тугры калып, намуслы тормыш итүдә.

Пьесада мөһим урынны яшь малай Флорид образы алып тора. Авторның укучы-тамашачыга җиткерергә теләгән фикере нәкъ менә бабай белән онык диалогында бирелү дә игътибарга лаек. Әсәрдә алгы планга чыгарылган нәсел традицияләрен дәвам итү фикере, билгеле инде, ата-бабадан килгән йола-гадәтләрнең яшь буынга тапшырылуын таләп итә, нәсел буынының бер чылбыры буларак, малайдан әлеге вазифаны үз өстенә алу таләп ителә. Гарифулла нәкъ менә яшь буынга үзенең иң изге, васыяте булырдай теләк-фикерләрен җиткерә: *«Әгәренки, син өй салырга уйласаң, нигез ташларың таза булсын. Мурып беткән таш өстенә өй салып булмый, өй, бүрәнәләре искергәнче үк, кыйшаеп, ишелеп төшә. Ә таза нигез ташы өстенә әллә ничә тапкыр өй салырга була. Менә мин дә әтиеңне, абыйларыңны шуның өчен ачуланам. Алар нык булса, таза булса, минем нәселнең гомере озын булачак»*[2]. Шул рәвешле, өйнең нигез ташлары нәсел ныклыгы, әхлакый кыйммәтләргә тугры булып яшәү кебек төшенчәләргә килеп тоташа. Ил картының васыятькә тиң әлеге сүзләре авторның укучы-тамашачыга җиткерергә теләгән төп фикере булып тора. Әлеге пьесада Т. Миңнуллинның алдагы иҗатында киң урын алачак бер үзенчәлек урын ала, бу –

[1] *Батталова А.Д. Т*атар драматургиясендә йорт образының үсеш-үзгәреше (1960–2000 еллар): монография. – Казан: Алма-Лит, 2009. – Б. 48.

[2] *Миңнуллин Т.* Нигез ташлары // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 60.

тирән оптимизм. Күтәрелгән мәсьәләләр чишелеше аша, әдип укучы-тамашачы күңелендә өмет-ышаныч хисе уята, моның өчен малайлар – нәсел дәвамчылары образыннан уңышлы файдалана. Шәһәрдән кунакка кайткан Флорид һәрдаим бабасына тартыла, аның белән җиңел аралаша, уртак тел таба, авыл фольклорын яратып өйрәнә. Бу үзенчәлек киләчәктә аеруча «Әлдермештән Әлмәндәр»дә тулы һәм мәгънәле гәүдәләнеш ала.

«Нигез ташлары» билгеле бер кимчелекләрдән азат түгел. Гарифулла ил карты буларак, нигездә, уңышлы ачылса да, башка образларның эшләнеше сораулар тудыра. Картның улларына фикер ачыклыгы җитми. Хәлилнең урлашуы мәсьәләсе дә бәхәскә урын калдыра. Ул чорда авыл халкы мохтаҗлыктан тилмерә. Йорт салу өчен мүк-кадактан алып, шифер-пыялага кадәрге бөтен әйберне табу зур проблема булуын өлкән буын яхшы хәтерли. Еш кына кирәк материал я йогынтылы кеше аша, я ике бәясенә табыла. Сер түгел, шуңа да урлашу гадәти хәлгә әверелә. Т. Миңнуллин урлашуны җитди әхлакый проблема итеп чыгарса да, социаль сәбәпләрен читләтеп үтә.

Пьесаның үз вакытында, соңрак спектакль буларак күп тапкырлар куелышында да бәхәс уяткан мәсьәләнең берсе – жанр белән бәйле. Автор «комедия» дип атаса да, күтәрелгән проблеманың җитдилеге, аның вакыйгалар аша үстерелеше һәм чишелеше пьесаны «драма» жанры буларак бәяләүне сорый.

* * *

Т. Миңнуллин иҗаты реалистик сурәтлелек белән сугарылган. Әдип үз заманына, тормышчан хәл-күренешләргә мөрәҗәгать итә һәм шулар аша яшәешнең каршылыклы мәсьәләләренә килеп чыга. Шуңа да аның иҗатында кешенең тормышта үзүзен табуы, хакыйкать эзләве зур урын били. Әлеге гаять зур һәм катлаулы мәсьәлә драматургның беренче әсәрләрендә үк урын алып, алдагы бөтен иҗатын иңләп үтә. Җитди мәсьәлә шундый ук көчле һәм үзенчәлекле конфликтта чагылуны һәм гыйбрәтле геройлар язмышына бәйле чишелүне таләп итә. Ә инде башлангыч чор иҗатында ул аеруча тулы һәм фәлсәфи яңгырашлы булып «Миләүшәнең туган көне» (1968)

драмасында чагылыш таба. Шуны да билгеләп үтик, автор соңрак әлеге әсәренең дәвамы буларак «Дуслар җыелган җирдә» (1978) һәм «Хушыгыз» (1990) драмаларын яза һәм алар бергә, трилогия тәшкил итеп, тулы бер буынның гомер юлы буларак киң полотнолы әсәр булып оеша.

«Миләүшәнең туган көне» драмасы гаилә-көнкүреш вакыйгалары белән башлана. Туган көнен билгеләп үтүче Миләүшә янына бергә укыган дуслары җыела, авылдан этисе үзенең фронтовик дусты белән килеп төшә. Дусларның туган көн уңаеннан очрашуы әкренләп социаль-фәлсәфи эчтәлек ала һәм җитди мәсьәләләр турында бәхәскә әверелә.

Драма интеллектуаль эчтәлеге, яшәешнең әхлакый һәм социаль-иҗтимагый мәсьәләләрен шактый кискен куюы белән киң яңгыраш ала. Автор заман куйган сорауларны иҗат кешеләре тормышы аша ачу омтылышы ясый. Иҗат кешесе кем ул? Аның яшәештәге максат-бурычы нидән гыйбарәт? Әлеге һәм башка сорауларга җавап эзләү максатында автор туган көн уңаеннан бергә укыган дусларны очраштыра. Әсәрдәге беренче күренеш үк каршылык белән башлана. Рәссамнар оешмасында җитәкче урында эшләүче Шәһит хатыны Миләүшәнең туган көнен оныткан, шуңа да яшьлек дуслары шагыйрь Рәфисне, музыкант Фәһимне чакыруны да кирәк тапмаган. Алай гына да түгел, дуслар буларак алар белән араны өзүгә дә каршы түгел. *«Дуслар бит ул үзеңә тигез булсалар гына дуслар. Мин фикерләр тирәнлеге турында әйтәм»*[1], – ди ул Миләүшәгә, үзен алардан өстен куюын яшермичә.

Вакыйгалар барышында әлеге каршылык иҗат кешесенең тормыштагы максат-бурычы мәсьәләсендә җитди иҗтимагый конфликт булып оеша. Әсәр язылган чорда иҗат кешеләренә бәйле сорау буенча җитди бәхәсләр урын ала. Билгеле булганча, сугыштан соңгы һәм 1950 елларда социалистик реализм иҗат методын әдәбият-сәнгатьтә берьяклы гына аңлау урын ала һәм нәтиҗәдә еш кына тормышны бизәп, каршылыкларны шомартып сурәтләү күзәтелә. Ә инде илдә демократик үзгәрешләр

[1] *Миңнуллин Т.* Миләүшәнең туган көне // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 403.

башланып, чынбарлыкны объектив чагылдыруга омтылыш көчәйсә дә, ул шактый авырлык белән юл яра. Т. Миңнуллин драмасы белән әлеге бәхәскә кушылып китә. Пьесадагы вакыйгада Рәфис, рәсем-портретларны караганнан соң, Шәһит алдына сорау куя: *«Ә кеше кайда? Художник күзе күргән кеше? Һәр ударникның портретын язу художникның вазифасына керми торгандыр ич?»*[1] Шунда ук кызып китеп, рәссамнар күргәзмәсендә булуын әйтеп, фикерен дә җиткерә: *«Профессор портреты эленеп тора, аннан көләч йөзле монтажниклар. Барысы да бер төсле. Барысы да елмаялар. Бәлки, профессор уйлана да беләдер»*[2]. Әнә шул рәвешле, әңгәмә җитди төс алып, геройлар позициясен ачыклау булып үсә. Шул рәвешле, тормыш-яшәеш принциплары, сәнгать һәм чынбарлык мөнәсәбәте турында җитди иҗтимагый проблемалар кузгала. Шәһитнең тормышны берьяклы гына аңлап, сәнгатьтә аны ал төсләрдә чагылдыру омтылышы – идеология кысаларында, соцреализм юнәлешендә иҗат итү. Шуңа бәйле матди һәм рухи кыйммәтләр, шәхеснең җәмгыятьтәге урыны турында бәхәс алып барыла. Шәһитнең бу мәсьәләгә үз карашы бар, ул сәнгать әсәре кешедә матур хисләр уятырга тиеш дип саный. Бергә укыган талантлы рәссам Нурисламның эшләрен дә шуннан чыгып тәнкыйтьли: *«...Ул бик еш тайпыла. Ә үзе кеше киңәшенә колак салмый. Аның геройлары һәрвакыт мескеннәр, кыерсытылганнар. Бернинди яктылык юк. Заман бездән икенче нәрсә таләп итә»*[3].

Авылдан Миләүшәнең әтисе Харис һәм аның фронтташ дусты Әһлиулла килү фикер-карашларны тагын да кискенләштерә. Шәһит «мескен» дип атаган портреттагы кеше үзе алар каршында. Сугышта батырлыгы өчен күпсанлы орден-медальләр белән бүләкләнгән, бер аягын югалткан Әһлиулла да бит заман кешесе. Хезмәт кешесе, колхоз рәисе Харисның иҗатчыларга таләбе бер – кеше күңелен, аның рухи дөньясын сурәтләү. Шуңа да ул Шәһит ясаган портретка кискен бәя бирә: *«Сыер савучы ап-ак*

[1] *Миңнуллин Т.* Миләүшәнең туган көне // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 406.

[2] Шунда ук. – Б. 406.

[3] Шунда ук. – Б. 409.

*халаттан, кулына чиләк тотып, көлеп тора. Таң белән тора ул, кич караңгыда өенә кайта. Төзәт, кияү. Кыз, йокы баскан күзләрен тутырып, безгә карап торсын. Мин сауган сөтнең кадерен белегез, янәсе»*[1].

Шәһитнең иҗат принципларына хас берьяклылык, тормышны шомартып сурәтләргә омтылуы, аның шәхси сыйфатлары, әхлакый йөзе белән тыгыз бәйле. Вакыйгалар барышында ул үзен генә яратучы эгоист булып ачыла. Кешеләргә дә биләгән урыннарыннан чыгып бәя бирүне өстен күрә. Һәр адымын, сүзен, эш-гамәлен кат-кат уйлап кына кылучы Шәһиткә тулы бәяне сәхнәдә бик аз гына күренеп киткән Нурислам бирә: *«...салкын тимер кебек. Сүзләре белән теләсә кемнең җанын өшетә»*[2]. Рәфис исә аның күзенә карап, *«кешеләр язмышы белән уйнарлык булып кай арада җитештең»*[3], ди. Шәһитнең Әһлиуллага түбәнсетеп каравы Харисны чыгарыннан чыгара: *«Синең кебекләр аның алдында дүрт аякланып йөрергә, аның агач аягын үбәргә тиеш»*[4].

Драмада барган фикер көрәшендә Шәһитнең яшәү фәлсәфәсе кире кагыла. Дуслары гына түгел, Миләүшәнең әтисе Харис, аның фронтовик дусты Әһлиулла да, Шәһитнең яшәеш фәлсәфәсен кире кагып, өен ташлап китәләр. Миләүшә дә ире корган яшәү рәвешен үтеп чыгарга үзендә көч таба: *«Кешеләрсез яши алмыйм мин, Шәһит. Кирәкми миңа алтын читлек, читлектәге кош бәхете кирәкми миңа!»* [5]

Драма буенча куелган спектакль үз вакытында югары бәя ала. Шулай да тәнкыйди язмаларда Әһлиулланың шактый мескен булып күренүе, пассивлыгы, образ буларак эшләнеп бетмәве турында фикерләр яңгырый. Әсәр тормышчан булып, геройлары чорның төрле типлары буларак күзаллана. Арада колхоз рәисе булып эшләүче Харис белән аның фронтовик дусты Әһлиулла

---

[1] *Миңнуллин Т.* Миләүшәнең туган көне // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 429.

[2] Шунда ук. – Б. 424.

[3] Шунда ук. – Б. 439.

[4] Шунда ук. – Б. 444.

[5] Шунда ук. – Б. 445.

аерылып тора. Әгәр Харис үзен яклый белүче көчле шәхес итеп күзалланса, Әһлиулла исә берьяклы гына ачыла. Каравылчы булып эшләүче, шактый мохтаҗлыкта яшәүче сугыш ветераны тормышта үз урынын таба алмаган. Ул үзенең йомшак булуын, баш иеп яшәвен яшерми. Шуңа да әледән-әле сугыш вакыйгаларын искә алырга ярата. Тәнкыйди язмаларда аның бу халәтен образның эшләнеп бетмәве белән аңлатулар булды. Шулай да Әһлиулла чор тибы буларык уңышлы ачылган. *«Мин дөнья арбасыннан төшеп барам. Шуны күреп торуы авыр. Эх, бер җилкенеп аласы иде, Харис туган. Тау-таш актарасы иде»*[1], – ди ул үз хәле турында. Аның бу сүзләрендә яшәп килгән системага тәнкыйть яңгырый. Чөнки Әһлиулла кебек «тау-таш актарырдай» ветераннар нигә шундый хәлдә? Аларның көч-энергиясенә, теләк-омтылышына юл ачу да – җәмгыять бурычы. Ул бит бүгенге халәтеннән ничек котылырга белми азаплана. Сугышта бар да ачык – алда дошман, арыслан булып аның өстенә ташланырга тиешсең. Ә монда арыслан гайрәтен кемгә, нәрсәгә юнәлтергә соң? Әһлиулланың һәрнәрсәгә битараф булып күренүе артында җан әрнүе ята. Т. Миңнуллин җәмгыятьнең игътибарын әнә шуларга юнәлтүе белән дә үзгәрешкә чакыра.

Автор үз карашларын укучы-тамашачыга җиткерү өчен әдәби детальләрдән, символлардан файдалана. Драмада Шәһит кулындагы «шәп» портфель турында Рәфиснең *«Шәп бит, ә? Министерский, тик эче генә буш, ахры»*[2] диюе дә хуҗасының аңа лаек булмавын, күңеле белән түбән, буш булуына ишарә итә. Харис авылдан алып килгән икмәк тә – геройларны бәяләүче деталь. Рәфис белән Фәһим авыл хатирәсе булган икмәкне тиз-тиз бүлеп алсалар, Шәһитнең бер дә исе китми. Вакыйга бара торган шәһәр квартирасы да, ябык пространство буларак, геройларның күңел халәте турында сөйли. Ул шулай ук җәмгыятьтәге тар, бертөрле тынчу тормышка ишарә итә. Шуңа да Шәһиттән башкалар аның квартирасын – «алтын читлеген» – ташлап китәләр.

---

[1] *Миңнуллин Т.* Миләүшәнең туган көне // *Миңнуллин Т*. Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 427.

[2] Шунда ук. – Б. 404.

*«Драматург шәхескә, аның рухындагы, күңел түрендәге һәртөрле үзгәрешләргә бик тә игътибарлы, үз геройларының психологик кичерешләрендәге нечкә борылмаларга гаять сизгер»*[1] булып, үзенчәлекле образлар галереясы иҗат итә. Әлеге интеллектуаль эчтәлекле пьесада һәр геройның үз дөреслеге бар. Шәһит һич тә чор укучы-тамашачысы күнеккән тискәре герой булмаган кебек, икенче рәссам Нурислам да, хәтта фронтовик Әһлиулла да идеаллаштырып бирелмиләр. Үз иҗатында реализмга өстенлек биргән драматург сәнгать әсәрендә дә тормыш дөреслеген, реалистик детальләрне яклап чыга. Гомумән, пьеса-бәхәстә күтәрелгән сорауларга җавап табылып бетми, монысы тамашачы өлеше булып, аның күңелендә дәвам итәчәгенә шик юк.

Т. Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» драмасы «Миләүшәнең туган көне» пьесасының дәвамы булып тора. Автор тулы бер буынның язмышын эзлекле тикшерүне дәвам итә. Әсәрдә без элекке танышлар белән очрашабыз. Арада Шәһит юк, Миләүшә аннан аерылгач, ул алар белән аралашуны өзгән. Әмма Гайнулла белән Гөлия өстәлгән, алар ун ел инде бәйрәмнәрне бергә үткәрә. Беренчесе кебек үк «пьеса-бәхәс» булып, драмада вакыйгалар юк диярлек.

Нурисламның квартира алуы уңаеннан һәм яңа гына тәмамлаган картинасын карау өчен, дуслар чираттагы очрашуга җыела. Очрашу гадәттәгечә башланып, барысы да Нурисламны яңа картинасы белән котлый һәм сүз тиз арада бер-берсен мактауга, анекдотлар сөйләүгә, кыяр-помидор үстерү, тозлау серләренә күчә. Дуслыкларының ныклыгына, үзләренең гади-гадәтилегенә, бер-берсенә мөнәсәбәтнең эчкерсезлегенә укучы-тамашачы ышанып беткәч, автор кискен борылыш ясый. Нурислам дусларына әкият сөйли: бер бөкре егет урманга килгәч, пәриләр туена тап була. Алар сикерә-сикерә бииләр һәм «чәршәмбе, чәршәмбе» дип кычкыралар икән. Егет «бүген җомга», дип аларны төзәтергә теләгән, әмма бик тиз бу уеннан кире кайткан һәм пәриләргә кушылып, «чәршәмбе, чәршәмбе» дип кычкы-

[1] *Әхмәдуллин А.Г.* Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе: монография. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 159.

ра башлаган. Карт пәри егеттән, җомга була торып, чәршәмбе дип кычкыру сәбәбен сораган. *«Меңләгән пәри чәршәмбе дип кычкырганда, берүзем җомга дип әйтергә базмадым», – дигән егет. (...) Карт пәри егетнең аркасыннан сыпырган икән – бөкредән җилләр искән, төп-төз егеткә әйләнгән егет»*[1]. Моны ишетеп, күрше авылның бөкре егете дә урманга киткән һәм пәри туена эләккән. Пәриләрнең «чәршәмбе, чәршәмбе» дип кычкыруына каршы чыгып, *«Бүген чәршәмбе түгел, җомга»* дип, аларны төзәткән. Карт пәри егет янына килеп, меңләгән пәри коллективына каршы чыгу сәбәбен сораган. *«Дөресе шулай, бүген җомга бит,* – дигән егет. – *(...) Карт пәри егетнең аркасыннан сыпырган икән – егетнең бер бөкресе янына икенче бөкре үсеп чыккан. Карт пәри бу бөкре егеткә теге бөкре егетнең дә бөкресен өстәп куйган, ди»*[2].

Дуслар арасында ыгы-зыгы куба, берсе Нурисламны әдәпсезлектә гаепләргә тели, икенчесе бу әкият белән нәрсә әйтергә теләвен аңлатуны таләп итә башлый, өченчесе... Нәтиҗәдә алар үзара ачуланышып таралыша. Дусларның үзара аңлаша алмауларына бәйле туган каршылык артында һәрберсенең үз-үзен табуга, аңлауга, бәя бирүгә нигезләнгән эчке каршылыгы калкып чыга.

Әкият катнашучыларга көчле тәэсир итә, тынычлыкларын ала. Нурислам белән ялгызы калган Миләүшә әкиятнең үзләре турында булуын тиз аңлап ала. Ул үз тормышыннан, җырчы – иҗатчы буларак эш-гамәленнән канәгать булмаса да, моны үзгәртү өчен ни дә булса кылмавын әйтә. Нурислам белән икесе мөнәсәбәтендә дә йомшаклык күрсәтүен, шуның белән бәхетеннән баш тартуын аңлауга килә.

Әкият Рәфис белән Саҗидәнең дә тынычлыгын ала, әмма алар мәгънәсенә тиз генә төшенеп җитә алмый. Рәфис *«җәтмәгә эләккән балык сыман чәбәләнүен, капкынга эләккән җәнлек кебек»*[3] тыпырчынуын яшерми. *«Әкият сөйләгән булып,*

---

[1] *Миңнуллин Т.* Дуслар җыелган җирдә // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т.: пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 455.

[2] Шунда ук. – Б. 456.

[3] Шунда ук. – Б. 464.

*бездән көлде, безне мыскыл итте. Янәсе, безнең бәябез сукыр бер тиен»*[1], дип тузына, моның сәбәбе үзендә булуын аңларга теләмичә. Бераздан тәнкыйть утын Нурисламга күчереп карый, янәсе ясаган картинасы да әллә ни мактарлык түгел. Ә инде ни өчен мактавын үз иҗатына булган мөнәсәбәт белән аңлатырга тырыша: *«Күңелен кайтарасым килмәде. Иҗат бит. Шигырь яза идем, тәнкыйтьләп биздерделәр. Бизәрлек булгач, димәк, шагыйрь булмаганмын»*[2].

Фәһим белән Эльмира квартирында да ут сүнми, Нурислам әкияте йокыларын качыра. Иреннән аермалы буларак, Эльмира әкиятнең серенә шактый тиз төшенә. Нурислам картинасын да бит бары ул гына мактамый: *«Картинасының җаны юк. Яратып язмаганы сизелә. Ул аны үзе дә белә, ахры»*[3]. Фәһимне битарафлыкта, тынычланып, тукталып калуда, хәтта эшләргә теләмәүдә гаепли. Музыкада балет, опера, симфония кебек зур әйберләр язуны максат итәргә чакыра. Фәһимнең исә үз карашы. *«Халык кул чапмаячак. Аңа симфонияләр кирәкми, аңа җыр кирәк. Гап-гади җыр. Мәҗлесләрдә җырларлык*, – ди ул һәм, Нурислам әкиятенең асылына төшенеп җитмәгәнлеген аңлатып, дәвам итә. – *Меңләгән кеше чәршәмбе дип кычкырганда, ни өчен җомга дип кычкырырга»*[4]. Әмма Нурислам әкиятенең аңа көчле тәэсир итүе күренә. Икесенең дә халәтен Эльмира ачып бирә: *«Әгәр Нурислам әкиятен сөйләмәгән булса, без төн уртасында монда утырмас идек. Җыен юк-бар, анекдот сөйләп, яки кыяр тозларга өйрәнеп утырыр идек. Йә булмаса уйсыз-нисез мышный-мышный йоклар идек»*[5]. Аларның бәхәсе, киенеп, Нурисламга китү белән тәмамлана.

Әлеге төркемгә соңрак килеп кушылган Гайнулла белән Галиянең дә тынычлыгы югалган. Төп геройлар булмаса да, автор әлеге ике образ фикерләре аша үзенең күңелендәге бор-

---

[1] *Миңнуллин Т.* Дуслар җыелган җирдә // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т.: пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 466.

[2] Шунда ук.– Б. 466.

[3] Шунда ук. – Б. 469

[4] Шунда ук. – Б. 470.

[5] Шунда ук. – Б. 470.

чуларын ачык итеп укучы-тамашачыга җиткерә. Галиянең *«без һаман йокыда, уянырга вакыт»* дигәне XX йөз башындагы әдипләр (С. Рәмиевнең «Таң вакыты» программ әсәре) чакыруына авваздаш. Т. Миңнуллин татар җәмгыятенең генә түгел, ил тормышының торгынлыкта булуын ачык аңлап, «уянырга» һәм «үзгәрергә» чакыра. Һәрдаим «Их, дуслар!» дип беркатлыланып сөйләнеп йөргән Гайнулла булган хәлләргә һич тә битараф түгел. Ул үзе дә сизмәстән үткәне һәм бүгенгесе, эш-гамәле, яшәү рәвеше турында уйлана башлый һәм күңеле төбендәге хакыйкать бәреп чыга: *«Ни җырың юк, ни моңың юк, ди Фәһим. Җырым да бар, моңым да бар – тавышым үземнеке түгел...»*[1] «Үз тавышың булмау» – бу илдәге тынчу атмосфера, идеология йогынтысы чагылышы. Югарыдан кушканны һәм тиешне генә сөйләргә мәҗбүр ителү күпләрнең шәхес буларак үз йөзләрен югалтуга китерә дә инде.

Тынычлыкларын югалту аша эчке каршылыкларын җиңеп, Нурислам янына яңадан җыелгач та, җитди әңгәмә дәвам итә. Аларның җыелуы – үзе зур нәтиҗә, димәк, дуслар пошмас җанга әйләнеп бетмәгән, аларның күңел түрендә очкын бар әле. Хәзер инде Нурислам шикләнүләрен, борчуларын ачык итеп әйтә: *«Мин сөйләгән әкияттәге пәриләр – безнең күңелебезгә, йөрәгебезгә кереп оялаган үшәнлегебез, ялкаулыгыбыз, ваемсызлыгыбыз, битарафлыгыбыз, тәти булып күренергә тырышуыбыз. (...) Шуның чаклы күнегелгән, дөньяның, тормышның бүтәнчә булуын күз алдына да китермибез»* [2]. Шул рәвешле, драматург совет системасының кешене бер төрле уйларга, эшгамәл кылырга мәҗбүр итүен, рухи богауда тотуын тәнкыйтьли. Укучы-тамашачыны шәхес ирегенә омтылып, мөстәкыйль фикерле булып яшәргә чакыра.

Тагын шунысы игътибарга лаек, «Миләүшәнең туган көне» драмасында Миләүшәнең элекке ире Шәһит аларны *«вак кешеләр»* дип атый. Әллә ул хаклы булганмы соң? Шәһитне яраклашуда, чынбарлыктан читләшүдә гаепләгән дуслар үзләре шул

---

[1] *Миңнуллин Т.* Дуслар җыелган җирдә // *Миңнуллин Т*. Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 475.

[2] Шунда ук. – Б. 485.

хәлдә калган икән бит. Дуслар күңелендә үзгәреш башланса да, ул җитди эш-гамәлләргә, үзең һәм башкалар өчен җаваплылык тоеп яшәүгә үсеп җитәрме? Моңа ачык кына җавап бирү әлегә мөмкин түгел. Шуңа да Нурислам куйган сораулар әсәр геройлары өчен дә, укучы-тамашачы өчен дә актуаль булып кала.

Т. Миңнуллин уңышлы детальләр, ачкыч-сүзләр ярдәмендә эчтәлекнең мәгънәсен тагы да тирәнәйтә. Пьеса геройлары, картинаны ошатмасалар да, мактыйлар, бер-берсенә һәм Нурисламга яраклашалар. Нурислам ваткан ваза дуслыкның җимерелүен аңлата: дуслар «пәриләргә ярау өчен ялган сөйләүче егетнең нәкъ менә үзләре булуларын бик яхшы аңлыйлар. (...) Тик хакыйкатьне үз эчләрендә йомып, белмәмешкә салышып, көлә-шаяра яши биргәннәр»[1]. Шул рәвешле, автор совет җәмгыятенә бәя бирә һәм ялганга, алдашуга яраклашкан кешеләрнең битлеген ача.

Т. Миңнуллин, фикер-карашларын укучы-тамашачыга үтемлерәк җиткерү максатында, яңа формалар, алымнар эзли. Эстетик төшенчә буларак «уен»нан әдәби алым һәм сурәтләү предметы буларак файдалану аның бер чагылышы булып тора. Й. Нигъмәтуллина билгеләгән әлеге үзенчәлек драматургның «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә», «Хушыгыз» драмаларыннан торган трилогиясен аңлау-бәйләүдә нигез, хәтта ачкыч булып тора[2]. Сәнгать кешеләре тормышын чагылдырган әлеге трилогия – җәмгыятьтәге иҗтимагый һәм социаль шартлар йогынтысында кешеләр, хәтта якын дуслар арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзгәрүе, әхлакый кыйммәтләрнең җимерелә баруы турында. Әлеге пьесалар сәнгать кешеләре тормышын чор тудырган вакыйгалар аша сурәтләп, характер сыйфатлары белән аерылып торган геройлары һәм финалда да җитди бәхәскә китерүләре белән игътибарга лаек. Бер-береннән шикләнү, курку, ваемсыз яшәү, әйләнә-тирәдәгеләргә битараф-

[1] *Яхин А.* Әдәбият дәресләре: Укытучылар, югары уку йортлары студентлары һәм укытучылар өчен методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 77.

[2] *Нигматуллина Ю*. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. – Казань: Фэн, 2002. – С. 153.

лык, үзара мөнәсәбәтләрнең ялганга корылуы һәм боларның «Дуслар җыелган җирдә» драмасында пәриләр турындагы әкият аша үтемле, тәэсирле итеп ачылуы совет җәмгыяте турындагы мифны җимерүгә һәм яшәеш хакыйкатен ачкан яңа миф тудыруга хезмәт итә.

## 1.4. Драматургның яңа жанр формалары өлкәсендәге эзләнүләре

Т. Миңнуллин үз чоры сәхнә әдәбиятын жанр формалары белән баетып, аларның эчке хасиятләрен ачуга, төрләндерүгә җитди өлеш кертә.

Ул драма һәм комедия жанрларында бердәй тигез эшли. Арада комедия жанрының шаян комедия («Бәхетле кияү», 1967), җитди комедия («Нигез ташлары», 1968), лирик комедия («Яшьлегем-юләрлегем», 1978), водевиль («Диләфрүзгә дүрт кияү» (1972), моңсу комедия («Әлдермештән Әлмәндәр», 1976); сатирик комедия («Бәйләнчек», 1982); драма жанрының интеллектуаль драма («Миләүшәнең туган көне», 1968; «Дуслар җыелган җирдә», 1978), тарихи драма («Канкай углы Бәхтияр», 1975), социаль драма («Әниләр һәм бәбиләр», 1981), фәлсәфи-публицистик драма («Моңлы бер җыр», 1981) кебек жанр формалары бар. Драматург өчен әсәрнең эчтәлегенә салынган төп фикерне ачык, мәгънәле, тамашачыга тәэсирле итеп җиткерү юлларын табу мөһим, жанрлык хасиятләре шул максаттан урынлы файдаланыла. Шуңа нисбәтле аның аеруча «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Дуслар җыелган җирдә», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Ай булмаса, йолдыз бар» пьесалары аерым жанр чикләрен үтеп чыгулары, бертөрле генә бәяләнмәүләре, төрлечә укылышка урын калдырулары белән җәмәгатьчелектә киң яңгыраш ала.

Яшьләрнең кавышып гаилә кору мәсьәләсе әдәбиятта, бигрәк тә драматургиядә иң еш очрый торган темалардан булып, көнкүреш пьесаларын иңләп үтә. Бу теманың әһәмиятен яхшы аңлап, авторлар төрле планда, төрле проблеманы калкытып, кискенләштереп куярга омтыла. К. Тинчурин «Назлы кияү» (1915) комедиясендә надан, әдәпсез, булдыксыз Рәшитне көлү объекты итеп ала һәм егетнең, әйләнә-тирәсендәге якыннарының

мәгънәсез эш-гамәлләрен ачып, ахырда егетне үзенең асравына өйләндереп, аннан ачы итеп көлә. Бу темага гасыр уртасында Ш. Хөсәенов мөрәҗәгать итә һәм «Профессор кияве» (1952) комедиясендә тормышка үтеп кергән мещанлык, ярату-бәхет төшенчәләрен акча-байлык белән бәйләп карау кебек мәсьәләләрне калкытып куя. Соңрак Х. Вахитның «Кияүләр» комедиясе бу теманың яңа якларын җиңел юмор аша ача.

Т. Миңнуллин сәхнә әдәбиятына килгән елларда ук «Бәхетле кияү» комедиясен язып, бу мәсьәләне җиңел юмор аша чагылдыра. Аның инде кабаттан әлеге темага алынуы берничә сәбәп белән аңлатыла: бердән, автор сәхнә әдәбиятындагы бертөрлелектән котылу, тема-мотив төрлелегенә ирешү максатында тормыш-чынбарлык күренешенә мөрәҗәгать итә; икенчедән, драматургиягә Х. Вахит алып килгән яшьлек, мәхәббәт темасын җыр-музыка белән баетылган, лиризмга нигезләнгән әсәр белән дәвам итә.

Әдипнең «Диләфрүзгә дүрт кияү» (1972) водевиле уенкөлкегә, үзенчәлекле интрига һәм җыр-музыкага нигезләнүе, мәхәббәт-яратышу темасын шаянлык аша ачуы, үзенчәлекле образлары һәм тирән оптимизмы белән игътибарны җәлеп итә. «Диләфрүзгә дүрт кияү»нең язылу тарихын автор болай искә ала: *«...Мин шактый пьесалар яздым бугай инде, әмма иң рәхәт язылганы әлеге комедия булды. Чөнки аны миңа әти белән әни язышты, аларның миңа, бер-берсенә карата булган кайгыртучан мөнәсәбәте яздырды»*[1]. Әсәр сюжетына салынган вакыйгада дүрт егетнең чибәр Диләфрүзнең мәхәббәтен яулап алу өчен тартышуы үзәктә тора. Автор үзенчәлекле башлам тәкъдим итә – әсәрдә катнашучы Сәҗидә белән Амур тамашачыларны геройлар һәм булачак вакыйгалар белән таныштыра, тамашачы белән сәхнәдә барган вакыйгалар арасында арадашчы ролен дә үти.

Сурәтләнгән вакыйга шактый таныш: авыл кызы Диләфрүзнең күңелен яулап алу өчен дүрт егетнең тартышуы. Бер кыз артыннан берничә егетнең йөрүе табигый хәл. Шуның өстенә моннан ике ай элек «Азат хатын» журналында Диләфрүз рәсемен

---

[1] *Миңнуллин Т.* Диләфрүзгә дүрт кияү // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 8 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 65.

бастырып чыгарганнар һәм шуннан соң *«Диләфрүзгә көн саен 40–50 егетләр хаты килеп тора»*[1] икән. Диләфрүз үзе сәхнәдә күренгәнче үк Амур белән Саҗидә аңа мондый характеристика бирә: *«Чеп-чибәр, чап-чая кыз. (...) Өстәвенә эшкә уңган. Эшләмәгән эше юк. Читтән торып институтта да укый»*[2]. Алга таба аның шактый тапкыр, үткен булуы, матур җырлавы да күренә. Дөрес, кыз тулы канлы үзенчәлекле образ булып ачылмый. Автор өчен кияүләрнең кем һәм нинди булуын күрсәтү мөһимрәк. Автор тормышчан күренешләрдә авыл егетләре турында мәгълүмат биреп, аларның төрле типларын сәхнәгә чыгара.

Кияүлеккә беренче кандидат Галимне Саҗидә болай бәяли: *«Укымышлы егет. Менә унбиш ел инде читтән торып укый. Башка нинди егетлек эшләгәндер, анысын авыл халкы хәтерләми»*[3]. Әлеге бәядә мактаудан бигрәк юмор белән көлү, төрттерү сизелеп тора. Кырык яшен узып та өйләнмәгән егетнең физик хезмәттән читләшүче, үзен күбрәк яратучы эгоист булуы ачыла. Укымышлы күренергә теләве дә «сез» дип мөрәҗәгать итүгә һәм мәкальләр кушып сөйләшүгә генә кайтып кала. Гаилә коруга да аның үз фәлсәфәсе бар: *«Әгәр бер егет өйләнергә тели икән, өйләнәсе кешесе интеллектуаль яктан үзенә тиң булырга тиеш. Чөнки өйләнгәч, мәхәббәт төшенчәсе үзенең баштагы асылын югалта. Акыл гына кала»*[4].

Кияүлеккә икенче кандидат булган Шәкүр турында Амур болай ди: *«Ике потлы герне ике кулы белән ике тапкыр күтәрә ала. Сабый чагында тәрәзә ваткан өчен хулиган исемен алган булган. Хәзер шул исемне аклар өчен җай эзләп йөри»*[5]. Әлеге бәядә юмор белән шактый усал итеп төрттерү, геройның мин-минлек, мактану сыйфатын аерып чыгару чагыла. Саҗидә *«батыр куян»* дип атаган егет башкалар белән аралашканда да шактый беркатлы булып ачыла. Диләфрүзгә мәхәббәт аңлатуы

---

[1] *Миңнуллин Т.* Диләфрүзгә дүрт кияү // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 8 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 63.

[2] Шунда ук. – Б. 62.

[3] Шунда ук. – Б. 62.

[4] Шунда ук. – Б. 70.

[5] Шунда ук. – Б. 62.

да хисләрен күрсәтүдән бигрәк, үзен әллә кемгә куеп сөйләшүгә кайтып кала: *«Күктә кояш, җирдә – мин. Diләфрүз, йә сез мине бәхетле итәсез, йә ... (...) мине шушы агач ботагында асылып торачак баудан эзләсеннәр»*[1]. Вакыйгаларда ул үзгәрешсез кала, шуңа да мондый егетне Диләфрүзнең ярата алуы бик тә бәхәсле.

Ә менә Җәмилне Саҗидә: *«Серле егет. Шушы яшенә җитеп бер кызга да яратам дип әйтмәгән. Шулай да без аны киявлеккә өченче кандидат итеп сайладык. Егет кеше – түзмәс, йөрәк серләрен бер чишәр, дип уйладык»*[2], – дип тәкъдим итә. Чыннан да ул башкалардан тыйнаклыгы, хис-кичерешләрен ачып күрсәтмәве белән дә аерылып тора. Романтик табигатьле Җәмил барысын да бик тирән уйлый, китаплардан үзе укып белгән «ярату»га омтыла. Диләфрүзне яратып йөрсә дә бу турыда кызга ачык итеп әйтергә уңайсызлана. *«Сереңне әйтерсең берәүгә, синең сереңнән ул көләр»,* – ди ул монологында, әлеге сөю-ярату хисеннән арына алмыйча.

Диләфрүзгә яратуын белдергән дүртенче егет – күрше авылдан Исмәгыйль. Амур сүзләре белән әйткәндә, *«Бәхетсез егет, әллә ничә кат өйләнергә җыенган, тик өйләнәсе кызлары ямьсез булу аркасында өйләнә алмый калган»*[3]. Бик еш мәхәббәтен аңлатучы егет күңелендә саф хисләргә урын юк, дияргә була. Әнә ул үзе дә сизмәстән элегрәк йөргән кызларының исемнәрен саный башлый: Зөлхәбирә, Гадилә, Хәлимә ... Үз сөйләме белән үзенә бәя бирүче егетнең эш-гамәлләрен укучы-тамашачы да елмаеп-көлеп кабул итә. Шул рәвешле егетләр авыл кызлары һәм укучы-тамашачы каршында сынау үтә, нәтиҗәдә Диләфрүз Җәмилгә беренче булып яратуын әйтә.

Пьесаның водевиль булуы аның бөтен төзелешенә йогынты ясый. Ул җыр-музыкага, уен-көлкегә бай. Геройлар да еш кына хисләрен җыр аша аңлата. Җырларның күп булуы пьесадагы лиризмны арттыра, геройларның рухи дөньясын ача.

---

[1] *Миңнуллин Т.* Диләфрүзгә дүрт кияү // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 8 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 69.

[2] Шунда ук. – Б. 62.

[3] Шунда ук. – Б. 63.

Автор исә әсәр теленә, геройлар сөйләменә зур игътибар бирә. Нәкъ менә сөйләмдә шәхси сыйфатлары ачыла. Аларның теге яисә бу мәсьәләгә, бигрәк тә мәхәббәт аңлатуга бәйле карашларын тагын да үстерү, көчәйтү максатында әдәбиятта классик буларак билгеле авторларның укучыларга яхшы таныш булган гыйбарәләре, афоризмнары кушылып китә. Аерым алганда, дөнья классикасыннан Шекспирның Офелия белән Джульеттасы һәм Дездемона белән Отеллосы, Робинзон Крузо белән Борис Годунов исеме, Тарас Бульба сүзләре, татар әдәбиятыннан М. Фәйзинең Исмәгыйле, «Сак-Сок бәете»ннән өзек урын ала. Интертекстуальлек пьесадагы вакыйганы, геройларны кабул итүне җиңеләйтә, аларны билгеле геройлар белән чагыштырып, я кискен каршы кую, я хис-кичереш чагылышын арттыру мөмкинлеге бирә. Автор тарафыннан бирелгән үткен диалогларда татар теле бөтен байлыгында ачылып, халыкчан юмор, уен-көлке белән кушылып, гомумән, карнаваллыкны тагын да үстерүгә, эмоциональлекне арттыруга хезмәт итә. Шуның бер чагылышы буларак, түбәндәге диалогны мисал итеп китерәбез:

*«Исмәгыйль. Эзләп тапсам ни була?*

*Диләфрүз. Ике яңагыгыз ут булыр.*

*Исмәгыйль. И җаный, вай җаный, сезнең әтиегезнең кызы бигрәк усал икән. Бу рәшәткә ни өчен?*

*Диләфрүз. Бакчабызга алмагачлар, кәҗә кермәсен өчен»*[1].

Гомумән, болар барысы да вакыйгаларның җанлы, динамик булуына, көтелмәгән үзгәрешләр аша тиз алышынып торуына һәм нәтиҗәдә укучы-тамашачы тарафыннан яратып кабул итүенә китерә.

* * *

Т. Миңнуллин сәхнә әдәбиятының барлык жанрларында уңышлы иҗат итсә дә, ул аеруча яратып драма жанрына, аның күптөрле формаларына мөрәҗәгать итә. Әлеге жанр авторга тормыш каршылыкларын тулы һәм үз асылында чагылдыруда киң мөмкинлекләр ача. Ә инде катлаулы вакыйгаларда хәрәкәт

---

[1] *Миңнуллин Т.* Диләфрүзгә дүрт кияү // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 8 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 67.

итүче геройларның күңел халәтен ачуда әдип психологизм алымнарына нигезләнә, хис-кичерешләрен укучы-тамашачыга җиткерүнең яңадан-яңа юлларын, алым-формаларын таба. Әдипнең социаль-психологик пьеса жанрына мөрәҗәгать итүе шуның бер чагылышы булып тора. Мондый әсәрләрдә көнкүреш вакыйгасы сурәтләнеп, аның артында фәлсәфи һәм әхлакый фикер калкып чыга. Гадәти сюжет сызыгына бәйле җитди мәсьәләләр куела. Т. Миңнуллин яшәешкә үтеп кергән икейөзлелек, куштанлык, ялган, тупаслыкның артуына һәм шул ук вакытта үзара ышаныч, ярдәмләшү кебек сыйфатларның югала баруына борчыла.

«Үзебез сайлаган язмыш» (1973) драмасы мәгариф-мәктәп тормышына багышланып, бу өлкәдә яшәп килүче күзбуяучылык, формализм күренешләрен киң җәмәгатьчелеккә чыгаруы белән игътибарга лаек. Укыту-тәрбия эшен оештыруга бәйле каршылык яшь директор Илгиз Туктаров һәм өлкән яшьтәге завуч Мөнирә Шакировна эш-гамәлләренә бәйле оеша. Әкренләп аңа бөтен коллектив тартыла. Вакыйгалар үзәгендәге Илгиз Туктаровның, өченче ел гына мәктәп директоры булып эшләвенә карамастан, район мәгариф бүлегендә авторитеты бар. Әмма ул белем-тәрбиянең сыйфаты түбән булуны яхшы белә. Мәктәпне медаль белән тәмамлаган укучыдан килгән хат аның бөтен тынычлыгын алган. Менә аның эчтәлеге: *«Туктаров абый, миңа биргән аттестатыгызны үзегезгә җибәрәм. Миңа аның кирәге юк. Чөнки ул ялган аттестат. Мин ул аттестатка ышанып институтка кермәкче идем. Хыялым инженер булу иде. Бер генә имтихан тапшырып, җиңел генә үтмәкче идем. Алтын медалле укучы бит. Ләкин беренче имтиханда ук икеле алдым. Мин берни дә белмим икән. Нигә сез берни дә белмәгән надан укучыга еллар буе бишле куеп килдегез? Нигә сез мине алдадыгыз? Алыгыз аттестатыгызны, миңа ул кәгазь кирәкми. Медальне бирмим, алдануымның истәлеге булып калсын. Мин инде эшкә урнаштым. Анда аттестат кирәкми. Мактаулы укучыгыз Хәлил Саттаров»*[1]. Үз эшеннән, коллектив эшчән-

[1] *Миңнуллин Т.* Үзебез сайлаган язмыш // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 270.

легеннән канәгать булмаган яшь директорга әлеге хат көчле этәргеч була. Ул мәктәптәге формализмга, макталу өчен сан артыннан кууга, кайбер укытучыларның ялган авторитетына каршы көрәш башлый. Әмма әлегәчә булган белән канәгатьләнеп яшәргә күнеккән укытучыларны кузгату җиңелдән түгел. Аларның бер өлеше аны аңламый һәм аңларга да теләми. Арада Нариман кебек тәҗрибәле, чын мәгънәсендә үз эшенең остасы да бар. Ә инде завуч Мөнирә турыдан-туры каршы чыга. Аның: *«Нишләвегез бу, Илгиз Кәримович? Нигә кирәк? Яхшы гына эшләп килгәндә нигә сез? Нигә ул хатны тартып чыгарырга иде. Коллектив алдында, хәзер беләсезме ни буласын мәктәпкә? Тыныч кына эшләп ятканда...»*[1] – дигән сүзләрендә коллектив өчен борчылудан бигрәк, үз мәнфәгатен кайгыртуы ачык сизелә.

Булган белән канәгатьләнеп, барысын да ничек бар шулай калдырырга теләүчеләр уку-укыту эшләре мөдире Мөнирә тирәсенә туплана. Ул үзен аңа баш иеп яшәүчеләр белән чолгап алган, кирәк вакытта, билгеле инде, аларга «ташламалар» да ясый, ягъни эленке-салынкы дәрес бирүләренә күз йома. Драмада Мөнирәнең укучылар арасында авторитетны ялган яисә яхшы билге кую аша яулап алырга омтылуы ачык чагыла. Автор бу героинясына да битараф түгел, аның бу кадәр түбән төшүенең сәбәпләрен ачарга омтыла. Мөнирәнең күңеле яралы – ул гаилә кора алмаган, ялгыз яши. Яшь вакытта үзен яратып йөргән егеткә, гади колхозчы миңа тиң түгел дип, кияүгә чыкмаган. Ялгызлык, үкенү, кеше бәхетенә көнләшеп карау аның характерындагы тискәре сыйфатларның өстенлек алуына китергән.

Шулай да яшь директор ялгыз түгел, ул яшь укытучыларга таянып, инде акны карадан аера белүче укучыларның ышанычын тоеп эш итә. Бу мәсьәләдә аеруча Нурия катылык, ныклык күрсәтә. Кайбер укытучыларның үзенә кырын караячагын белсә дә, ул үзгәрешләрнең котылгысызлыгын яклап чыга. Укучы хаты белән танышуга ук үз фикерен ачыктан-ачык белдерә: *«Ниһаять!.. Рәхмәт Хәлил Саттаровка... Югыйсә мактанышабыз да, мактанышабыз. Без – алдынгы! Без – беренче!*

[1] *Миңнуллин Т.* Үзебез сайлаган язмыш // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 272.

*Күрдегезме инде. (...) Узынам, Мөнирә Шакировна. Ниһаять, дөреслеккә юл ачылды. Безнең чын йөзебезне ачтылар. Без җинаять эшләп ятабыз икән»*[1]. Билгеле, яшь укытучының бу сүзләрендә ашыгу да, беркадәр дуамаллык та бар. Әмма ул ихлас, киләчәккә карап яши, шуңа да авторның бу героен яратып һәм аңлап иҗат итүе күренеп тора.

Автор Туктаровның эчке каршылыгын уңышлы ача. Яшь директор тәҗрибәсезлеге, ара-тирә кызып китүе белән коллективның бер өлешен үзенә каршы куя, аларның эшчәнлеген тиешле юнәлештә үстереп җибәрә алмый. Шулай да үзен туры сүзле, намуслы, сүзендә нык торучы, принципиаль, зур ихтыяр көченә ия булган яхшы тәрбияче итеп күрсәтә. *«Бөтен көч, бөтен ихтыяр, бөтен вакыт, гомеребез, иманыбыз балаларга багышланган булырга тиеш. (...) Әгәр кем дә кем шулай укытырга сәләтсез икән, мәктәпкә якын килмәсен! Монда сезгә дә, миңа да ташлама юк. Үзебез сайлаган язмыш, түзәргә туры килә»*[2], – ди ул үзгәрешләрне кабул итәргә телмәгән мәктәп завучы Мөнирәгә.

Вакыйгалар барышында укытучыларның күпчелеге директорны яклап чыга. Баштарак каршы килеп, бары элекке укучылары, үткән хатирәләр белән генә яшәргә җыенган Нариман да директорның хаклы булуын аңлауга килә. Моңа кадәр һәрнәрсәгә битараф булып, үз дөньясы белән генә яшәгән, йомыкый, миңа ничек тә ярый дип йөрүче Фасилда да үзгәреш башланып, аның битарафлык сазлыгыннан чыгуын аңлата.

Илгиз Туктаров мәктәптән китәргә мәҗбүр булса да, рухи җиңү аның ягында. Укытучыларның һәм укучыларның аны озатырга килүе шуны күрсәтә. Драма «намуслы хезмәт, үз эшеңә, профессиягә бирелгәнлек белән генә укытучы дигән олы исемгә лаек булырга мөмкин»[3] дигән идеяне раславы белән әһәмиятле.

---

[1] *Миңнуллин Т.* Үзебез сайлаган язмыш // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 271.

[2] Шунда ук. – Б. 293–294.

[3] *Заһидуллина Д.Ф.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. 2 т.: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – Б. 178.

Автор укытучы хезмәтенең кайбер якларын ачып, бу мәсьәләгә киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә. Пьеса үзенең психологизмы, үзенчәлекле геройлары, конфликтның тормышчанлыгы, эзлекле үстерелеше белән киң яңгыраш ала.

* * *

Т. Миңнуллин социаль-иҗтимагый яңгырашлы «Әниләр һәм бәбиләр» (1982) драмасында бала тудыру йортындагы вакыйгаларны сурәтли. Монда дөньяга яңа кеше туа, башка бер җирдә дә булмаганча, һәр ананың эчке дөньясы, әхлакый йөзе бөтен тулылыгы белән ачыла.

Әлеге пьесаны язуга килү тарихын Т. Миңнуллин «Әниләр һәм бәбиләр» язмасында ача. Драматургның гел хатын-кызлардан гына торган пьеса язарга теләге булып, байтак вакыт моңа ирешә алмый йөри. Ниһаять, ул бала табу йортындагы вакыйгаларны сурәтләүгә килә. *«...бер палатада ятучы дүрт ана минем фантазиямдә танышып-сөйләшеп киттеләр дә... башланды галәмәт. Үзем өчен дә бик күп яңалыклар ачылды. Аналарга бишек җырын җырлатмакчы идем – белмим икән; хатын-кызлардан сораштырдым – алар да белми; китаплардан эзләдем – композиторлар, шагыйрьләр язган бар, халыкныкы юк. Шунда әсәрнең төп идеясе туды. Әгәр дә без бишек җырларын онытып барабыз икән, балаларыбызга ни өйрәтербез соң? Аларны моннан мәхрүм итмибезме? Һәм ул вакыты-вакыты белән фаҗигаларга илтмиме? Каты күңелле хатын-кызлардан рухи гарипләр туып, ул балалар рәхимсез, миһербансыз булып үсмиләрме? "Әгәр"ләр күбәйсә, кешелек җәмгыяте нишләр? Шундый күп сорауларга җавап эзләргә тырыштым мин бу драмада»*[1].

Палатадагы дүрт хатын-кызны ана булу берләштерсә дә, алар характерлары белән гаять төрле. Нәкъ менә ана вазифасын үтәүгә бәйле беренче күренештә үк кискен каршылык туа – Дилемма исемле 20 яшьлек хатын баласын ашатмый, хәтта баш тарта. Катнашучыларны гына түгел, укучы-тамашачыны

[1] *Миңнуллин Т.* «Әниләр һәм бәбиләр» // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 8 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 67–68.

да сискәндереп җибәргән бу хәл геройларны каршы якларга гына аерып калмыйча, һәрберсенең күңел дөньясын, дөньяга карашын, кешелек сыйфатларын ачуга да китерә. Алгы планда уникенче баласын тапкан татар хатыны Гөлфинә тора. Ул бөтен барлыгы белән татарга хас милли сыйфатларны үзенә туплаган, гаять ачык, гади-гадәти, ярдәмчел, вакыты белән беркатлы, әмма гаҗәеп тормышчан, үзе өчен яшәеш фәлсәфәсен үзләштергән Ана. Шактый күпне күргән, күпне кичергән хатын үзенең оптимизмы, яшәү дәрте, тынгысыз булуы белән башкалардан аерылып тора. Характеры, иң матур сыйфатлары белән ул әлеге хатыннарга тартыла, һәрберсенә әйтер сүзен таба, юата, киңәш бирә, тәҗрибәле ил анасы булып ачыла. Татар драматургиясендәге ана образларын үстерә барып, Гөлфинә милли образ, олы характер буларак калка. Ул халык акылын, тәҗрибәсен җыйган, горур табигатьле, үз-үзенә ышанган, иренә тугры хатын, балаларына изге ана булып ачыла. Шунысы игътибарга лаек, палатадагы өч хатын-кыз ирләр, алар белән мөнәсәбәтләрне кору турында даими сөйләшә, фикер алыша, кайвакыт бәхәсләшеп тә китәләр. Гаилә ныклыгының нигезе нәрсәдә? Әлеге мәңгелек сорау һәркемне борчый, уйландыра. Халык арасында таралган «Ир – баш, хатын – муен» гыйбарәсен кемдер таный, кемдер кабул итми бит. Гөлфинә бу мәсьәләдә тулы җаваплылыкны хатын-кызга йөкли. Аныңча, гаиләдә ир һәм хатын мөнәсәбәте дә, балаларның кем һәм нинди булып үсүе дә, «кем баш һәм кем муен» мәсьәләсен хәл итү дә хатын-кыздан, аның акылыннан, тапкырлыгыннан, оста психолог булуыннан, кешеләрне яратуыннан килә. *«...ирләр алар сабый бала белән бер. Без яхшы булсак, алар яхшы, без начар булсак, алар начар. Дөньяның тоткасы – хатын-кызда. Патшалар да хатын-кыз сүзеннән чыкмаган. Хатыны әйткән икән мондый закон чыгар дип, икенче көнне үк патша шундый закон чыгарган. Без, дип ирләр түш кенә киереп йөри, эшләүчеләре без аның»*[1], – ди ул хатын-кызның гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге урынын яхшы аңлап. Р. Зәйдулла язганча, «Гөлфинә (...) кебек самими, садә

[1] *Миңнуллин Т.* Әниләр һәм бәбиләр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 387.

җаннар бөтенебезгә дә кирәк икән! Күңелеңнең тузаннарын кагар өчен, дөньядагы матурлыкны аңлар өчен кирәк ул Гөлфинә кебек фидакяр хатыннар!...»[1]

Палатадагы башка хатыннар да үз йөзе белән ачыла. Рус хатыны Валентина җиде ел буе бала таба алмаган. Шуңа да ул бүген бәхет диңгезендә йөзә. Шатлык хисләрен җыеп бетерә алмыйча, әлеге хатын аларны һәркем белән уртаклаша, аның шатлыгы башкалар күңеленә дә үтеп керә. Ирен, туганнарын бөтен барлыгы белән яратучы хатынның олы йөрәге гаделсезлекне, түбәнлекне кабул итми. Валентина ярдәмчел Гөлфинәгә тартыла, ә миһербансыз Дилемманы кабул итми, вакыты белән аны кыйнап ташларга да әзер ул.

Драматургның Алтынчәче дә гыйбрәтле образ булып хәтердә кала. Әлеге казакъ кызы үзен ямьсез дип саный, сәбәбе исә әлегәчә егетләр карамауда. Шуңа да ул үзенә ошаган кешедән язылышмыйча гына бала таба. Һәртөр гайбәттән качу өчен башка шәһәргә күчеп китеп, әнисенең ачуына дучар булса да, бу хатынны гаепләргә беркемнең дә авызы ачылмас. *«Мин – ана, минем балам бар. Миннән соң дә минем каным аңарда калачак, җанымның бер өлеше аңарда булачак. Минем балам минем күкрәк сөтемне имгәндә миннән дә бәхетле кем бар дөньяда!»[2]* – ди ул үзенең җирдәге төп бурыч-вазифасын аңлатып. Табигать дөньясына якын булуы, халык җырларын, шул исәптән бишек җырын белүе, саф һәм чиста күңеле белән үзенә тарта Алтынчәч.

Драмада аеруча мөһим урынны Дилемма алып тора. Яңа туган сабыеннан баш тартучы бу бәндә кайда һәм ничек үскән? Мондыйлар җәмгыятьтә каян килә? Әлеге һәм башка шундый сорауларга әсәр дәвамында җавап эзләнә. Яшь кенә булса да, аның инде дөньяга карашы формалашкан, ул үзе өчен, бары үз рәхәте өчен генә яшәүче. Баланы калдырган өчен җаваплылык

[1] *Зәйдулла Р.* «Әниләр һәм бәбиләр» // Туфан Миңнуллин: фәннипублицистик, документаль-биографик җыентык / төз. Г. Рәхим. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 584.

[2] *Миңнуллин Т.* Әниләр һәм бәбиләр // *Миңнуллин* Т. Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 371.

булу турында сүз чыккач, үз аргументын да әйтә: *«без җинаять эшләмибез. Аборт ясатып үтергәнгә хөкем итмиләр, ә моның өчен нигә хөкем итәргә тиешләр? Ни аермасы бар?»*[1] Халыкның һәртөр әхлакый кыйммәтләрен кире кагучы әлеге хатын белән әңгәмәсендә врач Айзарә Әхәтовна нинди генә мисаллар, гыйбрәтле очраклар китерсә дә, теләгенә ирешә алмый. Түбәндәге диалог шуны күрсәтә:

*«Айзарә. Иманыгыз бармы сезнең?*

*Дилемма. Мин ул сүзне аңламыйм.*

*Айзарә. Бишек җыры беләсезме сез?*

*Дилемма. Безгә аны өйрәтмәделәр.*

*Айзарә. Сез бит ана!*

*Дилемма. Мин хатын-кыз гына. Ул миңа корсакта чакта ук ят иде.*

*Айзарә. Кеше исемен йөртәсез бит сез!*

*Дилемма. (...) Сез тормышны үзегезчә күрәсез, мин – үземчә. Мин бит, нигә минемчә уйламыйсыз, дип бәйләнмим, нигә сез үз рецептыгыз белән миңа бәйләнәсез?»*[2]

Һәртөр җаваплылыктан качып, «ничек телим, шулай яшим» дигән куркыныч фәлсәфәгә таянган бу хатынның әти-әнисе кем соң? Вакыйгалар барышында автор безне Дилемманың каенанасы һәм үз әнисе белән очраштыра. Иренең әнисе Вазифа шактый сәер яктан ачыла. Ул барысына да улының йомшаклыгы, хатын сүзеннән чыга алмавы гаепле дип саный. Чит кеше дип тормыйча, врачка үз иренең булдыксызлыгын әйтеп, аны төрлечә хурлый,түбәнсетә. Ә инде Дилемманың әнисе Римма йөзендә без йола-гадәт, әдәп-әхлак дигән төшенчәләрне белмәүче, бала тәрбияләүне ашатып-эчертүгә генә кайтарып калдыручы хатын белән очрашабыз. Беренче сүзләреннән үк кем икәнен белеп алган Баш врач аның белән озак сөйләшеп тормый, куалап чыгара. Хәтта баланы алырга теләсә дә, аңа бирмәячәкләрен ачык итеп әйтә: *«Кешеләр арасына бер имгәк үстереп җибәргәнегез дә бик җиткән (Римма елый башла-*

[1] *Миңнуллин Т.* Әниләр һәм бәбиләр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 373.

[2] Шунда ук. – Б. 374.

*гач.) Кыланмагыз, гражданка. Чынлап елаган аналарның күз яшьләрен пычратмагыз. Сугыш вакытында Ил, Ватан өчен башларын салган балалары өчен елаган аналар рухын рәнҗетмәгез»*[1]. Әлеге ике ана белән очрашу, аларның тәрбия ысулы, дөньяга карашы белән танышу да яңадан-яңа сораулар тудыра. Билгеле инде, драматург бу мәсьәләне махсус бөтен кискенлегендә куя, шуның белән укучы-тамашачыны да битарафлыктан чыгарып, уйланырга этәрә. Драманың язылу тарихына бәйле Т. Миңнуллин истәлеге дә шул хакта: *«Бу очракта мине язарга мәҗбүр иткән нәрсә күптәнге тема: аналар һәм балалар мәсьәләсе иде. Дөресрәге аналарның балаларына мөнәсәбәте. Без бүгенге көндә бала тәрбияләүне мәктәп эше, милиция (хәзер – полиция. – Ә.З.) эше дип санарга өйрәнеп барабыз. Ә бит күптәнге хакыйкать – бала киләчәктә яшәр өчен төп юнәлешне гаиләдә алырга тиеш, әхлак нормаларын ата-анасының күзәтүе астында үзләштерә башларга тиеш. Әгәр бала иң бәләкәй чагыннан ук гаиләнең әхлак нормаларын үзләштермәсә, аны мәктәп тә, милиция дә төзәтә алмый»*[2].

Шул рәвешле, берәүләр, уникенче баласын тапкан Гөлфинә шикелле, үзләренең тормышчанлыгы, табигыйлеге, башкаларга һәм үз балаларына мөнәсәбәте белән Изге Ана образына кадәр күтәрелсә, икенчеләр, беренче баласыннан баш тартучы Дилемма кебекләр, ниндидер зур югалту, түбәнлек хисләре уята. Табигать хатын-кызга бала табып үзенең нәселен дәвам итү кебек изге бурыч-вазифа йөкләгән. Драматург, Дилемма кебек үзен табигать законнарына каршы куючыларның арта баруы өчен борчылып, аны кешелек җәмгыятенең әхлакый бөтенлеген югалтуына тиңли. Бала атасыннан килгән телеграммадан күренгәнчә, сабый язмышына ул да битараф бит. Вакыйгалар барышында әлеге җан өшеткеч күренешнең сәбәпләре ачыклана: халыкның гасырлар дәвамында буыннан-буынга күчеп килгән традицияләре, гореф-гадәтләре, милли үзенчәлекләре югала

[1] *Миңнуллин Т.* Әниләр һәм бәбиләр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 397.

[2] *Миңнуллин Т.* «Әниләр һәм бәбиләр» // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 8 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 69.

бара икән. Нәкъ менә әлеге язылмаган кануннар кешене кеше итеп саклый, күңелендә Яхшылыкның өстенлек алуына китерә. Шуңа да пьесада Гөлфинә буыннарны тоташтыручы Ана булып ачыла.

Пьесаның төзелеше, автор кулланган алым-чаралар төп идеяне ачуга буйсындырылган. Аеруча мөһим урынны алып торган «“Бишек җыры” метафорик образ дәрәҗәсенә җиткерелгән. Ул милли гадәт-йолаларның кешелек кыйммәтләренә барып тоташуын чагылдыра»[1]. Ике ана тарафыннан башкарылган бишек җырлары барлык вакыйгаларны озата барып, төп лейтмотив булып күтәрелә. Әлеге бишек җырларында Ананың үз Баласына булган ярату хисе, теләге, өмете, ышынычы, борчу-уйланулары чагылыш таба:

*Гомерең сукмагын зур юллар буйлап,*
*Өмет йолдызым,*
*Үтәрсеңме син?*
*Илеңнең данын Намус, Вөҗданың,*
*Балам, әй, балам,*
*Итәрсеңме син?*[2]

«Әниләр һәм бәбиләр» драмасы үзенең социаль-әхлакый эчтәлеге, уңышлы табылган формасы, сәнгати алым-чаралары белән драматург иҗатында аерым урын алып тора. Автор хатын-кызның гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге урынын билгеләүгә яңа яктан якын килә һәм бөтенлекле образлар тудыруга ирешә. Драмадагы конфликт әхлак кысаларыннан чыгып, иҗтимагый яңгыраш ала, яшәешнең авыру нокталарын ачуга китерә.

* * *

Т. Миңнуллинның күпсанлы язмаларында, әңгәмәләрендә чагылыш тапкан тормыш-яшәеш концепциясе пьесаларында да киң урын ала – ул битараф булмау, үҗәтлек дәрәҗәсендәге тырышлык, үз-үзеңә ышану, оптимизм, милләт язмышын кай-

---

[1] *Әхмәдуллин А.* Туфан Миңнуллин // Татар әдәбияты тарихы: алты томда: 6 т: 60–90 еллар әдәбияты. – Казан: «Раннур» нәшр., 2001. – Б. 424.

[2] *Миңнуллин Т.* Әниләр һәм бәбиләр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 397.

гыртып яшәү һ.б. «Ай булмаса, йолдыз бар» (1977) пьесасы, социаль-психологик эчтәлекле мелодрама буларак, авырлыклар алдында баш имәс герой иҗат итүнең матур үрнәге булып тора. Әдипнең шәхес концепциясен ачуда һәм аларны укучы-тамашачыга җиткерүдә көчле рухы, ихтыяр көче, чыдам-сабырлыгы, яклаган идеаллары өчен үзен корбан итәргә әзер булган Мәдинә Сафина образы мөһим урын алып тора. Әсәр – драматург эзләнүләрендә, һичшиксез, яңа бер баскыч. С. Сөләйманова, А. Гыйләҗев, А. Әхмәдуллин, И. Илялова һ.б. билгеләп үткәнчә, драма үзенең төзелеше, әдип мөрәҗәгать иткән алым-формалар белән игътибарны җәлеп итә. Тормыш авырлыкларына бирешмичә, тешен кысып түзгән, шуның белән кешегә, бигрәк тә хатын-кызга хас мөмкинлекләрнең чикләрен бермә-бер үстергән героиняның рухи халәтен тулырак ачу максатында драмага Автор образы килеп керә. Аның турыдан-туры вакыйгаларга катнашып китүе, төп герой белән бәхәс алып баруы мөһим үзенчәлек буларак кабул ителә. Прологта бирелгән әлеге күренеш әдәби әсәр иҗат итү серләрен ачуга да хезмәт итә. Билгеле булганча, тулы канлы герой әсәрдә үз характеры, үз тормышы белән яши, автор теләгенә буйсынмый. Әлеге драмада әнә шул каршылык туа. Автор мелодрама жанрындагы әсәр язарга уйлап, героен елатырга тели, әмма ул ризалашмый, чөнки характеры андый түгел. Дөрес, авторда да хаклык барлыгын искәртергә кирәк: *«Күз яше – кайгы-хәсрәтнең юлдашы, кайгы килгәндә кеше җылап җибәрә, аңа җиңелрәк була»*[1]. Төп конфликтны тәшкил иткән әлеге ике караш, алга таба сюжет җебен сузарга мөмкинлек бирә. Язмыш Мәдинә алдына кайгы-хәсрәтне таудай өеп куя. Иң элек нәселдән килгән авыру аркасында күзләре сукырайган әнисен карау аның өстенә төшә. Мәдинә үзенең олы йөрәге, түземлек-сабырлыгы һәм мәрхәмәте белән укучы-тамашачысыны җәлеп итә. Аерым сыйфатларын тагы да үстерү максатыннан, күрше кызы Хәмидәгә үзенә дип теккән туй күлмәген биреп чыгару күренеше дә өстәлә. Ул әнисенең урынсыз киреләнүен, аны кимсетүен, яши белмәүдә гаепләүләрен дә тү-

[1] *Миңнуллин Т.* Ай булмаса, йолдыз бар // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 181.

землек белән кабул итә. Әнә шундый киеренке мизгелдә пьесага «Мәдинә» җыры килеп керә. «Герой концепциясен ачуда җыр контексты мөһим урын алып тора. Драматургның сәнгати фикерләвендә халык җыры «Мәдинә» сюжет хәрәкәтен билгеләп, әсәрнең тирән мәгънәсен ача»[1]. Алга таба да җыр хатынның күңелен бушатуына хезмәт итү белән бергә, аның җан борчуларын тоемларга ярдәм итә.

Совет җәмгыятендә хатын-кызның тормыштагы урыны, роле мәсьәләсенә гаять зур игътибар бирелә. Алгы планга аның гаиләдәге вазифасыннан бигрәк, хезмәте, коллективтагы урыны мәсьәләсе чыга. Хатын-кызларның ирләр белән тигезлеген раслау өчен, аларның авыр хезмәттә интегүләре дә еш кына үрнәк буларак тәкъдим ителә. Т. Миңнуллин әзер штамплар белән эш итми. Аның өчен хатын-кызның рухи көчен сынау мөһим. Драмада Мәдинәне башка хатын-кызлар белән чагыштыру мөмкинлеге бирелә. Күршеләре Ания, Хәмидә, хәтта үз анасыннан да кискен аерылып тора ул. Автор һәрберсенең теге яисә бу сыйфатын аерып күрсәтә, Мәдинәнең яхшылыгына начарлык белән җавап биргән Ания – рухи түбәнлек чагылышы. Ул эшгамәле белән әхлак кануннарын санга сукмаучы хатын-кыз буларак бирелә. Шул ук вакытта Мәдинәнең явызлыкка каршы тора алмавын да күрәбез, бу вакытта ул кызганыч кеше буларак күзаллана. Шуңа да әнисе Разия аның характерын үзгәртергә тели: *«Әй сау чагым булса... Күрсәтер идем мин ул хайванга. Әйтеп торам мин сиңа, җебегән булма дип. Бер сүз әйтсәләр, икене әйт, бер суксалар, уны белән кайтар. Дөньясы шундый»*[2]. Ананың үз тормыш фәлсәфәсе бар. Ул усаллыкка бары усаллык белән генә каршы торып була дип саный: «*Юаш булма, сытар-*

---

[1] *Закирзянов А.М., Хабутдинова М.М.* Новое прочтение женской темы в спектакле «Без луны, звезда нам светит» по одноименной пьесе Т. Миннуллина (2015) (реж. Р.Р. Фазлыев) // Филология и культура. Philology and culture. – 2016. – № 1 (43). – С. 201.

[2] *Миңнуллин Т.* Ай булмаса, йолдыз бар // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 2 т. –Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 191.

*лар. Яхшылыкның кадере юк аның*»[1]. Дөрес, аның бу сүзләре бераз ясалма тоела. Безгә аның үткәне билгеле түгел. Ул тормышта үзе шулай яшәгәнме? Шулай яшәсә, кызы Мәдинә моны күреп үскәндер бит, нигә карашын белдерми, сиздерми?

Пьесада төп геройның абыйсы Исхак образы, аның бары тик түбәнлек, кешелексезлек дип кабул ителәчәк эш-гамәлләре дә Мәдинәне калкытып куюга хезмәт итә. Әлеге бәндә үзен генә кайгыртучы, шул ук вакытта башкалар алдында яхшатлы булып кыланучы эгоист буларак ачыла. Энисен озатырга да кайта алмаган энесен тиргәве, хурлавы артында үзенә йорттан өлеш чыгаруны соравы ярылып ята: *«Ә минем вакытым бармы? Мин якында яшимме? Кайттым бит. Миңа әни булса, аңа да әни бит ул. Миңа гына расходланырга дигәнмени. Кайтырга-китәргә билетка гына да йөз сум чыгарып салдым. Йорттан миңа да өлеш чыгарыгыз, диярргә ояты җитәр әле сволочьның. Өлеш сорап карасын – күрсәтермен мин аңа*»[2]. Кемнән-кемнән, ә үзенең бертуган абыйсыннан энисенә һәм үзенә шундый караш күргәннән соң, Мәдинә күңелендә моңа кадәр ышанып яшәгән принципларына карата ниндидер бер икеләнү, шикләнү хисе барлыкка килә. Шуңа да ул алга таба да куячак соравын яңгырата: *«... нигә кешеләр шундый була икән?»*[3] Шул ук вакытта күңелендә бу сорауга җавап та бар: *«Кешеләр түгел... Кеше... Юк, алай да түгел... Кеше кеше булырга тиешләр ул. Күңеленең кайсыдыр бер почмагында яктылык ятарга тиештер...»*[4]

Мәдинә алдына куелган икенче сыналу мәхәббәт белән, гаилә тормышы белән бәйле. Автор аның ярата һәм яраттыра белүен ышандырырлык итеп ача. Кырыс чынбарлыктан арына алмаса да, Мәдинә күңелендә романтик күтәренкелек, өмет хисе бар. Мәхәббәт ярдәмендә кешеләрне бәхетле итеп булуына да ышана ул. Ул яраткан кешесе Мирзанур белән киләчәген бәхетле итеп күрә. Йөрәге сөю хисеннән ташыган кеше

---

[1] *Миңнуллин Т.* Ай булмаса, йолдыз бар // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 191.

[2] Шунда ук. – Б. 195.

[3] Шунда ук. – Б. 197.

[4] Шунда ук. – Б. 197.

генә мондый сүзләрне әйтә ала: «*Сиңа мин ышанам... Ышанасым килә. Син минем таянычым, Мирзанур. Җанымны ярып кара – анда син*»[1]. Әлеге кеше Мәдинәгә хыянәт итә. Иренең эш-гамәләре тулысынча дәлилләнеп җитмәсә дә, хатын өчен гаять зур сынау, чираттагы сынау. Мәдинә эчендә ут, әрнү, ачу янса да, аны тышка чагырмый, гаҗәеп сабырлык белән боларны кабул итә. Шул вакытта да иренең үзенә авыр вакытта ярдәм итүен рәхмәт хисе белән искә ала. Әлеге хәлләрдән соң, Мәдинәнең сыгылып төшүен, күз яшьләре күрсәтүен көткән Автор тагын оттыра. Аларның чираттагы бәхәсе әнә шул турыда. Автор Мәдинәдән бигрәк тамашачы өчен әлеге образның уйлап чыгарылмаганлыгын, бәлки тормыштан алынганлыгын әйтә. Ә анда һич тә җиңелдән түгел. Шуңа да ул янәдән Мәдинәне кисәтергә мәҗбүр: *«Йөз шатлыгыгызга бер хәсрәт китерермен. Ул хәсрәт кеше күтәрә алмаслык булыр. Сыгылып төшәрсез. Каршыма тезләнеп җыларсыз. Мин үземнең көчле икәнемне расларга мәҗбүрмен»*[2]. Аңлашылса кирәк, бу урында Автор теләге Язмыш белән кушылып китә. Кешенең язмышы алдан билгеләнгән, ул аны бик теләсә дә үзгәртә алмый, дигән гыйбарә бар. Язмышка каршы бару алдан ук җиңелүгә дучар була. Т. Миңнуллин Язмыш кешене сынау өчен җибәрелгән, дигән фикерне яклап, шәхеснең ролен югары күтәрә.

Чыннан да Мәдинә алдына куелган сынауның алдагысы кеше күтәрә алмаслык – ул бердәнбер кызын югалта. Пьесада Талия белән бәйле эпизодлар күп түгел. Әмма булганнарында кызның әнисе Мәдинәгә ошаган булуын, бәхет өчен яратылуын, романтик табигатен тоемлау мөмкинлеге бирелә. Ә инде 16 яшьлек кызның гомере иң матур чагында фаҗигалы үлеме, югалтуның ачысын тагы да арттыра, ана фаҗигасының чиксезлеген үстерә. Кайгыдан чәчләре агарган ананың күңелеката, ул бик теләсә дә елый алмый. Мәдинә бу олы хәсрәтне дә үтеп чыгарга үзендә көч таба.

[1] *Миңнуллин Т.* Ай булмаса, йолдыз бар // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 207.

[2] Шунда ук. – Б. 212.

Сынауны шушы урында туктатырга да булыр иде, әмма «Язмыштан узмыш юк» икән, аңа кайгының тагын берсен күтәрергә туры килә, ул сукырая. Әлеге хәлләрне башыннан кичергән Мәдинәнең күңел халәтен укучы-тамашачы да яхшы аңлый, тоемлый һәм Автор белән бергә Бөек хатын-кыз каршында баш ия. Пьесаның эпилогы вакыйгаларга нәтиҗә ясаудан бигрәк, кешенең рухи көче турындагы әңгәмә булып оеша. Хәзер инде Мәдинә каян көч алуы турында уйланып, авторга болай ди: *«Зуррак кайгыларга түзгән, кеше булып калган кешеләрне беләм мин. Күрәсез, мин һаман яшим, яшәрмен. Сынармын, ләкин сыгылмам. Минем юлыма сез миңа кайгы китергән кешеләрне, көтелмәгән бәхетсезлекләр очраттыгыз. Әмма белегез, кеше кешеләр арасында яши. Берәвесе этеп екса, унысы тартып торгыза. Кешедәге көч ул үзе уйлаганнан күбрәк. (...) Кешеләр барында мин тормышта урынымны табармын. Кояш яктыртмаса, ай бар. Ай булмаса, күктә йолдыз бар*»[1]. Әнә шул рәвешле, автор әсәр исеменә чыгарган фикер яңгырый. Әйе, тормышта кеше барыр юлын кояш һәм айга карап билгели, ә инде караңгыда ай да булмаса, аңа йолдызлар юл күрсәтә. Бу кешенең рухи көче, өмет-ышанычы чагылышы. Шул ук вакытта бу юлларда Мәдинәдән бигрәк әсәр авторының фикерләре дә яңгырый. Хатынның мин кешеләр ярдәмендә тормышта үз урынымны таптым дигәне бераз сәер яңгырый. Вакыйгалар барышында Мәдинәгә ярдәм иткән, аның белән кайгы-хәсрәтләрен бүлешкән кеше очрамады бит. Алдарак та әйтелгәнчә, мондый күренешләр пьесага билгеле бер ясалмалык алып килә.

«Ай булмаса, йолдыз бар» драмасы буенча куелган спектакльләр үз вакытында да, соңрак та тамашачы тарафыннан яратып кабул ителә, югары бәя ала. Бу, беренче чиратта, көчле хатын-кызны алгы планга чыгару, аның көченә, ныклыгына соклану белән бәйле иде. Әлмәт театрында куелган спектакль, пьеса авторы Т. Миңнуллин, куючы режиссер Г. Хөсәенов һәм Мәдинә ролен башкаручы Д. Кузаева 1979 елда Татарстанның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек була.

---

[1] Миңнуллин Т. Ай булмаса, йолдыз бар // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 221.

А. Габәши-Салихова язганча, «көчле рухлы, үзенең әхлакый тәртип-низамына беркайчан хыянәт итмәячәк Мәдинә Сафина үзенең дә, башкаларның да хата-ялгышларын кичерми. Аның өчен иң мөһиме – намус, вөҗдан, бурыч иминлеге. Үз чорының хатын-кыз идеалын әнә шундый биеклеккә күтәрде Туфан Миңнуллин»[1].

Шулай итеп, пьесада Т. Миңнуллин кеше һәм язмыш төшенчәләре турында фәлсәфи эчтәлекле бәхәс алып бара. Ул кешедәге ихтыяр көченә, аның мөмкинлекләренә соклану белән кушылып китә. Шуңа да Автор-катнашучы зур рухи көчкә ия булган, язмышка буйсынмыйча, авырлыкларга бирешмичә яши алган хатын-кыз алдында баш ия, үзенең җиңелүен таный. Т. Миңнуллин язмыш сынауларына каршы тора алган хатын-кыз образы тудырып, совет чорында киң танылу алган геройлар галереясын баета. Бер үк вакытта, үз-үзеңне табу аша гына кеше тормышта мәгънәле яши ала дигән карашны яклавы белән пьеса бүген дә заманча яңгырый.

## 1.5. «Әлдермештән Әлмәндәр» феномены

Т. Миңнуллинның иҗат концепциясен яңа тип милли геройга йөз тоту билгели. Аны, беренче чиратта, көчле рухлы, ихтыяр көченә ия булган, тормыш авырлыкларында куркып калмаучы, үзен, гаиләсен кайгырта алучы геройлар кызыксындыра. Әмма бу һич тә гел уңай герой гына эзләү дигән сүз түгел. Җәмгыятьтәге каршылыклар, явызлык һәм әхлаксызлык күренешләре дә, тормышта үз урынын таба алмыйча аптырап-югалып калган геройлар да аның пьесаларында урын ала, һәм бу хәлләрнең сәбәпләре турында җитди сүз алып барыла. Шуңа да геройлары тормышчан һәм үзләренә генә хас холык-характерга ия булулары белән аерылып тора, бу юлда әдип психологизм алымнарына нигезләнә, геройларның хис-кичерешләрен укучы-тамашачыга җиткерүнең яңа алым-формаларын таба. «Ир-егетләр» (1971), «Ат карагы» (1972), «Китәр юлың еракмы?» (1974), «Ай булмаса, йолдыз бар» (1977), «Әлдермештән Әлмәндәр» (1975),

[1] *Габәши-Салихова А.* Иҗатында – ил гаме // *Миңнуллин Т.* Пьесалар / кереш сүз авт. А. Габәши-Салихова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 8.

«Монда тудык, монда үстек» (1982) һ.б. пьесалары нәкъ менә фикер ачыклыгы, көчле холыклы герой бирелеше, төп фикер әйтеп бетерелмичә, нәтиҗә ясау укучы-тамашачы өлешенә калдырылу белән үзенчәлекле.

Драматургның бөтен иҗаты милләт гаме белән сугарылган. Ул кыю рәвештә татар милләте, аның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, традицияләре сагында тора. Барлык әсәрләрен дип әйтерлек иңләп үткән, үзе бөтен барлыгы белән яклаган, милли менталитетның асылын билгеләгән сыйфатлар булып хезмәт ярату, өлкәннәргә хөрмәт, буыннар арасында рухи бәйләнеш саклану, борынгыдан килгән әхлакый кануннарга тугрылык, туган җирне ярату тора. Шуңа әдипнең «Йөрәк янар өчен бирелгән» (1970), «Уйланыр чак» (1972), «Әлдермештән Әлмәндәр» (1975) һ.б. пьесалары тормышчанлыгы һәм образларның логик яктан ныклы, бөтенлекле булып ачылуы белән җәлеп итә. Драматургның иҗаты төрләләнгән саен, аның үзенә хас стиль үзенчәлеге ачыла һәм ул яңа алым-чаралар белән байый бара. Ә инде реаль тормыш материалын шартлылык һәм фантастика элементлары белән кушып сурәтләүдә җитди казанышларга ирешә.

Т. Миңнуллин иҗаты үзенчәлеген генә түгел, чор әдәбиятының йөзен билгеләгән әсәрләрнең берсе – «Әлдермештән Әлмәндәр». Автор «моңсу комедия» дип билгеләгән пьеса яшәешнең мәңгелек төшенчәләрен гыйбрәтле образлар аша ачуы белән киң яңгыраш ала. Драматург яшәү һәм үлем, мизгел һәм мәңгелек, яшәү мәгънәсе һәм аның асылы турында уйлана, вакыйгалар аша укучы-тамашачыны да шулар турында уйланырга этәрә.

Әсәр сәхнәгә куелуга киң әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә, күпсанлы бәяләмәләр басылып чыга. Аларның төп фикере уртак – пьеса һәм спектакль татар әдәбиятының һәм театрының бер казанышы булып тора. Алдагы елларда аның Марий Эл, Удмуртия, Бурятия, Үзбәкстан, Калмыкия, Төньяк Осетия-Алания республикаларында, шулай ук Әстерхан, Воронеж, Мичуринск, Түбән Новгород, Новокузнецк, Омск һ.б. шәһәрләр театрларында куелуы да шул хакта сөйли. Татар дәүләт академия театры тарафыннан сәхнәләштерелгән

«Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле өчен Т. Миңнуллин һәм аның режиссеры М. Сәлимҗанов, баш рольне башкаручы Ш. Биктимеров 1979 елда Россиянең К. Станиславский исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. Әсәр бүген дә дәүләт һәм халык театрлары сәхнәләрендә тулы зал тамашачыга уйнала. «Әлдермештән Әлмәндәр»нең уңыш сере, феномены нәрсәдә соң? Моңсу комедия шактый тулы өйрәнелгән, күпсанлы язмаларда аның эчтәлек-формасына, поэтикасына бәйле үзенчәлекләренә игътибар бирелә. Шуларга таянган хәлдә, куелган сорауга җавап эзләргә тырышыйк.

Т. Миңгуллин пьесада «Татар кешесе кем ул, нинди ул?» дигән сорауга җавап эзләве белән үк игътибарны җәлеп итә. Автор аны гап-гади авыл кешесенең тормыш-көнкүрешендә таба. Ә бит татар язмышы фаҗигалар белән тулы. Барысына да тукталмастан, якынрак тарихка килеп, рус дәүләте тарафыннан яулап алынганнан соңгы дәвергә игътибар итсәк тә, халкыбыз күргән рухи һәм физик кыенлыкларның иге-чиге юк. Аерым алганда, көчләп чукындыру, торган җирләреннән, зур елга буйларыннан куылу, җирләрен тартып алу, яшь буынны укыту өчен бертөрле дә ярдәм күрсәтмәү, хокуксызлык, милли изелү һ.б.га бәйле халкыбыз таркалу, югалу, башкалар арасында эреп бетү куркынычына дучар булса да, ул үзенең бөтенлеген, менталь сыйфатларын, динен саклап кала. Әкренләп эчке потенциалын җыя, генофондын туплый һәм башка халыкар казанышларын үзләштерү аша, алар белән тигезләшүне максат иткән Яңарышка килә. XX йөз башында милләт буларак формалашып, парламент юлы белән үз мәнфәгатьләрен яклау юлына чыгуы да татар халкының тизләтелгән үсешенә китерә. Совет чорында да халкыбызга күптөрле авырлыклар аша үтеп, үз йөзен, үзенә хас традицияләрен, гореф-гадәтләрен якларга һәм сакларга туры килә. Татар халкы, зур югалтулар белән булса да, әлеге афәтләрдән ничек чыга алды, ни-нәрсә көч-таяныч булып торган соң? Пьесадагы вакыйгалар аша, башкалардан берни белән дә аерылып тормаган Әлмәндәр авылы кешеләре яшәешендә автор бу сорауга да җавап эзли. Әсәрдә авыл кешеләренең гомумиләштерелгән образын күзалларлык сыйфат-билгеләр калкып

чыга: үзара ярдәмлеккә, игелек-миһербанлыкка нигезләнгән бердәмлек; авырлыкларны җиңеп үтәргә ярдәм иткән сабырлык, ныклык; максат куеп хезмәт итәргә этәргән тырышлык һәм, боларның барысын үзенә туплап, бабаларыбыздан килә торган әдәп-әхлакка тугрылык. Т. Миңнуллин укучы-тамашачы каршында әлеге үзенчәлекләрне ачып, аны кызыксындыра, уйланырга, билгеле бер нәтиҗәләр ясарга этәрә.

Драматург татар кешесен тулырак ачу өчен, аның үлеме алдындагы берничә көнен сурәтли һәм шартлылык алымы ярдәмендә Әҗәл образын кертеп, Әлмәндәрнең аның белән тартышын үзәккә куя. Әлеге мифик образ халык мифологиясендә, аннан фольклорда киң урын алып, кеше яшәешендә яшәү-үлем антиномиясе буларак гасырлар дәвамында кулланылып килә. Кеше үлем каршында бөтен барлыгы белән ачыла, аңа нидер ялганнарга, яшерергә һ.б. урын калмый. Шуңа да Әҗәл образын «кешеләштерү» зур кызыксыну тудыра. *«Үлем – куркыныч нәрсә*, – дип яза Т. Миңнуллин көндәлегендә. – *Ул үзе белән шаярганны яратмый. Әмма аңардан бик үк өркеп китмәүчеләрнең дә барлыгы язылачак пьесаның юнәлешен, жанрын билгеләде. Ул, әлбәттә, комедия булырга тиеш иде. Әҗәлнең үзен дә кеше кыяфәтенә кертеп сәхнәгә чыгарырга кирәк санадым. Күрсеннәр, кешеләр, әллә ни явыз түгеллегенә ышансыннар. Үлем турында түгел, Яшәү турында уйлансыннар»*[1].

Әсәр үзенең фәлсәфи эчтәлеге белән көчле. Автор пьеса язылуга йогынты ясаган сәбәпләр турында уйланып, яшәеш кыйммәтләре чагылган әсәр язарга тиешлеген аңлауга килә. Моны ул болай искә ала: *«Әдәбиятта һәм сәнгатьтә, кешелек дөньясының нинди генә формаларына кереп яшәвенә карамастан, беркайчан да искерми торган темалар бар. Мәхәббәт һәм нәфрәт, Яхшылык һәи Явызлык, Яшәү һәм Үлем. Борынгы заманнардан алып бүгенге көнгәчә бер генә язучы да бу темаларга кагылмыйча үтә алмый. Мин дә, табигый, аларны читләтеп уза алмадым. Яшәү һәм Үлем турында язучы буларак ныклап уйланырга иң якын кешеләрем – әти белән әнинең бер-бер*

---

[1] *Миңнуллин Т.* «Әлдермештән Әлмәндәр» // *Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – Б. 184.

*артлы үлеп китүләре дә этәргеч булды»*[1]. Автор тормышның асылын билгеләгән яшәү-үлем фәлсәфәсен яңа яссылыкта сурәтләп, пьесаны гыйбрәтле, кызыклы, күпмәгънәле итә.

Т. Миңнуллин үзенчәлекле сюжет һәм композициядә кеше һәм Әҗәл тартышын төрле хәл-ситуациядә ачып, конфликтның эзлекле чишелешенә килә. Әлмәндәрнең Әҗәл дәфтәренә үзе сорап кул куюы – кешенең бөеклегенә дан җырлау булып тора. Ислам динен, Коръән тәгълиматын үзенчәлекле аңлатуны күздә тоткан суфичылык күренешендә кешенең үлеме, аңа әзерлеге, Аллаһы Тәгалә каршына баруы, аның белән якынаю теләге гаҗәеп күптөрле образ-символлар ярдәмендә ачыла. Шундыйларның берсе булып, адәмнең мәңгелеккә шатланып (елмаеп) китүе тора. Суфилар аны кеше җанының гөнаһлы тәннән аерылып, Аллаһ каршына шатланып килүе дип аңлата. Т. Миңнуллин кешенең мәңгелеккә китүе мәсьәләсенә яшәеш кануннарыннан чыгып якын килсә дә, героеның эш-гамәлләре, уй-фикерләре белән суфиларныкы арасында якынлыкны күрми мөмкин түгел. Матур гомер кичереп, тормыштагы теләкләренә ирешкән Әлмәндәр карт тыныч күңел белән Әҗәл дәфтәренә кул куеп, шаян җыр белән Ходай каршына китә.

Моңсу комедия үзенең образлар системасы белән кеше мөнәсәбәтләренең яңа битен ача. Билгеле инде, пьесаны Әлмәндәр образы тотып тора. Әлеге ил карты – татарның иң матур сыйфатларын үзенә туплаган милли образ. Әлмәндәр мәгънәле, матур гомер кичерүе, кайгы-хәсрәтне үтеп чыга алуы, шатлыкка куанып яшәве, өмет-ышаныч хисен җуймавы белән чын мәгънәсендә соклану уята. Ул – *«халыкчан персонаж. Иң элек, тормышка һәм үлемгә реаль мөнәсәбәте белән. Өлкән яшьтә булуга карамастан, тапкыр, акыллы. Ул күп хәлләрне башыннан кичергән, халык өчен иң җаваплы чорларда вакыйгалар уртасында кайный һәм бу аны халыкның үз кешесе дәрәҗәсенә күтәрә»*[2]. Үткәннәр турында сыкранып искә алса да, 91 яшьлек карт рухи

---

[1] *Миңнуллин Т.* «Әлдермештән Әлмәндәр» // *Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – Б. 183.

[2] *Ахмадуллин А.Г.* С. Татарская драматургия (история и проблемы). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С. 349.

бөеклеген, яшәү дәртен, яшәү теләген югалтмаган. Татар милли характеры булып ачылган Әлмәндәр образын иҗат иткәндә драматург материалны үз авылдашларыннан ала. Истәлекләрендә үзе белгән өлкән агай-бабайларларның кыенлыклардан сыгылып төшмичә, яшәү дәртен саклап, киләчәккә йөз тотып яшәүләрен яза. Үлем турында көлебрәк сөйләшә торган авылдашларын әдип болай күз алдына китерә: *«Картая белмәүчеләрдән тагын бер бабайны күздә тоттым мин “Әлдермештән Әлмәндәр”не язганда. Гыйльми бабай иде ул. Туксаннан узды шикелле. Җыен юк-барны сөйләп кеше көлдерүче әкәмәтрәк кеше иде инде. Аның юк-бар сүзләрен бөтенебез дә рәхәтләнеп тыңлый идек. Чөнки ул сөйләгәннәрнең төбендә мәгънә ята иде»*[1].

Автор героенның гомер юлын сөйләп чыгуны максат итми. Ул кирәк тә түгел, чөнки башкалардан әллә ни аерылып тормавын беләбез. Әлмәндәр 1904–1905 елларда рус-япон сугышы, 1914–1918 елларда Беренче Бөтендөнья сугышы фронтларын кичә, икесендә дә үлем куркынычына юлыга, колхозлар төзү вакытында күрше авыл кешесе Евстигней ярдәмендә генә кулаклар һөҗүменнән исән кала. Бөек Ватан сугышына биш улын озатып, бары берсен генә каршы ала алган. Сугыш чорында тылдагы авырлыкларны да үз башыннан кичергән. Шуларга карамастан, күңелендә яшәү дәртен, өмет хисен бервакытта да сүндермәгән. Евстигнейга ул моны болай аңлата: *«Мин, үзең беләсең, шыңшып йөрүне яратмадым. Дөньядан ямь табып яшәдем. Җылап йөрүчеләрне җенем сөйми»*[2]. Әлмәндәр карт гомерендә ике тапкыр өйләнсә дә, яшьли яратып кавышкан, балаларының анасы булган Йөзлебикәсен сагынып яши. Аның якты истәлеге гомере буе озата барганлыгы сизелеп тора. Ә инде үлеме алдыннан яшьлегенә кайтып, яшь чакларын, егет белән кыз вакытын хыялында яңарта. Пьесага гаҗәеп романтик рух, хис-кичереш дулкыны, үзара якынлык, җылылык чыгылышы алып килгән әлеге күренештә Йөзлебикәнең матур образы балкып кала.

---

[1] *Миңнуллин Т.* «Әлдермештән Әлмәндәр» // *Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – Б. 183.

[2] *Миңнуллин Т.* Әлдермештән Әлмәндәр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 39.

Әйләнә-тирәдәге якыннары белән мөнәсәбәтендә, диалог-әңгәмәләрендә карт яңадан-яңа сыйфатлары белән ачыла. «Төп игътибар аның шәхси һәм милли сыйфатларына – шаянлыгына, хуҗалыклыгына, игелеклегенә, дөньяга, бигрәк тә балаларга соклanулы һәм сак карашына ясала»[1]. Улы Искәндәр һәм килене Өммия белән аралашуы пьесадагы иң тормышчан, иң отышлы күренешләрнең берсе булып тора. Сугыштан авыр яраланып кайткан 70 яшьлек Искәндәр яраларыннан интегеп яши. Вакыты белән күңел төшенкелегенә бирелеп, яшәү тәмен югалткан кебек тоела. Әлмәндәр төрттерү, үз итеп ачулану аша аның рухын кузгатырга, күңелен күтәрергә, өмет хисен үстерергә тели. Бер урында *«Чирләшкә! Япь-яшь башыннан... Җитмеш яшендә чирләп ята»* дип ачуланса, икенче урында *«Авыруйм дип өйдә ятасың. Чир ул яткан кешене эзләп йөри. Эшләгән кешедән курка. Ник дигәндә, ул аңа ябышып торалмый, тир белән юылып төшә»*[2] дип киңәшен бирә. Өченче урында күңеленнән сыкранулы дөреслек чыга: *«Шулай... Чурту-матыр, Гитлер тәресе, әрәм итте әзмәвердәй малайларны. Чирләп ята торган кешеме...»*[3] Бу юлларда сугышка нәфрәте дә, улы өчен сызлану да урын ала. Дүртенче халәтендә карт улының хәлен аңлап, ныграк булырга, бирешмәскә өнди: *«Әгәр син зарлана дип мин зарлансам, син сукрана дип мин сукрансам, ни була...»*[4] Татар ир-атларына хас булганча, тыштан үзенең хисләрен әйтеп бетермәсә дә, Әлмәндәр карт, билгеле инде, улын ярата, аның өчен тирәнтен борчыла. Үлеме алдыннан өстендәге казакиен салып, Искәндәр иңенә ябуында, кайгыртуы һәм үз җылысын, ата җылысын улына биреп калдыруы чагыла.

Әлмәндәр белән Өммия мөнәсәбәте татар гаиләсенең бер читен ачып куя. Бер яктан, Өммия – татар әдәбиятында еш очрый торган усал килен образының бер чагылышы, әмма автор аның

[1] *Салихова А.Р.* Особенности формирования и развития татарского сценического искусства. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – С. 184.

[2] *Миңнуллин Т.* Әлдермештән Әлмәндәр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 15–16.

[3] Шунда ук. – Б. 16.

[4] Шунда ук. – Б. 31.

«усаллыгы» турында Әлмәндәрдән әйттерү белән чикләнә. Дөресрәге, бу исем белән атавы әче балны өйгә керттермәгәнлек сәбәпле генә булып чыга. Әлмәндәрнең күршесе Хәмдебануга булган җылы, мөлаем карашында, карчыкның сабырлыгы, мәрхүм иренә тугрылыгы алдында баш июе чагылыш таба. Бу – тугры татар хатын-кызын зурлавы, рәхмәте һәм аңа соклануы билгесе.

Пьесада картның оныгы Гөлфирәгә, аның егете Мансурга мөнәсәбәтендә үзгә бер ихласлык урын ала. Автор яшьләр арасындагы чиста, саф хисләрнең һәрвакыт актуаль булып калуын, аның тәрбиягә, әдәп-әхлакка барып тоташуын ача. Ә менә яшь малай Илсур образына гаять зур йөкләмә салынган. Ул – Әлмәндәр карт кебек авылдашларына җорлык, күтәренке күңел алып килүче. Халык җырларын өйрәнүе дә яшәештәге хәл-күренешләргә җыр-такмак аша үз мөнәсәбәтен белдерүче булачагына ишарә итә. «Әлмәндәр аларда үзенең дәвамын, үз нәселенең, авылының киләчәген күрә. «Туганнары белән саубуллашканда Әлмәндәр җырының укучы тарафыннан аның дөньяга карашы, эшләре һәм уйлары варисы буларак кабул ителгән Илсур авызыннан яңгыравы символик мәгънәгә ия»[1].

Әлмәндәр картның Әҗәл белән тартышында иң матур, кешелекле характер сыйфатлары урын ала. Икесе арасындагы диалогта картның яшәеш принцибы да ачыла: *«Кеше мине күреп елмая икән, мин кирәк дигән була. Минем яннан елмаеп киткәч, бүтәннәр янында да елмая ул. Аның елмайганын күреп, бүтәннәр дә елмая. Минем аркада ничаклы кеше елмая. Шуннан соң кирәк булмыйммы инде мин?»*[2] Иң мөһиме, Әлмәндәрдәге рухи көчне, яшәү омтылышын, тормышны ятратуын күргән, тойган саен Әҗәл дә үзгәрә бара. Ул карттан үкенечләре турында сорый, ә җавабында Әлмәндәр үз тормышына нәтиҗә ясый: *«Юк. Мин кылган эшләремә үкенмәдем. Эшләргә ниятләгән эшемне ахырына җиткезеп туктадым. Ярты юлда менә шушы алачык кала, тагын... тагын... Дөнья кала. Төзелеп бетмәгән дөнья*

---

[1] *Шарипова А.С.* Татарская драматургия XX – начала XXI века: проблема инварианта: Монография. – Казань: ИЯЛИ, 2022. – С. 158.

[2] *Миңнуллин Т.* Әлдермештән Әлмәндәр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 25.

*кала. Төзеп бетерәсе иде. Кешеләр үлсәләр дә, ичмасам, минем яшемә җитеп үз үлемнәре белән үлсеннәр иде. Уттан кырылмасыннар иде»*[1]. Соңгы юллар картның васыяте төсен алып, укучы-тамашачыга аталганлыгы ачык күренә.

Югарыда әйтелгәнчә, Әҗәл образы һәм аңа салынган йөкләмә, татар әдәбиятында җитди башлангыч булып, драматургиядә яңа юнәлешкә нигез сала. Пьесада Әҗәлнең үлемсезлеге кешегә бирелгән гомернең кадерен, асылын аңлауга, аны мәгънәле итеп үткәрүнең мөһимлеген ачуга хезмәт итә. *«Үлемсез булу начар, Әлмәндәр. Үлү зур бәхет ул. Сез кешеләр шуңа бәхетлеләр. – ди ул. – Минем миллиард ел яшәвем сезнең бер ел гомерегезгә тормый. Сез төзисез, сез өмет белән яшисез. Минем өмет юк, мин җимерүче»*[2].

Алдагы күренешләрдә Әҗәл әкренләп картны яклаучыга әверелә бара. Антоновка авылына качып киткән Әлмәндәрне таба алмыйча, үз дөньясына кайткач, ул Фәрештәгә күңелендәгене әйтеп сала: *«Әгәр кулымнан килсә, мин үзем Әлмәндәр урынында булыр идем. Без кемнәр синең белән? Үлемсез булуыбыздан ни мәгънә? Безнең бар белгәнебез: кайгы, хәсрәт, күз яшьләре»,* –ди ул. Фикерен болай дәвам итә: *«Үзгәрә алсам, Әлмәндәр картны Газраил кулына бирмәс идем»*[3]. Бу инде Әлмәндәр картның рухи көчен тану, аның алдында җиңелүен белдерү чагылышы. Шуңа да алар арасындагы каршылык картның үлем кәгазенә кул куюы белән чишелсә дә, чын җиңүнең Әлмәндәр карт ягында булуын аңлау кыен түгел. Хәзер инде Әҗәл үзе картка характеристика бирә: *«Гап-гади кеше. Ләкин гомере буе яшәүнең кадерен, тәмен белеп яшәгән кеше. Иң авыр чакларда да тормыштан ямь таба белгән, күңел көрлеген югалтмаган кеше. Ул – авылның шатлыгы, өмете. Аны күреп сөйләшкән кеше кайгысын оныта. Мин дә Әлмәндәр карт яшенә җитәрмен дип өметләнә»*[4].

[1] *Миңнуллин Т.* Әлдермештән Әлмәндәр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 41.

[2] Шунда ук. – Б. 22

[3] Шунда ук. – Б. 37.

[4] Шунда ук. – Б. 37.

Үлеме алдыннан Әлмәндәр үзенең иң якын кешеләре белән саубуллашып, аларга фатихасын биреп, күңел җылысын калдырып китә. Пьесаны Язмыш мифологемасына нисбәтле өйрәнгән А. Шәмсутова болай дип яза: *«Әлмәндәр карт алдына Язмыш бу юлы да сынау рәвешендә сайлау хокукы бирә. Үзе урынына Әҗәл белән улын җибәрә ала ул. Ләкин Әлмәндәр бу мөмкинлекне үз файдасына кулланмый. Ул, үзенә бирелгән соңгы минутларны матур итеп тәмамлап (...), үз Язмышын үзе кабул итә»*[1]. Гомумән, Әлмәндәр карт, беренче чиратта, милләтебезгә хас иң матур сыйфатларны үзенә туплаган ил карты, нәселенең үзәк тамыры булып күзаллана. Әҗәл, шартлы-символик образ буларак, халыкка каршы көч рәвешен ала, аның карт белән тартышы милләткә янаган куркыныч һәм аннан котылу юлларын эзләү булып та аңлашыла. Нәтиҗә рәвешендә Әлмәндәр картның эш-гамәлләренә бәйле әсәрнең төп идеясе калка: *«Һәркем матурлыкка, гармониягә омтылып яшәргә тиеш, шул очракта гына кеше үзен тулы бәхетле тоя алачак, яшәве матур, мәгънәле булып, башкалар күңелендә дәвам итәчәк»*[2].

Пьесаның киң яңгыраш алуында авторның җор теле, күп төрле мәкаль-әйтемнәрдән, гыйбарәләрдән, афоризмнардан уңышлы файдалануы да зур роль уйный. Т. Миңнуллин үзен диалог кору остасы итеп таныта. Ә инде әдипнең *«Килен явызланды. Картая башлады. Картайган саен явызлана»; «Булмады, малайның бәхете булмады, озын гомерле хатынга туры килде»; «Ир кеше үз гомерендә ике хатын да җирләрлек яшәмәгәч, ир кеше буламы»* кебек гыйбарәләре тел нечкәлекләрен белүнең, халыкчан юмордан файдалануның матур бер үрнәге булып тора.

Пьесадагы җырлар автор карашларын, шулай ук Әлмәндәр образының мөһим сыйфатларын ачуда, укучы-тамашачыга төп

---

[1] *Шәмсутова А.А.* Туфан Миңнуллин пьесаларында Язмыш мифологемасы // Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш: фәнни мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 98.

[2] *Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М.* ХХ гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек. 2 т.: ХХ йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – Казан: Казан университеты, 2011. – Б. 106.

идеяне җиткерүдә гаять зур урын алып тора. Тексттагы һәрбер җыр аерым бәягә лаек булса да, берсенә генә тукталып үтик:

*Ала карга дигән, әй, асыл кош.*
*Имән башларына ник кундың?*
*Никләр кунганыңны да белмәгәч,*
*Якты дөньяларга ник тудың?*[1]

Бер караганда, бәхәскә урын калдыра торган каршылык урын алган, әмма авторның ала карганы асыл кош дип атавы аллегория булып тора. Бу юлларда һәр кешенең үз бәхете белән тууына да ишарә бар. Шуның белән бергә, һәркем алдында нинди максат белән яшәве турындагы сорау торуын да аңлата. Шуны да искәртеп үтик, пьесада кулланылган сан идея эчтәлекне аңлауда мөһим урын алып тора. *«Әсәрдә Әлмәндәрнең үлемсезлеген милләтебезнең үлемсезлеге итеп тә күрсәтү максаты бар*, – дип яза Т. Миңнуллин. – *Тамашачыларның сизгеррәкләре игътибар итә – комедиядә “Бер мең дә биш йөз илленче номер Әҗәлне Газраил янына җибәрегез”, – дигән реплика бар. Бүгенге көндә булса, әлбәттә, бер мең дә биш йөз илле икенче санын бирер идем. Әсәр 1976 елда язылды, ул заманда 1552 санын кычкырып әйтсәң, пьесаның сәхнәгә чыкмый калуы бик мөмкин хәл иде»*[2].

Пьеса үзенең сәнгатьчә эшләнеше белән көчле. Автор татар драматургиясенең иң матур традицияләрен дәвам итеп, пьесада, А. Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә, «төрле кәеф төсмерләренә бай, мул бизәкле» һәм «җиңел, уйнак юмор, җитди көлү, сатирик үткерлек, лиризм, драматизм» ярдәмендә «бер яңа стиль тудыруга»[3] ирешә.

Шулай итеп, «Әлдермештән Әлмәндәр» моңсу комедиясе – драматургның иҗат биеклеген билгеләүче әсәрләренең берсе. В.В. Фролов билгеләп үткәнчә, әдәбиятның иң яхшы традиция-

---

[1] *Миңнуллин Т.* Әлдермештән Әлмәндәр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 40.

[2] *Миңнуллин Т.* «Әлдермештән Әлмәндәр» // *Миңнуллин Т.* Татарның бер баласы. – Казан: Рухият, 2003. – Б. 236.

[3] *Әхмәдуллин А.* Күңелләрне уятыр: хәзерге татар драматургиясе: монография. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 61.

ләрен дәвам итүче соклandыргыч пьесада[1] туган җир кадере, ата-ана һәм бала, ир-хатын мөнәсәбәте, йола-гадәтләргә тугры калу кебек әхлакый һәм милли проблемалар яшәешне фәлсәфи бәяләү белән кушылып китә. Автор тудырган милли герой үзенчәлекле холкы, тормышка мөнәсәбәте, яшәү кадерен белүе, җорлыгы, ачык күңеле, тирән психологизмы белән җәлеп итә. Ә инде дини-суфичыл Әҗәл образы һәм аның Әлмәндәр белән тартышы пьесага үзгә яңгыраш биреп, Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбиятларында урын алган әдәби-эстетик карашларның кисешү ноктасына әйләнә.

### 1.6. Драматург иҗатында тарихи шәхесләр

Үткәннәр тәҗрибәсе кешелеккә хаталарны кабатламыйча, бүгенгене һәм киләчәкне матуррак, гаделрәк итеп төзергә ярдәм итә. Һәр халыкның үткәне булган кебек, аның тарихындагы данлыклы яисә фаҗигалы вакыйгаларда үсеп чыккан тарихи шәхесләре дә бар. Бу татар халкының күпгасырлык тарихына да карый. Рус дәүләте тарафыннан яулап алынганнан соң, татар тарихы рәсми чыганакларда, шулай ук фәнни хезмәтләрдә һәм әдәби әсәрләрдә берьяклы гына бәяләнеп килене[2]. Аерым алганда, XVI гасырга кадәрге тарихи вакыйгалар «татар-монгол иго»сы булуын дәлилләүгә кайтып калса, аерым шәхесләрнең эш-гамәле явызлык чыганагы буларак бәяләнде. Мисал өчен, билгесез авторның «Казанская история» (1564–1965), М.М. Херасковның «Россияда» (1779), С.Н. Глинканың «Сумбека или Падение Казанского царства» (1806), М.С. Рыбушкинның «Иоанн, яки Казанның алынуы» (1813) һ.б. хезмәтләрдә әнә шундый карашлар киң урын алган. Ә инде татарлар тарафыннан фәнни тикшеренүләр соңарып, бары тик XIX гасыр урталарында гына башлана һәм 1917 елга кадәр бары шәхси инициативага нигезләнә. Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, Ш. Әхмәров һ.б. хезмәтләре тарихи чыганакларны җыю, туплау, бәяләү ягыннан

---

[1] *Фролов В.В.* Бүгенге татар драматургиясе турында сөйләшү (түгәрәк өстәл утырышы) // Казан утлары. – 1984. – № 11. – Б. 167.

[2] *Усманов М.А.* О Михаиле Худякове и его книге // *Худяков М.Г.* Очерки по истории Казанского ханства. – М.: ИНСАН, СФК, 1991. – С. 5.

әһәмиятле булса да, алар киң таралыш алмый, байтагы кулъязма рәвешендә кала. Совет чорында татарлар тарихын өйрәнү буенча җитди адымнар ясала, әмма галимнәр көчле идеологик басым астында булып, татар тарихын рус тарихына бәйле яисә рус галимнәре яклаган концепция кысаларында гына өйрәнергә тиеш булдылар. Ә инде ВКП(б) ҮКның 1944 ел 25 августында кабул ителгән карары нигезендә Алтын Урда тарихын өйрәнү бөтенләй тыела. Шулай да ХХ гасырның 60 елларыннан башлап ерактагы һәм якындагы тарихны, шәхесләрне өйрәнүгә мөмкинлек ачыла һәм Болгар дәүләте, Алтын Урда чоры тарихына караган тикшеренүләр башлана.

Күпгасырлык тарихыбыз әдәбиятта ничек чагыла соң? Сүз сәнгатендә тарихи вакыйгаларның һәм аерым шәхесләрнең сурәтләнеше шактый үзенчәлекле: әгәр рус әдәбияты үрнәкләреннән «Слово о полку Игорове», «Повесть временных лет», «Послание Владимира Монамаха» кебек әсәрләрдә, нигездә, тарихи шәхесләр урын алса, татар әдәбиятында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» (1233), Котбның «Хөсрәү вә Ширин» (XIII гасыр), С. Сараиның «Сөһәйл вә Гөлдерсен» (XIV гасыр), М. Болгариның «Нәһҗел фәрадис» (XIV гасыр), Сәйядинең «Бабахан дастаны» (XIV гасыр) һ.б. әсәрләр я дини мифологиягә, я Шәрыктан кергән сюжетларга нигезләнә. Дөрес, С. Сараиның «Гөлстан бит-төрки»ендә, билгесез авторның «Идегәй» дастанында, Мөхәммәдьяр поэмаларында татар тарихын күз алдына бастырырлык фактлар да урын ала.

Татар әдәбияты ХХ йөз башында, реализм һәм романтизмның әдәби-эстетик принципларын тулысынча үзләштергәч кенә, реаль вакыйгаларга һәм тарихи шәхесләрнең әдәби образларына мөрәҗәгать итә башлый. Аның башлангычында Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» (1909), «Безнең көннәр» (1914), Ш. Камалның «Таң атканда» (1927), М. Галәүнең «Болганчык еллар» (1930), «Мөһаҗирләр» (1934) һ.б. әсәрләр тора. Алдагы елларда тарихи тематика Г. Бәширов, К. Нәҗми, М. Әмир, И. Гази, Ф. Хөсни, А. Расих һ.б. иҗатында үстерелә.

Ә инде драматургиядә тарихи тематика Г. Исхакый исеме белән бәйле. Драматург «Зөләйха» (1911) трагедиясендә

көчләп чукындыру вакыйгасына мөрәҗәгать итә. Россия тарихын тамырдан үзгәрткән Октябрь революциясеннән соң язылган К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр» (1923), «Ил» (1927), Н. Исәнбәтнең «Һиҗрәт» (1923), Ә. Фәйзинең «Пугачев Казанда» (1927), «Тукай» (1943) һ.б. пьесалар тарихи вакыйгаларны әдәби җанландыру ягыннан игътибарга лаек. Алдагы елларда драматургиядә тарихи тема һәм аерым шәхесләр чагылышы Н. Исәнбәтнең «Идегәй» (1941), «Гөлҗамал» (1943), «Муса Җәлил» (1947), М. Гали, Х. Уразиков «Каюм Насыйри» (1944), Т. Миңнуллинның «Канкай углы Бәхтияр» (1974), «Моңлы бер җыр» (1982) һ.б. пьесаларда уңышлы ачыла. Авторлар тарихи вакыйга яисә аерым шәхесләр аша татар милли фаҗигасы сәбәпләрен ачуга, нәтиҗәләр ясауга килә. А. Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә, үзгәрешләр иң элек шәхес концепциясен ачуда чагыла. Хәл-ситуациянең драматизмын ачу белән бергә, шәхес язмышының драматизмын тирәнрәк ачу омтылышы көчәя. Мондый әсәрләрдә сурәтләүдәге реалистик алым һәм стиль еш кына романтик пафос белән тулылана[1]. Ә инде без сүз алып бара торган чорда прозада тарихка, беренчеләрдән булып, Н. Фәттах мөрәҗәгать итә. Аның «Ител суы ака торур» (1973) романы зур кызыксыну уятып, башкаларны да кузгатып җибәрә. Драма төрендә шактый тәҗрибә туплаган Т. Миңнуллин да татар тарихы һәм аның билгеле шәхесләре темасыннан читтә кала алмый. Ул тарих сәхифәләренә мөрәҗәгать итеп, билгеле шәхесләрнең әдәби образларын тудыруга килә. «Канкай углы Бәхтияр» (1974), «Моңлы бер җыр» (1981), «Без китәбез, сез каласыз» (1986) кебек драмалары, тарихи вакыйгаларны торгызу белән бергә, татарның ерактагы һәм якындагы тарихына яңача бәя бирүнең уңышлы үрнәге була.

Россия составына кергән халыклар, шул исәптән татарлар гасырлар дәвамында милли, дини, социаль изүдән интегеп яшәгән. Тормыштагы гаделсезлекләр яшәп килгән тәртипләргә каршы баш күтәрүләргә китергән. Төрле төбәкләрдә яисә аерым халыкларда «бунт»лар даими булып торса да, алар хөкүмәт

[1] *Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия (история и проблемы). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С. 342.

тарафыннан бик тиз һәм аяусыз бастырылган. Шулай да Россиянең якындагы тарихында Разин восстаниесе (1670–1671), Батырша восстаниесе (1755–1756), Пугачев восстаниесе (1773–1775) кебек баш күтәрүләр җитди тарихи вакыйга булып тора. Бу аларда төрле халык вәкилләреннән күп кеше катнашу, вакыт ягыннан сузылулары һәм Россия җәмгыятенә, патша властена йогынты белән аңлатыла. Әлеге вакыйгаларда татарлар актив катнашып, аерым төбәкләрдә яисә отрядларда төп көч булып, араларыннан осталыклары белән аерылып торган җитәкчеләр чыккан. Татарларның бу хәрәкәтләрдә катнашуының төп сәбәбе патша власте алып барган сәясәт белән бәйле. Рус дәүләте Казан ханлыгын басып алганнан соң башланып киткән христианлаштыру һәм руслаштыру күренеше бер көчәеп, бер кимеп XVIII гасырга кадәр дәвам итә. Ул исә каршылык күрсәтүчеләрнең җирләрен тартып алу, гаиләләрне аеру, башка җирләргә күчеп китәргә мәҗбүр итү кебек нахак рәнҗетелү белән бәйле була. Шуңа да татарлар гаделлек, дин иреге, тигезлек таләп итеп, баш күтәрүчеләр арасында алгы сафларда була.

Т. Миңнуллинның «Канкай углы Бәхтияр» тарихи драмасында XVIII гасырдагы крестьяннар баш күтәрүенә бәйле хәл-күренешләр сурәтләнеп, үзәккә Пугачев гаскәрендә полковник булып хезмәт иткән Бәхтияр Канкаев шәхесе тора. Әсәрнең прологы ролен үтәгән беренче күренештә төп геройлар белән очрашабыз. Урман аланына җыелып ял итүче, төн кунучы лашманчылар лагерена әледән-әле сәфәр чыккан мосафирлар килеп чыга. Шундыйларның берсе (укучы-тамашачы алдагы күренешләрдә аның Пугачев булуын беләчәк) аз сөйләшүе, әмма һәрбер сүзенә ниндидер мәгънә салынган булуы белән аерылып тора. Икенчесе үзен Кунгур ягына юл тотучы Бәхтияр Канкаев дип таныштыра. Аларның әңгәмәсе геройлар белән таныштыру һәм киләчәк вакыйгаларны аңлауга әзерлек ролен үти. Оренбург ягына юл тотучы Пугачев үзенең бу тирәгә килеп чыгуын болай аңлата: *«Казан каласында читлектә идем – читлекләре тар булды. Шундый иркен дөнья барында тар читлеккә бөркет ничек сыйсын. Тау бөркете кыя эзли, дала бөркете дала-*

*сына оча»*[1]. Шул рәвешле, беренче күренештә үк Пугачев ирек сөюче, көчле-гаярь, нык характерлы, үзен горур бөркет белән чагыштыра алучы чын ир-ат булып күзаллана. Шуның дәвамы буларак, Пугачев белән Бәхтияр диалогы бу ике кешенең теләк-омтылышлары якынлыгын һәм моның киләчәктә аларны якынайтасын аңларга ярдәм итә:

*Бәхтияр. Мин адашмадым. Мин эзлим.*

*Пугачев. Нәрсә эзлисең.*

*Бәхтияр. Хаклык.*

*Пугачев. Таптыңмы соң.*

*Бәхтияр. Юк.*

*Пугачев. Юк. Эзләп табылмый хаклык. Хаклыкны эзләмиләр, туган. Хаклыкны тартып алырга кирәк*[2].

Бәхтиярне күбрәк ачу, шәхси сыйфатларын киңрәк бәяләү өчен, автор аның хатын-кызга мөнәсәбәтен ача. Ул ире тарафыннан байга сатылып та, аныкы булырга теләмәгән хатынны һәртөр мәҗбүрилектән коткара. Әлеге күренештә Бәхтияр үзен гайрәтле, киң күңелле ир итеп таныта. Нурсолтанны явызлардан аралап алуы, аңа күңелен ачуы аны укучы-тамашачы каршында үстерә, якынлык хисе тудыра.

Пьесаның иҗтимагый-тарихи катламын Бәхтияр Канкаевның халык бәхете өчен көрәшкә чыккан шәхес буларак үсү тарихы алып тора. Иштуган сотнясындагы көрәшче Канкай углы Бәхтияр яшь вакытта мәдәрәсәдә укый. Киләчәген яшь буынга аң-белем таратуга багышларга уйласа да, тормыш шартлары аңа башка язмыш әзерли. Ул һәркайда гади халыкның мохтаҗлыгы, хокуксызлыгы, ә боярларның комсызлыгы белән очраша. Бу хәлнең сәбәбе аерым кешеләрдә булмыйча, хакимияттә яшәп килгән тәртипләрдә икәненә төшенә бара. Шуңа да Петр Өченче дигән патшаның халыкка җир-су, ирек вәгъдә итеп язылган Манифесты Бәхтиярне кузгатып җибәрә һәм ул крестьяннардан отряд оештырып, бояр утарларын туздырып йөри башлый. Үзенең бу адымын болай аңлата: *«Минем атамны кызганмадылар,*

---

[1] *Миңнуллин Т.* Канкай углы Бәхтияр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 212.

[2] Шунда ук. – Б. 213.

*җиреннән кудылар. Мин ул талаучының утарын яндырдым. Качтым, нужа чиктем, бәгырем катты, төннәрен юлбасарлыкта йөрдем. Инде көн килде. Үзебезнең падишабыз исән калган. Ул безгә җир-су бирә, түләүләрдән коткара»*[1].

Бәхтияр баш күтәрүнең ахыр нәтиҗәләрен ачык күз алдына китермәсә дә, ирекнең һәр көне, һәр мизгеленең кадерен белә. Гаделсезлеккә, хокуксызлыкка каршы күтәрелгән крестьяннарның зур көч булуын ачык күрә, аларга дөрес юнәлеш күрсәтүне бурычы дип саный: *«Бу дәрья – мәңге кипмәс дәрья. Ул дәрьяны дистә меңләгән елга, чишмәләр туендыра. Ул чишмәләрне ачучылар без»*[2].

Бәхтияр Канкаевның үзен патша Петр Өченче дип белдергән Пугачев белән очрашуы да игътибарга лаек. Патшасына баш иеп буйсынуын белдергән Бәхтияр баш киемен салмый. Пугачев аннан үзен шулай ирекле тотуының сәбәбен сорагач, горур Бәхтиярнең мондый җавабын ишетә: *«Бөек падишаһыбыз, татарның кәләпүше башыннан башы белән бергә генә салына»*[3].

Бәхтиярнең уй-фикерләре, теләк-омтылышлары муллалыгын ташлап аларга кушылган Әбүбәкер Теләчев белән әңгәмәләрендә ачыла. Әбүбәкернең гаделлекне кан түгеп урнаштыруга каршы чыгуын да тирән аңлый ул. *«Кылыч булган җирдә кан түгелә. Ләкин ул кан изге эш өчен түгелә»*[4], – ди Бәхтияр башка юл юклыгына ишарәләп. Баш күтәрүчеләрнең җиңелә баруын, патшаның регуляр гаскәрләренә каршы тора алмавын, үзләрен я үлем, я каторга көтүен дә яхшы аңлый ул. Әмма күңелендә үкенү хисе юк. Көрәштә үткән бер ел вакытны ирektә кеше булып яшәү чоры дип бәяли. Соңгы көрәшкә ташланыр алдыннан, үзенең гаскәренә болай дип мөрәҗәгать итә: *«Максатым изге булды. Җир юклыктан, су юклыктан интеккән, ирек юклыктан тыны кысылган кара халыкны – сезләрне яклап яу чыктым. Һәм кылган эшләремә бер кәррә дә үкенмим. Әгәр Бәхтиярнең*

---

[1] *Миңнуллин Т.* Канкай углы Бәхтияр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 228.

[2] Шунда ук. – Б. 251.

[3] Шунда ук. – Б. 244.

[4] Шунда ук. – Б. 245.

*үлеме йөзләрне әҗәлдән коткара икән – монысы минем өчен зур бәхеттер»*[1].

Пьесадагы ирек өчен көрәш рухы Пугачев образы белән дә тыгыз бәйле. Әлеге Җаек буе казагы михнәттә яшәгән халыкны ирек өчен көрәшкә күтәрә. Кешеләр күңелендә яхшы патша килеп, һәркемне бәхетле итәр дигән хыял яшәвен ул яхшы белән. Шуңа да үзен халык мәнфәгатен яклавы өчен хакимияттән куылган Петр Өченче дип игълан итә. Вакыйгаларда ул гаделлекне яклаучы, дошманнарына рәхим-шәфкатьне белмәүче булып ачыла.

Бәхтиярнең рухи дөньясын ачуга хезмәт итүче икенче катламда Нурсолтанга булган хис-кичерешләре чагылыш таба. Үзе теләмәгән кеше белән бергә булудан баш тарткан хатынга ул чын-чынлап гашыйк була. Әмма монда да әхлакый таләпләрне сакларга омтыла. Автор ирнең күңел кичерешләрен шактый уңышлы ача Ул, бер яктан, Нурсолтанны бәхетле итә алмаячагын да аңлый, шуңа да хатынның ире янына китәргә теләвенә каршы килми, икенче яктан, хисләрен тыя алмыйча, аңа тартыла. Әлеге күренешләрдә ул ярата һәм яраттыра белүче гади кеше булып калка.

Пьесада кан коешка китергән сәбәпләрне ачуга киң урын бирелә. Бәхтияр күңелендә дә соңгы максатка бәйле икеләнүләр юк түгел. Билгеле күпләр үзләрен туендыручы җир-су өчен сугыша. Әмма автор болардан да өстенрәк әйбер барлыгына аерым басым ясый. Моны ул Пугачев полковникларының берсе булган башкорт Кинҗәдән әйттерә: *«Адәм баласына иң кирәге – ирек. Ирек! Җан иреге, рух иреге. Җанга ирек булмаса, һай авыр, Бәхтяр туганым. Минем җирем дә, суым да бар иде, тамагым тук иде. Рухыма ирек җитми иде, читлектәге кош кеби иде. Әгәр дә син бүтәннәр кеби үк Адәм илә Һәваның газиз баласы булып та, сиңа үги балага караган кебек кимсетеп карасалар, кыерсытсалар, телеңне киссәләр, динеңне-иманыңны таптасалар, тамак хәсрәте онытыла, туганым».* Әлеге сүзләр пьесаның төп идеясен ачуга хезмәт итү белән бергә, тарихилык белән заманчылык төшенчәләрен үзара тыгыз бәйләнештә кабул

[1] *Миңнуллин Т.* Канкай углы Бәхтияр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 264.

итү мөмкинлеге бирә. Шул рәвешле, драматург татар халкының күпгасырлык теләк-омтылышларын тирән аңлап, азатлык көрәшенә чыккан тарихи шәхеснең гыйбрәтле образын иҗат итә.

* * *

Ерактагы төрки-татар тарихында әдәби иҗатлары белән киң танылу алып, халык хәтеренә кереп калган шәхесләр күп булса да, Казан ханлыгыннан соңгы чорда, кызганыч ки, андыйларның исемнәре күп сакланмаган. Моның сәбәбе дәүләтчелек белән бәйле. Бу урында Казан ханлыгы чорында яшәп иҗат иткән Кол Шәрифне атау урынлы булыр. Ул дәүләт җимерелгәннән соң, татар халкы коточкыч физик һәм рухи торгынлыкка дучар ителә. Әлеге шартларда ниндидер тарихи вакыйгада катнашып танылу мөмкин булмый диярлек. Андый бик азлар арасыннан иҗат белән дә шөгыльләнгән милли азатлык көрәшчесе Батырша калка, М. Колый, Г. Утыз-Имәни исемнәре танылу ала. Бары XIX гасырда гына татар халкының иҗтимагый-фәлсәфи фикерендә җитди алга китеш урын алып, Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри кебек шәхесләр үсеп чыга. Алар ислам динен заманга яраклаштыру, татар халкын аң-белемле итү, галәмдә үз урынын аңлау, барлау, башкалар белән тигезлеккә ирешү юнәлешендә җитди эш башкара. Uяну хәрәкәте буларак формалашкан мәгърифәтчелек алга таба теләк-омтылышларны гамәлгә ашыруны күздә тоткан җәдитчелеккә үсеп әверелә, башкаларны әйдәп барырлык шәхесләр тарих аренасына чыга. Нәтиҗә буларак, XX гасыр башында татарлар милләт буларак формалашып җитә.

XX гасыр дәвамында иҗаты белән илдә яисә төрки дөньяда, аерым төбәкләрдә киң танылу алган байтак язучыны атый алсак та, арада Тукай һәм Җәлил исемнәре мәгърур кыя булып калка. Тукай, татар милли әдәбиятына нигез салучыларның берсе буларак, XX йөз башындагы Яңарыш хәрәкәтен әйдәп баручылардан була, әдәби эчтәлек һәм формада, тема-мотивларда, сүз-сурәт тудыру алымнарында яңалык алып килеп, әдәбиятны үзгәртүгә җитди өлеш кертә, яңа традицияләргә нигез сала. Иҗаты, татарлар белән бергә, күпсанлы төрки халыкларның

әдәби-мәдәни тормышына гаять көчле тәэсир итеп, аларда да киң танылу ала. Милләт гаме белән сугарылган әсәрләренең кыйммәте вакытлар үтү белән арта барып, ул татар халкы яшәеше символына әверелә.

М. Җәлил тормышы һәм иҗаты Бөек ватан сугышы елларында фашизмга каршы көрәше белән киң танылa. Илдә вакытта ук шагыйрь буларак танылу алган М. Җәлил яраланып әсирлеккә эләгә һәм, концлагерьлар аша үтеп, татар легионына языла. Шул шартларда ул, яшерен оешма әгъзалары белән бергә, әсирләр арасында аңлату эшләре алып бара, нәтиҗәдә Көнчыгыш фронтка җибәрелгән ике легион, немец офицерларын юк итеп, Белоруссия партизаннарына кушыла. Әмма М. Җәлил һәм аның иптәшләре кулга алына һәм Германиянең империя суды тарафыннан үлемгә хөкем ителә. Төрмә шартларында ул үлемсез шигырьләрен яза. «Моабит дәфтәрләре» күп телләргә тәрҗемә ителеп, фашизм белән көрәштә үтерелгән шагыйрьнең үлемсез шигырьләре символы буларак илебездә, Европа илләрендә киң билгеле була. Фашизмга каршы көрәштәге батырлыгы өчен М. Җәлил Советлар Союзы Герое исеменә (1956), ә «Моабит дәфтәрләре» циклы СССРның Ленин премиясенә лаек була. Ул дәүләтнең мондый ике иң зур бүләген алган бердәнбер кеше булып кала.

Татар халкы, башкалар белән бергә, бу ике исемне хәтерендә кадерләп саклый, аны алдагы буыннарга җиткереп килә. Әдәбият һәм сәнгатьтә Тукай һәм Җәлилгә багышлап күпсанлы әсәрләр иҗат ителгән. Т. Миңнуллин да бу ике зат турында әсәр язып, әдәби образларын тарихта калдыру турында уйлана. *«Безнең тарихтагы бөтен затлы исемнәрне дә санап тормастан, бу очракта мин Тукай һәм Җәлил исемен генә атар идем. Белмим, кайчан тугандыр ул фикер, мин шушы ике бөек зат турында ике пьеса язарга тиешмен, дигән карарга килдем. Дөньяга үз сүзен әйтергә дип кулына каләм алган һәр кешегә, иҗатчы буларак, әлеге икәүгә үз мөнәсәбәтләрен белдермичә калу гөнаһ булыр сыман. Чөнки алар – безнең яшәвебезнең, иҗат итүебезнең эталоны, без үзебезнең кыйблабызны аларның намусы, батырлыгы, фидакярлеге белән билгеләсәк кенә*

*нигә дә булса ирештек дип әйтә алабыз»[1],* – дип яза драматург бу турыда. Аның батырлык, намус, туган җиреңне, илеңне ярату кебек төшенчәләр турында уйланулары әдәби әсәр булып кәгазьгә төшә. «Нинди генә хәлдә дә гаярь ир, чын кеше булып калу, илаһи кыйммәтләр дигәндә, үз-үзеңне аямыйча, җаныңны фида кылып яшәү дәрәҗәсенә күтәрелү – болар нindидер гайре төшенчәләр түгел, ә бәлки гап-гади кеше тормышының аерылгысыз бер өлеше, алардан башка тормыш бармый, барырга тиеш тә түгел. Туфан Миңнуллин әнә шуларны табигый итеп сурәтли белә»[2], – дип яза А. Габәши-Салихова.

«Моңлы бер җыр» публицистик драмасында Т. Миңнуллин, шартлы-абстракт алымнардан файдаланып, бүгенге заманның яшь шагыйрен хыялында легендар шәхес Муса Җәлил белән очраштыра. Алгы планга вакыйгалылык түгел, бәлки уй-фикер көрәше чыга. Аларның диалог-монологларында, шулай ук Җәлилнең дуслары һәм дошманнары белән очрашуларда яшәү һәм үлем, батырлык һәм хыянәт, үлем һәм үлемсезлек турында фәлсәфи бәхәс бара. Драматург үзе пьесаның язылу тарихын болай билгели: *«Әсәрдә беренче планга биографик мәгълүматлар түгел, публицистика чыгарга тиешлегенә мин инанган идем. Әнә шул публицистик сүзнең тамаша залында утыручыларның күңел кылларына орынып, аларны тибрәтү алымын табарга кирәк иде. Шул алымны озак эзләдем. Шулай килеп чыкты – язганда үзем белән үзем бәхәсләшергә керештем. Ил, Ватан, халык алдындагы изге бурычларыбызны үтәр өчен Җәлил фидакярлеге бездә бармы? Намус, вөҗдан турында уйланганда вариантлар эзләмибезме? Мин бүгенге заман шагыйре образына кереп, әнә шундый четерекле сорауларга җавап эзләдем»[3]*.

Пьеса заман шагыйренең Җәлил иҗатына ачкыч булып хезмәт иткән «Җырларым» шигыреннән өзек уку белән башла-

[1] *Миңнуллин Т.* «Моңлы бер җыр» // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 8 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 40.

[2] *Габәши-Салихова А*. Иҗатында – ил гаме // *Миңнуллин Т.* Пьесалар / кереш сүз авт. А. Габәши-Салихова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 8.

[3] *Миңнуллин Т.* «Моңлы бер җыр» // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 8 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 41.

на: *«Гомерем минем моңлы бер җыр иде»*[1]. Моңлы җырга әйләнгән шагыйрь гомеренең таяныч-терәге, батырлыгының нигезе нәрсәдә? Бу сорау әсәрдәге барлык күренешләрне, геройларны иңләп үтә. Җавап эзләгән Шагыйрь каршында Муса Җәлил гади-гадәти, бераз серле булып, әмма иленең киләчәген ачык күзаллаган, үзенең хаклы булуына нык ышанган шагыйрь булып ачыла. Муса үзен борчыган, дөресрәге, үлемгә барганда белә алмаган сорауга җавап эзли: *«Туган илемдә кем булачагымны белә алмый дөньядан киттем»*[2]. Ә инде Шагыйрь аның шигырьләрен сөйли башлагач, шатлыгын яшерә алмый. Һәрбер шагыйрь өчен иң зур бүләк булып яңгыраган сүзләрне әйтә: *«Киләчәк буын шагыйре минем шигыремне яттан сөйли»*[3]. Әмма әлеге очрашу алдагы сорауга җаваптан бигрәк, яңа сораулар тудыра. *«Сезне аңлыйсым килә, җаныгызны, рухыгызны аңларга телим. Сезне бөеклеккә күтәргән көчнең сере кайда? Шуны эзләп азапланам. (...) Төрмәдә үлем җәзасы көткәндә ничек инде шаян шигырь язып утырырга мөмкин. Палач балтасы астына башны салганда ничек елмаерга мөмкин? Аңлый алмыйм мин боларны, Муса абый, акылыма сыймый»*[4], – ди Шагыйрь Мусага.

Шагыйрь хыялында, җавап эзләп, төрмәдә Муса белән бер камерада утырган Италия гражданины Рениеро Ланфредини янына килә. Ул исә гыйбарә булып тарихта калган «Татарлар елмаеп үлделәр» дигән сүзләрне әйтә. Т. Миңнуллин әсәрне язган чорда дингә ышану, Аллаһы Тәгалә сүзе кире кагылып килә. Шуңа да автор Мусаны атеист итеп сурәтли. Ланфредини аның берничә сыйфатын аерып күрсәтә: көчле рухлы булуы, төшенкелеккә бирелмәве, кылган эшләре өчен үкенмәве, киләчәккә омтылып яшәве. Җәлилчеләрнең елмаеп үлүе, ул – алар яклаган туган илгә тугрылык, гаделлек, намус һ.б. идеяләрнең мәңгелек булып, палач балтасы үтерә алмаслыгын аңлау, шуңа ышану чагылышы.

---

[1] *Миңнуллин Т.* Моңлы бер җыр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр. 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 362.

[2] Шунда ук. – Б. 364.

[3] Шунда ук. – Б. 365.

[4] Шунда ук. – Б. 368.

Җәлилчеләрнең үлемгә елмаеп баруын башкача да аңлату бар. М. Җәлил һәм аның иптәшләренең барысы да диярлек дини карашлар урын алган гаиләдә үсә. Мәдрәсәдә уку аларны ислам дине, Коръән тәгълиматы белән таныштыра. Чор рухында алар дини таләпләрне үтәмичә, дөньяви яшәешкә өстенлек бирсәләр дә, Аллаһы Тәгаләгә тел-теш тидермиләр. Ә инде озак вакыт төрмәдә үлем көтеп утыруга бәйле, күңелләрендә дини карашлар киңрәк урын алган булуы ихтимал. Җәлилчеләрнең елмаюы, Шәрык әдәбиятында чагылдырылганча, төрмә михнәтләреннән интеккән җанның иреккә чыгып, теге дөньяда Ходай янына очу, аның белән якынаю шатлыгы чагылышы да булырга мөмкин.

Ланфредини тәкъдиме белән Шагыйрь Мусаның дошманнары белән дә очраша. Көнчыгышта басып алынган җирләр белән идарә иткән, җинаятьләре өчен Нюрнберг Халыкара суды тарафыннан үлемгә хөкем ителгән Альфред Розенберг җәлилчеләр батырлыгын «фанатизм» дип атый. Ә менә «Идел-Урал штаты» Президенты Шәфи Алмас Мусаны һәм аның көрәштәшләрен батыр булудан бигрәк, *«Алласыз мескеннәр. Саташканнар. Милләтсез, кыйбласыз кыргыйлар»*[1] дип саный. Җәлилчеләрнең серләрен дошманнарга саткан Хаинның үз фәлсәфәсе: *«Сатканмын икән, җанымны иң кадерле нәрсә – яшәү бәрабәренә саттым»*[2]. Кешеләр гомерен өзүче Палач кешеләр башын марка белән бәяләүче булып тора. Аның өчен кешелек гасырлар дәвамында туплаган кыйммәтләр берни түгел. Әнә ул хатынының акушерка буларак бала табарга ярдәм итүен, үзенең адәмнәр гомерен юк итүен ниндидер бер масаюлы интонация белән Шагыйрьгә җиткерә. Кеше канын коючы гаиләсендә кадерле, ягымлы кеше, яраткан əти дә икән. Әнә шул рәвешле, драматург Шагыйрьне дөньяга өч төрле караш, өч төрле яшәү рәвеше белән очраштыра. Алар барысы да М. Җәлилне һәм җәлилчеләрнең көрәшен аңламый, кабул итми. Ә моның артында исә үз мәнфәгатен яклау, үз рәхәте өчен яшәү һәм шуның өчен теләсә нинди түбәнлеккә барырга әзер булу дигән гап-гади фәлсәфә ята.

[1] *Миңнуллин Т.* Моңлы бер җыр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр. 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 374.

[2] Шунда ук. – Б. 382.

Капма-каршы көч буларак Розенберг, Хаин, Палач карашлары укучы-тамашачыда бары чиркану хисе уята. Ә менә Ш. Алмас белән мәсьәлә катлаулырак. Драма язылган елларда әлеге кеше немецлар ягында торып, совет иленә каршы көрәшкән дошман буларак билгеле иде. Тарихчы галим И. Гыйләҗевнең «Легион “Идель-Урал”. Представители народов Поволжья и Приуралья под знаменами “третьего рейха”» (2005) хезмәтендә татар легионнары, аларны оештыруда «Идел-Урал штаты» оешмасы вәкилләренең роле турында мәгълүмат бирелә[1]. Әлеге кеше дә үзенчә татар халкын якларга һәм сакларга тели. *«Татар булгач, татар өчен көрәшергә кирәк. Ул үз гражданнарын җәзалап үтерүче илне ватаным дип атады. Аны ят иткән ил белән горурланды. Шул кыргыйлар иле өчен үлде»*[2], – ди ул М. Җәлил сайлаган юлны тулысынча кире кагып. Әмма әлеге кеше үз максатына ирешү өчен явызлыкка таяна. Бу – аның хатасы һәм фаҗигасы.

Драмада күп урынны Шагыйрьнең җәлилчеләр – Абдулла Алиш, Гайнан Кормаш, Абдулла Батталов, Фуат Булатов, Әхмәт Симаев, Гариф Шабаев, Зиннәт Хәсәнов, Фуат Сәйфелмөлеков, Әхәт Аднашев, Сәлим Бохаров – белән әңгәмәсе алып тора. Бу аңлашыла да, чөнки бер кеше батырлыгы гаҗәеп үрнәк, аерым бер феномен буларак кабул ителә. Ә инде дистәдән артык кеше уртак уй-фикер белән яшәп, ватан азатлыгы өчен икеләнүсез гомерен бирә икән, моның сәбәпләре тирәндә булып, туган җиргә, халыкның милли сыйфатларына, теләк-омтылышына барып тоташа.

Әлеге гаҗәеп кешеләр белән очрашкан Шагыйрь, үзе дә сизмәстән, аларны замандашлары белән чагыштыра башлый. Үзе яшәгән җәмгыятьтәге каршылыклар, кешеләрдәге үзгәрешләр турында борчулы уйлары белән Шагыйрь янәдән Муса Җәлилгә эндәшә: *«Әллә ваклandык микән без, Муса абый? Бәлки, без рухыбыз белән, иманыбызның ныклыгы белән Сездән бик түбәндер? Сезне бөек иткән көч бездә юктыр? Уйлануларыбыз*

---

[1] *Гилязов И.А.* Легион «Идель-Урал». Представители народов Поволжья и Приуралья под знаменами «третьего рейха». – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – С. 260–296.

[2] *Миңнуллин Т.* Моңлы бер җыр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 374.

*да чын түгелдер, кылану гынадыр? Әллә соң безгә ваемсызлык, үшәнлек чире йоктымы? Кеше рухының көчен, кешенең иле, халкы алдындагы иң изге бурычларын аңламас хәлгә җиттекме? Яшәүнең мәгънәсе тарайдымы? Сезнең фидакярлеккә авыз ерыбрак карарга өйрәндекме? Тормыштан кәмит эзләргә генә күнегеп барабызмы? Яшәү бит бүген дә җиңел түгел, яшәү бервакытта да җиңел булмаячак. Тормыш бездән дә көн саен имтихан ала. Сездәге рух булмаса, бөек имтихан алдында каушап калмабызмы?»*[1] Бу сорауларның укучы-тамашачы өчен дә куелуын аңлау кыен түгел. Ә иң мөһиме: алар киләчәк буыннарга аталган. Менә ни өчен әлеге драма бүген дә заманча яңгырый. Татар халкының бүгенгесе һәм киләчәге җитди борчулар тудырган вакытта, «Син һәм мин милләт өчен нәрсә эшли алабыз? Син һәм мин мөмкин булганны эшләдекме?» дигән сораулар һәркайсыбыз алдында тора бит. Алардан читләшү өчен сәбәпләр җитәрлек. Ә җавап Муса сүзләрендә: *«Вөҗдан, намус бер генә бит ул, энекәш, вариантлар юк»*[2].

Шагыйрь хыялында туган Рәхимә әбинең улы Мусага васыятендә Җәлилнең һәм җәлилчеләрнең рухи көче чыганагы бөтен тулылыгында чагыла: *«Илеңне, телеңне, халкыңны, моңыңны онытма. Үз моңын оныткан – бүтәннәр моңын ишетми башлый. Иманыңнан яза күрмә. Боларны мин сиңа әйтәм, син бүтәннәргә әйт. Бүтәннәр үзләреннән соң килгәннәргә әйтеп калдырсын»*[3]. Мусаның бөтен тормышы, фашизмга каршы көрәше һәм үлемсез иҗаты әлеге васыятькә тугрылык үрнәге булып тора. Ул үзе дә – киләчәк кешесе, чөнки әсәрләрендәге уй-фикер зурлыгы, хис-кичереш байлыгы, рух хөрлеге, бигрәк тә үлем белән үлемсезлекне яулау идеясе, яшәү мәгънәсенә әверелеп, укучы-тамашачы күңеленә сеңә һәм аның иманын ныгыта, алга, киләчәккә дәшә.

Заман кешесенең алгы планга чыгарылуы Җәлил һәм җәлилчеләр батырлыгының тирән тамырларын ачу, алар батырлы-

---

[1] *Миңнуллин Т.* Моңлы бер җыр // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 376.

[2] Шунда ук. – Б. 377.

[3] Шунда ук. – Б. 381.

гына үз чорыннан һәм әсәр язылган көн биеклегеннән торып мөнәсәбәт белдерү мөмкинлеге бирә. Шул рәвешле, Т. Миңнуллин шартлы чаралар, жанрлар синтезы ярдәмендә җәлилчеләр батырлыгын кабат тергезә һәм аларның, намус белән ил-халык каршындагы бурычларын үтәп, башны горур тоткан хәлдә мәңгелеккә атлавын «моңлы бер җыр» буларак тасвирлый.

* * *

«Без китәбез, сез каласыз» драмасында Тукайның 1909 елда Идел буенда мануфактура фабрикалары белән дан тоткан миллионер Акчуриннарга сәфәре сурәтләнә. Пьеса үзенең тарихи җирлеге белән үк игътибарга лаек. Шагыйрь әлеге сәфәр турында ниндидер истәлек калдырмаган, моның сәбәбе дә билгеле түгел. Икенче яктан, берни язып калдырмаган икән, димәк, аның күңеленә тәэсир итеп, билгеле бер уйлануга, фикер алышуга китермәве, үзе үк Тукай сәфәренең аның өчен нәтиҗәсез булуы, аннан күңеле төшеп кайтуы турында сөйли. Шул ук вакытта әлеге сәфәр эзсез калырга да тиеш түгел, чөнки бу – шул чорда татарның иң билгеле шагыйре Габдулла Тукай һәм Россия дәрәҗәсендә танылу алган, мәктәп-мәдрәсәләр ачулары белән дан казанган Акчуриннар очрашуы. Алар атна дәвамында аралашкан. Әлеге шәхесләр нәрсә турында сөйләшеп, әңгәмә корды икән? Тукай тормышы һәм иҗаты белән таныш булган һәркемдә бу сорау кызыксыну тудыра. Тукай турында әсәр язуны бурычы дип санаган Т. Миңнуллинны бу вакыйганың җәлеп итүе дә шуның белән аңлатыла, күрәсең.

Вакыйгалар барышында Тукайның бертуган Акчуриннар, элекке танышы музыкант Кыяметдин, авыл малае Абдулла белән очрашу-әңгәмәләре сурәтләнә. Аларда сүз яшәешнең төрле якларын иңләп алу белән бергә, татар тормышын үзгәртү, аны тәрәккыят итү мәсьәләсенә барып тоташа.

Т. Миңнуллин әлеге вакыйганы үз чорыннан торып чагылдыра, без исә XXI гасыр башыннан торып бәялибез. Бу XX гасыр башы татар тормышын аңлау-бәяләүдә, нәтиҗәләр ясауда төрле чорлар, буыннар мөнәсәбәтенә бәйле билгеле бер каршылыкка китерә.

Тукай бу сәфәргә Ф. Әмирхан кушуы буенча барганлыгын үзе үк әйтә. Беренче күренешләрдә үк ул үзен иреклe тотып, беркемгә дә яраклашмыйча сөйләшүе, бу кешеләргә күңеле тартмаса, үзен мәҗбүр итеп, очрашуны кабул итүе сизелеп тора. Алга таба әлеге каршылык үсә барып, тышка да бәреп чыга, бер-берсенә шактый усал, тупас сүзләр дә әйтелә. Фикер төрлелегенә, яшәү рәвешенә бәйле каршылык булса да, төп конфликт икенче катламда, ул һәрбер катнашучының рухи дөнясы, үз-үзе белән канәгатьсезлегеннән килеп чыга. Төп геройларның берсе дә үзен бәхетле итеп сизми, һәрберсенең күңелен канәгатьсезлек, өмет катыш сызлану хисе били.

Тукайны кунакка чакырган Хәсән Акчурин – үзенең либераль карашлары белән киң танылу алган кеше. Аның әлеге очрашуга алдан ук әзерләнгәнлеге күренеп тора. Ул кат-кат Тукайга хөрмәт белән караганлыгын, шагыйрь иҗатын яхшы белүен, эш-гамәлләренең халык мәнфәгатен яклауга юнәлтелгәнлеген әйтә. *«Ашау-эчү – ачларга тансык, уен-көлке – гамьсезләр шөгыле. Сез – бүгенге көндә милләтебезнең уйчан бер баласы. Сез аерым хөрмәт вә игътибарга лаек, – ди ул Тукайга. – (...) Безнең татар әле сезне бәяләп бетерә алмый, үз илендә пәйгамбәр булмый, дип кемдер әйткән бугай»*[1]. Х. Акчурин шагыйрьнең «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» дигән мәкаләсеннән этәрелеп китеп, әлеге очрашуга китергән төп сорауны алга куя: Татар милләтен ничек уятырга? Хәсән бай мәсьәләнең катлаулылыгын, шул ук вакытта гаять мөһимлеген яхшы аңлый. Аның фикеренчә, татар милләтен яңарышка китерүнең өч юлы бар. Беренчесе татарны аң-белемле итү, мәгърифәткә чакыру белән бәйле, әмма бу рәвешле милләтне уятып булмый. Икенче юлны социал-демократ Х. Ямашев тәкъдим итә икән – алар дөньяны, яшәп килгән тәртипләрне җимерү ягында. Х. Акчурин бу юлны да кире кагып, халкыбыз шул җимерелгән хәрабәләр эчендә күмелеп калмасмы дип борчыла. Хәсән бай үзе өченче юл яклы булып, аның нигезен «байлар милләтнең арка терәге» дигән фикер тәшкил итә. Халык арасыннан күп санлы байлар,

[1] *Миңнуллин Т.* Без китәбез, сез каласыз // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 335.

миллионерлар үсеп чыгу милләтне ил, хәтта дөньякүләм танытуга китерә. Бу исә киң процесс булып, бөтен халык массасын кузгатып җибәрә, дип саный ул. *«Татарларны бигүк санлап бетерми торган хөкүмәт тә кулларында зур капитал булган милләт белән санлашырга мәҗбүр булачак*, – ди Хәсән бай һәм фикеренә мондый ачыклык кертә, – *әгәр безнең кебекләр милләтнең матди ягын күтәрсә, сез – рухани ягын»*[1].

Татар милләтен уяту өчен Хәсән бай Акчурин тәкъдим иткән юлны Тукай кабул итми. *«Баер өчен кемдер эшләп тапканны кемдер талап алырга тиеш»*[2], – ди ул, мәсьәләгә сыйнфый төсмер биреп. Тукай фикеренчә, байлар төрле халыкларны тигез итеп талау ягында булса, ул үзе малны тигез итеп, гадел итеп бүлү ягында тора. Шагыйрь милләтне уяту мәсьәләсендә төрле халыклар тигез һәм бердәм булып, һәр халыкның хокукларын саклап эш итү кирәклеген яклый. Менә шуларны аңлатып кына халыкны уятырга мөмкин дигән караштa тора.

Тукай сәясәт белән максатчан кызыксынмаган. Шигырьләрендә Дәүләт думасына карата үткен сатирасыннан тыш, бу мәсьәләдә, теге яисә бу позициядән торып, мөнәсәбәтен белдерү очрамый диярлек. Ә менә югары катлам вәкилләрен Тукай өнәп бетермәгән, монысына язмаларыннан, хатларыннан мисаллар шактый табыла. Т. Миңнуллин, билгеле, шуларга таяна һәм Тукай белән Хәсән Акчуринны каршылыкта сурәтли. Шулай да драматург үз чоры идеологиясеннән дә котыла алмаган, күрәсең. Тукай авызыннан әйттергән кайбер фикерләрнең бүген инде башкача кабул ителүен күрәбез. Хәсән Акчурин сүзләрендә хаклык булуын да танырга кирәк.

Ике билгеле шәхеснең милләт язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшү үзәк мәсьәлә булса да, автор Тукайның уйлануларын, шәхси кичерешләрен, борчуларын читләтеп үтә алмаган. Елга ярында, табигать кочагында калып, бер малай белән әңгәмә корганда, Тукай ачылып китеп, бөтен җанын бушата. Ә анда әрнү, газаплану... *«Мин дә бу җиһанга көлеп*

---

[1] *Миңнуллин Т.* Без китәбез, сез каласыз // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 228.

[2] Шунда ук. – Б. 339.

*яшәргә дип яратылган идем. Көлмәкче булам – адәм балаларының сыкранып елаганнарын ишетәм дә туктап калам. Дөньяны акларга дип, пакьләргә дип килгән идем, керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым. Хыялларым олы иде, теләкләрем изге иде, инде хәзер...,* – ди ул икеләнүле халәттә. – *Кай тарафка карасам да, өметсезлек. Җанымның әрнүенә түзә алмый ачынып кычкырам – тавышымны ишетүче юк. Йөрәгемне ачып, әрнегән, кан саркып торган җанымны күрсәтмәкче булам – күрергә теләүче юк. Халкым, милләтем дип, күңелем сандугачын сайратам, көй көйлим, җыр чыгарам – кушылып җырлаучылар, көемне күтәреп алучылар юк. Зур өметләр баглаган милләтем төрткәләп тә уята алмаслык йокыга талган»*[1].

Шагыйрь үзенең иҗаты белән халкын уятырга һәм яңарышка әйдәргә тиешлеген яхшы аңлый. Бары шулай гына татар җәмгыятен үзгәртергә була. Әмма аны ишетүче, аның сүзенә колак салучы юк. Андыйларны шагыйрь өч төрле социаль катлауга бүлеп бәяли. Берләре, *«ашый-ашый бирәнгә сабышкан кап-корсаклары төшләрендә калҗа белән марҗа күреп кикерә-кикерә йоклый. Аларның йөрәген, җанын, вөҗдан-намусларын май баскан»*. (...) Икенчеләре, *«ачлыкта, фәкыйрьлектә изелгәннәре үз язмышларына үзләре разый булып, хәлсезләнеп, гафләт йокысы белән йоклыйлар»*. Өченчеләре, *«йокламаган әрсезләр, куштаннар, оятсызлар, саламторханнар милләт сатып көн күрә, кәсеп итә. Алар өчен тел дә, моң да, иман да юк. (...) Аталарының телен уллары, аналарының телен кызлары аңламый. Рух фахишлеге, җан фахишлеге»*[2].

Тукай татар җәмгыятенең әхлаксызлык, имансызлык сазлыгына батуына борчыла. Әнә балаларыбыз хәреф таныганчы, сүгенергә өйрәнә, милли көй урынына хисне рәнҗетә торган шалтыравыклар яңгырый, тавышсыз җырчылар сәхнәдән акырып, җанны кыйный. Мондый шартларда хакыйкать эзләүчеләр дә наданлык, ваемсызлык, гамьсезлеккә бәрелеп, юлларыннан читләшә. Шагыйрь фикеренчә, милләт йокыдан уянып күзен ачса,

[1] *Миңнуллин Т.* Без китәбез, сез каласыз // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 343.

[2] Шунда ук. – Б. 343–344.

үзенең хәлен аңлар иде. Ә бит аның тарихын йолкыйлар, бозып язалар, ул тарихка вәхшилек мөһере сугылган, ата-баба җирендә без килмешәк булып яшәргә дучар ителгән. Моннан котылу юлын эзләү өчен, боларга күзне ачып карарга һәм хакыбызны дауларга кирәк. Әнә шул рәвешле, драматург Тукайның XX гасыр башындагы борчулы уйларын милләтенең үз чорындагы хәле белән бәйли, шагыйрь сүзләре белән замандашларына эндәшә.

Драмада шул чорда татарда гына түгел, рус җәмгыятендә дә билгеле миллионер Акчуриннарны ачуга шактый урын бирелә. Әмма аларның яшәү рәвеше, гаилә әгъзалары белән күбрәк таныша барган саен, күңелдә билгеле бер сызлану хисе калка. Пьесада ачыктан-ачык әйтелмәсә дә, текст артында бу гаиләнең киләчәге юк, алар сүнеп бара, дигән нәтиҗә чыга. Дөрес, Хәсән бай Акчурин әлегә үз көчендә, либераль буларак татар җәмгыятенә дә йогынтысы көчле. Әмма ул инде олыгаеп бара, фабрика белән җитәкчелек итү кулыннан китеп, туганнарына тәэсире дә кимегәннән кими. Тукай аңа мондый бәя бирә: *«Мәдәни, прогрессив кеше булып уйный. Тулаем бай абзыйлар – уенга маһир халык. Акча чөеп тә уйныйлар, фиркаләргә әгъза булып кереп уйныйлар. Акча ул уйлата да, уйната да, хәлфә»*[1]. Югарыда әйтелгәнчә, тарих күзлегеннән караганда, бу бәя бигүк гадел түгел.

Якуб Акчурин пьесада үз катламының типик вәкиле булып ачыла. Ул ярлы халык белән уртак тел табуны түбәнлек дип саный. Аксөяк булуы (гәрчә ерак бабалары мужик булган) белән горурлана. Тукайны кабул итми, үзләренә тиң түгеллеген һәрдаим сиздерә. Тукай аңа мондый бәя бирә: *«Якуб куркыныч, ул ерткыч җанвар. Ул Абдулла түгел, өрмичә генә тешли. Ул хамелеондай төсен алыштырып тора. Мулла күрсә, укынып, попка очраса, чукынып йөри торган. Аның һәр сүзе саналган, һәр адымы фәлән тиен. Аның ишеләргә Пушкиның бер урыс, Тукаең "гололобый" гына»*[2].

Акчуриннарның кечесе Абдулла милли яшәештән киткән, күбрәк русча яисә французча гына сөйләшеп, хәмер эчеп,

---

[1] *Миңнуллин Т.* Без китәбез, сез каласыз // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 353.

[2] Шунда ук. – Б. 353.

вакытын рестораннарда шансонеткалар белән үткәрүче булып күзаллана. Ул бөтен нәрсәне, хәтта байлыкны да кире кага. Дөньяга карашын үзе болай аңлата: *«Надо уничтожить этот мир. До основания. Барысын да бетерергә. Бер генә кеше дә калмасын. Әгәр бер кеше исән калса, ул тагын дөньяны пычратачак. Человек хуже любого зверя»*[1]. Бу бәндә эшчеләрне колга саный. Шунда ук кол буласылары килмәсә, каршы чыксыннар дип тә акыл сата. Тукай аның кем булуын тиз аңлап ала һәм, сөйләшүдән баш тартып, бик тиз яныннан китеп бара. Ахырда бер сүз белән бәяли: «Ахмак».

Ә менә Әйшә Акчурина психологик яктан уңышлы ачыла. Ул гаиләдә мөселман тәрбиясе алган, әмма үзен моның белән чикләргә теләми. Ул шәхесен якларга тели, татар матбугатын укый, кызыксына. Аны гаилә кысалары белән чикләргә теләгән абыйсына кыю җавап бирә: *«Булса соң татар кызы! Булса соң мөселман! Әллә мин кеше түгелме? Үзегез генә җыеласыз да сөйләшәсез, мине бикләп куясыз»*[2]. Тукай шигырьләрен укып, күңеленә якын ала, кайберләрен шагыйрьнең үзенә дә сөйли. Гашыйк булып, аңа тартыла, аралашасы, сөйләшәсе килә, әмма шагыйрь әлеге чибәр кыз белән очрашудан кача. Шул уңай белән Тукайның хатын-кызларга мөнәсәбәте мәсьәләсе калкып чыга. Кыяметдин хәлфә белән әңгәмәсендә ул бу мәсьәләгә ачыклык кертә. Аралашудан качуы куркудан булмыйча, хатын-кызны хөрмәт итүдән, идеаллаштырудан, дип аңлата ул. Усал теле белән ярамаган сүз әйтеп, аларны рәнҗетүдән дә курка. Шагыйрь үзен шигърияткә багышлаган, бөтен барлыгы белән шуңа хезмәт итүче дип саный. Шул ук вакытта Тукай күңелендә ярату хисе булуын әйтә: *«Кем әйтте янмый дип? Мин бәлки күпләрдән артыграк янамдыр? (...) Мәхәббәт ул – илаһи хиссият. Аңа мәҗүсиләр агачка, үлән-чәчәкләргә, җиргә-суга, утка табынган сыман табынырга кирәк. Аны бары тик күңелеңдә, йөрәгеңдә генә сакларга кирәк. Саклый белмәсәң, табына белмәсәң, ул төссезләнә, ямьсезләнә һәм үлә»*[3].

---

[1] *Миңнуллин Т.* Без китәбез, сез каласыз // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 347.

[2] Шунда ук. – Б. 326.

[3] Шунда ук. – Б. 354.

Тукай өйләнү мәсьәләсендә дә бик катгый булып, җитди таләпләр куя. Бары яратышу, бер-береңә ышану, таяну һәм, иң мөһиме, синең яндагы кешене бәхетле итә алганда гына бу адымга барырга кирәк дип саный.

Драмада шагыйрь һәм шагыйрьлек мәсьәләсе эзлекле ачыла бара. Шагыйрь буларак үзенең бурычын яхшы аңлаган Тукай бу җаваплы вазифаны кеше шәхесе белән тыгыз бәйләнештә карый. *«Баш игән бәндә шагыйрь була алмый. Шагыйрьләр үз кәвешенең очына карап түгел, йолдызларга, айга, кояшка күз төбәп иҗат итәргә тиешләр. (...) Мин үземнең кем икәнлегемне бик яхшы беләмен. Дөрес, минем әтрафымда бик күп юләр балыклар, бушбугазлар чуала, алар мине үзләренең дәрәҗәләренә төшермәкчеләр. Юк, бу гали җан түбән төшәр өчен түгел, югарыга үрләр өчен яратылган. Килер заман, хәлфә, Тукайны искә алырлар*, – ди ул танышы Кыяметдингә. – *(...) Безнең исем дә милләтебез күгендә Пушкиннар рәтендә торыр»*[1].

Шулай итеп, драмада Тукайның гаять үзенчәлекле, бертөрле генә бәяләнми торган әдәби образы торгызыла һәм шагыйрьнең тормыш-яшәештәге күптөрле мәсьәләләргә мөнәсәбәте публицистик планда укучы-тамашачыга тәкъдим ителә. Т. Миңнуллин XX гасыр башында яшәгән шагыйрь карашларының бүген дә заманча булуын, актуаль яңгыравын, бигрәк тә милләт киләчәгенә бәйле эш-гамәлләребезгә юлкүрсәткеч роль уйнавын ачуга килә.

* * *

Т. Миңнуллин пьесаны ул вакытта билгеле булган фактларга нигезләнеп яза. Тукай истәлекләрендә дә бу сәфәр турында бик аз мәгълүмат бирелә. Шунлыктан әсәрдә Акчуриннар белән Тукай арасындагы мөнәсәбәт шактый салкын итеп сурәтләнә. Соңрак, яңа фактлар табылгач, Т. Миңнуллин «Ялгыш төзәтелергә тиеш» дигән зур булмаган язмасында кайбер мәсьәләләргә ачыклык кертә. Тукай сәфәрен һәм драматург карашларын аңларга ярдәм иткәнгә күрә, аны тулысынча китерәбез:

[1] *Миңнуллин Т.* Без китәбез, сез каласыз // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 352–353.

*«Заманында мин “Без китәбез, сез каласыз” дигән пьесамда Тукайның фабрикат Акчуриннарга кунакка баруы турында язган идем. Анда Тукайны озату сәхнәсендә, шагыйрьнең Хәсән Акчурин биргән акчаны алмавы язылган иде. Күптән түгел генә мондый мәгълүматны укыдым. Тукай, Гурьевкада фабрикант Акчуриннарда булып кайтканнан соң, апасы Газизә Зәбировага хат яза. Хатның сәфәргә кагылышлы өзеге вафатына бер ел тулу уңае белән басылган мәкалә эчендә китерелгән: “Казаннан бер дә читкә чыкканым юк дияр идем, әле шул арада гына Сембер янындагы Хәсән Акчурин дигән фабрикантка барып, биш кич кунып кайттым. Бер дә көтмәгәндә, аңсыздан хәбәр бирделәр... Сыйлауларыннан каләм гаҗиз. Бару-кайту расходы алардан. Шуның өстенә, киткәндә 50 тәңкә акча һәм киемлекләр биреп җибәрделәр. Бер белмәгән, танымаган кешенең кисәктән шундый хөрмәт күрсәтүе гаҗәп түгелме?”*

*Пьеса язылганда мин бу фактны белми идем, шуңа пьеса ахырында тупас ялгыш киткән. Аны миңа, ни кызганыч, әйтүче булмады. Тукайның бу сәяхәте турында сорашсам да, белүче табылмады, баруы гына мәгълүм, диделәр. Мин Тукайның байларга мөнәсәбәтен үз язмаларыннан укып белгәнгә, Акчуриннар белән саубуллашканда аны кырысрак итеп сурәтләдем. Өстәвенә, үзенә шагыйрьне кунакка чакырган Хәсән Акчурин шәхесен сурәтләүдә дә хилафлык киткән. Ярый әле исән чагымда ялгышымны төзәтеп өлгерәм. “Без китәбез, сез каласыз”ның финалын төзәтеп яздым. Үземнең китапханәмдә саклана торган унтомлыкта пьесаның үзгәртелгән варианты саклана»[1].*

[1] *Миңнуллин Т.* Ялгыш төзәтелергә тиеш // Казан утлары. – 2011. – № 4. – Б. 135.

## 2 БҮЛЕК

# Т. МИҢНУЛЛИННЫҢ XX ГАСЫР АХЫРЫ ИҖАТЫНДА ӘДӘБИ-ЭСТЕТИК ЭЗЛӘНҮЛӘР

## 2.1. XX гасыр ахырында социаль-мәдәни шартлар һәм сәхнә әдәбияты үсеш-үзгәреше

Иҗтимагый-сәяси тормыштагы үзгәрешләргә бәйле, XX гасыр ахырында җәмгыятьтә үзенчәлекле социаль-мәдәни ситуация барлыкка килә. Тарихка «күчеш чоры» булып кереп калган бу дәвердә әдәбият-сәнгать дөньясында, шул исәптән драматургиядә дә эстетик күптөрлелек урнаша. Яшәеш кыйммәтләренең тамырдан үзгәрүе белән моңа кадәр ышанган, хәтта табынган идеалларның юкка чыгуы драматургларны үткәннең гыйбрәтле сәхифәләрен, тормыш-чынбарлыкны, яңа тип геройларны, каршылыклы яшәешне чагылдыруның үзенчәлекле алым-чараларын эзләүгә этәрә. Шул рәвешле традицияләр белән яңаның бергә кушылып, үрелеп китүе – үзгә бер күренеш барлыкка китерә.

Сәхнә әдәбиятындагы җитди үзгәрешләр үткәнне тәнкыйтьләүнең яңа сыйфат-билгеләр белән баюы, кеше шәхесен төрле, еш кына хәлиткеч хәлләргә куеп сурәтләү, милли тематикага игътибар арту һәм тарихка, мифларга, дингә нисбәтле мәсьәләләрнең торган саен кыюрак куелуы, киң планда милли үзтәңгәллек нигезләрен эзләү белән бәйле була. Д. Заһидуллина фикеренчә, «әлеге процесста драматургия, башка әдәби төрләрдән авангард формаларның активлыгы һәм әдәби иҗатның

роленә, функцияләренә яңача караш белән аерылып, үзенә лидерлык ролен ала»[1].

Бу чор сәхнә әдәбиятында Т. Миңнуллин, И. Юзеев, А. Гыйләҗев, Ә. Баян, Р. Батулла, Р. Хәмид, Р. Мингалим, Ф. Садриев кебек танылган драматурглар янәшәсендә Ә. Гаффар, Ф. Яруллин, Ф. Сафиуллин һәм Р. Җиһаншина, М. Маликова, Ф. Бәйрәмова, И. Мәхмүтова кебек әдәбият-сәнгатьнең башка төрләреннән килгән авторлар драматургик процесска уңай йогынты ясый. 1980 еллар ахырында сәхнә әдәбиятында З. Хәким, Г. Каюмов, Д. Салихов, Р. Сәгъди, М. Гыйләҗев, Аманулла, Р. Зәйдулла, Ф. Галиев кебек яшь каләм ияләре үз иҗат йөзләре белән аерылып торган «яңа дулкын» тәшкил итә.

Татар драматургиясе җәмгыятьтә 1980 еллар уртасында башланып киткән үзгәрешләргә, нигездә, әзерлекле килә, дөресрәге, әйдәп баручы әдипләр үз иҗатлары белән халыкның киң катламын яңарышка әзерләүгә билгеле бер өлеш кертә. А. Гыйләҗевнең «Әгәр бик сагынсаң» (1980), Т. Миңнуллинның «Әниләр һәм бәбиләр» (1984), «Ефәк баулы былбыл кош» (1984), Р. Хәмиднең «Китәм инде» (1983), «Майның унбишләрендә» (1984) һ.б. пьесаларда яшәп килгән системаның гаделсез яклары, өстенлек иткән идеология йогынтысында рухи ныклыгын югалткан кешеләр язмышы отышлы сәнгать чаралары аша сурәтләнеп, укучы-тамашачының аңына, күзаллавына, дөньяга карашына көчле йогынты ясый. Социаль-иҗтимагый вакыйгалар, хәбәрдарлык алып килгән шартларда аеруча милли республикаларда, шул исәптән Татарстанда халыкның милли үзаңы үсеше күзәтелә. Әдәбият-сәнгатьтә әкренләп дөнья сурәте үзгәрү башлана. 1980 елларның икенче яртысында ул өстенлекле рәвештә үткәнне кире кагу, моңа кадәр тыелган темаларга мөрәҗәгать итү, совет системасының гаделсез якларын фаш итү һәм милли яшәешне үзгәртеп кору, татар халкының киләчәк үсеш юлын эзләү белән бәйле иде. «Хәзер бездә үткән-

[1] *Загидуллина Д.Ф.* Татарская литература и национальный театр: одна дорога на двоих // Театр XXI века и вызовы нового времени: материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 110-летию татарского театра / под ред. Э.М. Галимовой. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – С. 11.

нәрне тәнкыйть күзлегеннән уздыру, аларга яңача төшенү процессы бара. Бу закончалыклы хәл. Чөнки моңарчы илебездәге хәлләрне үз вакытында һәрьяклап, хәбәрдарлык һәм демократия шартларында фикерләү мөмкинлегебез булмады. Тәнкыйть фикерләре барыбызда да тупланып килде, һәм алар менә хәзер (...) тышка бәреп чыкты»[1], – дип яза Т. Миңнуллин. Р. Хәмиднең «Олы юлның тузаны» (1986), «Җиде баҗа» (1988), Ю. Сафиуллинның «Нигез туздыручылар» (1986), «Пар канат» (1987) А. Гыйләҗевнең «Көйсезләнгән сәфәр» (1988), Ш. Хөсәеновның «Безнең подъезд төбендә» (1989), Д. Салиховның «Яшьлек хатам – йөрәк ярам» (1989), М. Гыйләҗевнең «Бичура» (1989), Г. Каюмовның «Мирас» (1990) драмалары тема-проблематика, сюжет-композиция, образлар системасы ягыннан төрле булсалар да, драматургларны чорның социаль мохитен тудырып, заман алып килгән җитди иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләр турында борчылып, әрнеп уйлану берләштерә.

Ю. Сафиуллинның «Нигез туздыручылар» (1986), «Пар канат» (1987) кебек драмаларында җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең котылгысызлыгы, искечә яшәү мөмкин түгеллеге ачыла. Әлеге чор әсәрләрен берләштерә, аларны иңләп үтә торган мәсьәләләрнең берсе буларак, драматург алгы планга яшьләрне, аларның үзара мөнәсәбәтләрен, дуслык, мәхәббәт, гаилә мәсьәләләрен куя. Ул персонажлары аша укучыга эндәшә, аны кисәтә, ваемсызлыктан арынырга чакыра. Р. Хәмид «Олы юлның тузаны» (1988) пьесасында яшәешкә үтеп кергән ямьсез күренешләр – шәхеснең рухи кыйбласын югалтуы, әхлакый түбәнлеккә төшүе, күңел катылыгы – турында чаң кагыла. Нәүхәбәр әбинең төрле әйбер-предметларга мөрәҗәгать итеп сөйләшүендә язмышы ачыла, үткән һәм бүгенгебез, киләчәгебез турында, ата-бабадан калган гадәт-йолаларыбызга, заман алып килгән үзгәрешләргә, авыллар язмышына, гаиләдәге мөнәсәбәтләргә карашы чагыла. Әбинең уйлану-сөйләнүләрендә үзенең, гаиләсенең генә түгел, бөтен халыкның каршылыклы, авыр, вакыты белән фаҗигалы язмышы ачыла. Р. Хәмид

[1] *Миңнуллин Т.* Каләмебез, сүзебезне эшкә җигик! // Казан утлары. – 1989.– № 11.– Б. 128.

совет системасының кешелексез якларын фаш итә, җәмгыятебезгә килеп кергән рухи бушлык, миһербансызлык, байлык артыннан куу кебек әхлаксызлык күренешләре өчен тирәнтен борчыла. Ата-ана каршындагы бурычыңны үтәү, гореф-гадәтләрдә, йолаларда сакланып калган матур сыйфатларны саклауның изге бурыч булуын ачып, Нәүхәбәр әби язмышы аша драматург милләтнең бүгенгесе, киләчәге турында уйлануга алып чыга.

Җәмгыятьтәге тотрыксызлык, рухи кыйммәтләрнең җуелуы бик күпләрнең икеләнеп, буталып калуына, хәтта яшәеш ориентирларын югалтуына китерә. Нәкъ шундый вакытта мәңгелек кыйммәтләрне калкытып кую, киң катлау укучы-тамашачының күңелендә өмет һәм ышаныч тәрбияләү кирәклеген аңлау Д. Салиховны «Яшьлек хатам – йөрәк ярам» драмасын язуга китерә. Пьесада чорның караңгы яклары, аракы зәхмәтенә бирелеп, үзләрен, якыннарын кайгы-хәсрәткә салган кешеләр язмышы чагылыш таба.

Драматург бәхетсезлеккә дучар ителгән ике гаиләне янәшә сурәтли. Вакыйга-күренешләр төп геройларның мәңгегә хушлашуы белән тәмамланса да, пьесада кеше ихтыярына, гаделлек тантанасына ышану өстенлек ала.

Татар милләтенең яшәеше, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында уйлану драматургларны җитди сәнгати эзләнүләргә алып килә. Аның башлангычы татар тарихында билгеле шәхесләрнең әдәби образларын иҗат итү, эш-гамәлләренең милли асылын аңлау омтылышы белән бәйле. М. Җәлил һәм Г. Тукай кебек милләт символына әверелгән яисә Һ. Такташ һәм Х. Туфан кебек иҗатта камиллеккә ирешкән әдипләргә багышлап Т. Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» (1986), «Агыла да болыт агыла» (1999), Ф. Бәйрәмованың «Атылган йолдыз» (1985), Ә. Гаффарның «Соңгы сәгать» (1986), Р. Батулланың «Сират күпере» (1986) кебек әсәрләр языла, уңыш белән сәхнәләргә куела. Әсәрләрдә үзәккә чыгарылган Г. Тукай, М. Җәлил, Һ. Такташ һәм Х. Туфан образлары Идел-Урал буе төрки халыкларына яхшы таныш булып, алар аша татар дөньясы, халкыбызның яшәеш кыйммәтләре, аерым сыйфатлары ачыла. Авторлар әлеге шәхесләрне үзләре яшәгән, иҗат иткән, көрәш

алып барган чор үзенчәлекләренә нисбәтле сурәтли, гаять гыйбрәтле әдәби образлар калкып чыга.

Милли яшәешкә мөрәҗәгать итүнең тагын бер уңышлы юлы буларак, Р. Хәмиднең «Ак тамырлар иле» (1989), И. Юзеевнең «Ак калфагым төшердем кулдан» (1990) пьесалары моңа кадәр читтә калдырылган проблемаларны бөтен кискенлегендә күтәрүләре белән киң яңгыраш ала. Авторлар яңа композицион алымнар, үзенчәлекле сурәт чаралары ярдәмендә үткән, бүгенге һәм киләчәк бәйләнешендә милләт язмышы турында җитди уйлануга, укучы-тамашачы белән фикер алышуга, бәхәскә алып киләләр.

* * *

1990 еллар башында ил тормышын тамырдан үзгәрткән сәяси вакыйгалар (СССР таркалу, компартиянең властьтан читләштерелүе, Татарстанның суверенитет игълан итүе, Россия белән уртак Килешүгә кул куелу һ.б.), әдәбият-сәнгать өлкәсенә дә көчле йогынты ясый. Драматурглар үткәннең иң матур традицияләренә таянган хәлдә, заман рухына бәйле эзләнүләрне дәвам итә.

Кеше һәм җәмгыятьтәге хәл-халәткә мөнәсәбәт драматургиянең үзәгендә булып, яшәешнең җитди проблемалары белән тыгыз бәйләнештә сурәтләнә. Ул исә милли төсмерләр белән кушылып, яшәү мәгънәсе, шәхеснең үз-үзен табуы, милләт язмышы кебек мәсьәләләрне үз эченә ала. Әдип иҗатының заманчалыгы – чорның социаль-иҗтимагый сорауларын чагылдыруы һәм чишү юлын барлавы белән аңлатыла. Посттоталитар җәмгыятьтә, бигрәк тә «кыргый» капитализмга күчү шартларында, үткәннең кешелексез күренешләрен тәнкыйтьләү, бүгенге тормышның ямьсез якларын, яшәештәге мәгънәсез эш-гамәлләрне сурәтләү, үз урыннарын таба алмаган, тормыш «төбендә» яшәүче геройларны алга чыгару күзәтелә. А. Әхмәдуллин бу чор драматургиясенә ясаган күзәтүендә җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле яшәешкә үтеп кергән рухи түбәнлек күренешләрен, аның драма әсәрләрендә чагылыш үзенчәлекләрен «гаҗизлек мотивы» дип атый[1].

[1] *Әхмәдуллин А.Г.* Бүгенге татар драматургиясенең кайбер үзенчәлекләре // Мирас. – 2004. – № 2. – Б. 88.

Шуңа да ул елларда дөнья күргән пьесаларда, аерым алганда, М. Гыйләҗевнең «Бичура» (1989), Т. Миңнуллинның «Бажа мал түгел, кәҗә туган түгел» (1992), З. Хәкимнең «Кишер басуы» (1993), И. Юзеевнең «Эзләдем, таптым, югалттым» (1997) һ.б. әсәрләрдә совет системасын тәнкыйтьләү киң урын ала, яшәешнең кырыс шартларына эләгеп, авыр хәлдә калган шәхес фаҗигасын социаль-фәлсәфи планда чагылдыру күзәтелә. З. Хәкимнең «Кишер басуы» трагикомедиясендә 1980–1990 еллар чигендәге татар авылы тасвирлана. Кишер басуы әсәрдә җәмгыять символы булып килә. Социализм дәверендә чынбарлык белән сүз-сәясәт арасындагы аерма ялган, күз буяучылык үсешенә китерә. Тормышның ялганга корылуы кеше күңелендә ышаныч хисен сүндерә. Шуңа да әсәрдә чит планетада яшәүче татарлар очып килгән Кораб өмет, киләчәккә ышану билгесе булып тора. Киләчәк исә халыкның бердәмлегенә бәйле. Автор уен алымыннан да иркен файдалана. Яшәештәге абсурд буларак кабул ителергә тиешле күренешләр гадәти хәл рәвешендә бәяләнә башлаган – бу инде чынбарлыкта кыйммәтләрнең югалуын күрсәтә.

1990 еллар татар драматургиясе, совет чоры вакыйгаларына мөрәҗәгать итеп, тоталитаризмның кешелексез якларын фаш итү, аның барлыкка килү, шактый озакка сузылу сәбәпләрен эзләүгә актив тартыла. Аның үрнәкләре яңа чор каршылыкларын ачуны максат иткән әсәрләрдә дә күренә (Г. Каюмов. «Мирас»; Р. Хәмид. «Олы юлның тузаны» һ.б.). Ә инде сталинизм дәверенең аяусыз күренешләре аеруча тулы булып Ф. Бәйрәмованың «Безне онытмагыз» (1988), Д. Салиховның «Чукрак» (1995), Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә» (1998) драмаларында чагылыш таба. Ф. Бәйрәмованың «Безне онытмагыз» драмасы «37 ел синдромы»н аңларга омтылу белән игътибарга лаек. Драмада «халык дошманнары» хатыннары гаять үзенчәлекле образлар буларак сурәтләнә. Аларның эш-гамәлендә, гыйбрәтле язмышында чорның кешегә китергән газап-михнәтләре бөтен фаҗигасы белән ачыла. Драма үткәнне сурәтләсә дә, киләчәккә атап язылган: автор вакыйгалар аша укучы-тамашачы белән дә әңгәмә кора, аның үз иреген саклау өчен көрәшергә тиешлеген искәртә. Үткәннәргә дөрес, объектив бәя бирү аша ерактагы һәм

якындагы тарихи сәхифәләрне барлау хата-югалтуларны кабатламаска, бүгенгене тулырак аңларга, киләчәккә ачык-аңлаешлы планнар корырга мөмкинлек бирә. Д. Салиховның «Чукрак» пьесасы гаять катлаулы, каршылыклы вакыйгаларның киселгән-кимсетелгән, бәхетсезлеккә дучар ителгән кеше язмышларында чагылуын сурәтләве белән яңгыраш ала.

Дөньяның төрле төбәкләрендә сугышлар алып бару совет системасының тагын бер кешелексез ягы булып тора. Ә инде XX гасырның 80–90 нчы елларында барган әфган һәм чечен сугышлары меңнәрчә корбаннар сыйфатында Россиянең үзенә дә бары афәт кенә алып килә. Авторлар сугыш фаҗигаларына бәйле киселгән язмышларны сурәтләгәндә дә, алгы планга Кеше дигән олы исемгә тап төшермәгән характерларны чыгаралар. Ф. Бәйрәмованың «Сандугачның балалары» драмасында әфган сугышына бәйле вакыйгалар тасвирлана. Автор, бер яктан, ил башында утыручыларның кеше язмышлары белән шахмат фигуралары кебек уйнауларын ачса, икенче яктан, ике улын әфган «иттурагычына» озаткан Сандугач белән авыл советы рәисе Бәкер каршылыгы тормышка бәяне икенче яссылыкта үстерә. Вакыйгалар аша автор халкыбызның үткәне, бүгенгесе, киләчәге турында уйланырга мәҗбүр итә. Сандугач әсәрдә гомумиләштерелгән образ дәрәҗәсенә күтәрелеп, милләт анасы буларак ачыла. Әдибә аны матур кешелек сыйфатлары белән тасвирлый. Бала хәсрәтеннән акылын җуйган хәлдә дә ул Бәкер кебекләрдән бер башка өстен. Россиядә яшәүче күпсанлы халыкларның канлы ярасына әверелгән чечен сугышы темасына татар әдәбиятында беренчеләрдән булып Ю. Сафиуллин мөрәҗәгать итә. Драматург «Йөзек һәм хәнҗәр» (1996) трагедиясендә сугыш кайтавазының, Татарстан җиренә җитеп, кеше язмышларына йогынты ясавын үзенчәлекле вакыйгалар, гыйбрәтле геройлар аша сурәтли. Беренче күренешләрдә үк, чеченнарда пленда булып, аннан психикалары бозылып кайткан Линар белән Рәсимнең тотнаксызлыгы, әйләнә-тирәдәгеләр белән уртак тел таба алмаулары көрәш-бәрелеш интригасы тудыра. Бер яктан, егетләр белән әйләнә-тирәдәгеләр арасында, икенче яктан, Россия армиясендә командир приказын үтәп, чечен

авылларын җимергән, кулларына корал тотып каршылык күрсәтүчеләргә генә түгел, бәлки хатын-кыз һәм бала-чагаларга каршы да танк белән барган Линар һәм Рәсим белән йорт-җирләрен, сөйгәннәрен югалтып, туган иленнән качып китәргә мәҗбүр булган Хания һәм Разия арасында конфликт оеша. Боларга өченче төр каршылык – төп геройлар күңелендә барган рухи көрәш үрелә. Авторны аеруча Линар белән Рәсимнең җан бәргәләнүләре, тыныч тормышта үзләренә урын таба алмаулары борчый. Бер яктан, җимерелгән авыл-калалар, үтерелгән гөнаһсыз кешеләр егетләрнең җанына тынычлык бирми, икенче яктан, дәүләт тарафыннан читкә кагылулары әрнү булып бәреп чыга. Шул рәвешле, пьесадагы каршылыкларны үзенә туплаган шәхес һәм система конфликты калка. Әсәр ахырында Линарның үлеме вакыйгаларның логик нәтиҗәсе булып аңлашыла. Тыныч шартларда ике яшь кешенең гомере өзелә, драматург исә гаепләү актын сугышка, аны башлаучыларга юнәлтә.

Җәмгыятьтәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә милли үзаң үсү, дәүләтчелекне торгызу идеясенең киң яклау табуы әдәбиятта милли тематиканың калкулануына китерә. Милләт язмышы яшәешнең төрле якларын иңләп ала. Шуңа да авторлар сайлап алган тормыш материалы да күптөрле. Т. Миңнуллин «Илгизәр плюс Вера» (1991) драмасында катнаш никах мәсьәләсен әхлакый-иҗтимагый проблема буларак күтәрсә, «Шәҗәрә»се (1998) морзалар катламы язмышына бәйле халыкның үткәне-бүгенгесе, гореф-гадәтләр сакланышы турында уйлану буларак языла. Вакыйгаларда тоталитар система эзәрлекләве аркасында таралып беткән, үзара бәйләнешләрен, туганлык җепләрен югалткан, язмыш тарафыннан кагылып-сугылып йөртелгән морза нәселенең фаҗигасы ачыла. Кинокадр чылбырын хәтерләткән күренешләрдә бөеклек һәм түбәнлекнең, горурлык һәм мескенлекнең гыйбрәтле мисаллары күз алдыннан үткәрелә. Әлеге токым язмышы татар халкы язмышын күз алдына бастыра. Әсәр ахырында морза нәселенең туганлык җепләре ныгуына ишарә булган кебек, татар халкының да берләшүенә, дус-тату яшәвенә өмет туа.

Халкыбызның үткәне, бүгенгесе, киләчәге белән кызыксынуга бәйле, аның төрле этник катламнары яшәешен әдәби

сурәтләрдә тасвирлау ягыннан Т. Миңнуллинның «Гөргөри кияүләре» (1995), «Йөрәк маем» (1997) комедияләрендә тормыш-көнкүреш вакыйгалары аша халыкның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, әхлакый сыйфатлары, гомумән, милли йөзе ачыла. Шул ук вакытта, әлеге пьесаларда тормыштагы, аерым кешеләр характерындагы кимчелек-каршылыкларны җиңел юмор, ирония аша тәнкыйтьләү дә урын ала.

Драматурглар ерактагы һәм якындагы тарихка мөрәҗәгать итеп, төрле дәверләр тудырган олы шәхесләрнең әдәби образын мәйданга чыгаралар һәм, иң мөһиме, шулар аша җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең сәбәбен эзлиләр. Ә. Баянның «Каракош» (1991), Ю. Сафиуллинның «Идегәй» (1994), Р. Хәмиднең «Хан кызы» (1995), З. Хәкимнең «Мәңгелеккә изге сәфәр» (1996), И. Юзеевнең «Бәгырь» (1998) пьесаларында данлы һәм фаҗигалы тарихыбызның аерым сәхифәләре аша хәзергене фәлсәфи планда аңлау омтылышы ясала. Мондый әсәрләрдә тарихи фактлар белән әдәби уйланманың үзенчәлекле, киң яңгырашлы, эмоциональ тәэсирле синтезына ирешелә. Югарыда аталган пьесаларның күбесендә милли эчтәлек алгы планга чыга һәм автор позициясе белән бәйле төп идеядә чагылыш таба.

Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән Казан ханлыгы, аның ханнары, аеруча соңгы ханбикәсе Сөембикә гасырлар дәвамында татар һәм рус әдипләренең, тарихчыларының игътибарын җәлеп итеп килә. Тарихыбызның әлеге чоры белән кызыксыну XX гасыр ахырында аеруча арта. Сөембикә-ханбикәнең яшьлек еллары анык кына билгеле түгел. Илнең иминлеге өчен дип, улы белән Мәскәү патшасына тоткын итеп җибәрелгәннән соңгы язмышы да билгесезлек пәрдәсе белән капланган. Болар, үз чиратында, Сөембикә турында төрле риваять һәм легендаларның киң таралуына китерә[1]. Соңгысы исә әдипләргә ул чор вакыйга-күренешләренә бәйле Сөембикә образын, аның язмышын төрле юнәлештә ачарга мөмкинлек бирә[2].

---

[1] Сөембикә ханбикә. Җыентык: Тарихи, фәнни хезмәтләр, бәяннар, әдәби әсәрләр, әсәрләрдән өзекләр. – Казан: Идел-Пресс, 2001. – Б. 279.

[2] *Рәмиева И.Р*. Рус, татар, төрек әдәбиятларында ханбикә Сөембикә образы. – Казан, 2009. – 244 б.

XX гасыр ахырында рухи кыйммәтләрнең үзгәрүе халыкның билгеле бер катламында киләчәккә ышанычны бетерә, ризасызлык, җәмгыятьтән читләшү тудыра, бу исә яшәешнең мәгънәсезлеге турында уйлануларга һәм пьесаларда сызлану мотивының өстенлек алуына, субъективлыкка, кеше иреген абсолютлаштыруга этәрә. Аерым әсәрләрдә социаль һәм милли яшәеш проблемалары каршында куркып, икеләнеп калган, яшәешнең асылын аңламаган, мәгънәсен тапмаган, авырлыклардан котылу юлы үлемдә дип санаган персонажлар мәйданга чыга. Дөрес, соңгысы татар әдәбиятында киң урын алмый. Ислам дине кешенең үз гомерен үзе чикләвен зур гөнаһ буларак кире кага. Әмма тормыш-яшәешне бөтен каршылыгында ачу масатында аерым авторлар әлеге күренешләрне читләтеп үтмиләр (Г. Каюмов. «Мирас» («Упкын өстендә уен»); Д. Салихов. «Яшьлек хатам – йөрәк ярам»; З. Хәким. «Шайтан куентыгы» һ.б.). Арада З. Хәкимнең «Шайтан куентыгы» пьесасы гыйбрәтле сюжеты, бай алым-чаралары, фаҗигалы финалы, үзенчәлекле геройлары белән аерылып тора. Пьесада үзара тыгыз бәйләнгән шәхес белән җәмгыять һәм шәхеснең эчке каршылыгы калку итеп куела. Геройларның бер-берсе белән аңлаша алмаулары да шуларга килеп тоташа. Тормыш-көнкүреш вакыйгаларына нигезләнгән пьеса социаль-иҗтимагый яңгыраш ала, аерым шәхесләрнең үз-үзен югалтуы халык фаҗигасы булып үсә.

Татар драматургиясе яшәешне романтизмның куе, җете буяулары, хыял дөньясының яңадан-яңа катламнары, мәхәббәтнең бай төсмерләре аша чагылдыруның төрле юлларын эзли. Алдагы чорда бу юнәлештә уңышлы эшләп килгән И. Юзеев, Р. Батулла, Ә. Гаффар һ.б. янәшәсендә төрле юнәлешләрдә каләм сынап, романтик алымнарга мөрәҗәгать иткән Аманулла, Х. Ибраһим, Р. Сәгъди, Л. Лерон, Б. Сәлахов һ.б. әсәрләре дөнья күрә. И. Юзеевнең «Гашыйклар тавы» (1989), Р. Сәгъдинең «Сынган беләзек» (1994), Аманулланың «Әле кичә генә яз иде» (1998) һ.б. пьесалар лирик-эмоциональ башлангычка йөз тотулары, җыр-музыкадан иркен һәм максатчан файдаланулары белән киң яңгыраш ала. Романтик сурәтләү үзенчәлекләре буларак геройның әхлакый сайлау алдына куелуын, иҗтимагый эчтәлекнең шәхси башлангыч

белән үрелеп китүен, тойгы-кичерешләрнең фәлсәфи уйланулар белән кушылып баруын билгеләп үтәргә була. Мөһим сыйфат рәвешендә «романтик рухлы әдип әдәби образда барыннан да элек үзен күрсәтергә»[1] тиешлеге дә игътибардан читтә калмый Аларда хис-кичерешләр дөньясы хөкем сөрә, мәхәббәт идеал дәрәҗәсенә күтәрелә һәм аңа тугрылык саклау-сакламау геройның бүгенгесен генә түгел, киләчәген дә билгеләүче күренешкә әверелә. Бөтен иҗат гомерендә романтизм юнәлешенә тугрылык саклаган И. Юзеевнең «Гашыйклар тавы» башта повесть-поэма (1986) итеп язылса да, соңрак, мөстәкыйль драма буларак (1989), сәхнә тормышы башлана. Халыкта мәгълүм Серле үрдәк турындагы риваятькә нигезләнгән әсәр фаҗигалы мәхәббәт тарихы турында сөйли. Автор яшьлек хыялына, мәхәббәткә тугрылык кына яшәешне матур, мәгънәле итә, ә инде хыянәт тормыштагы гармонияне югалтуга, өметсезлеккә китерә, «җан һәлакәте мәңгелек кыйммәтләрне юкка чыгара, аларның әһәмиятен җуя»[2] дигән фикерне яклый.

Аманулланың романтик эчтәлекле, тирән лиризм белән сугарылган «Әле кичә генә яз иде» драмасында урта мәктәпне тәмамлаучыларның олы тормышка беренче адымнары сурәтләнә. Әсәрнең романтик рухы, беренче чиратта, кызларның күбесе, аеруча Әлфинур гашыйк булган класс җитәкчесе Альберт Равилевич образы, аның эш-гамәлләре белән бәйле. Әсәрдә укучыларның һәм ата-аналарның тирән хөрмәтенә лаек булган укытучының гаять үзенчәлекле, серле, матур һәм бай рухи дөньясы ачыла. Драматург геройларының күңел кичерешләрен, эчке халәтләрен оста тотып ала. Укытучы һәм укучылар бәхәсендә хисләр бәрелеше дә, яшәеш фәлсәфәсе дә, кеше дигән затның гаять төрле, серле, катлаулы булуын аңлау, шуның сәбәпләренә төшенү теләге дә һәм, ниһаять, үз хыялына, яшәү рәвешенә,

---

[1] *Гуляев Н.А.* Литературные направления и методы в русской и зарубежной литературе XVII–XIX веков: Кн. для учителей. – М.: Просвещение, 1983. – С. 4.

[2] *Заһидуллина Д.Ф.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – 2 т.; XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – Б. 75–76.

тормыш матурлыгына тугры калган, шуның белән хөрмәт уяткан олы җанлы Укытучыны аңлау да тоемлана.

Әлеге чор татар драматургиясендә барган эзләнүләрнең бер үзенчәлеге булып әдипләрнең реалистик һәм романтик күренешләр үрелеп барган һәм әлеге кысаларга гына сыеп бетмәгән яңа алым-чараларга мөрәҗәгать итүе, кеше шәхесенә, аның рухи кичерешләренә игътибар арту тора. Сәхнә әсәрләрендә яшәешнең әхлакый, социаль-иҗтимагый, милли мәсьәләләре белән бергә, чынбарлыкның аңлап һәм аңлатып бетерү мөмкин булмаган, кешенең көчсезлеге, гомеренең чиклелеге, яшәү мәгънәсе кебек фәлсәфи сораулар да өйрәнү предметы итеп алына. Традицион алым-чараларның бер төрен кире кагу һәм яңаларга мөрәҗәгать итү, билгеле, һич тә үзмаксат түгел, бәлки тормышны тулылыгында, күптөрлелегендә, каршылыгында чагылдыру, шуларны укучы-тамашачыга җиткерүнең яңа юлларын эзләү омтылышы булып тора. Д. Заһидуллина билгеләп үткәнчә, бу чор әдәбиятында, бер яктан, яшәешнең абсурдлыгын, буталчыклыгын һәркайсы үзенчә чагылдырган модернизм һәм постмодернизм урын алса, икенче яктан, хәтта яшәеш гармониясенә һәм бөтенлегенә омтылган, кеше һәм табигатьнең, шәхес һәм җәмгыятьнең үзара бәйләнешен үз эченә алган классик сәнгать тә (реалистик һәм романтик) әлеге сыйфатларын югалта[1].

Тормыштагы каршылыкларны, битарафлык һәм икеләнүле халәтне үтеп чыгу, яшәештә гармониягә омтылу һәм, шул максатта, сурәтләүнең яңа юлларын эзләү хәзерге татар сәхнә әдәбиятында мифологик күзаллаулар, архетиплар белән кызыксынуның көчәюенә китерә. Мифологик күзаллау кешеләрнең әйләнә-тирә дөньяны төрле образлар, геройлар аша кабул итүе белән бәйле, шуңа да анда Галәм, Җир һәм Кеше ятратылышы, шулай ук яшәеш өчен аеруча кирәкле хәл-күренешләр тәртибе аңлатыла. «Тормышта билгеле бер тәртип урнаштыручы һәм шуны тайпылышсыз саклаучы мифлар борынгы җәмгыятьнең

[1] *Загидуллина Д.Ф.* Татарская поэзия и проза рубежа XX–XXI веков: эстетические ориентиры и художественные поиски: монография. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2018. – С. 4.

рухи нигезен тәшкил иткәннәр»[1]. Шуңа да мифология матур әдәбиятның җирлеге булып тора.

Әдипләрнең тормыш-чынбарлыкны күзаллау үзенчәлегенә, яңа әдәби дөнья тудыру омтылышына, әдәби-эстетик карашларын яңа алымнар ярдәмендә укучыга җиткерү теләгенә бәйле, мифологиядән файдалану бер төрле генә түгел. Аерым пьесаларда борынгы мифологиядән турыдан-туры файдалану алга чыкса, икенчеләрендә автор тудырган текстта, кеше аңының чагылышы буларак, гомумиләштерелгән, универсальлеккә дәгъва иткән образларның, вакыйга-күренешләрнең урын алуы күзәтелә, өченчеләрендә китап укучылар аңында милли культура, милли аң символына әйләнгән аерым шәхесләр яисә мәдәни күренешләр урын ала. Борынгы мифологиягә мөрәҗәгать итү, аны үз әсәрләрендә файдалануның уңышлы үрнәкләре Р. Хәмиднең «Актамырлар иле» (1989), М. Гыйләҗевнең «Бичура» (1989), З. Хәкимнең «Су төбендә сөйгәнем» (1995), «Шайтан куентыгы» (1995), Р. Зәйдулланың «Саташкан сандугач» (2000) һ.б. пьесаларда күзәтелә. Мифологик образлар яңа эчтәлек белән байый, трансформацияләнә.

Р. Хәмиднең «Актамырлар иле» (1989) трагедия-реквиемында милләт язмышы, аңа янаган юкка чыгу, ассимиляцияләшү куркынычы гыйбрәтле күренешләрдә ачыла. Пьесаның төп конфликты өлкән буын белән милли яшәү рәвешен кире каккан яшь буын арасында барлыкка килә. Шуларга бәйле авылларның таркалуы, гореф-гадәтләрнең юкка чыгуы, әхлаксызлык күренешләренең артуы, эчкечелекнең тирән үтеп керүе, ата-ана белән бала арасында рухи бәйләнешнең югалуы кебек гаять актуаль мәсьәләләр алга чыга. Актамырлар иле турындагы риваять катнаш никахның милләт язмышына куркыныч ясавын ачуга хезмәт итә. Драматург милли асылыбызны яклау һәм саклау, гасырлар дәвамында сыналган гореф-гадәтләргә, традицияләргә тугры булу, әхлакый кыйммәтләргә нигезләнеп яшәү кирәклеге турында кисәтә. М. Гыйләҗевнең «Бичура» (1989) драмасында кеше күңеленең ике ягын – өмет һәм өметсезлек, яктылык

[1] *Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. 1 т. (А–Г). – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 9.

һәм караңгылык, яхшылык һәм явызлык, тугрылык һәм мәкер чагылышын сурәтләү үзәккә куела. Заман кешесе турында уйлану-тикшеренүләренә нигезләнгән автор концепциясенең мифологема, шартлылык, билге-символлар аша чагылуы, ике төрле дөнья моделе төзү, ялгызлык һәм сызлану мотивларын уңышлы куллану пьесаны постмодернистик әдәбият кысаларына кертеп карау мөмкинлеге бирә. Бичура турындагы миф әдәби әсәрнең сюжет чыганагы булып тора, һәм мифик образ авторга кеше күңелендәге каршылыкларны ачуга, җәмгыятьтәге социаль-иҗтимагый һәм милли мәсьәләләрне калкытып бирүгә хезмәт итә. Яшәешнең җитди мәсьәләләре турында тирән уй-фикерләргә, бәхәсләргә китерүче пьесаларның берсе – З. Хәкимнең «Су төбендә сөйгәнем» комедиясе. Автор, Су анасы турындагы мифтан һәм Г. Тукай эшкәртүендә һәр татар кешесенә таныш булган Су анасы образыннан файдаланып, үз чоры татар җәмгыятенә пародия тудыра.

Реалистик һәм фантастик күренешләр үрелеп, драматург кеше ышанмастай хәлләр аша ямьсез, әхлаксыз, җан әрнеткеч тормыш сурәтен тудыра. Әсәр төзелешендә «абсурд театры» элементлары, вакыйга-күренешләрнең, бер-бер артлы килеп һәм өстәлә барып, коллаж төсен алуы, төп геройларның эш-гамәлендә ачык чагылган уен алымы чынбарлыкны хаос төсендә кабул итүгә китерә. Постмодернистик концепциягә нигезләнгән пьесада үз чоры татар җәмгыятенә үтеп кергән эчкечелек, рухи матурлыкны югалту, үзара мөнәсәбәтләрдә татар менталитетына хас билгеләрнең юкка чыгуы, җитәкчеләр белән халык арасында аңлашылмаучылыкның арта баруы кебек сыйфатлар ачыла. Вакыйгалар барышында безгә таныш мифның җимерелүе яшәештәге торгынлык һәм ямьсезлекне тагы да аянычрак күрсәтүгә хезмәт итә. Автор әлеге усал тәнкыйть аша чынбарлыкны үзгәртүнең һәркемгә бәйле булуы, моның өчен үз күңелеңдә матурлыкка, сафлык-чисталыкка урын бирү кирәклеге турындагы нәтиҗәгә китерә.

Әлеге чор драматурглар иҗатына хас тагын бер үзенчәлек – метафора булып килгән яисә шартлы-метафорик вакыйгаларга, алым-детальләргә мөрәҗәгать итү. Пьесаларда әлеге чаралар җәмгыятькә бәя бирүгә, герой характерын ачуга, гомумән, төп

идеяне, автор позициясен билгеләүгә хезмәт итә. Д. Салиховның «Алла каргаган йорт» (1990), Ф. Бәйрәмованың «Вакыйга юләрләр йортында бара» (1991), З. Хәкимнең «Җүләрләр йорты» (1995), әсәрләрендә вакыйгалар бара торган психбольница җәмгыятькә метафора булып килә һәм тарих фаҗигаларын, тоталитар системаны, 1990 елларның кешелексез якларын фаш итә.

Драматургларның сәнгати эзләнүләрендә, вакыйга-күренешләрне, автор фикерен укучы-тамашачыга җиткерүдә үтемле чара буларак, образ-символлардан файдалану активлаша. Сәхнә әдәбиятының күренекле вәкилләре И. Юзеев, Т. Миңнуллин, Р. Хәмид, Ю. Сафиуллин, Р. Батулла, Ф. Бәйрәмова, М. Гыйләҗев, Д. Салихов һ.б. иҗатында образ-символларның ике төрле кулланылышын күрәбез. Берсе – әсәрнең төп эчтәлеге символлар аша белдерелгән вакыйга-күренешләрдә ачылу, икенчесе – символ ярдәмендә әсәрдә күтәрелгән проблемалар, аерым геройларның эш-гамәлләре, характер сыйфатлары ачыклану. Образ-символларның вакыйгаларны һәм алардан чыккан нәтиҗәне тулыландыручы буларак кулланылышы Р. Батулланың «Сират күпере», И. Юзеевнең «Ак калфагым төшердем кулдан...», Ю. Сафиуллинның «Йөзек һәм хәнҗәр», Аманулланың «Җәйге кырау» һ.б. пьесаларда калку. Р. Батулланың «Сират күпере»ндә Шәүлә, гадәти персонаж кысаларыннан чыгып, Тукайга гына түгел, бөтен татар халкына дошмани көч символына әйләнә. И. Юзеевнең «Ак калфагым төшердем кулдан...» әсәрендә ак калфак – туган җир, милләт, аның яшәү рәвеше символы булып тора. Ул туган җир җылысы, буыннар бәйләнеше, рухи якынлык, бердәмлек идеясен генә аңлатып калмый, бәлки тоталитар режимга нәфрәт билгесе буларак та шәрехләнә ала. Ю. Сафиуллинның «Йөзек һәм хәнҗәр» әсәрендә йөзек – яшәеш, мәхәббәт, тынычлык символы, хәнҗәр исә – үлем, кайгы-хәсрәт алып килүче, дошманлыкка илтүче төшенчәне белдерә. «Җәйге кырау» драмасы белән Аманулла кеше җанын аңлап бетерү мөмкин түгеллеге турындагы бәхәскә кушыла. Әсәр үзенең психологизмы, кеше бәхете, аның рухи көче, өмет-ышаныч мәсьәләләре турында укучы-тамашачыны җитди

уйлануга этәргүе белән уңышлы. Табигать күренеше булган җәйге кырау – көннәр җылына башлагач, кисәктән килгән салкын һава – яшь үсентеләрне, яңа ачыла башлаган бөреләрне юк итә. Әлеге күренеш пьесада Зөфәр язмышын аңлатучы метафора булып тора. Кыю, батыр һәм көрәшче егет мәхәббәтендә, үз-үзен тотышында, кешеләргә мөнәсәбәтендә хаталар ясый, шуның өстенә үзе ышанган кешеләрнең хыянәтенә тап була. Зөфәр аларны үтеп чыгарга, тормышын яңадан башларга көч таба алмый һәм үзенә үзе кул сала.

Берничә кеше язмышы аша драматург дуслык һәм хыянәт, мәхәббәт һәм мәкер, яшәү һәм үлем, куркыныч чиргә әверелгән эчкечелек кебек проблемаларны күтәрә. Яшь кешенең гомере өзелү кебек фаҗиганың сәбәпләрен ачыклау, аны булдырмау юлларын эзләү автор белән укучы диалогы рәвешендә дәвам итеlә. Аманулла Зөфәр язмышын Ак сөлге символы аша аңлата. Драманы беренчеләрдән булып тикшергән Й. Нигъмәтуллина фикеренчә, ул дүрт төрле символик мәгънәдә бирелә[1]. Берничә кеше язмышы аша, драматург дуслык һәм хыянәт, мәхәббәт һәм мәкер, яшәү һәм үлем, куркыныч чиргә әверелгән эчкечелек кебек проблемалар куя. Драмадагы мифопоэтик катлам яшь кешенең гомере өзелү кебек фаҗиганың сәбәпләрен ачыклау, аны булдырмау юлларын ачарга ярдәм итә.

Драматургларның чынбарлык күренешләрен әдәби чаралар ярдәмендә эстетик планда тасвирлап бәяләү омтылышы тема-проблемаларга, алым-формаларга һәм иҗат агым-юнәлешенә бәйле әсәрнең персонажына килеп тоташа. Бу аңлашыла да, чөнки нәкъ менә әдәби образда язучының дөньяны танып белү концепциясе чагыла, эстетик күзаллаулары урын ала. Драматургиядә кеше психологиясен ачуның яңа чара-юлларын, алымнарын эзләү арта. Авторларның актив рәвештә «җан хәрәкәте», эчке монолог, үзанализ, төрле заттан бәя бирү һ.б. алымнарга мөрәҗәгать итүе күзәтелә. XX гасыр ахырында дөнья күргән пьесаларда, А. Саттарова фикеренчә, совет чоры әдәбиятындагы «уңай герой», «герой-романтик», «гаделлек өчен көрәшүче»,

[1] *Нигматуллина Ю.Г.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. – Казань: Фэн, 2002. – С. 132–140.

«максималист» урынына, алгы планга «трагик», «урталыктагы», «маргинал», «манкорт» һ.б. чыга[1]. Арада теләк-максатларына ирешә алмаган, гаҗизлектә гомер итүчеләрнең еш очравын билгеләп үтәргә кирәк. Т. Миңнуллинның «Хушыгыз», Аманулaның «Җәйге кырау», Г. Каюмовның «Сагынырсың әле син дә бер», З. Хәкимнең «Кишер басуы», «Шайтан куентыгы», Ю. Сафиуллинның «Йөзек һәм хәнҗәр» һ.б. пьесаларда шундый геройлар белән очрашабыз. Г. Каюмовның «Сагынырсың әле син дә бер...» психологик драмасында әдәп-әхлак кануннарына кул селтәгән, тормыштагы беренче адымнарында ук сөрлеккән яшь геройлар үзәктә тора. Әйләнмә композициягә нигезләнгән вакыйгалар үзәгендә Гөлсинә һәм Кәрим – ике төрле яшәү фәлсәфәсенә таянган кешеләр язмышы ачыла. Пьесада төрле жанр элементларының кушылып килүе әдипнең үзенчәлекле стилен барлыкка китерә.

XX гасыр ахыры сәхнә әдәбиятында заман герое, бигрәк тә яшь геройлар игътибар үзәгендә тора. Т. Миңнуллин, Р. Хәмид, Ю. Сафиуллин, Р. Батулла, Ф. Яруллин, З. Хәким, М. Гыйләҗев, Г. Каюмов, Р. Сәгъди, Ф. Бәйрәмова, Р. Зәйдулла һ.б. иҗатында араларында чор каршылыкларында буталып калган, төшенкелеккә бирелгән, аракы-наркотик сазлыгына батканнары да (Тәфкил – Р. Хәмиднең «Олы юлның тузаны»нда; Айрат – Д. Салиховның «Алла каргаган йорт»ында; Фәнзилә һәм Разим – З. Хәкимнең «Шайтан куентыгы»нда һ.б. шулай ук һәртөр сынауларга каршы ныклы ихтыяр көчен куеп, үз максатына ирешкәннәре дә бар (Сәет – Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә»сендә; Фәрит һәм Галия – З. Хәкимнең «Кишер басуы»нда, Кәрим – Г. Каюмовның «Сагынырсың әле син дә бер...»ендә һ.б.). Т. Миңнуллинның заман герое, яшь герой, аның рухи-әхлакый йөзе турында уйланулары «Илгизәр плюс Вера» (1991), «Җанкисәккәем» (1995), «Шәҗәрә» (1996) пьесаларында гаять үзенчәлекле, үз рухи дөньялары, характерлары белән аерылып торган яшьләр образы булып мәйданга чыга.

---

[1] *Саттарова А.М.* Современная татарская драматургия 1985–2000 гг.: Концепция эпохи и героя. – Казань: Гуманитария, 2003. – С. 6.

Әлеге чор драматургиясендә барган эзләнүләрнең мөһим бер тармагы балалар өчен язылган пьесалар белән бәйле. XX гасыр ахырында язылган бу төр әсәрләр идеологиядән азат булып, авторларның игътибар үзәгендә бала психологиясе, аның олылар яшәешен өйрәнүе-аңлавы аша зур тормышка әзерләнүе тора. Балалар драматургиясендә Т. Миңнуллин, Р. Батулла, Ю. Сафиуллин, Ш. Фәрхетдинов, Р. Корбан, Л. Лерон, Р. Сәгъди, Р. Харис һ.б. актив эшли. Балалар өчен язылган пьесаларның иң уңышлылары фикер ачыклыгы, акцентларның төгәллеге, әхлакый мәсьәләләрнең кыю куелышы белән игътибарга лаек. Т. Миңнуллинның «Авыл эте Акбай» (1989), «Акбай нигә күңелсез?» (1991), «Акбай белән Кыш бабай» (1991), «Акбай, Тәмлетамак һәм Этбүреләр» (1992), «Акбай һәм сарык малае» (1993), «Акбай, SOS!» (1994), М. Гыйләҗевнең «Патша кәләше» (1989), «Кәвеш кигән песи» (1994), Г. Каюмовның «Ак баба иле» (1995), Ш. Фәрхетдиннең «Әкият турында әкият» (1993), «Алтын алма» (1995), Г. Каюмовның «Сарык арыслан» (1997), Х. Җәләйнең «Шәрә бүре» (1999), Р. Сәгъдинең «Гүзәл Аппаксылу» (2000) һ.б. әсәрләрдә өлкәннәргә хөрмәт, миһербанлылык, горурлык, үз шәхесеңне яклый белү, туган җиргә, телгә хөрмәт һ.б. мәсьәләләр уңышлы алым-формаларда чагылдырыла. Балалар өчен пьесалары белән танылган авторларның берсе – Р. Сәгъди. Әсәрләре бертөрле генә түгел: берләрендә, яшәешнең җитди мәсьәләләре балалар психологиясенә, аларның теләк-омтылышына бәйле куелып, зурлар өчен дә гыйбрәтле вакыйгалар аша ачыла һәм җитди уйлануларга китерә, икенчеләрендә исә балалар тормышына хас хәл-күренешләр уен, тамаша формасында тәкъдим ителә. Беренче төркем әсәрләр арасында «Баһадурның бәхете» (1992), «Гүзәл Аппаксылу» (2000) пьесалары аерылып тора. Р. Сәгъдинең «Гүзәл Аппаксылу» пьесасында фантастик күренешләр, маҗаралы вакыйгалар чынбарлык күренешләре белән аралашып бара. Пьесаның төп конфликты яхшылык һәм явызлык көрәшенә нигезләнә һәм Таңбатыр белән Дию пәрие каршылыгында ачыла. Әлеге геройлар янында тарафдарлары туплана. Драматург Коръәннән, хәдисләрдән килә торган карашфикерне калкытып куя – асылы белән явыз булган җан иясе юк.

Тере табигатьнең аерым вәкилләрендә өстенлек алган кыргый сыйфатлар яшәеш өчен көрәш, тормыш шартлары нәтиҗәсе булып тора. Алардан котылу юлы бер генә – әлеге җан ияләре күңеленә яхшылык, изгелек, миһербанлылык, ярату, хөрмәт кебек кыйммәтләр орлыгы салу. Автор татар теленең бай мөмкинлекләреннән уңышлы файдаланып, балалар психологиясенә туры килә торган кызыклы диалог-ситуацияләр кора, тамашачыны мавыктыра, хәл-күренешләргә «катнаштыра».

Сәхнә әдәбиятының тематик төрлелеккә, үткән һәм бүгенгенең гаять җитди иҗтимагый, социаль, әхлакый мәсьәләләренә мөрәҗәгать итеп, фәлсәфи гомумиләштерүләргә омтылуы жанр һәм жанр формалары өлкәсендәге эзләнүләрдә дә чагылыш таба. Тормыш-яшәешнең төрле якларын, аерым алганда шәхес һәм җәмгыять, шәхеснең эчке каршылыгын, геройлар арасындагы катлаулы, еш кына бәхәсле мөнәсәбәтләрне сурәтләүдә драма жанрында иҗат ителгән әсәрләр киң яңгыраш ала. Шуларга бәйле әлеге жанрның иҗтимагый-фәлсәфи (Т. Миңнуллин. «Хушыгыз», 1992), иҗтимагый драма (Ф. Бәйрәмова. «Безне онытмагыз», 1988), публицистик драма (Р. Хәмид. «Тигезәкләр», 2000), психологик драма (Г. Каюмов. «Сагынырсың әле син дә бер»), фаҗигалы драма (И. Юзеев. «Ак калфагым төшердем кулдан», 1990), тарихи драма (Ю. Сафиуллин. «Идегәй», 1994), тарихибиографик драма (Ф. Бәйрәмова. «Атылган йолдыз», 1985) һ.б. кебек жанр формалары дөнья күрә.

Татар драматургиясенең бер үзенчәлеге булып, авторларның мелодрама жанрына еш мөрәҗәгать итүе тора. Билгеле булганча, мелодраматик әсәрдә гыйбрәтле язмышлар, гаять тәэсирле, күңелдә хис-кичерешләрне уятырлык вакыйгалар сурәтләнеп, алар җыр-музыка белән үрелеп бирелә. Әлеге жанр формасының уңышлы үрнәкләре булып Р. Сәгъдинең «Сынган беләзек» (1996), Р. Суфиевның «Сакаллы сабыйлар», Р. Җиһаншинаның «Улларым», И. Мәхмүтованың «Син бит минем бер генәм» (1996), Х. Төхфәтнең «Сакла сөюне, ташлама берүк» һ.б. пьесалар тора. Р. Сәгъдинең «Сынган беләзек» пьесасында төрле сынауларга дучар булган кеше язмышы сурәтләнә. Пьесадагы вакыйгалар тулысы белән мелодрама жанры таләпләренә

буйсындырылган. Чит илгә сәфәргә җыенучы Хафизның борчулы уйлануларына, бер яктан, яшәешнең социаль каршылыклары, икенче яктан, күршеләре Зиннур карт сөйләүләренә бәйле Мифтахетдиннең якты сурәте кушылып, кызыксыну-интриганы тагын да үстерә. Хафизның әтисе Мифтахетдин белән очрашуы – хисләр ташкыны, уй-фикер бәрелеше, төрле буын бәйләнеше, кан белән кан, ата белән ул кавышуы. Мелодрама жанрына хас булганча, Мифтахетдиннең дә әлегәчә билгеле булмаган язмышы укучы-тамашачы күңеленең иң нечкә кылларына тиеп, адәм баласы башына төшкән кайгы-хәсрәт газабы, шуларга түзеп яшәгән кешенең сабырлыгы турында уйлануларга этәрә, кеше хәсрәте үзеңнеке кебек кабул ителә. Бу төр әсәрләрнең мөһим үзенчәлеге буларак, җыр-моң пьесада үзгә урын били. Әлеге җырларда сагыну да, үкенү дә, борчылу да тулы чагылыш таба. Вакыйгалар барышында шактый еш урын алган җырлар геройларның күңел кичерешләрен, үзара мөнәсәбәтләрен, барыннан да бигрәк, күңел төбендә сакланган иң кадерле хис-кичерешләрен ачуга, укучы-тамашачыга җиткерүгә хезмәт итә.

Татар драматургиясенең бер үзенчәлеге буларак, комедия жанры барлык чорларда да дип әйтерлек өстенлек итә. XX гасыр ахырында әлеге жанр үсешенә аеруча уңай шартлар барлыкка килә. Бер яктан, үткәнне фаш итү комедиячел конфликт таләп итсә, икенче яктан, җәмгыятьтә урын алган әдәпсезлек-әхлаксызлык күренешләре үзләре үк юмор-сатира аша сурәтләүне сорап тора кебек. Бу чорда әлеге жанрның лирик комедия (Ф. Яруллин. «Сөембикә егет сайлый», 1992), сатирик комедия (Д. Салихов. «Пуля»), иҗтимагый комедия (Аманулла. «Әлепле артистлары», 1994), көнкүреш комедиясе (Ф. Яруллин. «Бер күрешү – үзе бер гомер», 1996), музыкаль комедия (Г. Каюмов. «Һинд кызы», 1992) кебек жанр формаларының җанлануы күзәтелә. Заман үзгәрешләрен, яшәешебезгә үтеп кергән ямьсез күренешләрне, аяныч хәлләрне, начар сыйфатларны фаш итүче әсәрләр арасында Аманулланың «Кылый Кирам балдагы» (1996), Ф. Яруллинның «Бер күрешү – үзе бер гомер» (1996), «Кызларның кызганнары» (1997) һ.б. пьесалар тәнкыйди яңгыраш ала.

Заман үзгәрешләренә игътибарлы драматург Д. Салихов җәмгыятьнең «караңгы почмакларына» үтеп кереп, икейөзлелек, куштанлык, наданлык, мескенлек, әхлаксызлык кебек күренешләрне комедия жанрына хас поэтик чаралар аша фаш итә. Тамашачылар яратып кабул иткән «Микүләй дәдәйнең бөер ташы», «Бәйрәмгалинең сыер тышавы» (1990), «Капчыктагы Мәгъфия», «Пуля», «Булса кодаң – генерал» һ.б. пьесаларында көлкеле вакыйга-күренешләр, үзенчәлекле комедиячел конфликт, көтелмәгән сюжет борылышлары белән очрашабыз. Г. Камал, Г. Исхакый, И. Богданов, К. Тинчурин, Н. Исәнбәт, Г. Насрый, Х. Вахит, Ю. Әминев кебек комедия осталарыннан килүче традицияләрне дәвам итеп, ул әлеге жанрны яңа сыйфатлар белән баета. Пьесаларда бөеклек һәм түбәнлек, акыллылык һәм мәгънәсезлек янәшә килеп, тормышның тискәре якларын бөтен тулылыгында ачуга хезмәт итә. Халыкчан көлүне яңа шартларда үстерә барып, авторның карнавал фикерләве аерым сыйфат яки күренешләрнең абсурд дәрәҗәсенә җиткән мәгънәсезлеген ачып сала.

XX гасыр сәхнә әдәбиятында активлашкан жанр формаларының тагын берсе – трагикомедия. Тормышта кайгылы һәм көлкеле күренешләрнең алмашынып торуы, еш кына берсеннән икенчесенә күчү күзәтелү трагикомедиячел күзаллауның нигезен билгели. Чынбарлыкны трагикомедиячел күзаллау, гадәттә, кискен үзгәрешләр чорында күзәтелгән рухи кризис белән бәйле активлаша. Капма-каршы сыйфатларга ия булган геройлар көлкеле яклары белән бергә фаҗигалы халәтләре дә тулы ачыла торган катлаулы, каршылыклы хәл-ситуацияләргә куела. Аның уңышлы мисаллары булып Д. Салиховның «Алла каргаган йорт», Ф. Бәйрәмованың «Вакыйга юләрләр йортында бара», «Аллалар ялгышы», З. Хәкимнең «Кишер басуы», «Җүләрләр йорты», А. Хәлимнең «Кияү урлау», М. Маликованың «Оҗмах балалары» (1990) һ.б. әсәрләр тора. Авторлар яшәешнең социаль, әхлакый мәсьәләләрен үзәккә алып, кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтен алгы планга чыгара. Җәмгыятьнең авыру ноктадары еш кына метафора аша сурәтләнә. Мондый пьесаларда башка жанр формаларының элементлары да урын алып, билгеле бер синтез тәшкил итә. Автор ирониясе ачык чагылып, һәртөр

мәгънәсезлектән көлү аша трагикомедиячел эффект тудырыла. Трагикомедиянең традицион өч тибыннан тыш, комедиялелек, фаҗигалылык һәм драматизм үзара кушылып килү дә күзәтелә. Комедия һәм трагедиянең жанр үзенчәлекләренә нигезләнеп, әсәрләрдә көлкелелекнең фаҗигалылыгы һәм фаҗигалылыкның көлкелелеге сурәтләнүгә киң урын бирелү, чынбарлыктан риза булмау, социаль, әхлакый, фәлсәфи сорауларны бөтен кискенлегендә ачу һәм аларны кабул итүнең фаҗигалылык тибы өстенлек итү белән аңлатыла.

Әлеге чорда трагедия жанрының да уңышлы үрнәкләре пәйда була һәм сәхнәгә куела[1]. Үткән тарихыбызның фаҗигалы дәверләрен, әфган һәм чечен сугышларын чагылдырган пьесаларда трагик шәхесләр аша халык язмышын тасвирлау алгы планга чыга (Ю. Сафиуллин. «Идегәй», «Йөзек һәм хәнҗәр»; Р. Хәмид. «Хан кызы» һ.б.). Шул ук вакытта трагедия-реквием (Р. Хәмид. «Ак тамырлар иле»), трагифарс (Г. Каюмов. «Упкын өстендә уен» («Мирас») кебек жанр формаларына мөрәҗәгать итү дә игътибарга лаек.

Шулай итеп, XX гасыр ахырында татар драматургиясе үсешенең яңа этабына аяк баса. Тормыштагы тотрыксызлыкны, юлсызлыкны, әхлаксызлыкны, элеккеге традицияләр-кыйммәтләр җимерелеп, алар урынында бушлык калуны сурәтләү объекты итеп алып, заман типларын, милли характерлар тудыруда, сурәтләүдә төрлелеккә омтылуда җитди эзләнүләргә йөз тота. Шул максатта авторлар реализм һәм романтизмның бай чараларыннан файдалану белән бергә, модернистик һәм постмодернистик алымнарга да теләп мөрәҗәгать итә. Болар исә XXI гасыр башындагы яңалыкларга нигез булып тора.

## 2.2. Т. Миңнуллинның XX гасыр ахыры иҗатында чор һәм шәхес

Иҗаты белән совет системасы урнаштырган тәртипләрне, ул яклаган идеологияне шактый кискен тәнкыйтьләгән, шул ук вакытта халкыбыз тормышын төрле яклап сурәтләп, гасырлар-

[1] *Әхмәдуллин А.* Эзләнүләр бәрәкәтлеме? // Казан утлары. – 2000. – № 8. – Б. 134.

дан килгән традицияләрне саклауга, рухи дөньяның тирән катламнарын ачып, яшәешкә өмет-ышаныч уятып килгән Т. Миңнуллин 1980 еллар уртасында җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә башланып киткән үзгәртеп кору процессына актив кушыла. Дөресрәге, бөтен иҗаты белән ул моны әзерләшә, аның котылгысызлыгын дәлилли, шуңа да тормышның демократик юнәлештә үсешенә, фикер төрлелегенә, кеше ирегенә ирешүгә әсәрләре белән дә, иҗтимагый-сәяси позициясе белән дә ярдәм итә.

Драматург иҗатында яңа этап башланып, ул тема-мотивлар төрлелегенә, публицистик пафоска, укучы-тамашачы белән җитди әңгәмә коруга һәм, чынбарлыкны бөтен каршылыгында сурәтләү максатында, пьесаларында яңа дөнья тудыру, аны яңа алым-чаралар ярдәмендә ачуга нигезләнә. 1980 елларның икенче яртысында язылган әсәрләре әлеге катлаулы чорны аңлау омтылышы белән бәйле булып, әдип икътисади һәм сәяси яңалыклар йогынтысында кеше аңында барган шактый авыр үзгәрешләрне чагылдыруга йөз тота. «Без китәбез, сез каласыз» (1986), «Тал бөресе имәндә» (1987), «Вөҗдан газабы» (1987), «Гармун белән скрипкә» (1988), «Авыл эте Акбай» (1989) пьесалары теге яисә бу дәрәҗәдә әлеге идеягә хезмәт итә. Т. Миңнуллин алдагы традицияләргә таянып, халык рухына тәэсир итәрдәй темалар эзли, яңа эчтәлеккә, заман мәсьәләләрен чагылдыруга омтыла. Үзгәреш җилләренең асылын аңлау һәм аны тамашачыга җиткерү максатында, таяныч буларак, татар дөньясында танылган шәхесләрнең эш-гамәлләренә мөрәҗәгать итә. Моңа 1986 елны бөек Тукайның тууына 100 ел тулу да этәргеч бирә. Шундый шартларда «Без китәбез, сез каласыз...» тарихи-биографик драмасы языла. Тукайның Идел буенда мануфактуралар тоткан Акчуриннарга сәфәре вакыйгасын үзәккә алган пьесада, шагыйрьнең уй-фикерләренә бәйле, үзгәртеп корулар куйган сорауларга да җавап эзләү бар. XX йөз башында көчле үзгәрешләр уртасында калган Тукай да даими уйланган, эзләнгән, еш кына икеләнеп тә калган. Әмма төп мәсьәләдә аның иманы нык һәм ачык: милләт язмышын үз язмышы итеп яшәү генә кешегә иман ныклыгы, фикер ачыклыгы, яшәү яме бирә.

Бу дәвердә яшәешнең төрле өлкәләрендә башланып киткән үзгәрешләр моңа кадәр гадәтләнгән яшәү рәвешен, җәмгыятьтә урнашкан системаны һәм, барыннан да бигрәк, кешенең боларга бәйле аң-акылы үзгәрүен таләп итә. Соңгысы иң авыры булып чыга. Бу исә ул чорда күп төрле кыенлыкларга, еш кына фаҗигаларга дә китерә. Аеруча партия-совет оешмаларында эшләүче җитәкчеләр күнеккән эш стилен, административ-команда системасын үзгәртүдә зур кыенлык кичерә. Т. Миңнуллин сәхнә әдәбиятында беренчеләрдән булып әлеге күренешләрне «Вөҗдан газабы» (1987) драмасында сурәтләргә алына. Исеменнән күренгәнчә, үзәктә партия райкомының беренче секретаре Тимергазинның яңа шартларга бәйле эшләргә омтылу юлында кичергән рухи кыенлыклары тора. Партия секретаренең якыннары һәм эштә хезмәткәрләре белән мөнәсәбәте, кылган гамәлләре артында моңа кадәр яшәп килгән системаның гаделсез, мантыйклы булмаган яклары ачылып, алар тәнкыйтькә дучар була. Драма чор авазын чагылдыруы, үзгәрешләрнең котылгысызлыгын ачуы, кеше шәхесенә игътибарның арта баруын үзенчәлекле образларда сурәтләве белән заманча яңгыраш ала һәм укучы-тамашачыны төп идеяне аңлауга китерә: «үзгәртеп кору һәркемнең үзеннән башланырга тиеш»[1].

Драматург чор каршылыкларын сатирик формада сурәтләү юлларын да эзли. Аның «Кәҗә туган түгел, бажа мал түгел» комедиясе хакимият тирәсендәгеләрнең эш-гамәлен сатирик планда сурәтләве белән үзенчәлекле. Анда үзгәртеп кору турында һәрдаим сөйләп, шул ук вакытта идарә итү системасында ялган, күз буяу, юк белән баш катыру, ягъни совет чорындагы бюрократлык күренешләренең дәвам итүе тәнкыйтьләнә. Мандас Мумиев докладында мәкальнең дөрес куллану-кулланылмавына бәйле күтәрелгән бәхәс ике якның да чын йөзен ачу, аларны фаш итү белән тәмамлана. Автор арттыру, сүз уйнату, геройларның бер-берсен һәм үз-үзләрен фаш итү алымнары һәм әдәби шартлылык аша хакимият өчен көрәшүче чиновникларның тулы бер галереясын мәйданга чыгара, алардан ачы көлә. Чын-

[1] *Әхмәдуллин А.* Дөреслеккә ирешү юлында // Казан утлары. – 1989. – № 11. – Б. 151.

барлыктагы абсурд хәленә җиткән күренешләрне сурәтләү аша, драматург социаль, мәдәни, милли мәсьәләләргә килеп чыга, аларны җәмәгатьчелек каршына куя.

* * *

XX гасыр ахыры татар драматургиясендә яңачалыклар тема-жанрлар төрлелегендә дә, әдәби сурәтләүнең алым-формаларында дә күзәтелә. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр нәтиҗәсендә милли үзаң үсү, дәүләтчелекне торгызу идеясенең киң яклау табуы әдәбиятта милли тематиканың киң чагылуына китерә. Милләтебезне инкыйраздан ничек коткарырга? Аның телен, менталитетын, яшәү рәвешен, традицияләрен ничек саклап калырга? Әлеге сораулар бу чор драма әсәрләренең күпчелеген иңләп үтә.

Милләтнең бүгенгесе һәм киләчәге турында уйлану күп төрле мәсьәләләрне үз эченә алып, билгеле инде, тематик төрлелектә дә чагылыш таба. Т. Миңнуллинның XX гасырның 90 елларында язылган пьесалары нәкъ менә сюжет яңалыгы, милләт язмышына турыдан-туры йогынты ясый торган сорауларны бөтен кискенлегендә һәм каршылыгында куюы белән бу чор сәхнә әдәбиятын әйдәп бара. Шуңа да катнаш никах мәсьәләсе урын алган «Илгизәр плюс Вера», «кыргый капитализм» шартларында иҗат кешеләренең онытылуга дучар ителүен чагылдырган «Хушыгыз», ил буйлап таралып яшәгән татарларның төрле этник катламнары турында «Гөргөри кияүләре», «Йөрәк маем», татарның морзалар катламы фаҗигасын ачкан «Шәҗәрә» һ.б. пьесалары киң яңгыраш алып, озак еллар сәхнәләрдән төшми уйнала.

Бөтен ил буйлап чәчелеп урнашкан, гомер иткән татар халкы эчендә керәшеннәр һәм мишәрләр дигән катламнар булып, алар үзләренә хас сөйләм үзенчәлеге, кием-салым, беренчеләре исә христиан динен тотулары белән аерылып тора. Т. Миңнуллинның керәшеннәр турындагы «Гөргөри кияүләре» (1995), мишәрләр тормышыннан алып язылган «Йөрәк маем» (1996) кебек комедияләре халыкның җанлы тормышын эчтән торып сурәтләве белән тамашачы тарафыннан яратып каршы алына. Пьесалар татарларның күп бизәкле, гаять гыйбрәтле, үзенчәлекле яшәү

рәвешен торгыза, аерым штрихлар белән бирелгән образлар аша чор рухын, халыкның көчен, эчке халәтен чагылдыра.

Милләтебезнең ассимиляцияләнүен тизләткән катнаш никах мәсьәләсе – җәмәгатьчелекне җитди борчыган һәм бертөрле генә бәяләп булмый торган сораулардан булып, үзгәртеп корулар чорында бөтен кискенлегендә алга килеп баса. Дөрес, бу мәсьәлә өр-яңа түгел. Борынгы чорлардан калган ядкярләрдә, язма истәлекләрдә төрле милләт балаларының яратышуы, качып китүе, төрле фаҗигаларга юлыгуы турында гыйбрәтле мисаллар бар. Татар дөньясында да андый очраклар булган билгеле, әмма алар гадәттән тыш хәл буларак кына кабул ителгән. Ислам дине төрле диндәге кешеләрнең кушылуына каршы чыкмаса да, аларның исламга килүен таләп итә, никах шул вакытта гына укыла ала. XX йөз башында бу мәсьәләгә беренчеләрдән булып Г. Исхакый мөрәҗәгать итә. «Ул әле өйләнмәгән иде» повестенда (1916) татар егете Шәмсинең Анна Васильевна исемле рус хатыны белән яшәп, уртак балалар үстерүе сурәтләнә. Г. Исхакый герое ул чор татар дөньясында үзенә тиң тәрбияле, мәдәниятле кыз таба алмый, ә Анна Васильевнаның матурлыгы, чиста-пөхтәлеге, укымышлы булуы аны җәлеп итә. Рус хатыны корган рәхәт тормышка ул бик тиз ияләшә һәм аннан баш тартасы килми. Балаларын мөселман итү, Төркиягә алып барып укыту турында уйлары булса да, моны хәл итү өчен берни эшләми. Әсәрдә авторның Шәмсигә билгеле бер ироник карашы да сизелә. Совет чорында халыклар дуслыгы, интернационализм идеяләрен яклауга нисбәтле катнаш никахлар һәрдаим хуплана, андый гаиләләр үрнәк итеп куела, киләчәк гаиләсе буларак тәкъдим ителә. Әдәбиятта бу мәсьәлә артык күпертелмәсә дә, катнаш никахка кергән, башка милләт вәкилләренә өйләнгән яисә кияүгә чыккан геройлар әсәрләрдә еш очрый.

Ә инде заман үзгәрешенә бәйле, бигрәк тә милли күтәрелеш шартларында катнаш никахларның аз санлы милләтләрне көчсезләндерүе, халык санын киметүгә китерүе турында ачыктан-ачык сөйләшү башлана. Төрле динне тотучыларның гаиләләре эчендә туган каршылыклар да калкып чыга. Ул елларның татар һәм рус телендәге вакытлы матбугатында катнаш

никахларга төрле мөнәсәбәт чагылып килә. Әнә шундый шартларда гаять җитди мәсьәлә турында беркемне дә кимсетмичә, шул ук вакытта һәркемгә уйланырга җирлек бирә торган әдәби әсәрләр, пьесалар язу, соңгыларын сәхнәгә чыгарып, киң катлам халыкка тәкъдим итү мәсьәләсе дә көн тәртибенә куела. Әлеге темага беренчеләрдән булып Т. Миңнуллин алына.

Драматургның «Илгизәр плюс Вера» драмасы катнаш никах кебек четерекле мәсьәләне сәнгать чаралары ярдәмендә тәэсирле итеп сурәтләве һәм яшь геройларның рухи йөзен, психологиясен гыйбрәтле күренешләрдә ачуы белән җәмәгатьчелекнең хөрмәтен казана.

Идел буендарак урнашкан Җикән авылында барган вакыйгалар үзәгендә татар һәм рус халыкларының менталитетына, яшәү рәвешенә, гореф-гадәт, дин, традицияләр аерымлыгына нигезләнгән каршылык тора. Ике милләт вәкиле булган Илгизәр белән Вераның өйләнешүенә бәйле автор үткән һәм бүгенге тормышның гыйбрәтле якларын ача, яшәешебезгә заман алып килгән яман гадәтләр, әдәпсез-әхлаксыз күренешләрне чагылдырып, укучы-тамашачыны борчуга сала, аларның сәбәпләре турында уйланырга этәрә. Пьесада ике халыкның өч буыны язмышы, аларның үзара мөнәсәбәте, тормыш-яшәешкә, өйләнешүгә караш-фикерләре сурәтләнә.

Бер авылның ике ягын тәшкил иткән татар һәм рус халкы менә 300 ел буе дус-тату яши. Бер-берсенең телләрен өйрәнгәннәр, бәйрәмнәр дә уртак, туйларда күңел ачканда ике халык җырларын бергәләп башкаралар, «Әпипә»не җиңел генә «Барыня-сударыня» алыштыра. Сөю-сөешү дә ят нәрсә булмаган. Драмада тасвирланган гаиләләрнең төрле буын вәкилләре арасында да булган ул хис. Әмма өйләнешү мәсьәләсендә алар «язылмаган законнар» белән эш иткәннәр. Чөнки гаилә кору ике кеше мөнәсәбәте белән генә чикләнмичә, әти-әни, әби-бабай, гомумән, бөтен нәсел белән бәйләнеп, туачак балалар аша киләчәккә дә барып тоташа. Аның ике халык мөнәсәбәтендә чагылыш табачагы да аңлашыла. Гаиләдә савыт-саба шалтырамый тормый. Андый чакларда кызып китеп бер-береңә милли хискә тия торган сүз әйтелсә, зур тавыш чыгасын күзаллау кыен түгел.

Бу турыда өлкән буын вәкиле Нурхәмәт бабай болай ди: *«Ир белән хатын кем ул? Сез әйтәсез дә, муж и жена – одна сатана, дип, одна сатанага әйләнгәнче, алар башта аерым-аерым сатана бит әле. Башта һәрберсе үз ягын каера. Кайвакыт каера-каера каерып ук чыгаралар. Башта юктан гына тавыш чыга да ызгышка әйләнә. Кызып китеп бер-берсенең начар якларын санап бетергәч, нәсел-нәсәпләргә барып җитәләр. Кайчак ахмак ир белән юньсез хатынның җүләрлеге аркасында чыккан ызгыш туган-тумачаларына күчә. Китә талаш, китә сугыш»*[1]. Бу фикерне рус карчыгы Мария дә бик теләп уртаклаша. Әлеге өлкән яшьтәге карт белән карчык арасындагы мөнәсәбәт үзенең гадилеге, эчкерсезлеге белән аерылып тора. Яшь вакыттагы сөю хисләре картларга хәзер дә якын, кадерле. Шулай да алар гаиләләрне, дөресрәге, ике халыкның яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен аерып торган, милләт буларак сакланышын тәэмин иткән үзгәлекләр символы булган, ата-аналары утыртып калдырган өянкенең тирән мәгънәсен белеп эш иткәннәр. Шуны ук һәрберсе үз баласына – Нурхәмәт Хәлиуллага, Мария Алексейга аңлатырга, яңа буын вәкилләре буларак төшендерергә тырышкан.

Хәлиулла белән Алексей, нигездә, моны аңлап эш итәләр. Аларның дус-тату, ярдәмләшеп яшәве дә бу фикерне раслый. Яшьләрнең өйләнешү турындагы хәбәрен дә алар сагаеп, борчылып кабул итә. *«Безнең бабайлар безнең патшалардан акыллырак булганнар*, – ди Алексей, үзара татулыкның нигезен аңлатып. – *Сез үз җирегездә рәнҗетелгән, без үз җиребездән куылган. (...) Язмышлар бер. (...) Безнең бабайлар бер-берсен хөрмәт итә белгәннәр. (...) Безнең тел бөек тел, сезнең тел бәләкәй дип, ахмак сүз сөйләмәгәннәр»*[2].

Алексей хатыны Наталья – драматург иҗат иткән уңышлы образларның берсе. Аерым эпизодларда гына күренсә дә, ул яхшыны яманнан аера белүче буларак күзаллана. Вераны тиешенчә тәрбияли алмавын, яшьләрнең кавышуына ризалыкны ашыгып бирүен дә аңлый ул. Авылда моңа кадәр сакланып

---

[1] *Миңнуллин Т.* Илгизәр плюс Вера // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 22.

[2] Шунда ук. – Б. 20

килгән кагыйдәне бозган өчен, Наталья халыктан гафу үтенә: *«Гаепләмәгез инде сез безне, авылдашлар»*[1].

Ә менә Хәлиулла хатыны Данияне бертөрле генә бәяләве кыен. Ул – катнаш никахны иң актив яклаучы. Вакыйга-күренешләрдә усал килен образының бер чагылышы булып ачыла. Каенатасын хөрмәт итмәүче, ирен дә санламаучы Даниянең гореф-гадәтләрне бозуы, үз белдеге белән эш итүе халкыбызга хас матур сыйфатларның кимүен, әхлакый йөзебезне югалту куркынычы барлыгын искәртә. Ул үзенең уйламыйча кылган эш-гамәлләрен чорга сылтый, замананың башка булуын да искәртә. Әсәр ахырында Дания караш-фикерләренең ялгышлыгын аңлаудан бигрәк, буталып калган, рәнҗетелгән ана буларак күзаллана. Килене Вераның үз динендә калып, аңа тугрылык саклаячагын күргәч, ачынып: *«Белмәдем, белмәдем. Мин тәре тага торган марҗага өйләндерергә үстермәдем улымны. Миңа тәреле марҗа кирәкми»*[2]. Бала тәрбиясендә автор хатын-кызның ролен калкытып куя. Дания милли яшәеш үрнәген улына бирә алмаган, шуңа Илгизәр хатыны Вера йогынтысында яши. Вера исә үз анасыннан рус тәрбиясе алган, шуңа да баласына исемне дә шуннан чыгып куша, бу яктан ул үз милләте дәвамчысы буларак бәяләнә. *«Т. Миңнуллин оста, нечкә итеп сурәтләгәнчә, хатын-кыз язмышы – үзе үк милләт язмышының үзәге. Хатын-кыз саклап тоткан гаилә нык булса, миллилек тә саклана»*[3].

Катнаш никах мәсьәләсен ике гаилә эчендә калдырмыйча, автор аңа авылдашлар мөнәсәбәтен дә ача. Пьесага махсус кертелгән Ислам сөйләме кискенрәк яңгыраса да, ул башкалар әйтеп бетермәгәнне ачыктан-ачык җиткерүче ролен дә үти. Катнаш никахка карашы да икеләнүгә урын калдырмый: *«Без урыс белән кушыла алмыйбыз. Урыс белән янәшә генә яши алабыз. Син марҗага өйләнгән бер татарның баласына татар исемен*

---

[1] *Миңнуллин Т.* Илгизәр плюс Вера // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 21.

[2] Шунда ук. – Б. 47.

[3] *Шәмсутова А.А.* Туфан Миңнуллин пьесаларында Язмыш мифологемасы // *Шәмсутова А.А.* Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш: фәнни мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 93.

*кушканын ишеткәнең бармы? Урыска кияүгә чыккан татар хатынының баласы әнисенә әни дип әйтәме? Урыс татар белән татарны йотар өчен генә туганлаша, белдеңме?!»*[1]

Яшь буын вәкилләре Илгизәр белән Вераның эш-гамәле, дөньяга карашы, хыял-максатлары, ахыр чиктә яшәү рәвеше – авторның игътибар үзәгендә торган мөһим мәсьәлә. Табигать тарафыннан адәмгә вазифа-хокук бирелгән: үсеп, билгеле бер дәрәҗәдә белем-тәҗрибә туплагач, ул гаилә кора, балалар үстереп, нәселен дәвам итә. Әсәрнең эпилогы ролен үтәгән татар һәм рус туйлары матур гореф-гадәт буларак тасвирлана. Халык җырындагы егет турында *«асыл заттыр сөяге»,* ә кызның *«эшкә уңган, төскә булган гүзәл зат»* булуына капма-каршы рәвештә Илгизәр белән Вера образлары калкып чыга. Пьесадагы беренче диалогларында ук аларның әле балалыктан чыгып җитмәве, олы тормышка әзер түгеллеге күренә. Өйләнешүгә яшьләр ниндидер бер уен, кызыклы күренеш, гадәти теләкләренә ирешү дип карыйлар. Бер-берсенә булган хисләре дә ачыкланып бетмәгән 17 яшьлек егет белән кызның акылдан бигрәк хисләре алдан йөри. Иң кызганычы, Илгизәр белән Верада әти-әнигә, әби-бабайга хөрмәт, олы тормышка беренче адымны алар фатихасы белән башлау кирәклеген аңлау юк. Татар һәм рус халыкларының милли үзенчәлекләре, дини аерымлыклары булуны да санга сукмый алар.

Яшьләрнең акылсыз эш-гамәлләре аркасында ике гаилә арасыннан «кара мәче» уза. Ә инде яңа туган балага Иван дип исем кушуларын белгәч, Дания хуштан язар хәлгә җитә, кая баруын белешмичә чыгып йөгерә. Шул рәвешле, милли аерымлыклар соң чиккәчә киеренкеләнгәч, баласын күтәргән Вера Илгизәрне калдырып китә. Ир исә ауган карт өянке янында кала. Әсәр ахырында Мария түтинең *«Ни булган бу өянкегә?(...) Ауган ич бу! Кара, бер дә авар кебек түгел иде ич. Ауган шул. Нурхәмәт белә микән? Кара син, ә, бер дә авар төсле түгел иде...»*[2] дигән сүзләрне кабатлап әйтүендә төп идея тагын да тирәнәя төшә.

---

[1] *Миңнуллин Т.* Илгизәр плюс Вера // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 38.

[2] Шунда ук. – Б. 52.

Әйе, һәр милләт үз кануннарына, гореф-гадәтләренә, дини карашларына нигезләнеп яшәргә тиеш. Аларның бозылуы юньлегә илтми, киресенчә, төрле каршылыклар, хәтта фаҗигалар туарга мөмкин. Шуның чагылышы булган катнаш никахлар күпсанлы, көчлерәк милләткә генә хезмәт итә. Шул рәвешле, Т. Миңнуллин әлеге драмасында катнаш никах кебек мәсьәләгә җитди якын килүне, яшьләрне тормышка әзерләүне, моның ата-ана алдында торган бурыч икәнен тирәнтен аңлауны җәмәгатьчелеккә тәкъдим итә. Һәр халыкның күпгасырлык яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен санга сукмаган яшь буын белән өлкәннәр арасындагы конфликт бөтен вакыйгаларны иңләп үтеп, заманның мөһим мәсьәләсе буларак яңгыраш ала.

Драматург милләт яшәешенең төрле якларын өйрәнүне дәвам итеп, аның үткән тарихында җитди роль уйнаган морзалар катламы вәкилләренең гыйбрәтле язмышын сурәтләүгә алына. Татар дәүләтчелеге вакытында формалашкан морзалар катламының бер өлеше, гасырлар дәвамында рус дәүләтенең кысу-изүгә корылган сәясәте аркасында, христиан динен кабул итеп руслашкан, икенчеләре исә хокукларыннан мәхрүм ителеп, бөлүгә дучар булган. Әмма нинди генә хәлдә дә үзләренең аксөяк нәсел билгеләрен, милли горурлыкны гасырлар аша алдагы буыннарга җиткерергә тырышкан. Кызганыч ки, тоталитар дәүләт әлеге социаль катлауның соңгыларын да юк итүгә, таркатуга ирешә. Т. Миңнуллин «Шәҗәрә» драмасында милләтнең ачы язмышының бер мисалын әлеге катлау вәкилләре тормышында сурәтли. Г. Камал традицияләрендә, кинокадр лентасын хәтерләткән күренешләрне бер-бер артлы тезеп, әдип морза нәселенең төрле вәкилләре тормышын гыйбрәтле вакыйгалар аша күрсәтеп кенә калмый, бәлки аларны үзара якынайту, берләштерү юлларын да эзли. Р. Хәмид язганча, *«“Шәҗәрә” халкыбызның үз тамырларын эзләргә омтылуын оригиналь сюжет аша күрсәтә...»*[1]. Татар халкының тирән катламнары, дәүләтчелек белән бәйле затлылыгы бар һәм ул бүгенгегә килеп җиткән – әсәр нигезенә салынган фәлсәфи һәм әхлакый мәгънәнең

[1] *Хәмид Р.* Татар драматургиясе миллиме? // Казан утлары. – 2002. – № 4. – Б. 158.

асылы әнә шунда. Ә ул исә бер затлы нәсел язмышы аркылы бөтен бер милләт язмышын, аның фаҗигасын чагылдыру һәм халкыбызның, нинди генә шартларда яшәсә дә, үзенә хас яшәү рәвешен, җыр-моңын һәм башка рухи кыйммәтләрен саклап калуын күрсәтү белән бәйле.

Әсәр нигезенә салынган тирән фәлсәфи мәгънә ерак авылдан Казанга килгән Сәет Шәрәфетдиновның әтисе кушкан йомышны үтәве белән бәйле. Егетнең ерак бабасы күп еллар элек морза Сәетбәковтан бурычка акча алып торган һәм аны вакытында кире кайтара алмаган. Әлеге бурычны түләү, бер буыннан икенчесенә күчә барып, Сәеткә килеп җиткән. Егет шәһәр буйлап Сәетбәковлар нәселе дәвамчысын эзләп йөри, гаять гыйбрәтле язмышлы кешеләр белән очраша һәм ахырда морза дәвамчыларыннан яңа гына өйләнешкән гаиләгә бурычын кайтара. Берничә буыннан килгән васыятьне үтәү вакыйгасы артында татар халкының гаҗәеп матур сыйфатлары турында җитди сүз алып барыла. Бу, беренче чиратта, намус төшенчәсе белән бәйле, ягъни үзеңнең бурычыңны кайтаруда һәм сиңа тиешле булмаган акчадан баш тарта алуда кешеләр сынала. Морза нәселе вәкилләре кичергән фаҗигалар артында ил-халык тормышы, тоталитар җәмгыятьнең кешелексез яклары ачыла.

Шул ук вакытта Т. Миңнуллин үзенчәлекле авыл егете образы тудыра. 18 яшьлек Сәет авторның эстетик идеалын чагылдыра: ул тәвәккәл, максатчан, намуслы, нәсел-нәсәбен яхшы белүе өстенә, аның белән горурлана, киләчәгенә өмет белән карый. Драматургның күпчелек әсәрләрен иңләп үткән төшенчә буларак, егетнең киләчәгенә, үз көче белән матур тормыш корачагына һәм аның нигезенең гаиләдә салынуына укучы-тамашачы күңелендә ышаныч тудыра. Кешене кеше итеп саклаган сыйфатлар рәвешендә намус, җаваплылык, сүзеңдә тора белүне яшәеш принцибы иткән Сәет образы чорның үзенчәлекле тибы буларак яңгыраш ала.

* * *

Т. Миңнуллин бу чор сәнгати эзләнүләрендә, төрле социаль катлау кешеләре тормышын өйрәнүне дәвам итеп, интеллектуаль башлангычка нигезләнгән «Хушыгыз» (1990) драмасын

иҗат итә. Алдагы елларда язылган «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә» пьесалары белән трилогия тәшкил иткән пьеса үзәгендә шәхес фаҗигасы ята. Автор уку елларында дуслашып алган бер төркем иҗат кешеләренең тулы бер тормышы белән таныштыра. Беренче әсәрдә яңарак кына олы тормышка атлап, үз юлларын эзләүче дусларга 25 яшьләр, икенче әсәрдә инде алар 40–45 яшьләр тирәсендә. Һәрберсенең тормышта тоткан урыны, билгеле бер ирешкән уңышы бар. Яшәеш принциплары буенча карашлар аерымлыгы алар арасында конфликт китереп чыгарса да, бер-берсен гафу итү, аңларга тырышу ачык сизелә. Өченче әсәрдә исә без олыгаеп баручы, ялга чыккан элекке дуслар белән кабат очрашабыз.

Пьеса ялгыз гомер кичерүче Миләүшәнең авылдан яшьлек дусты Галимулланы чакырып китерүе белән башлана. Аларның хатирәләр белән тулы әңгәмсендә танылган җырчы Миләүшә Нигъмәтҗанованың сызланулар белән тулы гомер юлы күз алдына бастырыла. Ул ике тапкыр кияүгә чыкса да, гаилә тормышы уңышлы булмый, аерыла. Сәхнә тоткан чагында иҗатын яратучылар чолгап алган булса, хәзер ялгызлыкта калган. *«Искә төшә, үкендерә, үзгәртеп булмый*, – ди Миләүшә үткәне турында. – *Уйлап-уйлап утырдым да – бу дөньяда мине чын-чынлап яраткан бер генә кеше булган икән дигән нәтиҗәгә килдем. Ул син булгансың кебек тоелды. (...) Ничек мин шуны аңлап белмәгәнмен...»*[1] Гомере ахырына якынлашуын сизеп, ул Галимуллага эч серен генә түгел, соңгы васыятен дә җиткерә.

Әңгәмә барышында аларның бүгенгесе белән яшьлек хатирәләре үрелеп бара. Үткәннәрендә күбрәк казынган саен Миләүшәнең фаҗигасы тирәнрәк ачыла бара. *«Безнең бөтен тормышыбыз уенга охшаган»*[2], – ди ул һәм тормышына бәйле хатирәләргә күчә. Гомеренең мәгънәсез булуын, бернигә дә ирешмәвен, нәтиҗә буларак беркемгә дә кирәкмәгән хәлдә, онытылып, ялгызлыкта калуын аңлауга килә. Беренче ире Шәһитне хәтерендә яңарта. «Миләүшәнең туган көне» драмасында төп

---

[1] *Миңнуллин Т.* Хушыгыз // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 489.

[2] Шунда ук. – Б. 498.

геройларның берсе дусларын үзенә тиң түгел дип саный, алардан читләшә башлый. Дуслары исә, гаделлек ягында торучылар, хаксызга рәнҗетелгән Нурисламны яклаучылар буларак сурәтләнә. Миләүшә хәзер инде ул чорга башка күзлектән карый. Шәһитне кискен кире каксалар да, үзләре дә әллә кем түгел икән. Алар күбрәк сүз сөйләү белән мавыгып, теләк-омтылышларына, яшьлек хыялларына ирешә алмаганнар.

Үткәннәрен искә төшереп юанган Миләүшә үкенечләрнең күп булуын аңлый. *«Даны да, шөһрәте дә, сәясәте дә, сәяхәте дә – берсе дә кирәкми инде миңа,* – ди ул. – *Күпме гөнаһ җыелган. Гөнаһларның беразын гына кимет дип, Ходайга ялварыр идем, бер генә дога да белмим. Догасыз калган буын. Тәһарәтсез буын»*[1]. Әнә шул рәвешле ул үзенең һәм үз чоры кешеләренең җан авызын ишеттерә. Ә бит Алла сүзеннән, догадан аерылган берничә буын үсеп җиткән. Алар соңарып кына булса да үз асылларына кайтырлар, билгеле, әмма җан тынычлыгына ирешә алмаячаклар, чөнки дога белмиләр.

Миләүшә һәм Галимулланың яшьлек хатирәләре әсәргә романтик рух, ярату матурлыгы, күңел сафлыгы алып килә. Аларны очраштырган, бер-берсенә якынайткан һәм гомерлеккә аерылышуларының да шаһиты булган Бакалы күлне икесе дә оныта алмый яшәгән. Миләүшә белән Галимулланың яшьлек мөнәсәбәте – ул йөрәк һәм акыл тартышы. Йөрәкләре бер-берсенә тартылса да, акыллары бергә була алмауларын аңлый. Галимулла өчен Миләүшә беренче һәм бердәнбер яраткан кешесе булып кала, шуңа да ялгыз гомер кичерә. *«Ходай мине сиңа тиң итеп яратмаган. Ә үзе сине яраттырган. Син өстә, мин түбәндә. Йөрәк шуны аңламый интегә»*[2], – ди ул кызга. Икесе ике төрле булып, бергә була алмау сәбәбен дә Миләүшәнең үзенә әйтә: *«Син үзеңне генә яратасың. Үзен күп яраткан кеше бүтәннәрне ярата белми»*[3]. Гомере буе табынып яшәгән кешесен соңгы юлга озата барганда тынычландыру сүзе дә таба:

[1] Б. *Миңнуллин Т.* Хушыгыз // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 506.
[2] Шунда ук. – 505.
[3] Шунда ук. – Б. 508.

*«Юк, юк синең гөнаһларың, Миләүшә. Күңелеңдәге моңын кешеләргә өләшкән кеше ничек гөнаһлы булсын? Кешеләргә матурлык бүләк итүче гөнаһлы була димени?»*[1] Гомумән, гомере буе музыка сәнгатенә хезмәт итеп тә, хәзер инде яшәвенең мәгънәсезлеген, тулы канлы олы тормышның янәшәдән үтеп китүен бик соңарып аңлаган, җәмгыять һәм «дуслары» тарафыннан онытылган Миләүшә – авторның зур табышы. Гомер кояшы баюга баруын ачык тойган халәттә ул ялгызлыктан, чарасызлыктан газаплана. Тирән сагыш, рәнҗү белән янган күңелендә якты нур булып яшьлек мәхәббәте саклана.

Пьесада Миләүшә белән Галимулла әңгәмәсе элекке дусларның хәл-халәтен ачу белән кушылып бара. Рафис белән Саҗидә гаиләсендә дә җан тынычлыгы юк. Аларның тормышта теләкләренә ирешмәве сизелә, әлеге канәгатьсезлек бер-берсенә төртмәле мөнәсәбәттә чагыла. Ир белән хатынга шактый тулы бәяне уллары Рөстәм бирә: *«Вы же клялись, не я. Вы же изучали моральный кодекс...»*[2] Ул чорда «Коммунизм төзүченең мораль кодексы» һәр уку йортында өйрәнелә иде. Аның эчтәлеге һәм мәгънәсе гомумкешелек кыйммәтләренә нигезләнеп, һәр кешедә булырга тиешле әдәп-әхлак кагыйдәләрен үз эченә ала. Нык үскән социалистик җәмгыятьтә шуларга нигезләнеп яшәү соралса да, тормышта ул, билгеле инде, үтәлми иде. Дөресрәге, совет чорының партия һәм дәүләт документлары кебек кәгазьдә генә кала. Шул рәвешле, автор ялганның өстән – власть тотучылардан башлануына да ишарә итә. Рәфис яңа шартларга яраклашкан кеше итеп сурәтләнә. Ул нәрсәгә дә булса каршы көрәшүгә караганда, шуннан файда эшләү юлын эзләүне кирәк саный. *«Мин кемнәргәдер ачу саклап җылап та утырмыйм. Кемгә ачу сакларга? Өстәгеләргәме? Алар барыбер безне күрми. Кешеләргәме? Нишләтәсең инде аларны? Заман нинди, кешеләре шундый. Йөрәк үлде, корсак кына калды кешедә»*[3], – ди ул.

---

[1] *Миңнуллин Т.* Хушыгыз // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 509.

[2] Шунда ук. – Б. 492.

[3] Шунда ук. – Б. 503.

Композитор буларак танылу алган Фәһим дә иҗаттан читләшкән, күңел төшенкелегенә бирелеп яши. Хатыны Эльмираның үзен кулга алырга чакыруы да әлегә нәтиҗә бирми. Вакыты белән ул якты дөньядан ваз кичкән, яшәү мәгънәсен югалткан кеше булып күренә. *«Яшисем килми минем бу дөньяда. Фәхешханәдә миңа кызык түгел*, – ди ул үз-үзен белештермәс халәттә. – *(...) Кайда ул кешеләр? Ике аяклы күшәүче хайваннар һәм аларны ашаучы ике аяклы ерткыч җанварлар гына калды. (...) Алла да юк. (...) Китте ул. Җиргә, кешеләргә кулын селтәде дә китте, кайтмаска китте ул. Җиргә Иблис хуҗа»*[1]. Шул рәвешле, аның күңелендә яшәешнең гаделсезлегенә, кеше шәхесенең түбәнлегенә ризасызлык чагыла. Ул ни өчен үзенең шундый мескен хәлдә калуының сәбәбен аңлый алмый газаплана. Композитор буларак танылу алып, дистәләгән җырлары озак еллар радио-телевидениедән яңгыраган булса да, бүген ул акчага мохтаҗлык кичерә. Аның сызлануы бөтен җәмгыятькә әрнү булып чыга. Фәһимнең *«Кем кемгә кирәк бу дөньяда?»* дигән соравы да барлык геройлар исеменнән һәм һәркемгә әйтелә кебек. Бу инде җәмгыятьнең төзек булмавы, эчтән таркалуы билгесе. Озак еллар ялган битлек киеп, дус булып йөрүнең, ниһаять, ачылуы. Ялган битлек алыну белән аларның бер-берсенә кирәк булмавы калкып чыга.

Миләүшә вафатыннан соң, Рәфис квартирасында җыелган дуслар магнитофон язмасында Миләүшәнең хушлашу сүзен тыңлый. Ул чын хакыйкатьне соңарып булса да аларга җиткерә: *«Дуслар булып, бер-беребезне алдашып яшәүдән туйдым»*[2]. Миләүшә үзләрендәге куркаклыкны, мескенлекне, мәгънәсезлекне яшерү өчен алдашуга баруларын һәм чын шәхес буларак юкка чыгуларын да әйтә. *«Бәхетсез илдә бәхетлеләр була алмый»*[3], – ди ул яшәү рәвешенең илдәге, җәмгыятьтәге мохит белән дә тыгыз бәйле булуын искәртеп. Миләүшәнең үзенә, элекке дусларына бәясе төрлечә кабул ителә. Нурислам үзләренә

[1] *Миңнуллин Т.* Хушыгыз // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 501.

[2] Шунда ук. – Б. 522.

[3] Шунда ук. – Б. 523.

төбәлгән тәнкыйть утын җәмгыятькә күчерә. *«Без алдашмадык*, – ди ул Миләүшә сүзләре белән килешмичә. – *Алдашмый яшәү өчен син яшәгән җәмгыятьнең дөреслеккә корылган булуы кирәк. Ә без ялганга, алдашуга корылган җәмгыятьтә үстек»*[1]. Рәфис әлеге фикерне дәвам итеп, үзләренең беркемгә кирәкмәвен тагын бер искәртә. Ул Миләүшәне әлеге гаделсезлеккә рәнҗеп китте дип саный. Шул ук вакытта үзен кимсетергә юл куймаячагын да әйтеп үтә.

Шул рәвешле, элекке дуслар үзләренең гомер юлына, иҗатчы буларак эшчәнлекләренә нәтиҗә ясауга килә. Яшьлектә алар дөньяны матур, яшәешне мәгънәле итү турында хыялланса-лар да, аны тормышка ашыра алмыйлар. Шуңа да Рәфис улы Рөстәмнең аларга биргән бәясе хакыйкать булып яңгырый: *«Кеше күңелен камил итәргә җыенасызмы? Кызганыч кешеләр сез. Бүгенге дөньяга сыймаган кешеләр. Шулай да сез миңа ошыйсыз. Чөнки сез җүләрләр, тилеләр. Ә кешеләр, җүләрләрсез, тилеләрсез яши алмый...»*[2] Автор тәнкыйте үткәндәге совет чоры белән бергә, геройлар яши торган постсовет җәмгыятенә дә юнәлтелә.

Шулай итеп, Т. Миңнуллин үзенчәлекле сурәтләү ысулына мөрәҗәгать итә. Миләүшә характерында, эш-гамәлендә Ялгызлык сыйфатын күтәреп куеп, укучы-тамашачы каршында яшәү белән үлем чигендә тормыш мәгънәсенә төшенү – Хакыйкатькә омтылу мизгелен ача. Пьесаны иңләп үткән төп лейтмотив булып сызлану (экзистенциализм) фәлсәфәсе тора. Ахыр чиктә Миләүшә язмышы ул – тулы бер буынның яшәү рәвеше, тормыш моделе дә бит. Гомере буе җавапсыз мәхәббәт белән янган Галимулла да бәхетсез. Әлеге ике геройны теләк-омтылышларының тормышка ашмавы, өметсезлек, мәхәббәткә ирешә алмау һәм шуларга бәйле Ялгызлык берләштерә. Т. Миңнуллин Миләүшә язмышы аша гомернең чикләнгәнлеген, Яшәешнең бер мизгел генә булуын, аның мәгънәсезлеген күрсәтсә дә, әлеге герой фаҗигасын булдырмау юлларын да эзли. Аның

[1] *Миңнуллин Т.* Хушыгыз // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 524.

[2] Шунда ук. – Б. 527.

башлангычы – рухи сафлыкта, яшьлек мәхәббәтенә тугрылыкта, күңелдә өмет хисен саклауда.

* * *

XX гасырның 90 нчы елларындагы икътисади торгынлык, матди һәм рухи кыйммәтләрнең үзгәрүе, әфган һәм чечен сугышы нәтиҗәләре йогынтысында тулы бер буын рухи кризис кичерә. Әлеге «югалган буын», аның сәбәпләре турында уйланулар З. Хәким, Д. Салихов, Аманулла, Ю. Сафиуллин, Т. Миңнуллин кебек драматурглар иҗатында бөтен кискенлеге белән куела. Әдипләр каршылыклы, еш кына фаҗигалы язмышлардан гыйбрәт алырга, андыйларга миһербанлык күрсәтергә чакыра. Укучы-тамашачы күңелендә хис-кичерешләр өермәсе кузгатып, әйләнә-тирәгә башка күз белән – ялгышу-хаталануын аңлап та, аны төзәтә алмыйча җәфаланучы кеше күзе белән карарга, рухи сафлыкка этәрә. Һәрбер иҗатчы кебек Т. Миңнуллин да яңа теманы тулы чагылдыручы заман героен эзли. Чорның актуаль мәсьәләләренә бәйле нинди генә тема-мотивларга мөрәҗәгать итмәсен, әдипне катлаулы вакыйгалар уртасында калып, җитди сынауларга насыйп булган кеше кызыксындыра. Алдагы чор иҗатындагы кебек XX гасыр ахырындагы әсәрләрендәге кеше образлары да төрле булып, һәрберсе үз йөзе, эш-гамәле, яклаган кыйммәтләре белән аерылып тора.

Драматург «Эзләдем, бәгърем, сине» (2000) драмасындагы гаҗәеп үзенчәлекле, беркемне дә битараф калдырмый торган тормыш материалына мөрәҗәгать итә – төрле сәбәпләр аркасында инвалид коляскасына беркетелгән яшь геройларны сурәтли. Тормыш каршылыклары һәркем алдына кыенлык-михнәтләрне таудай өеп куя. Көнкүрешнең күптөрле мәшәкатьләре, эшсезлек, хезмәт хакын вакытында түләмәү һ.б. нәтиҗәсендә яшәү мәгънәсен, киләчәккә өметен югалтучылар да бихисап, үзенә үзе кул салучыларның артуы да шул турыда сөйли. Ә бит инвалид-авыруларга икеләтә авыр. Т. Миңнуллин әнә шундый геройларның җан сыкрануларын, катлаулы һәм каршылыклы күңел тибрәнешләрен укучы-тамашачы алдына куя. Драмада бары ике генә герой катнаша – Рәхимҗан белән Нурсинә.

Сугыш афәтендә ике аягын югалтып, протез кияргә мәҗбүр булган Рәхимҗан – авторның табышы. Горур, үз шәхесен бәяли һәм яклый белә торган, авырлыкларга тешен кысып түзүче, акыллы һәм олы йөрәкле егет ул.

Күренешләрдә Нурсинә дә ихтыяр көченә ия, сабыр, тыйнак, шул ук вакытта башкаларны тыңлый һәм аңлый белүче кыз булып күңелдә кала. Драматург, оста психолог буларак, геройларының рухи халәтен ачык тоемлап, белеп һәм укучы-тамашачы күңеленә эмоциональ тәэсирле итеп чагылдыра. Беренче күренешләрдән алып соңгысына кадәрге хәл-сурәтләрдә геройларның рухи эволюциясе бирелә. Әдип кеше рухының көченә, бөеклегенә ышана, үз-үзләрен һәм бер-берсен таба алган егет белән кызга соклануын яшерми, кешене өмет-ышаныч яшәтә, үзебездә һәм башкаларда әлеге хис-сыйфатны булдырырга, сакларга тиешбез, ди кебек. Телефоннан гына сөйләшеп, күңелләрендә туган мәхәббәт хисе, Рәхимҗан белән Нурсинәне тормышка башка күз белән карарга этәрә, рухларын ныгыта. Драма ахырында очрашкан егет белән кыз – олы тормышка бергәләп атлаучы, чын мәхәббәтнең кадерен белүче, «аякларында» нык басып торучы һәм шуның белән укучы-тамашачы күңелендә дә теләктәшлек табучы яшь геройлар. Шул рәвешле, әдип, киләчәкнең яшьләр кулында булуын яхшы аңлап, аларның олы тормышка килүен, каршылыклар аша үзләрен табуын, еш кына ялгышларга дучар булуларын тәэсирле алым-чаралар ярдәмендә тамашачыга тәкъдим итә.

Шул рәвешле, Т. Миңнуллин XX гасыр ахыры иҗатында, яшәешнең яңа катламнарын өйрәнеп, сәнгать чаралары аша чагылдыруга бәйле яңа тема һәм мотивларга мөрәҗәгать итә. Заман рухындагы әсәрләр язу ихтыяҗы аны милләт яшәешенең төрле якларын, аерым алганда, этник катламнар яшәеше, күчеш чоры каршылыкларында традицияләрнең сакланышы, шулай ук социаль төркемнәр тормышы һәм гадәттән тыш шартларга куелган кешеләрнең үз-үзен табуы кебек мәсьәләләрне өйрәнүгә китерә. Пьесаларның конфликты чорга, яшәештәге каршылыкларга, гаделсезлекләргә бәйле оеша. Т. Миңнуллин аеруча яратып геройларның эчке каршылыгын ачуга килә.

## 2.3. Милли яшәешне сәнгати кабул итүдә яңа алымнар

Тормыш-чынбарлыкны бөтен тулылыгында чагылдыру максатында, Т. Миңнуллин сурәт чараларының бай палитрасыннан иркен файдалана. Автор иркен рәвештә метафора булып килгән күренешләргә, «уен» алымына, читләтеп әйтүгә, интертекстуальлеккә, мифологизмга һ.б. мөрәҗәгать итә. Шуның бер үрнәге буларак, әдип образ-символлар кулланып, җитди сәнгати казанышларга ирешә. Символ төшенчәсенә әдәби сүзлекләрдә, теоретик хезмәтләрдә, нигездә, үзара якын аңлатма бирелә: ниндидер әйбер-күренешнең асылын, эчтәлеген күчерелмә мәгънәдә зур гомумиләштерү аша аңлатучы билге[1]. Татар сүз сәнгате борынгы чорларыннан алып символларга мөрәҗәгать итеп килә. Борынгы һәм Урта гасырлар әдәбиятында ук Яхшылык һәм Явызлык, Яшәү һәм Үлем төшенчәләрен, кеше яшәешен табигать күренешләре аша аңлатуны символлар ярдәмендә бирү үрнәкләре очрый. Татар Ренессанс әдәбиятының гүзәл үрнәге булган Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә әт-Тәүхид фәлсәфәсе яисә Акыл, Матурлык, Сабырлык, Мәхәббәт, Сәнгать концепцияләре бирелешендә символлар кулланылышы мөһим урын алып тора[2]. XIX йөз ахырында Яңарыш юлына аяк баскан татар әдәбияты XX йөз башында чәчәк ату чорын кичерә. Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәби-эстетик фикере йогынтысы да уңай шартлар тудыра. Татар әдәбияты үз традицияләренә таянган хәлдә, төрле иҗат юнәлешләрен, агымнарын үзләштерә, чынбарлыкны танып белүнең, сурәтләүнең яңа баскычына күтәрелә. Реализм һәм роматизм белән янәшә модернистик алымнарга күпләп мөрәҗәгать итү күзәтелә. Дини-әхлакый һәм суфичыл эчтәлекле әсәрләрдә киң урын алган тасвирлау чараларын үстерә барып һәм рус-Европа әдәбиятлары йогынтысына нигезле, татар сүз сәнгатендә дә символизм җирләшә. Кызганыч ки, Октябрь инкыйлабыннан соң урнашкан хакими-

---

[1] *Ермилова Е.В.* Теория и образный мир русского символизма. – М.: Наука, 1989. – С. 4.

[2] *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. – 171 с.

ят шартларында әдәбиятта парадигмалар алышыну күзәтелеп, башка агымнар кебек үк, символизм агымының үсеше дә туктап кала. Дөрес, әдәби әсәрнең сәнгати эшләнешендә мөһим урын алып торган символлардан файдалану дәвам итеп, ул яңа социаль-мәдәни шартларга, әдипләрнең чынбарлыкка бәйле әдәби-эстетик эзләнүләренә яраклаша. Татар поэзиясендә образ-символлар системасын өйрәнгән Н. Йосыпова билгеләп үткәнчә, бу чорда идеологик төсмер алган мифологик лозунгларны раслау өчен тотрыклы образ-символлар да, аларның үзгәртелгән вариантлары да кулланылып, тормышка яңача карашны билгеләүгә хезмәт итә. Шулай ук идеологик мифлар, алар белән бәйле мифологик образларның, шулай ук сәяси җитәкчеләр исемнәренең дә символ булып килүе активлаша[1].

Әдәби әсәрдә һәрбер элемент – троплар, әдәби деталь, хәтта герой да символ була ала. Символ образ дәрәҗәсендә кабул ителү өчен билгеле бер шартлар үтәлергә тиеш: 1) образның кабатлануы һәм тотрыклылыгы, аның «үтәли образ» булуы; 2) образның әсәр идеясен ачудагы яисә гомумән язучының иҗат системасындагы әһәмияте; 3) образның мәдәни яисә әдәби контекстка каравы (борынгыдан килүче традицион символлар)[2].

Образ-символ әдәби әсәрнең эчтәлегендә мөһим роль уйнаучы төшенчә булып тора. Әдәбият белемендә символ төрләрен аерып чыгаруда ике классификация яши[3]. Берсе, гомуми булып, традицион һәм индивидуаль символларны аерып чыгара. Беренчесе таныш ассоциацияләргә нигезләнә һәм әзер образ буларак кулланыла (мәсәлән, былбыл һәм гөл – мәхәббәт символы). Традицион символиканың чыганаклары булып мифология, әдәби традицияләр, фәлсәфи концепцияләр тора. Индивидуаль символика исә әдип иҗаты белән танышу аша билгеләнә (мәсәлән, Каракош образы Р. Батулла иҗатында халыкка дошман көч

[1] *Юсупова Н.М.* Система образов-символов в татарской поэзии первой половине XX века: монография. – Казань: Ихлас, 2018. – С. 189.

[2] Основы литературоведения: Учебное пособие для филологических факультетов пед.ун-тов / В.П. Мещеряков, А.С. Козлов, Н.П. Кубарева, М.Н. Сербул; под общ. ред. В.А. Мещерякова. – М.: Московский Лицей, 2000. – С. 98.

[3] Шунда ук. – С. 99.

булып тора). Шул ук вакытта традицион символның яңа эчтәлек алып, тулыланып индивидуаль символ булып китү мөмкинлеген дә онытмаска кирәк.

Символларның икенче классификациясе конкретлыкка йөз тота: 1) аерым әдип иҗатының үзенчәлеген билгели торган образ-символлар (Дәрдемәндтә Кораб, Һ. Такташта Җил һ.б.); 2) әйбер, күренеш, пейзаж, сүз һ.б. символ буларак бирелүе (Ә. Еникинең «Шаяру»ында яулык – мәхәббәт символы); 3) мифологик образлар, мифлар, риваять-легендалар символ рәвешендә килү (Бичура – яхшылык, яктылык символы, Шайтан – явызлык, караңгылык символы); 4) тарихи шәхесләр символ дәрәҗәсенә күтәрелү (М. Җәлил – иленә, халкына тугрылык, батырлык символы); 5) әдәбиятта үзенчәлекле образ буларак урнашып, хәзер үзләре символ буларак кулланылучы типлар (Таһир-Зөһрә – үлемсез мәхәббәт символы, Дон Кихот – киң күңеллелек символы).

Хәзерге сәхнә әдәбиятының күренекле вәкилләре И. Юзеев, Т. Миңнуллин, Р. Хәмид, Ю. Сафиуллин, Р. Батулла, М. Гыйләҗев, Д. Салихов, Ф. Бәйрәмова һ.б. иҗатында образ-символларның ике төрле аспектта кулланылышын күрәбез. Берсе – әсәрнең төп эчтәлеге символлар аша белдерелгән вакыйга-күренешләрдә ачыла, икенчесе – символ ярдәмендә әсәрдә күтәрелгән проблемалар, аерым геройларның эш-гамәлләре, характер сыйфатлары тулылана, ачыклана.

Т. Миңнуллинның, сәнгати эзләнүләренә бәйле, гасыр ахырында язылган «Илгизәр плюс Вера», «Сөяркә» («Гөнаһсыз гөнаһлылар»), «Шәҗәрә», «Җанкисәккәем», «Саташу» (2000) һ.б. пьесаларында образ-символлар, мифологемалар, шартлылык кебек алымнар мөһим урын алып тора һәм еш кына төп идеяне ачуга хезмәт итә. Драматургның «Сөяркә»[1] драмасының сюжеты, беренче карашка, гади генә: утыз алты яшьлек укытучы кыз Әнисә менә инде ун ел эшмәкәр Хәбирнең сөяркәсе булып яши. Тормышта бернинди мохтаҗлык күрмәсә дә,

[1] Әлеге драма Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Сөяркә», Әлмәт дәүләт драма театрында «Гөнаһсыз гөнаһлылар», А. Мөбәрәков исемендәге Сибай Башкорт театрында «Ярату гөнаһмы?» исеме белән куелды.

аның күңелендә тынычлык юк. Шуның өстенә төшендә этисе Әнисәне әхлаксызлыкта, зина кылуда гаепли. Күңелендәге борчулы уйлар аны Алла каршына китерә һәм ул мәчеттән «Аятел-көрси» сатып алып, ишек өстенә элеп куя. Пьеса әлеге күренеш белән башлана һәм «Аятел-көрси» геройларның тормышын тамырдан үзгәртүче образ-символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Ул тормышыбызга ислам дине кыйммәтләре килеп керүне һәм кешеләрнең тормышларын шуңа нисбәтле үзгәртүне аңлауга хезмәт итә. Әлеге дини йола Әнисә һәм Хәбир тормышындагы имансыз (гөнаһлы) һәм иманлы (гөнаһсыз) чикләрне аера.

Башка берәүнең никахлы ире белән качып-посып очрашуның ярамаган эш булуын уйлап, Әнисә үз-үзенә һәм Хәбир алдына «Без гөнаһлы кешеләр түгелме?» дигән сорау куя. Күрәбез, мәсьәлә бик тә җитди. Гасырлар дәвамында телгә алуы да оят булып саналган күренешне драматург сәхнәгә алып менә. Аңлатмалы сүзлектә «өйләнешмичә, әхлак-әдәп нормалары белән исәпләшми җенси мөнәсәбәттә торучы ир яки хатын»[1] дип аңлатылган әлеге мәсьәләгә сәхнә әдәбиятында теге я бу дәрәҗәдә мөрәҗәгать итүләр шактый булды. Әмма әлегәчә ул аерым кешеләрдә генә очрый торган хурлыклы күренеш итеп бәяләнде. Баксаң, тормышыбызга шактый тирән үтеп кергән ләбаса. Ислам диненең каты чикләүләренә кул селтәп карый башлагач, әхлаксызлык сазлыгына батып барабыз икән ич.

Әсәрдәге барлык вакыйга-күренешләрне «Нәрсә ул гөнаһ?» дигән сорауга җавап эзләү берләштереп, туплап тора. Төп конфликт та аңа ничек җавап бирүгә бәйле карашлар каршылыгында ачыла. Әнисәнең кеше өлешенә кереп бәхетле буласы килми. «*Гөнаһтан куркам*», – ди ул һәм үзе Аллага, пәйгамбәргә тиң санаган Хәбиргә мондый хәлдә, ягъни сөяркә булып яши алмаячагын аңлата. Әнисә уй-фикерләрендә дөреслек булуын аңлаган Хәбир төп сорауга сөйгәнен тынычландырырлык җавап эзли башлый. Вакыйгаларда ул акыллы, тапкыр, кирәк вакытта кырыс та, ягымлы да, ярата һәм үзен дә яраттыра белә торган герой булып ачыла. Хәбир 18 яшендә үзеннән унике яшькә өлкән

[1] Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. V т.: С–Т. – Казан: ТӘһСИ, 2019. – Б. 193.

кешегә өйләнгән. Балалары инде үсеп буйга җиткән. Әмма ул үз хатынын түгел, Әнисәне ярата, бөтен җаны-тәне белән ярата. Тамашачының моңа бер тамчы да шиге юк. Сөйгәне белән бергә булу өчен бөтенесен эшләргә риза. Әнә бит аның өчен махсус җырлар да яздырта. Үз хатыныннан аерылырга тели, ләкин Әнисә ризалык бирми. Шул рәвешле, мәхәббәт утында янучы эшмәкәр образы тудырыла. Тыштан никадәр генә «крутой» булып күренмәсен, аның да җаны бар.

Нәрсә ул гөнаһ? Хәбирнең кабул итү бүлмәсендә утыручы яшь, чибәр 19 яшьлек Рәмзиянең бу турыда уйлаганы да юк. Әлеге сорау алдына куелгач, ул каушап кала, русча-татарча сүзләр катыштырып җавап эзли башлый. Рәмзия заманга яраклашырга өлгергән кеше булып ачыла. Әйбәт хезмәт хакы түли торган бу эшкә үзен тикмәгә генә алмаганнар дип саный һәм «хуҗа»сының мәхәббәт аңлатуын көтеп яши. Әлеге күренештә кыз башка ягы белән дә ачыла. Үзе әйтмешли, *«хочет быть порядочной»*. Шулай да Рәмзиянең төп сорауга җавабы бар: *«Гөнаһ ул – үзең ышанган кешенең алдавы, хыянәте»*[1]. Әлеге шактый тапкыр җавапны Хәбир Әнисәгә каршы «дәлил» итеп файдаланмакчы. Әмма, юкка. Сөйгәне аны бик тиз кире кага, чөнки алар арасында хыянәтнең булганы юк. Моны икесе дә яхшы белә. Әнисәнең күңелендәге каршылыклар предметлы сөйләшүгә үсә. Аның яшьтәшләре гаилә корып, балалар үстерә. Әнисәнең дә бала табасы килә, ләкин зинадан түгел.

Нәрсә ул гөнаһ? Бу сорауга Хәбир теләгән җавапны бәлки озын гомер кичергән, тормышның әчесен-төчесен күп күргән кеше бирер. Хәбирә әби образы белән сәхнәдә тормышыбызның кешелексез яклары ачыла. Беренче ире сугышта үлеп калгач, ул икенче тапкыр кияүгә чыга. Ләкин яратышып өйләнешмәгәнгә, балаларыбыз булмады, ди әби. Ире дә үлеп киткәч, пенсия акчасы җитмәгәнлектән, карчык урамга, үзе әйтмешли «шупа шупыч» сатарга чыккан. Алай гына да түгел, бирүчеләрдән хәер дә алуы турында оялып та, сыкранып та әйтә Хәбирә әби. *«Күңелләребез каралды, яулыгыбыз булса да ак булсын инде»*

---

[1] *Миңнуллин Т.* Сөяркә // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 19.

диюче карчыкның сорауга үз җавабы: *«Яратмаган кеше белән тормышыңны бәйләү – гөнаһ!»*[1] Бу фикер дә Әнисәнең карашларын үзгәртә алмый. Ул үз мөнәсәбәтләренең кешеләр алдында да, закон каршында да чиста булуын тели.

Нәрсә ул гөнаһ? Сорауга җавап эзләп һәм Әнисә белән яшәргә хокукы барлыгын дин ягыннан раслату мөмкинлеген ачыклау максатында, Хәбир, аптырагач, мәчеткә килә. Автор дин әһеленең тормышыбыздагы урынын төгәл билгели алган. Яшәеш турында фәлсәфи фикер йөртүче хәзрәтнең һәр сүзе ачык, төгәл, тирән мәгънәле. Консультация алырга кердем, диюче Хәбирнең дә үз эш-гамәлләрен акларга омтылу максатында бәхәсләшү теләген тиз аңлап ала ул. Гомумән, Хәзрәтнең *«явызлык-имансызлык арткан саен гаеплеләр азая бара. Имансыз җан һәрвакыт үзен-үзе аклар өчен җай таба»*[2] дигән сүзләре бүгенге тормышка карата әйтелеп, барыбызга да кисәтү булып яңгырый. Имам-хатыйпның куелган сорауга җавабы ачык – *«яратмау гөнаһ!»*[3] Шулай икән, Хәбир белән Әнисә бер-берсен яраталар бит. Нигә аларның мөнәсәбәтләре гөнаһ булырга тиеш? Кызганычка каршы, ди имам-хатыйп Хәбиргә, син нәкъ ун елга соңардын. Бу сорауны син үз-үзеңә, хатының һәм ике балаң була торып, чит кыз кочагына ташланыр алдыннан бирергә тиеш идең. Ә бит Әнисә дә шулайрак уйлый. Ул да соңга калып тәүбәгә килүе өчен үкенә түгелме? Шуның өстенә үзен яшь вакытта яратып йөргән, хәзер дә аны көтеп яшәүче кеше барлыгын искәртә. Вакыйгалар барышында Әнисә исеме белән мәхәббәт шигырьләре язучының әлеге кеше – Хәлил булуы ачыклана.

Тормыштагы бөтен каршылыкларын җиңеп үтәрдәй ихтыяр көченә ия булган Хәбир янында Хәлил мескенрәк булып күренә. Аның башка кеше куенындагы Әнисәнең «акылга утыруын» ун ел буе көтеп ятуын да Хәбир аңлый алмый. Хәлилгә бертөрле генә бәя бирүе кыен. Бер яктан, ул олы мәхәббәтен тап төшерми саклаучы, аңа гомере буе тугрылыклы ир булып күренсә, икенче

[1] *Миңнуллин Т.* Саташу // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 27.

[2] Шунда ук. – Б. 33.

[3] Шунда ук. – Б. 33.

яктан, яраткан кешесе өчен көрәшүдән качучы, пешмәгән, боламык ир дип бәяләргә дә мөмкин. Ничек кенә булмасын, Хәлил – Хәбир каршылыгы, һичшиксез, төп конфликтны тирәнәйтә һәм тулырак аңларга ярдәм итә.

Нәрсә ул гөнаһ? Бу сорау геройларга гына түгел, тамашачыга да куела. Заман үзгәрде, тормышыбызга кешелексезлек күренешләре үтеп керде, кешеләр әхлаксызланды дип лаф орабыз. Сәбәбен әлеге дә баягы заманнан, чордан эзлибез яисә чит илләргә күрсәтәбез. Ә үзебез соң, үзебез нинди хәлдә? Ничек яшибез? Башкаларга төртеп күрсәткәнче, үзебезгә «Нәрсә ул гөнаһ?» дигән сорауны куйганыбыз бармы? Пьеса укучыны һәм тамашачыны битарафлыктан чыгарып, әлеге мәсьәләләр турында уйлануга этәрә.

Драматург сөяркә булып «бәхетле» яшәүгә каршы җан, иман чисталыгын, күңел пакьлеген, якыннарың һәм үзең каршында намуслы булуны куя. Көндәлегендә моңа ачыклык кертеп болай дип яза: *«Ул пьеса нәкъ менә Мигъраҗ кичендә уйналырга тиешле әсәр. Чөнки анда сүз – аны-моны уйламыйча яшәп гөнаһка чумган хатынның иманга килүе турында»*[1].

Шулай да пьесага тулы бөтенлек җитеп бетми. Ул, беренче чиратта, Хәбирнең никахлы хатыны белән бәйле. Әлеге аталучы образ үзе күренмәсә дә, аның барлыгы, катнашучыларга йогынтысы бәхәс уятмый. Кем булуы Хәбир сүзләреннән генә аңлашылгангамы, ул геройлар бәхетенә киртә салучы буларак кабул ителә. Сәбәбе, күрәсең, аның күңел халәтен, уй-фикерләрен ачмауда. Ул да бәлки Хәбирне яратадыр. Әнә бит ике бала табып, тәрбияләп үстергән. Аның хокукларын кем яклар да, хисләрен кем аңлар? Иренең үзе белән түшәкне уртаклашмыйча, читләр янында йөрүенә ничек түзеп яши? Күрәсең, балалары хакына. Аларга әти кирәк. Пьесага Хәбирнең үз хатыны белән аңлашу күренеше кертелсә, әлеге сорауларга ачыклык кертер иде кебек.

Пьесада конфликтның чишелеше буларак, Әнисә Хәбир белән очрашудан баш тарта. Моны икесе дә гаять авыр кичерә.

---

[1] *Миңнуллин Т.* Каләмдәш Фәүзия Бәйрәмовага ачык хат // *Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б. 3.

Бу күренеш укучы-тамашачыга да тәэсир итеп, җитди бәхәсләргә китерә. Т. Миңнуллин «уйландырырлык һәм тирән хикмәтле»[1] әсәренең героинясы эш-гамәлләре аша шәхси теләккә каршы халыкның язылмаган кануннарын куя һәм соңгыларының өстенлеген раслый.

* * *

Т. Миңнуллин иҗатында реализм өстенлек итсә дә, ул һич тә романтик сурәтлелекне, аның җете буяуларын кире какмый. Сентименталь кичерешләргә киң урын бирелеп, җыр-музыка үрелеп барган мелодрама жанрына да мөрәҗәгать итә. Шуның белән бергә, әдип яңа алымнар ярдәмендә яшәешнең серле якларын ачуга да килеп чыга. Кеше күңелен аңлап һәм аңлатып бетерү мөмкин түгел, шуңа да ул аны төрле шартларга куя, төрле сынауларга дучар итә. Иң мөһиме: пьесаларда хәрәкәт итүче геройлар кем һәм нинди булуга карамастан, автор аларга хөрмәт белән карый, аңларга һәм ярдәм итәргә омтыла.

Әдипнең «Саташу» (2001) драматик хикәясендә күчеш чоры вакыйгалары сурәтләнә. Әсәр Прологында Саташкан әби бирелеп, аның монологы алдагы хәл-күренешләргә укучы-тамашачыны әзерләү белән бергә, бәя бирү, сурәтләнгәннәрнең башка мәгънәләрен ачу мөмкинлеге бирә. *«Барыйм әле, аннары кайтырмын. Барырга да кирәк иде, кайтырга да кирәк. Тукта, кая барам соң әле мин?.. Кая барырга чыктым соң әле мин?.. Урамдагы бу халык кая бара икән?.. Нигә ашыгалар? Кая чабалар? Баргач, кайтасын беләләр микән?.. Кайтыр юлларын онытмадылар микән?.. Берсен-берсе күрмиләр. Мине дә күрмиләр... Нигә күрмиләр? Әллә соң мин ят кешеме?.. Әллә мине ятсыналармы? Нигә үз итмиләр? Нигә ятсыналар? Мин аларга нинди начарлык эшләгән? Әллә инде без барыбыз да ятлармы? (...) Нигә исәнләшмиләр?.. Танымагангадыр инде. Танымаса ни булган. Без танымасак та исәнләшә идек. (...) Кызык инде бу дөнья – барыр юл да юк, кайтыр юл да онытылган... Шушыннан килгән идем бугай. Кайтыр юлыңны белеп чыгарга кирәк шул»*[2], – ди Саташкан

[1] *Гаетбай Н.* Ярату гөнаһ түгел // Мәдәни җомга. – 2010. – 22 октябрь.

[2] *Миңнуллин Т.* Саташу // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 248–249.

әби. Саташкан кешенең аңсызлык халәтендәге сөйләшүе төрле мәгънә төсмерләренә урын калдыра. Кеше каян килгән, шунда китәргә тиешлегенә, фанида изге гамәләр кылып, Аллаһ каршына бару кирәклегенә, шулай ук дөнья үзгәрү белән кешеләрнең бер-берсеннән читләшүенә, ят итүенә, нәтиҗәдә исәнләшү, ягъни яхшылык теләү сыйфаты юкка чыгуга ишарә бар. Ә бит авыл җирендә гомер бакый үз кеше белән дә, читләр белән дә исәнләшү гадәте булган. Аның онытылуы әлеге традицияләрнең, яшәү рәвешенең югалуын күрсәтә.

Үзәктә әти-әни, әби һәм кызлары Гүзәл булган бер гаилә язмышы тора. Төп вакыйга юрист белеме алган 27 яшьлек Гүзәлнең бәргәләнүләре белән башлана. Ул үзенә урын таба алмый, беркемне күрәсе килми. Психологик тотнаксыз, киеренке халәттә якыннары белән каршылыкка керә, егетен дә кискен кире кага. Билгеле инде, гаилә әгъзалары да бик борчулы хәлдә кызларын аңлый алмаудан гаҗиз калган. Бары Мөслимә әби генә сабырлыгын җуймыйча, салкын акыл белән киленен дә, оныгын да тынычландырырга тели. Кызның әнисе Галиябануның «Нинди дөнья соң бу? Мәктәпкә барсаң, анда балалар белән сөйләшү куркыныч, өйгә кайтсаң, үз балаң»[1], – диюендә чор тагын да каршылыклы, котсыз булып күзаллана. Әнә бит фәнни хезмәткәр булган әтисе Марат 10 ай, әнисе Галиябану 3 ай инде хезмәт хакы алганнары юк. Алдагы күренешләрдә Гүзәл борчуларына бәйле яшәешкә бәя көчәя бара. *«Мин кияүгә чыкмаячакмын. Беркемгә дә, беркайчан да,* – ди кыз егете Надирга. – *Кияүгә чыккач, бала табасы була. Ә минем бу хәшәрәт дөньяга корбан бүләк итәсем килми»*[2]. Шул рәвешле сызланулы халәт тудырып, Т. Миңнуллин караңгы чорда адашып калган, үз-үзен таба алмаудан иза чигүче шәхесне сурәтли.

Әлеге каршылыклы дөньяда Гүзәл кая барып бәрелергә белми, әйләнә-тирәсендә ярдәм сорарлык, киңәшерлек кеше дә таба алмый. Әбисе Мөслимәне ул намаз карчыгы, бу дөньядан бигрәк, теге дөньяга барырга әзерләнүче дип кабул итә.

---

[1] *Миңнуллин Т.* Саташу // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 253.

[2] Шунда ук. – Б. 257.

Әтисе һәм әнисе белән аңлаша алмый, чөнки аларның кызлары ничек яшәвен сорашырга да вакытлары юк. Егете Надир да кызганыч булып кына күзаллана. Моның сәбәбен җәмгыятьтә урнашкан шартларда, рухи кыйммәтләрнең үзгәрүендә күрә. Әйләнә-тирәдә гаделсезлек һәм әхлаксызлык өстенлек иткәндә намуслы кешегә бәхетле булу мөмкин түгел дип саный ул. Әтисе белән әңгәмәсендә бу турыда ачыктан-ачык әйтә:

*«Гүзәл: Сез мине тудырып, миннән курчак ясап уйнадыгыз. Менә үсеп җитте ул курчак. Кемгә кирәк мин? Берәүгә дә кирәкмим. Хәтта сезгә дә кирәкмим. Берегез кычкыра, икенчегез мыскыллап көлә. Бер сиксән яшьлек карчыкка гына кирәк мин. Ул гына миңа кызганып карый. Улының җинаятен ул гына аңлый.*

*Марат: Нинди җинаять?*

*Гүзәл: Сез мине тудырмаска тиеш идегез»*[1].

Әсәр геройлары кара, ялыктыргыч, шыксыз яшәештә күзгә күренеп тормаган пәрәвез җепләреннән ычкына алмыйча газаплана. Геройлары белән драматург та әлеге халәттән чыгу, кирәк булса хәтта качу юлларын эзли. Әмма юкка... Бу яшәештән качып булмый. Шул рәвешле, сызлану фәлсәфәсе бөтен әсәрне һәм геройларын иңләп үтә. Мондый яшәешкә кешеләр үзләре гаепле дигән фикергә килеп, Гүзәл әти-әнисен судка бирә. Судка гаризасында әлегә кадәр рухи кимсетелгән хәлдә яшәвен язып, гадел булмаган мохитне ача: гаилә «хрущевка» дип аталган ике бүлмәле кечкенә фатирда яши; кыз үз урынын таба алмый, чөнки намуслы юрист беркемгә дә кирәкми; әти-әнисенең хезмәт хакы бик түбән һ.б. Кызның горурланырлык якын кешесе юк, ул үз хәленнән, тормыш шартларыннан кимсенеп яши. Мондый хәлдә яшәвенә әти-әни гаепле, шуңа да алар әхлакый зыян салулары өчен җавап бирергә тиешләр, дип саный Гүзәл. Әти-әнисенә белдергән дәгъвасы, алардан бигрәк җәмгыятькә, кешеләрне шундый хәлдә калдырган системага аталган: *«Сез кайсы илдә яшәгәнегезне белеп тудырдыгызмы мине? Белеп. (...) Хатыныңның һәм үзеңнең беркемгә дә кирәге юклыгын белдегезме? Белдегез.*

---

[1] *Миңнуллин Т.* Саташу // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 415.

*Чөнки кирәк булган кешегә рәтле хезмәт хакы түлиләр. (...) Киләчәктә дә рәтле-юньле фатир булмаячагын сез белдегезме? Белдегез. Шуларны белгән килеш нигә сез дөньяга тагын бер мескенне тудырдыгыз? Җинаять түгелме бу?»*[1] Бу урында көчеш чорының гаять авыр, каршылыклы, буталчык заманы күз алдына килә. Хөкүмәтнең булдыксызлыгы аркасында кеше әнә шундый түбәнлеккә төшә. Автор милли сәясәт мәсьәләсенә дә тукталмый булдыра алмый. Шуңа да кызның *«Берәүгә дә кирәкмәгән татар теленә өйрәттегез. Берәүгә дә кирәкмәгән намус турында сөйләп мине алдадыгыз»*[2], дигән сүзләре сискәндереп җибәрә. Игътибар итик, Гүзәл сөйләмендә туган тел һәм намус төшенчәләре янәшә килә, бу төрле чорда «Татар теле нәрсәгә ул?» дип сөйләнеп йөрүчеләрнең намуссызлыгына да ишарә итә. Мөслимә әби сүзләре белән әйткәндә, адәм баласына баш булган телевизор ни күрсәтсә, шулай эшлиләр бит. Бу урында әлеге әдәби деталь, символ буларак, илдәге сәясәтне чагылдыра. Шуңа да очраклы кабызылган телевизорның Мәскәү каналыннан *«Великая неделимая Россия всегда будет великой державой. Великий наш народ никогда не позволит...»,* ә инде Казан каналыннан таныш мәзәкченең *«Мин хәзер шындый аникдут сүлим, ха-ха-ха...»*[3] дигән сүзләре яңгырап кала.

Вакыйгалар барышында ата-бабадан килә торган әхлакый кануннар сакланышы турында әледән-әле сүз булып алса да, бу җәмгыятьтә аларга урын юклыгы ачык аңлашыла. Надир кызны акылына килергә чакырып карый, әмма Гүзәл җавабы икеләнергә урын калдырмый: *«Кайда ул изгелек? Акыл сатма. Дөньяга күтәрелеп кара. Мин инде төштем күктән. Саташып йөрдем дә төштем»*[4]. Менә фаҗига кайда. Кыз әлегә кадәр намус, изгелек төшенчәләренең тормышта булуына ышанып, өмет белән яшәвен «саташу» халәте дип атый. Җәмгыятьтә әхлаксызлык өстенлек итүен, әхлакый кануннарга урын калмавын күр-

[1] *Миңнуллин Т.* Саташу // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 267.

[2] Шунда ук. – Б. 268.

[3] Шунда ук. – Б. 274.

[4] Шунда ук. – Б. 271.

шеләре Харис та кат-кат әйтә. Хатынына хыянәт итеп, Гүзәлне дә дачасына алып китү теләге белән йөргән бу бәндә заманга яраклашып өлгергән: *«Дөресен әйткән өчен мин үч алмыйм. Миңа оятсыз, диден, исем дә китмәде. Чөнки дөресе шулай. Оялып торсаң, бәхетеңне алып китүләре бар. Заманасы шундый»*[1]. Иң кызганычы, үзгәрешләр барган «күчеш чоры»нда яңа буын – тулы бер «югалган буын» үсеп җиткән. Марат үзләренең хәлен дөрес аңлап, болай ди: *«Яңа буын үсә, Галиябану. Циниклар буыны. Тамырыннан аерылган буын. Монда безнең генә гаеп түгел. Без корбаннар гына, Галиябану. (...) Галиябанулар, Хәлилләр, Таһирләр, Зөһрәләр яши иде бит безнең күңелдә. Алар югалды бүгенге буында, алыштырырга алмаш юк. Бушлык. Бушлык. Бушлык»*[2]. Аның бер үрнәге, мисалы булып, билгеле инде, әти-әнисен судка биргән кызлары Гүзәл калка. Ул бит бер-берсен яратып яшәгән ата белән анадан туган бала. Аларның үзара мөнәсәбәте, ахыр чиктә дин юлындагы әбисе ни өчен кызда миһербанлык орлыгын үстермәгән соң? Һәркемне борчыган бу сорауга җавап буларак, Мөслимә әби кешене теленнән, диненнән биздергән илдә башка чара булмавын да искәртә. «Халыкның әхлакый кануннарыннан читләшү илне дә, гаиләне дә, аерым шәхесне дә рухи харап итәчәк, дигән фикердә ул»[3], – дип яза Н. Ханзафаров.

Гаилә эчендәге конфликт кискенләшкән урыннарда сюжет тармагы рәвешендә Саташкан әби килеп кушыла. Әнә ул саташулы халәттә сөйләнә: *«Алыштырганнар ич галушларымны. Аякларым нигә атламый дисәм, галушларымны алыштырганнар. Минем галушларым кызыл эчле иде, болар кара эчле ич. Кызыл эчле галушка ияләшкән ич минем аякларым. Кара эчле галушны ятсыналар ич алар. Шуңа атламыйлар да. Ятсыналар шул. Ят галушны үз итмиләр. Бөтен нәрсә ят. Кешеләр дә ят, галушлар да ят, аяклар ничек атласын. Юк, кимим ят*

---

[1] *Миңнуллин Т.* Саташу // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 273.

[2] Шунда ук. – Б. 275–276.

[3] *Ханзафаров Н.* Драмаларда – күңел дөньябыз // Мәдәни җомга. – 2002. – 15 март.

*галушларны. Үземнекеләрне бирсеннәр. Минекеләр кызыл эчле иде. Кимим, кимим, кимим. Нишләп мин киим ят галушларны»*[1]. Әлеге монолог төрлечә аңлауга урын калдыра. Н. Йосыпова аны ике катламда карап, берсе «илдәге сәяси чынбарлыкка бәя бирсә», икенчесе исә «чит традицияләр, башка милләт йогынтысы көчләп тагылган татар халкы, милләте фаҗигасына бәя»[2], дип күрсәтә. Чыннан да кызыл һәм кара эчле галошлар илдәге система үзгәрешенә ишарә итә. Әбинең кызыл эчле галошка иярләшүе – аның гомере буе кызыл төсне символ иткән социалистик җәмгыятьтә яшәве билгесе. Ә инде капитал мөнәсәбәтләргә күчүне әби кабул итә алмый, монда аңа бар нәрсә ят.

Вакыйгалар барышында Гүзәл үзгәрә башлый. Моңа кадәр бөтен ачу-нәфрәтен үз эченә җыеп барса, хәзер ул алар турында ачыктан-ачык әйтә. Дөресрәге, күпләр кебек үк кешелексез җәмгыять шартларын кабул итеп, шуңа яраклашып, берәүдән дә курыкмыйча, берәүдән дә оялмыйча яшәүгә килә. Бу рәвешле яшәүнең җиңел булуын да әйтә ул шактый усалланып. Шуны гына көткәндәй, алгы планга яңадан Саташкан әби чыга. *«Китәм мин. Качам сездән. Еракка, еракка китәм. Китәм. Кайтмаска китәм. Үз кешеләр янына китәм. Сезне мин үзем белән алып бармыйм. Сез сәдака да ала белмисез, сәдака да бирә белмисез. Китәм!»*[3] – ди ул монологында. Бу сүзләрдә кыргый җәмгыятькә бәя-мөнәсәбәт тә яңгырый. Кешеләрнең ят булуы, сәдака ала да, бирә дә белмәве әхлакый йола-гадәтләрнең бозылуын, үзара ярдәмләшеп яшәүнең юкка чыгуын һәм боларны өлкән буынның кабул итмәвен аңлата.

Гүзәл исә яраклашып яшәүне дә кабул итми. Үзенең эшгамәленә бәя бирүгә этәргеч буларак, ул әбисеннән Аллаһы Тәгалә турында сораша, аннары бишек җыры җырлата. Үзенең саф, гөнаһсыз бала чагын хәтеренә төшерүе дә үз асылына кай-

---

[1] *Миңнуллин Т.* Саташу // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 280.

[2] *Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М. Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. – Т. 2: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – Б. 108.

[3] *Миңнуллин Т.* Саташу // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 283.

ту юлына чыгуын күрсәтә: *«(Мөслимәнең алдына башын куп) Чәчемнән сыйпа, әбекәем... Бишек җырыңны җырла. Мине бәләкәй чакта бишек җыры җырлап йоклата идең. Әнидән мин бишек җыры ишетмәдем»*[1].

Тынычланып йокыга киткән кыз төшендә суд процессын күрә. Әтисе Маратның судтагы чыгышы – ул илдәге системага усал тәнкыйть һәм шул шартларда яшәргә мәҗбүр ителгән кеше әрнүе, сызлануы: *«Мин үземне гаепле саныйм. (...) Без кайда һәм кайсы заманда яшәгәнебезне белмичә ялгыштык. Ләкин бу безнең гаебебезне киметмәи. Белергә тиеш идек. Акыл качкан илдә бала тудырмаска кирәклеген мин белергә тиеш идем. Ләкин без өмет белән яшәдек. Нидер булыр дип көттек. Бу илдә һәрвакыт нидер көтеп, өмет белән яшиләр. Ләкин көткәннең беркайчан да килгәне юк. Һәр буын үзенең бәхетсезлеге белән бергә туа. Мин аны белергә тиеш идем. Кызыбызны туры сүзле булырга, мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәтеп, икеләтә җинаять эшләгәнемне дә аңладым. Үзебез кебек куркак булмасын, дигән идем, ялгышканмын. Дөньялар үзгәрер, дигән идем, хаталанганмын. Әхлаксыз илдә әхлаксызлар гына яши ала»*[2]. Хәзер инде укучы-тамашачы каршында Гүзәлнең әти-әнисенә ташлаган гаепнең хакимияткә, ул корган системага юнәлтелүе ачыла. Ә инде Харисның сүзләре хакимият урнаштырган режимның чын асылын тирәнрәк аңлауга хезмәт итә: *«Нигә ул безнең режимны сүгә? Аның мескен булуында режимның ни гаебе бар? Андый мескеннәр җир өстендә яшәмәскә тиеш. Намус дигән була. Причем монда намус. Дөнья шулай яратылган. Сарык үлән ашый, бүре сарыкны буа, бүрене кеше ата. Причем монда намус. Дөрес эшли аларның кызы. Ул үлән чемченүче сарыкларны буарга тели. Бусын – тимәгез. Бугач, без аны атарбыз. Эшең бетте, кодагый. Причем монда әхлак?»*[3]

Гүзәл йокысыннан куркып, хәзер инде башка кеше булып уяна. Әмма ул соңара – гаепсез гаепләнгән ата-анасы юл

---

[1]*Миңнуллин Т.* Саташу // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 285.

[2] Шунда ук. – Б. 286.

[3] Шунда ук. – Б. 286.

һәлакәтенә очрап, сырхауханәгә эләгә. Кыз үзенең саташулы халәттә булуын, хаксызлыгын аңлауга килә һәм сыкрану белән әбисенә, аннары Ходайга эндәшә: *«Әбекәем... Борчылма... Гафу ит син мине... Ачуланма... (...) Берәр дога укы, әбекәем. Йа Ходаем! Үзең сакла...»*[1] Иң кыен минутта Гүзәлнең әбисенә сыенуы, аның иманга килүен, яшәү мәгънәсе, кеше яшәеше кебек әхлакый һәм фәлсәфи мәсьәләләргә төшенә башлавын аңлата. Кызның Аллаһка мөрәҗәгать итүе дә саташулы халәтеннән арынуның бер юлы буларак тәкъдим ителә. Ахырда ул үзе өчен төп хакыйкатьне таба: кеше өчен яшәү мәгънәсе якыннарың белән дус-тату, үзара ярдәмләшеп, бердәмлектә һәм саф иман белән гомер итүдә икән.

Әлеге пьеса Т. Миңнуллинның дөньяга карашында, чынбарлыкны кабул итүдә үзгәрешләр барлыкка килүне раслый. Ул яшәешнең камил булмавы, шул ук вакытта аны төзәтә алмау белән бәйле. Ә камил булмаган дөнья шундый ук геройларны мәйданга чыгара. Драматург яшәешнең сызланулы күренешләрен торгызу аша шунда үз урыныңны табу мәсьәләсен куя. Моны ул ислам динендә таба. Моңа кадәр «Илгизәр плюс Вера», «Гөнаһсыз гөнаһлылар» әсәрләрендә кешегә йогынты ясаган көчле фактор буларак бирелгән Корьән тәгълиматы «Саташу» да авыр хәлдә калган кешенең килеп сыеныр урыны буларак тәкъдим ителә.

Шулай итеп, Т. Миңнуллин драмада кешелексез, кыргый чор күренешен сурәтли. Шул шартларда тулы бер «югалган буын»ның мәйданга килүен, аның фаҗигасын ача. Драматург, яңа алым-чараларга, формаларга мөрәҗәгать итеп, үзенчәлекле әдәби дөнья тудыруга, эмоциональлекне арттыруга ирешә.

---

[1] *Миңнуллин Т.* Саташу // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 286.

## 3 БҮЛЕК

# Т. МИҢНУЛЛИННЫҢ XXI ГАСЫР БАШЫ ПЬЕСАЛАРЫНДА СУРӘТЛӘНГӘН ДӨНЬЯ

### 3.1. Яңа гасыр башы сәхнә әдәбияты

Күпгасырлык тарихында каршылыклы, еш кына фаҗигалы язмышка дучар булган татар халкының милләт буларак сакланышына, үсеш-үзгәрешенә һәм киләчәккә өметенә аеруча көчле йогынты ясаган факторларның берсе – дин, икенчесе – гореф-гадәтләре, традицияләре, яшәү рәвешендә чагылган менталь сыйфатлары, өченчесе – җыр-моңын, тел-мәгарифен, әдәбият-сәнгатен үз эченә алган мәдәният. Әдәбият-сәнгать исә боларның барысын да үзендә чагылдыра алу, яклау һәм саклау сыйфатына ия. Шуңа да без татар әдәбиятының XXI гасыр башындагы үсеш-үзгәреше турында сүз алып барганда, беренче чиратта, халыкның рухи ихтыяҗына ни дәрәҗәдә җавап бирә дигән сорауга җавап эзлибез. Драматургия театр белән аерылгысыз бәйле. Бүгенге чынбарлыкта исә, төрле иҗтимагый-мәдәни, икътисади сәбәп-шартлар йогынтысында сүз сәнгате җәмгыятьтә үзенең алдагы чорлардагы урынын бермә-бер югалтса да, бәхеткә, татар театры үз йөзен, асылын, димәк, халыкка эстетик һәм этик-әхлакый йогынтысын саклап калды. Бу исә театрның нигез ташы булган драматургиянең гаять зур әһәмиятен билгели һәм аңа җитди таләпләр дә куя.

Әдәбиятның башка төрләре кебек үк, драматургия дә, үзенең традицияләренә таянган хәлдә, ил-халык тормышы, көнне борчыган мәсьәләләр белән тыгыз бәйләнештә яши, үзгәрә.

Яңа гасыр башында Г. Каюмовның «Упкын өстендә уен» (2003), «Ул...» (2013), Ю. Сафиуллинның «Әллә өйләнергә инде» (2004), Д. Салиховның «Гыйлаҗ тәрәзәләре» (2004), Аманулланың «Моңлы ядкарь» (2005), Э. Яһүдиннең «Мәхәббәткә мәдхия» (2005), «Пьесалар» (2014), М. Гыйләҗевнең «Словарь любви» (2005), Х. Ибраһимның «Газиз ярым» (2006), З. Хәкимнең «Телсез күке» (2007), «Кайда син, Аттила?» (2013), «Газап» (2016), Д. Салиховның «Таш сандык» (2008), «Комедияләр» (2015), «Комедии» (2017), Р. Сәгъдинең «Гүзәл Аппаксылу» (2012), Р. Мөхсинованың «Кайнар токмачлы аш» (2017), авторлар коллективының «Мәктәп сәхнәсе өчен пьесалар» (2017), Б. Сәлаховның «Яратылмый калган ярлар» (2017), И. Зәйниевнең «Бәби» (2018) һ.б. пьеса җыентыклары басылып чыга. Аларда төрле елларда язылган әсәрләр урын алса да, һәр китап драматургның бу дәвер иҗатына нәтиҗә, йомгак булып тора һәм күпсанлы китап укучыларны үзенең серле әдәби дөньясы белән таныштыра.

Татар сәхнә әдәбиятына 2003–2016 еллар аралыгында оештырылган «Яңа татар пьесасы» конкурсы зур йогынты ясап, асылда аның үсеш-үзгәрешен билгеләүче факторга әйләнә. 14 тапкыр үткәрелгән бәйгедә йөзләрчә пьеса тикшерүгә алынып, иң яхшылары аерым җыентыклар буларак басылып чыга. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры Ф. Бикчәнтәев тәкъдиме белән ТР Мәдәният министрлыгы һәм Г. Камал исемендәге театр коллективы оештырган, башта «Татэнерго» ААҖнең, аннары «Сетевая компания» ААҖнең матди ярдәменә таянып, шулай ук «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе, «Казан утлары», «Татарстан яшьләре», «Сәхнә» журналлары катнашында алып барылган һәм ел саен нәтиҗә ясалган конкурс, нигездә, үзенең төп максатына ирешә. Беренчедән, аның башлангычы татар театрларының заман рухында һәм бүгенге тамашачыны күздә тотып язылган пьесаларга кытлык кичерүе белән бәйле иде. Бу яктан ул төрле буын драматургларны бик тә кирәкле һәм җитди эшчәнлеккә тарта. Икенчедән, җиңеп чыккан һәм җыентыкларда басылган иң яхшы әсәрләр барлык театрларга, шул исәптән район-шәһәрләрдәге халык

театрларына тәкъдим ителә. Өченчедән, конкурс яшь иҗатчыларларны барлап, аларны активлаштыруга юл ача. Анда төрле буын драматурглар белән бергә, иҗатка беренче адымнарын ясаучылар һәм әдәбиятның башка төрендә танылып, драматургиядә үзләрен сынап караучылар да катнаша. Дүртенчедән, әлеге конкурс хәзерге татар драматургиясенең төп көчләрен барлау, аларның сәнгати эзләнүләрен, үсеш-үзгәреш юлларын билгеләү мөмкинлеге бирә.

Яңа гасыр башы сәхнә әдәбиятына хас үзенчәлекләр, сыйфат-билгеләр турында сүзне алдагы чорга нисбәтле башлыйк. XX гасырның 90 нчы еллары – XXI гасырның беренче елларында драматургиядә уңышлы эзләнүләр, аерым табышлар булуын инкяр итмәстән, татар театрлары билгеле бер дәрәҗәдә яңа әсәрләргә кытлык кичерә башлый. Бу, бер яктан, классиканың гына түгел, төрле чор әсәрләре театрлар репертуарында шактый күп урын алуында һәм, икенче яктан, безгә яхшы таныш булган, вакыт сынавын узган проза әсәрләре буенча инсценировкаларның арта баруында күренә.

Конкурска килгән әсәрләр һәм соңгы елларда чыккан җыентыклар татар драматургиясендә эзләнүләр, үзенчәлекле экспериментлар баруы турында сөйли. Сәхнә әдәбиятында буыннар алмашу процессының традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңачалык белән эзлекле бәйләнештә булуы уңай нәтиҗәләргә китерә. Өлкән буын (Т. Миңнуллин, Р. Батулла, Ф. Садриев, Р. Хәмид һ.б.) һәм урта буын драматургларыбыз (З. Хәким, М. Гыйләҗев, Аманулла, Р. Сәгъди, Д. Салихов, Ф. Галиев, Г. Каюмов, Р. Зәйдулла, Ш. Фәрхетдин һ.б.) янәшәсендә яшь авторлар мәйданга чыга. Моңа кадәр әдәби иҗатта билгеле булсалар да, гасыр башында гына Э. Яһүдин, Х. Ибраһим, Л. Лерон, Р. Бохараев, А. Әхмәтгалиева драматург буларак киң танылу ала. Ә инде И. Зәйниев, Р. Сабыр, Р. Мөхсинова, С. Гаффарова, Й. Миңнуллина, А. Шәйдуллин исемнәре яңа буын килү турында хәбәр итә. Драматургиядәге төп яңалык исә сурәтләү дөньясының үзгәреш кичерүендә, поэтик алымнарда шактый ачык күренә. Иң мөһиме, татар дөньясы, яшәеше, нигездә, авыл белән бәйле сурәтләнеп, моңсу-сентименталь күренешләр үзәктә торса, яшь

авторларда яңа мәдәни мохитне – шәһәр мәдәниятен үзләштерү торган саен ачык сиземләнә. Милләт язмышы турында уйланулар гомумкешелек кыйммәтләре белән үрелеп, үзенчәлекле синтез тәшкил итә.

Әлеге чорда жанр һәм жанр формаларына бәйле эзләнүләрне билгеләп үтү кирәк. Традиция буенча комедия өстенлек итә. Бу мәсьәлә драматургия һәм театр тәнкыйтендә зур бәхәсләргә китерә. Театрлар репертуарында комедия һәм шул исем белән аталган һәртөр тамаша өстенлек итүенә, шул ук вакытта уй-фикергә йөз тоткан, әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләр кыю күтәрелгән пьесалар аз булуына борчылу күзәтелә. Аның сәбәбе дә ачык билгеле: татар тамашачысы, беренче чиратта, нәкъ менә уен-көлкегә, җыр-биюгә бай комедияләрне яратып карый. Моны халкыбызның милли сыйфатлары белән дә, тормыштагы авырлыклардан арынып тору, ял итү теләге белән дә, тамашачының зәвыгы түбән булу белән дә аңлатулар булды. Драматург М. Гыйләҗев бер әңгәмәсендә гыйбрәтле мисал рәвешендә, яшәү фәлсәфәсе турындагы җитди әсәре – «Бичура»ны тамашачы кабул итмәгәч, аңа охшый торган җиңел, тирән уй-фикерләр урын алмаган әсәре – «Казан егетләре»н язуы турында әйтә[1].

Күпсанлы комедияләр арасында «сатирик», «сагышлы», «моңсу», «көнкүреш», «музыкаль» дип аталганнары бар. Иң яхшы комедияләргә көлкеле хәлләрне, ямьсез фактларны, кешеләр характерындагы кимчелекләрне тапкыр, җор тел белән, мавыктыргыч хәл-күренешләрдә бирү хас. Аерым вакыйгаларны көлеп-елмаеп кабул итүдә татарның милли психологиясе дә ачыла. Еш кына әнә шунда авторның эстетик идеалы да чагыла. Т. Миңнуллин, Х. Ибраһим, Аманулла, И. Зәйниев һ.б. комедияләре заман рухын оста тоюы, милли төсмерләре, халыкчан җанлы теле белән игътибарга лаек. Шулай да җыентыкларда урын алган комедияләрнең бер өлешенә тормыш ваклыклары белән мавыгу, ясалмалылык, төче сурәтләр хас (Т. Миңнуллин. «Син мине күрәсеңме?»; З. Гыймаев. «Бакча караклары»).

[1] Хәрәкәттә – бәрәкәт (Ә. Закирҗановның М. Гыйләҗев белән әңгәмәсе) // Сәхнә. – 2020. – № 12. – Б. 6.

Комедиянең тәэсир итү, кызыксындыру, укучы-тамашачыны җәлеп итү көче, тормышның төрле якларын чыгылдыру, бигрәк тә тәнкыйть аша яңалык-яңарышны яклау мөмкинлеге зур булса да, драматургиянең үсеш-үзгәрешенә драма һәм трагедия жанрындагы әсәрләр көчлерәк йогынты ясый. Чөнки тормыш драматизмы, аннан да бигрәк кеше характерлары драматизмы пьесаның нигезен тәшкил итә, хәрәкәт тудыра. Бу елларда Т. Миңнуллин, З. Хәким, Р. Батулла, Э. Яһүдин, Р. Зәйдулла, Х. Ибраһим, Ф. Галиев һ.б.ның драма жанрына караган пьесалары языла. Арада «моңсу», «музыкаль», «монодрама» кебек жанр формалары бар. З. Хәким исә аларны «театраль роман», Р. Батулла «драматик хикәя», «пьеса-кыйсса» терминнары белән атый.

Бу жанрга караган әсәрләр арасында үткән тарихыбызга, олы шәхесләргә караган, кеше ялгызлыгын чагылдырган, яшьлек хаталары өчен борчылып яшәүчеләр турындагы, чечен фаҗигаларын яктырткан, суд-прокуратура органнарында эшләүчеләр тормышын сурәтләгән пьесалар бар. Әлеге жанрның төп сыйфат-билгеләре аеруча уңышлы Т. Миңнуллин, З. Хәким, Р. Батулла, Р. Сәгъди һ.б. әсәрләрендә урын ала.

Драма жанрлары арасында үзенчәлекле формасы белән монодрама аерылып тора. Бер генә персонаж катнашындагы мондый әсәрләр сирәк языла, шуңа да Т. Миңнуллинның «Тәнзиләкәй» пьесасы аеруча игътибарга лаек. Әсәрнең эчтәлеген Газинур исемле рәссам күңелендәге хис-кичереш хәрәкәте билгели. Шуңа да анда мәхәббәтнең фәлсәфи асылын аңлау омтылышы, ялгызлыктан котылу юлын һәм сәнгать матурлыгы белән чынбарлык матурлыгы мөнәсәбәтен ачу кебек сораулар үзара тыгыз бәйләнештә урын ала.

Драматургиянең трагедия жанры әдиптән җитди әзерлек, бай тәҗрибә, уңышлы сайланган тормыш материалы белән бергә, эстетика кануннарын, сәхнә закончалыкларын яхшы белүне таләп итә. Сәхнә әдәбияты тарихында уңышлы үрнәкләр булса да, соңгы елларда әлеге жанрга караган әсәрләрнең бик аз булуын күрәбез. Дөнья күргән әсәрләрдән М. Маликованың «Сөембикә»сен, Р. Батулланың «Мур кырылышы» фаҗига-

хроникасын, халык мифологиясенә, «Сак-Сок» бәетенә нигезләнеп язылган «Ана каргышы»н атап үтәргә була. Төрле жанрлар синтезында язылган әсәр буларак Айдар Хәлимнең «Кияү урлау» фантастик трагикомедиясе игътибарга лаек. Пьесада гасырлар дәвамында яшәп килгән кануннарны кире кагучыларның эш-гамәле җәмгыятьне афәт чигенә китерәчәге ачыла.

Яңа гасыр башында проза әсәрләренә нигезләнеп инсценировкалар язу активлашып китә. Моңа, билгеле, «Яңа татар пьесасы»н оештыручыларның инсценировкалар буенча махсус конкурс тәкъдим итүләре дә этәргеч бирә. Төрле җыентыкларда һәм журналларда Ф. Садриев һәм Л. Гәрәеваның «Көтелмәгән кайгы», Р. Зәйдулла һәм Р. Сабировның «Хөкемдар», Н. Гыйматдинова һәм Т. Хәләфнең «Утка очкан күбәләктәй...», Ф. Галиевнең «Болганчык еллар», И. Мөхәммәтгалиевнең «Мөһаҗирләр», Р. Сабырның «Яшел һәм кызыл» әсәрләре басылып чыга. Театрларда Т. Хәләфнең «Бер тамчы ярату» (Н. Гыйматдинова), Н. Гайнетдиннең «Йосыф-Зөләйха» (Кол Гали), И. Сираҗинең «Сержант» (Г. Әпсәләмов), Ф. Галиевнең «Алмачуар» (Г. Ибраһимов) һ.б. әсәрләргә нигезләнгән спектакльләр куела.

Сәхнә әдәбиятында жанр төрлелеге турында сүз алып барганда балалар өчен язылган пьесаларның арта баруын билгеләп үтәргә кирәк. Бу өлкәдә Т. Миңнуллин, Ю. Сафиуллин, Р. Сәгъди, Р. Батулла, Р. Корбан, Л. Лерон, М. Гыйләҗев, Х. Җәләй, З. Хөснияр, Ш. Фәрхетдинов һ.б. авторлар уңышлы эшләп килә. Р. Бохараевның «Тимер борчак», Р. Батулланың «Курчаклы уен», Т. Миңнуллинның «Интернет Акбай», «Гашыйк буласым килә», И. Зәйниевнең «Урман club» кебек пьесалары язылып, сәхнәгә куела. Р. Бохараевның татар халык йолалары, ышанулары нигезендә язылган «Тимер борчак» әкият-пьесасы үзәгендә яхшылык-явызлык көрәше тора. Автор Шүрәле, Дию, Су иясе, Юха елан кебек мифологик образларны кешеләр белән катлаулы мөнәсәбәтләргә кертә. Пьесада Мәхәббәт, Гаделлек. Хезмәт, Миһербанлык кебек изге кыйммәтләр өчен җитди көрәш бара. Мифологик хәл-күренешләр, халык авыз иҗаты әсәрләре, Г. Тукай шигырьләре фантастик һәм чынбарлык катламнарын үзара

бәйләп, бербөтен идеягә китерә. Ялган-хыянәт, мәкер кешеләргә күп кыенлык, михнәт, авырлык, күңел газаплары алып килә. Явызлык белән көрәштә яхшылык барыбер җиңәчәк, ди автор, әмма аның өчен күп югалтулар белән түләргә туры киләчәк. Шуның белән бергә, пьеса-әкиятнең теле авыр. Вакыйгакүренешләр, аеруча баштагы өлештә бик сузынкы, ялыктыргыч. Автор бала психологисе үзенчәлекләрен искә алып бетерми. Хатын-кыз образындагы Юха еланның эш-гамәле, сыйфатлары ачык-аңлаешлы булса, Шүрәле, Дию пәрие, Су иясе образларына салынган мәгънә-эчтәлекне кабул итү укучы бала өчен шактый каршылыклар тудырачак.

Ике гасыр чигендә татар драматургиясенә яшь автор Илгиз Зәйниев килеп, тиз арада укучы-тамашачының ихтирамын яулый. «Ай кызы», «Туйга ничә көн кала», «Күкләр елмаеп караса», «Суган чәчәге» кебек әсәрләре үк авторның тормышны оста күзәтүен, шуңа да сайланган тормыш материалының тирән мәгънәле булу белән бергә, гаять тормышчан һәм төрлелеген билгели. Аның беренче пьесаларында, исемнәреннән үк күренгәнчә, яшьләр үзәктә тора. Автор аларның хыял-омтылышын да, шатлык-борчуларын да яхшы белеп яза. И. Зәйниевкә яшәешнең җитди әхлакый һәм фәлсәфи проблемалары да чит-ят түгел. «Мәхәббәт турында сөйләшик»тә драматург ир-хатын, гаилә, яшәешнең асылы, мәгънәсе кебек мәсьәләләргә дә иркен мөрәҗәгать итә. Көнкүреш мәсьәләләре белән бергә җирдәге яшәешнең нигезендә яткан мәхәббәт төшенчәсен үзәккә алган әсәрдә табигыйлек, гадәтилек артында яшәгән һәр көннең, сәгатьнең кадерен белик, изге гамәлләр кылырга омтылыйк, күңелебездә мәхәббәт утын сүндермик, дигән фикер ята. Субъектив катламда суфичылык әдәбиятыннан килүче традиция барлыгы ачыла. Без мәңгелек юлында, ди кебек автор. Бүгенге яшәешебез – вакытлы тукталыш. Карт белән карчыкның фатирлары белән бүлешүе – матди яктан бигрәк, күңел камиллегенә омтылу күренеше. Алар бер гаиләне булса да сөендереп, мәңгелеккә китә. Әсәрнең уңышы – әхлакый һәм милли тамырларны барлауда, яшәү мәгънәсенең асылы яхшылык эшләп, үзең турында яхшы истәлек калдыруда дигәнне укучы-тамашачыга

җиткерүдә. Автор яратуга, үзара хөрмәткә, тигезлеккә һәм гармониягә нигезләнгән дөнья моделе тәкъдим итә.

И. Зәйниев драматургик иҗатның һәм драма, һәм комедия жанрларында уңышлы яза. Бу исә аның драматик һәм комедиячел каршылыкларны дөрес тоемлавын, диалог-монологлар аша хәрәкәтне эзлекле үстерү осталыгын күрсәтә. Яшь драматургның эзләнүләре, сәнгати фикерләү үзенчәлеге шактый тулы чагылган «Суган чәчәге» пьесасында әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә бәйле яшәешнең күптөрле проблемалары игътибарга алына. Вакыйга-күренешләрнең төп өлешен геройлар язмышына бәйле коллизияләр алып тора. Пьесаның «Суган чәчәге» дип аталуы да шуның белән бәйле.

Драматургның «Бәби» җыентыгына балалар өчен язылган пьесалары туплап бирелгән. Алар байтак алдан язылып, барысы да сәхнәләрдә уйналса да, китап драматург иҗатын барлап, аның турында тагын бер сөйләшү, фикер алышу мөмкинлеге бирә. Җыентыктагы «Бәби», «Ак чәчәкләр иле». «Кәҗә, сарык һәм башкалар», «Урман-club» пьесаларында автор яшәеш кануннарына, заман проблемаларына үзенә хас фәлсәфәдә бәя бирә, башкаларга охшамаган, тамашачы күңеленә кереп кала алырлык образлар тудыруга ирешә. «Җәүдәт берлән Зөбәрҗәт» музыкаль драмасында XX йөз башы вакыйгалары сурәтләнә. Драманың исеменнән күренгәнчә, вакыйгалар үзәгендә Җәүдәт белән Зөбәрҗәтнең мәхәббәт тарихы булып, ул романтик купшылык, тирән хисләр, фаҗигалы пафос белән үрелеп бара. Геройларның ярату хисен, үзара мөнәсәбәтләрен җыр-музыка аша аңлатуы да әлеге күтәренкелекне, хисчәнлекне баетып, укучы-тамашачыга эмоциональ тәэсир итә.

И. Зәйниев пьесалары тема һәм жанр төрлелеге белән дә игътибарга лаек. «Авыр туфрагың җиңел булсын» комедиясендә полиция хезмәткәрләре тормышы сурәтләү объекты булып тора. «Милиция» дигән атаманы «полиция»гә алыштыруга һәм әлеге авыр, катлаулы хезмәтнең асылын еш кына бозып аңлауга һәм аңлатуга, аерым алганда, полиция эшенең күрсәткече булып һәртөр начарлыкка, җинаятькә юл куелмау түгел, бәлки язылган беркетмәләр саны тору кебек гаять тормышчан кимче-

лекләр ачып салына һәм фаш ителә. Әмма шуларга нигезләнгән сатирик конфликт оеша башласа да, ул дәвам иттерелми. Авыл милиционерының өстән төшерелгән планны үтәү максатында ялган-формаль җинаять «табуы», тәртип бозуны «оештыруы» зураеп китә һәм ул абсурд төсен ала. Шуңа бәйле вакыйга вакланa, таркала, каршылык бик тиз гап-гади көнкүреш материалы төсен ала. Нәтиҗәдә әсәр авторның нәрсә әйтергә теләве ачык чагылмаган пьеса буларак тәмамлана.

Яшь драматургның соңгы елларда язылган әсәрләре арасында «Әрем исе» мелодрамасы иң уңышлысы дип әйтер идем. Яшәешнең җитди мәсьәләләрен үзәккә куйган пьеса үзара мөнәсәбәттәге ярату һәм нәфрәт, өмет һәм өметсезлек, ышану һәм ышанмау, горурлык һәм курку кебек төшенчәләрне иңләп үтә, аларның асылы турында уйланырга этәрә. Бер караганда, әллә ни яңалык та юк. Туган җирен, аннан да бигрәк авырлы хәлдә сөйгән кызын ташлап киткән Сәфәр 35 елдан соң туган авылына кайта. Яшьтәшләре белән очрашу яшь чагындагы хисләрен кузгатып җибәрә. Ул үзенең ялгышуын, әмма аны төзәтеп булмаячагын аңлауга килә. Ничек кайткан булса, шулай китеп барган ирнең эш-гамәленә, яшәү рәвешенә Сара бер сүз белән бәя бирә – кызганыч кеше! Игътибар итик, әлеге күренешләр теге яки бу дәрәҗәдә байтак әсәрләрдә урын алды инде. Арада әдәбият тарихында калганы – А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир»е. И. Зәйниевнең яңалыгы шунда, ул олыгаеп барган кешеләр язмышы аша яшь буын турында уйлануга китерә. Сәфәр белән Сара оныгы Нурзилә образы үзенчәлекле характер булып ачыла. Яшьлек хатасына дучар булган кыз хис белән генә яшәми, акылын эшкә җигеп, тормышка ачык күз белән карый белә. Укучы-тамашачыда аның киләчәктә үз-үзен табасына өмет туа. 16 яшьлек Сәяр белән физкультура укытучысы Равил образлары да чор рухын тудыра һәм Нурзилә образын киңрәк ачарга ярдәм итә. Әрем исе – туган җир исе буларак, кешенең туган җире, авылдашлары, барыннан да бигрәк ата-анасы, сөйгәне, якыннары алдындагы җаваплылык символы дәрәҗәсенә күтәрелә. Ә инде әсәрне иңләп үткән җыр-моң моны тагын да үстерә, киң яңгырашлы итә. Шуның белән бергә, пьесадагы аерым

күренешләрнең ясалмалылыгы аның тәэсирен киметә. Әйтик, беренче күренештә үк 17 яшьлек кыз яңа гына авылга кайткан, бабасы дип белсә дә, моңа кадәр бер тапкыр да күрешмәгән иргә үзенең авырлы булуы турында сөйләп ташлый. Гәрчә чит кешегә күңелен ачуга китерерлек сәбәп юк. Шул ук вакытта, Нурзиләнең авырлы булуын ярты авыл белә, ә менә тәрбияләп үстергән әбисе генә белми икән. Гомумән, сызлану фәлсәфәсе белән сугарылган пьеса мелодраматик пафосы, тормышның серле дә, каршылыклы да күренешләре аша җитди уйлануларга этәрүе белән күңелдә кала.

И. Зәйниевнең эзләнүләрен уңышлы чагылдырган әсәрләренең берсе – «Бөке» комедиясе. Машиналар хәрәкәте тукталуны аңлаткан күренеш буларак «Бөке» бүгенге тормышыбызны чагылдыручы символ дәрәҗәсенә күтәрелә. Үткән тормышыбызга әйләнеп караганыбыз бармы? Без үзебез бөкедә түгелме? Яшәү мәгънәсен югалтып, бары «тамак тук, өс бөтен» дип кенә гомер кичермибезме? Ә бит күпләребез бөкедә, әсәр герое Радик әйткәнчә, «гомер буе бөкедә кебек. Гел каядыр барып төртеләбез, бер рәхәтләнеп тын да алган җук». Ә әлеге халәттән, битарафлыктан ничек котылырга? Урамдагы бөкене таратып кына үзеңнең барыр юлыңны ача, таба аласыңмы? Бик тә үзенчәлекле күренеш – бөкедә машиналар туктап калган, төрле яшьтәге, төрле характерлы кешеләр очраша. Беренче күренешләрдә машина эчендә барган сөйләшү шуны ачык күрсәтә – үзара әңгәмә коручыларның күңелләре тыныч түгел, һәрберсенең үз борчуы, кайгы-хәсрәте барлыгы ачыклана. Иң мөһиме – җаннары борчыла, үз-үзләрен эзләгәннәре сизелеп тора. Төрле җирдән җыелган, бөкедә туктап калган кешеләрнең үзара диалогларына нигезләнгән текст әкренләп бербөтенгә оеша һәм чорыбызның тулы картинасын күз алдына бастыра. Әсәр геройлары күңелләрендә җыелып килгән борчу-икеләнүләрен ачкан саен, тыштан күренгән кырыслык, дорфалык әкренләп кими һәм һәрберсенең матур сыйфатлары күренә бара. Үз-үзләрен, теләк-омтылышларын, борчу-мәшәкать сәбәпләрен аңлый барган саен, үкенү хисе дә үсә. Соңгысы исә якыннарына карата булган матур хисләрен ача алмау, аларга тиешле җылылыкны

бирмәү белән бәйле. Вакыйга барышында күңелләрдәге борчулардан арынган кешеләр аерылышу-таралышуны түгел, бөкенең дәвам итүен телиләр. Автор әсәре белән мәңгелек хакыйкатьне искәртә: без бит кешеләр, аңлашып, ярдәмләшеп яшәүгә ни җитә?

XXI гасыр башы татар драматургиясенең тема-проблема киңлеген, фәлсәфи тирәнлеген, яңа алым-чараларга баюын билгеләгән авторларның берсе – Зөлфәт Хәким. Аның «Телсез күке»се, «Легионер»ы, «Бит»е, «Алма бакчасында алтын бар»ы, «Гасыр моңы» кебек пьесаларында башкаларны кабатламаган милли характер тудыруның уңышлы үрнәкләре белән очрашабыз. Автор үткән һәм якын тарихка, татарның рухын билгеләүче традицияләргә, йола-гадәтләргә еш мөрәҗәгать итә. Драматургның «Легионер» театраль романында Бөек Ватан сугышы тудырган фаҗигалы язмышларга бәйле яшәешнең әхлакый, фәлсәфи, милли, иҗтимагый проблемалары калкытып куела. Аның әсәрләре укучы-тамашачыны уйлануга, эзләнүгә, автор белән диалогка китерүе белән үзенчәлекле. Ул иҗат иткән геройлар нәкъ менә каршылыклы булулары, көтелмәгән эш-гамәлләре белән аерылып тора. З. Хәкимнең «Бит» пьесасында классташлар дуслык, мәхәббәт, яшәү мәгънәсе, бәхет турында җитди бәхәс алып бара. Ул исә бөеклек һәм түбәнлек конфликтына үсеп әверелә. Артем исемле егетнең чечен сугышында янып, карарга куркыныч йөзе элекке дусларның ялган битлеген салырга, чын йөзләрен ачуга китерә.

Драматургның «Ля – бемоль» драмасында сәнгать дөньясына якын булган кешеләр тормышы сурәтләнә. Җыр сәнгате тирәсендә барган ыгы-зыгыларның бер читен ачып, бу сәнгатьнең базар мәйданына әверелә баруын гыйбрәтле язмышлар аша күрсәтә. Пьеса интеллектуаль эчтәлеге, яшәеш кыйммәтләре, яшәү мәгънәсе, кеше шәхесе турында фәлсәфи бәхәсләргә этәрүе белән кызыклы. З. Хәкимнең «Җенле күл» (2011) театраль романы тулы бер гасырга якын вакыйгаларны иңләп ала. Автор туган як, аның тарихы, кешеләре турында сөйләү өчен кызыклы сюжет таба. Кеше теленә Җенле күл, куркыныч урын дип кергән авыл читендәге күл янында дөньяга килгән

бала язмышы, киң планда авыл кешеләре турында гыйбрәтле тарихка әйләнә. Җенле күл кешене сынауга, бәяләүгә хезмәт итүче метафора да булып тора. З. Хәким хәзерге сәхнә әдәбиятына «театраль роман» жанрын алып килде. Байтак әсәрләрендәге кебек үк әлеге пьесада да автор зур вакыт аралыгын үз эченә алган вакыйгалар тезмәсен аерым кешеләр язмышына бәйле сюжет тармаклануы рәвешендә тәкъдим итә. Әсәр исеменә чыгарылган «Җенле күл» үзе үк мифологик катламга мөрәҗәгать итүне күрсәтеп, бердән, бер ил, бер милләт кешеләренең сугышына китергән шартларны, икенчедән, Сәфәрҗанны шайтани исем белән атаучыларның үзләренең «җенле» булуына ишарә итә.

Сәхнә әдәбиятында кеше шәхесен гаилә-көнкүреш кысаларында, мәхәббәт-дуслык һәм әхлак кануннарына нисбәтле чагылдыру мәсьәләсе даими игътибар үзәгендә кала. Әлеге тема-мотивлар Хәбир Ибраһимның «Ялгыз каен күзе», «Нәфига ханым», «Утрау» пьесаларында үзәк урынны били. «Ялгыз каен күзе» моңсу драмасы «җирдә чын сөю, чын мәхәббәт барын» тагын бер кат раслау булып яңгырый. Вакыйгалар үзәгендә гайбәткә ышанып рухи көчсезлек күрсәткән, үзен дә, сөйгәнен дә бәхетсезлеккә дучар иткән егет язмышы тора. Пьеса яңалыгы белән аерылып тормаса да, автор кызыклы интрига кора, укучы-тамашачыны мавыктыра белә. Явызлык һәм мәкернең төрлелеген, төсмерләрен ачуы һәм чиста, саф намусны аклый алмауны гыйбрәтле күренешләрдә чагылдыруы да игътибарны җәлеп итә. Драматургның реаль тормыштан алып язылган «Нәфига ханым» сатирик комедиясендә җәмгыятьтә хөкем сөргән «кыргый капитализм»ның кешелексез, тупас яклары көнкүреш вакыйгалары аша фаш ителә. Алар җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең кеше аңында, психологиясендә төрлечә чагылуына, шуңа да берәүләрнең алдау-афера юлына басуын, икенчеләрнең күктәге торнага ышанып алдануын сурәтләү белән үрелеп бара. Әлеге төп башына утырып калучыларның асылын автор көлүнең төрле алымнары ярдәмендә ача: бу – авыл җүләре белән аек акыллы кешеләрнең бер-берсен тиң күреп сөйләшүе, түбәнлек белән бөеклек категорияләренең үрелеп баруы, көлкеле детальләрдән, үткен диалоглардан файдалануы һ.б. Нәфига, Хасият кебек ко-

мик персонажлар чынбарлык белән бәрелештә үз-үзләрен фаш итә. Пьесада төп герой – Көлү, ул авторның эстетик идеалын чагылдыру булып та тора.

Сәхнә әдәбиятының барлык жанрларында да уңыш белән эшләүче Аманулланың «Моңлы ядкарь» (2005) җыентыгына туплап бирелгән пьесалар үзенчәлекле яшәеш фәлсәфәсе, җор һәм бай теле, диалоглар кору остасы булган авторның ныклы адымнар белән сәхнә әдәбиятында эшләвен күрсәтте. Китап аша укучыга килеп ирешкән пьесалар тормышчанлыгы, конфликтның ачыклыгы, сюжет-композиция төзеклеге, хәрәкәт динамикасы белән җәлеп итә. Драматургның заман проблемаларын калкытып куюда шактый кыю эзләнүләр алып баруын күрәбез.

Прозаның детектив жанрында уңышлы эшләп килүе Рәдиф Сәгъдинең сюжет кору, вакыйга-интрига оештыру остасы булуын күрсәтә. Аның «Алсу томан артында» моңсу драмасында игътибардан читтәрәк калып килгән, әмма гаять мөһим, кирәкле тема – афәт булып бүгенгебезгә үтеп кергән наркомания мәсьәләсе һәм ятим, сукбай балалар, яшүсмерләр тормышы сурәтләнә. Әлеге мәсьәләләрне автор җәмгыятьтәге социаль-иҗтимагый шартлар белән бәйләнештә өйрәнә. Әлеге «тормыш төбендә» яшәүчеләрне ничек итеп наркомания, эчкечелек, фахишәлек сазлыгыннан саклап калырга, тартып алырга? Пьеса әнә шуларны бөтен кискенлегендә куюы белән иҗтимагый яңгыраш ала.

Кырым татарларының фаҗигалы язмышы – төрки-татарларның төзәлмәс әрнүле ярасы булып тора. Сталин төзегән тоталитар дәүләтнең кешелексез сәясәте символына әверелгән кардәшләребез кичергән афәткә мөрәҗәгать итеп, М. Юныс үз вакытында бер рухи батырлык күрсәткән иде. Бу юнәлештә тагын бер адым ясалды, ул – Р. Сәгъдинең «Бакчасарай гөлләре» мелодрамасы. 1944 елдан алып 1990 еллар башына кадәрге вакытны үз эченә алган вакыйгаларда бер гаилә язмышына бәйле Кырым-татар халкы фаҗигасы ачыла. Кырымдагы Симферопольдә, Төркиядәге Әнкарада, НКВД зинданнарында барган күренешләрдә чын мәхәббәткә, кеше бөеклегенә дан җырланса, әхлаксызлык-кешелексезлек гамәлләренә җан әрни. Пьесадагы

җыр-музыка ярату символы буларак лейтмотив ролен үти һәм эмоциональ халәт тудырып, укучы-тамашачы күңелендә явызлыкка нәфрәт һәм гаделлеккә өмет-ышаныч тәрбияли. Р. Сәгъдинең «Кайтаваз» драмасында 1940–1950 еллар татар авылы сурәтләнә. Конфликтның бер ягында кыен шартларда да чын кеше булып калучылар торса, икенче якта, авылдашларын куркытып, мәсхәрәләп, түбәнсетеп, үз рәхәтлекләре өчен яшәүче бәндәләр тора. Автор сугыш чоры авылының игътибардан читтәрәк калып килгән ягын – колхоз җитәкчеләренең бал-майда яшәү сәбәпләрен ачуны максат итә. Реалистик вакыйгаларга нигезләнгән пьесадагы җыр-моң сызлану пафосын тагы да үстерә барып, һәрбер түбән бәндәләргә нәфрәт хисе булып яңгырый.

Хакимият һәм иҗатчы мөнәсәбәте борынгы һәм Урта гасырларда киң эшкәртелеп тә, XX гасырда читтәрәк калып килде. Шуңа да Ркаил Зәйдулланың «Хан һәм шагыйрь» тарихи драмасы интеллектуаль эчтәлекле булып, әзерлекле укучыга атап язылганлыгы белән игътибарга лаек. «Ашина» драмасы нигезендә кешенең рухи бөеклегенә китергән һәм түбәнлеккә төшергән сәбәпләр турында уйлану ята. Автор ике проблеманы бер үзәккә туплап бирә: 1) нахак гаеп белән төрмә-лагерьлар аша үткән кеше фаҗигасы, 2) сусаклагыч төзү аркасында туып-үскән, ата-баба каны тамган җирен югалтучылар хәсрәте. Шуларга бәйле каршылык чишелеше көтелмәгәнчә: җәмгыятьнең кешелексез ягын үз җилкәсендә татучы да, хакыйкатькә соңарып килүче дә, гомере буе көнчелек, үч, комсызлык афәтеннән котыла алмаучы да су астында калып, мәңгелеккә күчә. Әмма яшь буын вәкилен, киләчәк кешесен бүре коткарып кала. Әлеге нәселнең башында торучы меңьяшәр бүре Ашина турындагы риваятьнең сурәтләнгән вакыйгалар белән бәйләнеше Ватан, Намус, Ирек төшенчәләренең мәңгелек булуы турында уйлануларга да этәрә.

Драматургиядә замандаш образын тудыру, тормышта кешелеклелек, гаделлек барлыгын расларга алыну һәм моны әхлакый һәм фәлсәфи эчтәлек белән сугарылган вакыйгакүренешләрдә, укучы-тамашачыны битараф калдырмый торган сурәтләрдә чагылдыру омтылышы көчәя. Эсфир Яһүдиннең

«Бер кояш астында», «Оҗмах бакчасында өч төн», «Олуг хан ярлыгы» кебек пьесаларында әлеге мәсьәләләр төрле яссылыкта чагылыш таба.

Татар драматургиясе тарихында Рабит Батулланың лаеклы урыны булу бәхәс уятмый. Яңа гасыр башында дөнья күргән «Китек күңел», «Җимерелгән бәхет», «Мур кырылышы» әсәрләре әдипнең һаман эзләнүдә булуын, татар дөньясын төрле яссылыкта өйрәнүен, драматик материалга соралып торган яңадан-яңа тарихи, иҗтимагый, милли төсмерле сюжетларга мөрәҗәгать итүен күрсәтә. Драматургның әдәби офыгы, сәнгати фикерләве киңлегенә сокланырга гына кала. Аның эзләнүләре төрки-татар тарихы белән генә чикләнмичә, Европа киңлекләренә үтеп керә. Иҗтимагый-сәяси һәм көнкүреш мәсьәләләре дини, фәлсәфи, әхлакый сораулар белән үрелеп барган «Мур кырылышы» киләчәктә төрле планда тикшереләчәгенә шик юк. Ә инде татарның чагыштырмача якындагы тарихын – XIX йөзнең соңгы чирегеннән алып XX гасырның 40–50 нче елларын иңләп алган «Җимерелгән бәхет» драматик хикәясе әдипнең зур табышы булып тора. Заһидә ханым Тинчурина язмышына бәйле татар милләтенең каршылыклы да, фаҗигалы да язмышы, аны инкыйразга этәргән сәбәп-шартларны ачу үзәктә тора. Укучы каршында Заһидә һәм Кәрим Тинчуриннар, Әхмәровлар нәселе генә түгел, бәлки татарның билгеле зыялылары, аның үсешенә, киләчәгенә билгеле бер дәрәҗәдә йогынты ясаган Ш. Әхмәров, Г. Исхакый, Г. Кариев, М. Мутин, Ф. Ильская кебек шәхесләребезнең гыйбрәтле һәм фаҗигалы язмышы сурәтләнә.

Т. Миңнуллин бу елларда да татар драматургиясен әйдәп баручы олы әдип булып кала. Һәрбер яңа әсәре белән чынбарлыкның яңадан-яңа якларын ачуын, сискәндереп җибәрә торган темаларны укучы-тамашачы алдына куюын күрми мөмкин түгел. Драматургның басылып чыккан яисә төрле сәхнәләрдә куелган «Галиябану, сылуым-иркәм», «Тәнзиләкәй», «Аерылабыз – хуш инде», «Син мине күрәсеңме», «Алты кызга бер кияү», «Гашыйк буласым килә», «Мулла», «Дивана» пьесалары тема-проблемалары, яшәеш мәсьәләләрен милли һәм гомумкешелек

кыйммәтләре яссылыгында каравы белән, һәрберсендә дип әйтерлек индивидуаль сыйфатлары белән аерылып торган замандашыбызның характерын иҗат итүе һәм әдип кулланган сурәт чараларының, форма-алымнарының төрлелеге, байлыгы, еш кына кабатланмаслыгы белән аерылып тора.

Чаллы театры артисты Булат Сәлахов, драматургия кануннарын уңышлы үзләштереп, актив иҗатка килә, пьесалары сәхнәләрдә куела. «Яратылмый калган ярлар» әсәрен ул «баллада» дип атый. Хис-кичерешләр белән тулы драматик вакыйгалар турында сүз баруын искәртә. Әйе, автор еракта калган сугышның әдәбиятта аз чагылыш тапкан сәхифәләренә мөрәҗәгать итә. Бу – хезмәт лагерьларына җибәрелгән хатын-кызлар язмышы белән бәйле. Әдәби текст буларак әсәр пьеса таләпләренә туры килеп тә бетми. Ул телеспектакль яисә кинофильм өчен сценарий булып тора. Вакыйгалар күбрәк хатирәләр рәвешендәге монологларда ачыла. Шуңа да мелодраматик хислелек кызларның эш-гамәленнән аерылгысыз. Әмма этюдлар рәвешендәге бер-бер артлы килгән күренешләрдә аяусыз чынбарлык киң чагылыш таба. Лагерь тормышының кешелексез законнары һәм кешелек сыйфатларын югалта баручы НКВД хезмәткәрләре эш-гамәлләре укучы-тамашачы күңелендә әрнү, борчылу һәм нәфрәт уята. Сызлану мотивы иңләп үткән әсәрдә автор гыйбрәтле, бер төрле генә бәяләнми торган образлар тудыра алган. Алар тулы канлы булып, бөтен сыйфатларында чагылмаса да, шул чор тудырган типлар буларак алга килеп баса. Никахсыз бала табып, сабыен имезү өчен сөте булмаудан теләсә нинди адымга барырга әзер Марта, ачлыктан тилмереп үлүен күрмәс өчен, үз баласын үтергән Аня, «Евгений Онегин»ны яттан сөйләүче лагерь начальнигы Волкопятов тарафыннан көчләнгән Екатерина, НКВД офицерына гашыйк булган немец кызы Анна-Мария – әлеге һәм башка меңнәрчә яшь кызлар, тол хатыннар язмышы ул – яратылмый калган ярлар фаҗигасы.

Юныс Сафиуллинның «Йосыф һәм Зөләйха»сы безгә яхшы таныш Кол Гали әсәренә нигезләнә, әмма автор драматик вакыйгаларны музыкаль бизәлеш һәм хореография элементлары белән баетып, эмоциональ тәэсирле, тамашалы һәм, иң мөһиме,

заманча яңгырашлы әсәр иҗат итә. Автор таныш кыйссаның гомумкешелек кыйммәтләренә йөз тоткан элементларын – бераллалык фәлсәфәсе, изге Корьән тәгълиматы, кешенең тышкы һәм эчке матурлыгы, мәхәббәт һәм матурлык эстетикасы – барысын да эзлекле һәм максатчан туплап, тирән фәлсәфи эчтәлекле әсәр иҗат иткән.

Зиннур Хөсниярның «Ут чәчәге» пьесасы чор афәтенә әверелә барган наркомания күренеше, аның таралыш сәбәпләре турында. Дөрес, проблема укучы-тамашачыга яхшы таныш булып, аның төрле планда чишелеше белән әдәбият-сәнгать әсәрләрендә (М. Маликова. «Чәчкә балы»; Р. Сәгъди. «Алсу томан» һ.б.) очрашкан идек. Вакыйга-күренешләр шактый таныш булып, спектакльдә, нигездә, ак һәм кара төсләр генә өстенлек итсә дә, ул фикер-карашларның ачыклыгы, чынбарлыкка якынлыгы белән уңышлы. Үзара катлаулы мөнәсәбәтләрне ачыклауга нигезләнгән вакыйгалар тезмәсе ата-ана һәм бала, байлык һәм бәхет, дуслык һәм мәхәббәт, ярату һәм хыянәт турындагы җитди сөйләшүгә алып килә. Автор акыл сатмыйча гына киңәш бирә: тормыш ыгы-зыгысы арасында балабызның хәлен белергә, башыннан сыйпарга, кызыксынулары белән танышырга, кирәк урында киңәш бирергә онытмасак иде!

Шамил Фәрхетдиновның «Гомер буе сине көттем...» пьесасында да мәхәббәт һәм нәфрәт, яхшылык һәм явызлык, миһербанлылык һәм кешелексезлек кебек мәсьәләләргә бәйле вакыйгалар төп сюжетны тәшкил итә. Үткәннәрне хәтердә яңарту һәм бүгенгенең гыйбрәтле хәлләре Әдилә исемле китапханәче образы аша ачыла. Ул – Т. Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар»ындагы Мәдинәнең бүгенге көннәрдәге дәвамчысы. Әмма әлеге әсәр героинясы хис-кичереш кешесе буларак сурәтләнә. Ул – язмышка буйсынып, һәрнәрсәне Аллаһтан дип кабул итүче, ягъни көрәшче түгел. Ахырда бәхетле тормышка ирешүе нәкъ менә түземлеге, корбанчылыгы нәтиҗәсе буларак кабул ителә. Гомумән, пьеса сызланулы, сыкранулы, күз яшьләре белән тулы язмышларны ачып, җыр-музыка яратучы тамашачыга атап язылган.

Айгөл Әхмәтгалиеваның «Сагынган чакларымда» драмасы өлкән яшьтәге карчыкның хатирәләрен яңартуы рәвешендә

язылган. Автор 1930–1940 елларның фаҗигалар белән тулы вакыйгаларын күз алдына бастыра. Алгы планда кеше һәм система каршылыгы булып, берәүләрнең ныклыгы, кешелеклелеге, икенчеләрнең түбәнлеге, мескенлеге, көчсезлеге гыйбрәтле күренешләрдә сурәтләнә. Колхозлар төзелү авырлыгы, салым өчен кешеләрнең соңгы мал-туарын яисә самавырын алып китү күренешләре, сугыш чорында хатын-кызларның урман кисәргә, җир казырга җибәрелеп, төрле җәберләүләргә дучар ителүе, совет властена елышкан һәртөр түбән җанлы бәндәләрнең кешелексез эш-гамәлләре җанлы кеше образлары аша тормышчан итеп ачыла. Автор авырлыкларны намус белән үтә алган Шаһидә, Гөлсем кебекләрнең рухи ныклыгына, иң кыен чакта да күңелләрендә өмет саклауга, ихтыяр көченә соклану тудыра. Алар тулы канлы, гыйбрәтле образлар булып алга килеп баса.

«Яңа татар пьесасы» конкурсы ачкан исемнәр арасында Сөмбел Гаффарова да бар. Аның «Килмешәк» драмасында сугышта әсирлеккә төшеп, концлагерь газаплары үткән кешенең Канададагы тормышы сурәтләнә. Чит илдә яшәп калган кеше бәхетлеме? Читтән килеп төпләнгән кеше – килмешәк – кем ул? Мескен җанмы, әллә бу җир аның өчен дә якын-кадерлеме? Туган җир, яшьлек, беренче сөйгән яр, әти-әни кадере кебек төшенчәләр кеше өчен ни дәрәҗәдә кыйммәт? Әлеге сорауларга һәм Дәрдемәнднең һәркемгә таныш «Ватан китәр, сөт калыр...» дигән гыйбарәсенә дә җавап эзләнә пьесада. Тема шактый таныш булса да, автор ретроспектив алым аша вакыйгаларны үткән-бүгенге бәйләнешенә кора һәм гыйбрәтле тормыш юлы үткән кеше язмышын сурәтли. Авторның «туган җир – чит ил» антиномиясе аша, кайда гына яшәсәң дә, милли асылыңны саклау сине шәхес итеп таныта, дигән карашы төп идея булып яңгырый. Ә инде пьесага уңышлы кертелгән кыр казлары, сәгать, бәрәңге кебек детальләр, вакыйгалар барышында образ-символ буларак, яшәешнең асыл кыйммәтләре, гомер агышы турында тукталып уйланырга мәҗбүр итә.

«Кайнар токмачлы аш» җыентыгы татар драматургиясенә яшь автор – Раилә Мөхсинова килүен хәбәр итә. «Яңа татар пьесасы» конкурсында лауреат булып, ул берничә әсәренең халык

театры сәхнәсендә куелуына ирешә. Р. Мөхсинова яратып һәм белеп яшьләр тормышына мөрәҗәгать итә. Ярату һәм нәфрәт, яхшылык һәм явызлык кебек әхлакый мәсьәләләр барлык әсәрләрен иңләп үтә. Сюжетка салынган вакыйгалар чынбарлык белән тыгыз бәйле булып, ачык, төгәл күз алдына бастырыла. Автор «Яшьлек хатасы», «Тәмуг газабы» кебек драмаларында ярату, тугрылык аша үзенең геройларын сыный, сайлау алдына куеп, рухи дөньяларын ачарга омтыла. «“Күрәзәче” Зөлфирә», «Йорт иясе» комедияләрендә яшәешебезгә үтеп кергән әдәпсезлек, ялган, эчкечелек, төрле юллар белән акча эшләү омтылышы кебек «авыру» нокталар фаш ителә, киң җәмәгатьчелек хөкеменә чыгарыла. Инде танылу алган «Кайнар токмачлы аш» комедиясендә студентлар тормышының берсен – тамак ягын кайгыртуны ачып, шуңа нисбәтле характер сыйфатлары, дөньяга карашлары төрле булган кыз һәм егетләрне бәрелештерә. Каршылыкны үстерә барып, уңышлы хәрәкәт тудыруга ирешә.

Шулай итеп, гасыр башы драматургиясендә тематик төрлелеккә омтылу күзәтелеп, драматурглар ерактагы һәм якындагы тарихыбызны, әфган һәм чечен сугышы кайтавазын, авылларның бетүе һәм глобальләшү күренешен, җәмгыятьтә барлыкка килгән яңа гадәтләрне, гомумкешелек кыйммәтләренең кимүе һәм шәфкатьсезлек билгеләренең арту сәбәпләрен, милли традицияләрне һ.б. өйрәнү аша заманның гаять мөһим мәсьәләләренә мөрәҗәгать итәләр. Сәхнә әдәбиятындагы табышлар, беренче чиратта, кеше образлары, милли характерлар иҗат итү белән бәйле. Иң яхшы әсәрләрдә милли тамырлардан аерылмаган, халык язмышын үз язмышы иткән, заман сынауларына бирешмәгән шәхесләр урын ала. Милли идеалларга караш, билгеле бер үзгәреш кичереп, глобализм шартларында милләтне саклап калу, Россия һәм Евразия тарихында татарларның урынын билгеләү омтылышы булып алга чыга. Бу исә аерым кешенең һәм халыкның табигать дөньясы, галәм һәм космос, мөселман һәм христиан цивилизацияләре һ.б. белән катлаулы мөнәсәбәтен ачыклауга китерә. Әсәрләрнең жанр һәм жанр формаларына бәйле төрлелеге сәнгати алым-чараларның баюына да юл ачып, шартлы алымнар, символик-метафорик күренешләр,

мифологик дөнья сурәтләре, психологизм алымнары һ.б. хәзерге пьесаларның поэтик нигезен тәшкил итә.

## 3.2. Яңа жанр формаларына йөз тотып

Әдәби, әсәр рухи иҗат нәтиҗәсе буларак, эчтәлек белән форманың диалектик бәйләнешенә нигезләнә. Язучы хыялында туган эчтәлеккә ярашлы форма эзли, ягъни беренчесе икенчесенең үзенчәлеген аңларга ярдәм итә. Шуңа да әдәбият белемендә формага карата эчтәлекнең беренчеллеге фикере өстенлек итә, әмма әдәби әсәрне укып аңлау процессында форма алга чыга. Чөнки башта вакыйга-күренешләрне, геройларны, алым-чараларны кабул итәбез һәм шуның аша әдәби эчтәлеккә төшенәбез. Шул рәвешле, хәзерге әдәбият белемендә эчтәлекнең һәм форманың бердәй әһәмиятле булуы фикере яклана. Сүз сәнгатендә әлеге компонентлар бәйләнешенең, автор карашларын ачуда һәрберсенең мөһим урын алып торуының уңышлы үрнәге белән Т. Миңнуллин пьесаларында да очрашабыз. А. Әхмәдуллин билгеләп үткәнчә, аның әсәрләренә драматургия кануннарын саклавы, уку өчен дә, сәхнәдән карау өчен дә кызыклы булулары, шартлылыкка киң урын бирелү һәм шуның ярдәмендә фикер тирәнлегенә ирешү, ә инде эчтәлектә кеше шәхесен алга чыгарып, аның күңел байлыгына, акыл көченә, рухи мөмкинлекләренә ышануны чагылдыру хас[1]. Г. Камал, Г. Исхакый, К. Тинчуриннардан килүче традицион алым-чараларга иркен мөрәҗәгать иткән драматург форма өлкәсендә яңадан-яңа эзләнүләр алып бара. Пьесаларында вакыйга-күренешләрне «оялап» урнаштыру, әсәр героеның вакыйга-күренешләрдә катнашып кына калмыйча, аларны сөйләп-аңлатып та баруы, әйләнмәле композициядән файдалану, ике генә яисә бер генә катнашучы булу кебек һ.б. формаларга мөрәҗәгать итә.

Аларның катлаулы рухи дөньяларын ачу өчен әдипнең психологизм алымнарына яисә традицион булмаган хәл-күренешләргә, алым-чараларга мөрәҗәгать итүе дә игътибарга лаек.

[1] *Әхмәдуллин А.* Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 126–127.

Т. Миңнуллинның «Тәнзиләкәй» монодрамасы татар сәхнә әдәбиятында сирәк кунак булган (моңа кадәр Р. Хәмиднең «Олы юлның тузаны» гына бар иде) «бер артист театры» формасында булуы белән игътибарга лаек. Ул бер герой монологларыннан гыйбарәт. Мондый әсәрләрне язуның кыенлыгы турында драматург бер көндәлегендә яза. Әлеге мәкалә сәхнә әсәре, аның үзенчәлеге, хәрәкәт тудыру серләрен ачу ягыннан да игътибарга лаек. Сүз, күрәсең, «Тәнзиләкәй» пьесасы турында бара: *«Язылa башлаган пьесаны дәвам итәргә кирәк булыр. Сөйгән ярын югалткан гашыйк җан турында бер кеше генә катнаша торган пьеса язарга тотынган идем. Туктап калдым, язуы читен. Сәхнә әсәрендә хәрәкәт булырга тиеш. Хәрәкәт булмаса, тамашачы спектакльне карамый. Сәхнәдә берүзе генә булган персонаж тирәсендә хәрәкәтне ничек тудырырга? Сүз генә җитми, маймылсыз зоопаркның кызыгы булмаган кебек. Уйлар бирелеше, хисләр көрәше, конфликт, интригаларсыз пьеса да була алмый. Шуларны эзләп, уйлап ятам. Уйлавым бушка түгел – бер күренешне күңелдән язып бетердем шикелле. Иртәгә кәгазьгә төшергәндә, бәлки, уйлаганча ук булмас. Шулай да рәхәт – күренешнең маймылы табылды»*[1]. Инде әсәргә мөрәҗәгать итик. Кырык яшьлек рәссам Газинур егерме өч ел инде җавапсыз мәхәббәт белән яши. Ярату хисе аңа сөйгәненең ике йөз портретын ясарга көч биргән. Тәнзиләнең туган көнендә ул икесенә бәйле хәл-вакыйгаларны хәтерендә яңарта. Әсәрнең эчтәлеген Газинур күңелендәге хис-кичереш хәрәкәте билгели.

Драматик хикәядә Газинур язмышы экзистенциализм (сызлану) фәлсәфәсенә нигезләнеп ачыла. Аның татар әдәбиятында чагылышын беренчеләрдән булып тикшергән Р. Ганиева фикеренчә, XVI гасырның икенче яртысыннан соңгы сүз сәнгатендә, билгеле сәбәп-шартлар нәтиҗәсендә, экзистенциаль күренешләр суфичылык идеяләренә кушылып урын ала. Автор аны декадентлык (ышанычны югалту, күңел төшү, чарасызлык мәгънәсен белдерә) төшенчәсе белән аңлата. Ә инде XX йөз башында, модернистик агымның бер чагылышы буларак,

[1] *Миңнуллин Т.* Таң алдыннан // *Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б. 113.

С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Н. Думави, Ф. Әмирхан, Ш. Камал һ.б. иҗатында урын ала[1]. Әлеге үзенчәлекле күренешне XX йөз башына мөнәсәбәтле өйрәнгән Д. Заһидуллина «ялгыз кеше трагедиясе» фәлсәфәсе рационализмга, акыл көченә шикләнеп караудан башлана, шикләнү чарасызлыкка китерә, дип билгели. Көнбатыш фәлсәфәчеләре А. Шопенһауэр, Ф. Ницше, И. Кант һ.б. фикерләрләренең күпләп үтеп керүе һәм җәмгыятьтәге шартлар XX йөз башы татар әдәбиятында кешенең ялгызлыгы һәм көчсезлеге хакындагы фикерләрнең күпләп урын алуына китерә. Әлеге фәлсәфә дөньяда рухи кыйммәтләр җуела баруны проблема итеп күтәрсә дә, «экзистенциалистлар кешенең чарасыз-ялгызлыгын гына сурәтләп калмый, бәлки яшәештәге хакыйкатькә туры карарга, тормышта үз юлыңны табарга да өйрәтә»[2].

Үткән гасыр башында үзенчәлекле агым тәшкил иткән әлеге күренеш белән «Тәнзиләкәй» пьесасында очрашабыз. Экзистенциализм төшенчәсе ике өлештән торып, яшәешнең мәгънәсен аңлау юлы булып күзаллана: берсе – кешенең үз күңелен аңлавы, үзен танып-белүе (эссенция) һәм шуның аша икенче баскычка килүе, ягъни тормыш чынбарлыгының мәгънәсезлеген, чарасызлыгын аңлау кебек хакыйкатьне ачуы (экзистенция)[3]. Үзенең истәлек-хатирәләрендә Газинур бала һәм яшүсмер елларындагы шатлык-куанычтан, олыгайгач күңелен биләп алган чарасызлык-өметсезлеккә таба юл үтә.

Әсәрнең беренче бүлегендә укучы-тамашачы ялгызлыкта калган, хыял белән чынбарлык арасындагы саташулы халәттә яшәүче Газинур белән очраша. Аның күңелендәге әрнү-сызлану, шат булырга тырышу артындагы моңаю сәбәбе – ялгызлык һәм мәхәббәт сагышы. Романтик әсәрләргә хас булганча, Газинур хыялында бер-бер артлы сабый чагы, яшүсмер еллары, ма-

---

[1] *Ганиева Р.К.* Декадентские мотивы в татарской литературе (первая четверть XX в.) // Милли мәдәният. – 2005. – № 7. – С. 11–15.

[2] *Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 80–81.

[3] Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / фәнни мөх.: Т.Н. Галиуллин, Д.Ф. Заһидуллина). – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 119–121.

тур яшьлекләре, Тәнзиләнең туе кебек күренешләр туа, укучының да күз алдына бастырыла.

Драматик хикәядә мәхәббәт илаһилык дәрәҗәсенә күтәрелә. Егет кызны йолдызларга, айдагы Зөһрәгә тиңли. Әлеге хис аны матурлыкны, беренче чиратта табигать матурлыгын күрергә ярдәм итә. Мәхәббәт матурлыгы белән сәнгать матурлыгы үзара кушылып, үрелеп бара. Геройның күңел хәрәкәте сурәтләү объекты булып торган әсәрдә сөйгәне портретларында чагылган мизгелләргә мөнәсәбәтендә Газинурның рухи бай дөньясы ачыла.

Т. Миңнуллин «Тәнзиләкәй»дә зур булмаган детальләр аша Тәнзиләнең рухи дөньясын ача һәм кешедәге, табигатьтәге матурлыкны, гомумән, яшәү матурлыгын күрә алмаучы зур сәнгатькә юл таба алмый, дигән нәтиҗәгә китерә. Газинур бик соңарып кына Тәнзиләнең үзе күрергә теләгән, хыялында йөрткән кеше булмавын аңлауга килә. Шуның белән бергә, автор яшәешнең акыл белән аңлап бетерү мөмкин булмаган яклары барлыгын искәртә. Ә бит Газинурның рухи дөньясы серле, гаять катлаулы. Ул үзенә үзе хөкемдар да, яклаучы да. Тәнзилә белән дә шул ук хәл. Аны гаепләргә кем җөрьят итәр икән. Алар гаепсез дә һәм гаепле дә, иң аянычы – бәхетсезләр.

Монологларында Газинурның төрле дәрәҗә-халәтләрдә бирелгән уйлары, гаять киң, тирән хыял дөньясы ачыла. Психологик киеренке халәттәге ир чынбарлык белән хыял чигендә яши, ул ниндидер аңсызлык, саташулы хәлдә. Болар исә яшәештәге мәхәббәт һәм нәфрәт, яшьлек һәм картлык, өмет һәм чарасызлык, ышану һәм ялгызлык, шатлык һәм кайгы, үткән һәм киләчәк, ниһаять, бәхет һәм бәхетсезлек кебек ике чик арасы рәвешендә укучы күз алдына бастырыла. Әсәр ахырында Газинурның чарасызлыкка килүе, мәхәббәтенең нәфрәткә алышынуы, гомумән, яшәеш фаҗигасын аңлавы күптөрле сораулар турында уйлануга һәм, иң мөһиме, күптөрле җавап вариантлары тудырып, автор белән укучы диалогына китерә. Ә ул исә һәркемнең күңелендә фаҗиганы булдырмый калу юлларын эзләү булып үсә. Газинурның яшәеш фаҗигасына бәйле, шул рәвешле, кешенең ялгызлыгы, яшәешнең асылы газап чигүдә булу

кебек сызланулы уй-фикерләр укучы күңелендә хис-кичерешләр кузгатып, аны чистарыну-катарсиска китерә һәм тормышның мәгънәсе үз-үзеңне аңлау, табу аша Матурлыкка, Өметкә, Мәхәббәткә таянуда, дигән олы Хакыйкатьне ача.

Геройлар язмышы аша драматург укучыны да бәхет һәм бәхетсезлек турындагы уйлануларга этәрә. Газинурның *«Бәхетнең ни икәнен белер өчен бәхетсез булып карарга кирәк. Гел бәхетле кеше бәхетле була белми»*[1] дигән сүзләрендә әлеге төшенчәнең чагыштырмача булуы һәм геройның яшәү фәлсәфәсе ачыла. Ә инде Тәнзилә фикере буларак яңгыраган *«бәхетсезлек ул – ялгызлык»*[2] гыйбарәсе бу хатынның яшәү фаҗигасын, матди байлыкның гына чын бәхет чыганагы булмавын аңлауга китерә. Ире, балалары булса да, Тәнзилә – бәхетсез, чөнки аның янында җан хәрәкәтләрен аңлаучы кеше юк.

Урта гасырларның романтик рухлы мәхәббәт дастаннарында сөю хисен чагылдыруда ике төрле мотив урын ала: мәхәббәт – рәхәтлек, бәхет-шатлык, мәхәббәт – кайгы-хәсрәт[3]. Шул традицияләрнең дәвамы буларак, Т. Миңнуллин әсәрендә мәхәббәт хәсрәт чыганагы буларак бирелә. Моның сәбәбе акыл һәм хис каршылыгында. Газинур сөйгәнен җан мәхәббәте белән ярата, тән мәхәббәте турындагы фикерләрен һәрдаим кире кага. Тәнзилә исә, беренче чиратта, акыл белән ярата. Күпсанлы портретлар символ булып килә. Аларны Газинурның үзенә мөнәсәбәтле табу һәм югалту дип атарга була. Рәссам үзенең асылын эзли һәм, моңа күбрәк ирешкән саен, хыялындагы Тәнзиләне югалта бара.

Шулай итеп, «Тәнзиләкәй» драматик хикәясе тормышяшәешнең фәлсәфи сорауларын үзенчәлекле алым-чараларда чагылдыруга һәм кеше күңеленең серле, кабатланмас якларын, сыйфат-билгеләрен ачуга бәйле драматург эзләнүләренең тирәнәюе турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Ул исә чынбарлыкны рухи кичерешләр аша фәлсәфи бәяләү, шартлы һәм

---

[1] *Миңнуллин Т.* Тәнзиләкәй // Казан утлары. – 2005. – № 9. – Б. 49.

[2] Шунда ук. – Б. 50.

[3] *Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. – Б. 97.

ассоциатив алымнар нигезендә текстны аңлау вариантларын арттыру, геройның яшәеш кануннарына каршы килүе һәм үзе уйлап тапкан чынбарлыкта яшәргә омтылуы кебек билгеләрне сурәтләүдә чагыла.

* * *

Т. Миңнуллинның «Галиябану, сылуым-иркәм» пьесасы әдәбият белемендә интертекстуальлек дип аталган форма-алымга нигезләнеп язылган булуы белән зур кызыксыну уята. Интертекстуальлек әдәби текстта алдагы чорларда язылган әсәрләргә мөрәҗәгать итүне, ягъни текстлар арасында билгеле бер бәйләнеш булуны аңлата. Әдәби термин буларак шактый соңарып дөнья күрсә дә, асылда ул сүз сәнгатенең башлангыч чорларына ук карый. Язма әдәбият үзенең тамырлары белән мифологиягә, халык авыз иҗатына барып тоташа һәм алардагы предмет-образларга, билге-символларга, исем-предметларга бик еш мөрәҗәгать итә. Үз чиратында, әдәби әсәрләрдә алдагыларында урын алган форма һәм эчтәлекнең аерым компонентлары, шул исәптән текст яисә аның өлешләре кабатлана, үстерелә, аңа мөнәсәбәт белдерелә һәм үзеннән соңгы чорларга илтеп җиткерелә. Шуңа да интертекстуальлек киң мәгънәсендә әдәби традиция, әдәби күчемлелек төшенчәләренә барып тоташа. Әдәбият белемендә аның өч төрен аерып чыгаралар: берсе – әдип иҗатына белеп, аңлап мөрәҗәгать итү; икенчесе – әдәби шаблонны аңсыз рәвештә, белмичә кабатлау; өченчесе – очраклы туры килү.

Хәзерге әдәбият белемендә «интертекстуальлек» белән бергә «реминисценция» термины да кулланыла. Алар үзара якын булсалар да, бердәй түгел. Элекке әдәби үрнәккә махсус яисә автор ихтыярыннан башка мөрәҗәгать итүнең аеруча киң таралган формалары булып цитаталар куллану, әсәрне һәм билгеле әдәби фактларны искә алу, аерым сюжетларны, образларны текстка кертү, әсәрләрне уртак исем белән атау һ.б. санала. Интертекстуальлек киңрәк төшенчә булып тора һәм анда алдагы чор текстына нигезләнү үзәккә алынып, бер яктан, яңа заман биеклегеннән аңа бәя бирүгә, икенче яктан, бу чор авторының аерым караш-концепциясен ачу-аңлатуга хезмәт итә. Аның төп

формалары булып цитаталар куллану, пародия, иярү, назыйрә һ.б. тора. Аңлашылганча, ике термин арасында үтеп чыкмаслык чикләр юк. Текстара бәйләнешнең кайсы төшенчәгә туры килүе соңгы әсәрдәге әдәби-эстетик функциясеннән чыгып билгеләнә. Шунлыктан таррак мәгънә белдергән реминисценция алымын интертекстуальлек эчендә, ягъни аның бер форма-элементы итеп карарга мөмкин.

Татар әдәбияты, шул исәптән драматургия интертекстуальлек алымына даими мөрәҗәгать итеп килә. Сәхнә әдәбиятының беренче үрнәкләреннән булган «Рәдде бичара кыз» (1888) пьесасында Ф. Халиди бер ел элек дөнья күргән «Бичара кыз» (Г. Ильяси, 1887) әсәренә мөнәсәбәтен белдерә (реминисценция) һәм ул хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен аңлауда авторларның концепцияләре төрлелеген аңлата. Мөселманнарның изге китабы булган Коръән аятьләренә турыдан-туры яисә читләтеп мөрәҗәгать итүне Г. Исхакый, К. Тинчурин, Н. Исәнбәт, Т. Миңнуллин, И. Юзеев, Р. Батулла һ.б. иҗатында очратабыз. XX гасыр башында иҗат ителгән драма әсәрләрендә реминисценциянең уңышлы үрнәкләре дөнья күрә. Мисал өчен, Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасы геройлары караш-фикерләрен И. Тургеневнең «Отцы и дети» әсәреннән алынган цитаталар ярдәмендә белдерәләр. Ф. Бурнашның «Таһир-Зөһрә» (1918), М. Җәлилнең «Алтынчәч» (1939), Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» (1939), «Идегәй» (1941), Т. Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» (1981), Ю. Сафиуллинның «Идегәй» (1994) әсәрләре һ.б. күпсанлы пьесалар интертекстуальлек алымына нигезләнеп язылган.

Т. Миңнуллинның «Галиябану, сылуым-иркәм» пьесасында интертекстуальлек авторның үзенчәлекле әдәби-эстетик концепциясен чагылдыруга хезмәт итә. Пьеса театр артистларының драматург Туран Муллин язган «Галиябану, сылуым-иркәм» исемле әсәрне укырга җыелу күренеше белән башланып китә. Вакыйгалар барышында берничә тапкыр «Укый башлыйк инде» дигән реплика яңгыраса да, моңа керешелми. Алай гына да түгел, катнашучылар авторның кем икәнен яхшы беләләр, шуңа да күзенә карап язганнарын «халтура» яисә «өч тиенле

пьеса» дип атаудан да кыенсынмыйлар. Дөрес, әле укылмаган пьесаны кире кагу бик үк аңлашылып бетми кебек. Әмма бу күренешкә бәйле диалог мөһим максатка хезмәт итә: Нәсимә һәм Әнвәр искәрткәнчә, Галиябану һәм Хәлил безнең әдәбият-сәнгатебез тарихында берәү генә, ягъни чын иҗат нәтиҗәсе буларак икенче «Галиябану» языла алмый, язылса да, «Идел» журналы битләрендә барган «Ша-ярыш» төсен генә алачак. Бу уңайдан шуны да билгеләп үтик: «XXI гасыр «Галиябану»ына килгән күпсанлы язмалар җәмәгатьчелектә бертөрле генә кабул ителмәде. Дөресрәге, яклаучы-хуплаучылар булуын кире какмастан, минемчә, күпчелектә яклау тапмады. Чөнки өлкән һәм урта буын гына түгел, яшьләр дә М. Фәйзи геройларын, аеруча Галиябануны олы, саф мәхәббәт символы буларак кабул итә. Ә инде «Ша-ярыш»ка килгән текстларда Галиябануның я җилбәзәк, я акчага гына кызыгучы; Хәлилнең я мескен, я исерек; Исмәгыйльнең я «мафиозник», я исерек һ.б. сыйфатларда бирелүе күңелдә урнашкан образларны юкка чыгара. Гомумән, язмаларның берсендә дә Галиябану белән Хәлилнең яхшылык, матурлык, сафлык, чын мәхәббәт үрнәге буларак тәкъдим ителмәвен ничек аңларга? М. Фәйзи әсәренә капма-каршы төсмерләрдә биреп, укучыларда көлү-елмаю тудыру теләгеме, әллә инде хәзерге заман яшьләрендә кара-караңгы сыйфатлар гына күрү чагылышымы бу? Ничек кенә булмасын, күптөрле сорау-бәхәсләргә урын кала.

Т. Миңнуллинның игътибар үзәгендә әдәбият-сәнгать дөньясы, аның кеше тормышындагы урыны, төрле буын кешеләрнең әдәби ядкярләргә караш-мөнәсәбәте һәм, иң мөһиме, кеше яшәешенең, аның теләкләренең, борчу-мәшәкатьләренең тирән катламнарын ачу, шуларны аңларга омтылу тора. Әсәрнең исемендә үк интертекстуальлекнең эчтәлекне билгеләүче форма булуына ишарә бар – «Галиябану, сылуым-иркәм». Әлеге исем XX йөз башында яшәп иҗат иткән М. Фәйзинең татар драматургиясендәге классик үрнәкләрнең берсе булган атаклы «Галиябану» мелодрамасына аваздаш булуын татар әдәбияты-сәнгате белән таныш кешегә сиземләү кыен түгел. Драматургның 1916 елда дөнья күргән «Галиябану» мелодрамасы татар

халкының иң яратып укылган һәм сәхнәдә каралган сәнгать әсәрләренең берсенә әйләнә. Сентименталь пафос белән өретелгән, саф хисләргә нигезләнгән мәхәббәткә мәдхия укылган, романтик самимилекләре, ихласлыклары белән башкалардан аерылып торган геройларның гаҗәеп матур хис-кичерешләре, шатлык-омтылышлары, кайгы-хәсрәтләре сурәтләнгән әсәр, халык көе С. Сәйдәшев эшкәртүендәге музыка белән кушылып, үзгә бер яңгыраш ала, укучы-тамашачы рухына гаять көчле тәэсир итә. Пьесаны тулысы белән халыкның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, сыйфат-билгеләре, өмет-юанычлары иңләп үтә һәм әлеге күренешләр чын мәгънәсендә аһәңле, яңгырашлы, чиста-матур татар теле аша укучы-тамашачыга җиткерелә. Нәкъ менә шушы сыйфатлар «Галиябану»ны киң яңгырашлы итә һәм сәхнә әдәбияты тарихындагы урынын да билгели. Берничә буын укучы-тамашачыны тәрбияләгән әсәр турында Т. Миңнуллин геройларының бәхәсе телевизордан яшь буын артистлар уйнавында «Галиябану» спектаклен карау, аны бәяләү аша үстерелә. Гомерләрен сәхнәгә багышлаган татар артистлары өчен, дөнья-күләм яңгыраш алган Шекспир әсәрләре кебек үк, татар драматургы М. Фәйзинең «Галиябану»ы да – соклангыч иҗат үрнәге. Шуңа да Галиябану һәм Хәлил образларын сәхнәдә уйнау, иҗат итү теләге һәркем күңелендә булып, моның олы дәрәҗә билгесе икәнен ачыктан-ачык әйтәләр. *«Булмады безнең яшьлек. Бездән Хәлилне уйнатмадылар»[1],* – ди Рамил, күңелендәге рәнҗүен яшермичә. Өлкән буын артистларның яшьләр уенына таләпчән мөнәсәбәтен аңлау кыен түгел. Дөресрәге, алар яшьләр уенында заман тәэсире булып аңлашылган билгеләрне, аерым алганда Галиябану һәм Хәлилнең гаҗәеп бай хис-кичерешләренә салкын карашны, тел хасиятләренә булган битарафлыкны кабул итә алмыйлар. Түбәндәге эпизодта ул ачык күренә:

*«Нәсимә (кычкырып). Туктатыгыз! Позор! Позор! (Барып телевизорны сүндерә.)*

*Фирая. Нәрсә булды, ә?*

---

[1] *Миңнуллин Т.* Галиябану, сылуым иркәм // *Миңнуллин Т.* Пьесалар / кереш сүз авт. А. Габәши-Салихова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 49.

*Нәсимә. Нәрсә булганын күрмисеңмени? «Галиябану»ны үтерәләр, тереләтә суялар. Шундый Галиябану буламы? Шундый Хәлил буламы? Булмый андый Галиябану.*

*Рамил. Нишләп булмасын. Боты озын, итәге кыска.*

*Нәсимә. Җаны юк, теле юк.*

*Фирая. Нигә инде син? Яшьләр бит әле.*

*Нәсимә. Театр ул балалар бакчасы түгел.*

*Әнвәр. Заманы ыштансыз булгач, Галиябану гына чишенми калмас инде»*[1].

Яшьләр уенына җаны белән әрнегән Нәсимә Ришатны чакыра һәм алар өзекне икесе уйнап күрсәтә. Т. Миңнуллин беренче карашка ачык та, гади дә һәм гадел дә булып тоелган юлдан – өлкәннәр уенын идеаллаштырып, яшьләргә үрнәк итеп кую белән китми. Аның өчен әсәрдәге персонаж роленә керү барышында артистның рухи дөньясын, күңелендәге кичерешләрне ачу тагы да мөһимрәк.

Интертекстуальлек, ягъни М. Фәйзинең «Галиябану» мелодрамасына мөрәҗәгать итү, яшьләр уйнавында спектакльдән өзекләр карау һәм өлкәннәрнең үзара уйнап күрсәтүе драматургның әдәби алым буларак «уен»ны файдалануын күрсәтә. Т. Миңнуллин «уен»ны әдәби алым буларак кулланып, бер яктан, классик әсәргә бәя бирә, икенче яктан, геройларының рухи дөньясын ача.

Нәсимә белән Ришат уенына да мөнәсәбәт бертөрле генә түгел. Һәрхәлдә, Әнвәр алар уенын кабул итми. Нәсимәгә дә *«Галиябануың котырган. Хәлил мондый кызны яраталмый»*[2], ди. Моңа каршы Нәсимә үзе иҗат иткән Галиябану образын болай сурәтли: *«Галиябану – ул хисләр йомгагы. Ул – әтисенә каршы чыгып Хәлилне сайлаган кыз. Тәрәзәдән егет керткән кыз. Аның яратуы вулкан кебек»*[3]. Бу урында драматург автор концепциясенең режиссер күзаллавында һәм артистлар уйнавында үзгәрешләр кичерү мәсьәләсенә килеп чыга. Шул уңайдан

---

[1] *Миңнуллин Т.* Галиябану, сылуым иркәм // *Миңнуллин Т.* Пьесалар / кереш сүз авт. А. Габәши-Салихова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 51.

[2] Шунда ук. – Б. 52.

[3] Шунда ук. – Б. 52.

Т. Миңнуллинның Хәлил образына укучы буларак карашы да кызыклы. Әлеге геройга бәя биреп, ул болай дип язган иде: «Минем элек-электән Хәлилгә ачуым килә иде. Җебегән егет дип саный идем. Мәхәббәте өчен егетләрчә көрәшә белмәве миңа ошамый иде. Бүген дә мин Хәлилгә сокланмыйм, Галиябануга сокланам. Ул көчле натура»[1].

Артист, сәхнәдә нинди тормыш кичереп, нинди образлар иҗат итүенә карамастан, беренче чиратта, кеше булып кала. Драматургның әсәр үзәгенә куйган сорауларының берсе әнә шуның белән бәйле. Вакыйгаларда һәрберсенең диярлек каршылыклы рухи дөньясы, эчке фаҗигасы ачыла. Галиябану роленә кереп уйнап, яшьлеген искә төшергән Нәсимә дә Әнвәргә күңелен бушата. Алар яшь вакытта бер-берсен яратсалар да, кавыша алмаганнар. Шулай да сагышлы мәхәббәтләрен гомер буе күңелдә саклап килгәннәр. Ул хис әле дә сүрелмәгән. Яшь буын вәкилләренең «Галиябану»ны уйнавы күңелләрен кузгатып җибәрә, яшьлекләрен искә төшерә, хата-ялгышларын яңарта. Пьеса дәвамында яңгыраган Нәсимә җыры һәм соңгы юлының кабатлануы да шуңа ишарә итә:

*Яшь гомер бер узгач,*
*Кайтмый ул яңадан.*
*Ә минем яшьлек кире кайтыр кебек.*
*Яшьлек бит күңелдә,*
*Иң матур җирендә*
*Вакытлыча туктаган бер җыр кебек.*
*Яшьлек бит күңелдә...*[2]

Автор өчен, билгеле, яшьләр уенына башкаларның да мөнәсәбәте кызыклы. Галиябану белән Хәлил диалогын караганнан соң, хәзер инде Гөлли, түзми, барып телевизорны сүндерә. *«Атлап йөрүләре татар кызы түгел. Артын марҗа кебек боргалый»*[3], – ди ул һәм әлеге эпизодны Ришат белән уйнап

[1] *Миңнуллин Т.* Хәлил әйбәт егетме? // Мәгариф. – 2000. – № 3. – Б. 32–33.

[2] *Миңнуллин Т.* Галиябану, сылуым иркәм // *Миңнуллин Т.* Пьесалар / кереш сүз авт. А. Габәши-Салихова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 56.

[3] Шунда ук. – Б. 57.

күрсәтергә алына. Әмма Галиябану ролендәге Гөллине Әнвәр кабул итми һәм кат-кат образ юклыгын, үзе күзаллаган образ тудырылмавын әйтә. Гөллинең борчылып елавы исә Әнвәр белән аңлашуга китерә.

Алдагы күренешләрдә геройлары теле белән драматург «Галиябану»га бәясен тирәнәйтә. Аеруча М. Фәйзи пьесасындагы образларның янып-көеп яратуында, сызлану-борчылуында, аңлашу-аерылышуында татарның милли рухы, яхшы да, яман да сыйфатлары чагылуы искәртелә. Шуңа да яшьләр уйнавында Хәлилне югалткан Галиябануның хәсрәтләнеп елау эпизодын Нәсимә дә, Гөлли дә тәнкыйтьли:

*«Нәсимә. Позор! Шулай елыйлармы? Үпкәләгән бала кебек мышкылдый.*

*Гөлли. Мужигы кыйнаган Марфа шикелле үкерә»*[1].

М. Фәйзидән алып уйналган соңгы күренеш Фираяның да хисләрен соң чиккәчә киеренкеләндерә. Аның Әнвәр белән аңлашуында каршылыклы, үкенечле, моңсу һәм бәхетсез язмышы ачыла. Фирая гомере буе Ришатны яратып яшәгән. Башкаларны ярата алмаганын аңлап, ялгыз гомер кичергән. Хәзер инде Әнвәрнең Фирая уенында образ булмавы турындагы фикере ачыклана төшә. Ул аның Галиябану ролендәге уенын реаль тормыштагы халәте, хис-кичерешләре, Ришатка мөнәсәбәте белән чагыштырып бәяли: *«Беләсеңме, Фирая, дөньяда Галиябанулар күптер, ләкин бердәнбер Галиябану – син. Ярата беләсең син. Олы мәхәббәтнең корбаны син».*

Пьесаның тагын бер үзенчәлеге – сәнгать әһелләре тормышының «пәрдә»сен ачып күрсәтү белән бәйле. Сәнгать алымнары ярдәмендә чагылдыру шактый авыр булган мәсьәләгә Т. Миңнуллин беренче тапкыр гына мөрәҗәгать итми. Драматургның «Миләүшәнең туган көне». «Дуслар җыелган җирдә», «Хушыгыз» драмаларын эченә алган трилогиясе сәнгать өлкәсендә эшләүче тулы бер буын язмышын тасвирлавы белән җәмәгатьчелектә киң яңгыраш тапкан иде. «Галиябану, сылуым-иркәм»дә театр артистларының үзенчәлекле тормышы

[1] *Миңнуллин Т.* Галиябану, сылуым иркәм // *Миңнуллин Т.* Пьесалар / кереш сүз авт. А. Габәши-Салихова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 58.

ачылып китә. Автор аларны сәнгать әһеле һәм кеше буларак аңларга омтыла. Бер яктан, интертекстуальлек һәм уен алымы, икенче яктан, вакыйга-күренешләрнең өч катламда бирелүе шул максатка хезмәт итә. Бер катлам булып, билгеле инде, яшь артистлар уены тора. Өлкәннәр аны «хиссез-кичерешсез» дип бәяли һәм пьесада ике буын арасындагы каршылык буларак та үстерелә. Соңгысы исә хәзерге яшьләр мәхәббәт дигән олы хискә артык җиңел карыйлар һәм бу аларның классик әсәрләребезне уйнавында да чагылыш таба, дигәнгә кайтып кала. Вакыйгаларның икенче катламы өлкән буын артистларның «Галиябану» ролендә уйнавы белән бәйле. Аның максаты, югарыда әйтелгәнчә, «уйнап» күрсәтү белән генә чикләнми. Монда артистларның яшәү рәвеше, үткән хатирәләре, театр сәхнәсенең милли телне, халыкның традицион яшәү рәвешен саклаудагы ролен, гомумән җәмгыятьнең рухи тормышындагы урынын ачык тоемлау – барысы да бергә үрелеп, бәйләнеп килә. Ниһаять, вакыйгаларның өченче катламында артистларның шәхси, рухи дөньялары ачылып китә. Артистның сәхнәдәге уены белән бергә, яшәештәге «роле» дә бар. Ул исә күпкә катлаулырак, тирәнрәк, еш кына фаҗигалырак та. Нәкъ менә Әнвәр белән бергә-бер калганда Нәсимәнең дә, Гөллинең дә, Фираяның да тормышка ашмаган хыял-омтылышлары, үзенчәлекле язмышлары ачыла. Шунысы игътибарга лаек, алар күңелендәге хис-кичерешләр күзгалышына «Галиябану»ны уйнау йогынты ясый. Әлеге мелодрамадагы Галиябанунның тирән мәхәббәте, сөйгәнен югалту кайгысы югарыда исемнәре аталган хатын-кызларның рухи кичерешләре белән кушылып китә һәм пьесадагы психологизмны баета. Шул ук вакытта М. Фәйзи «Галиябану»ының популярлыгы сәбәбе дә тагын бер кат искәртелә: әлеге мелодрама һәркем күңелендәге хис-кичерешләрне кузгата һәм яңарта, шуның белән укучы-тамашачыны сафландыра, җанын иркәли, күңелендә матурлыкка, мәхәббәткә омтылу, тартылу теләге тудыра. Үзе дә танылган драматург булган Р. Хәмид болай дип яза: «М. Фәйзи (...) халыкның, Д. Салихов язып биргәнчә әйтсәк, «миллилеген – гомер буе изелеп, колониядә яшәп тә, үзенең

моң-зарларын күз яшенә әйләндермичә, җыр-биюгә, уен-көлкегә, бәетләргә салып юанырга өйрәнүләрендә» күрә алган»[1].

Пьесада автор карашларын чагылдыручы үзәк герой юк. Дөрес, зур булмаган штрихлар ярдәмендә персонажлар һәрберсе үз йөзе, үз характеры белән ачыла. Шуның белән драматург артист тормышының гомумиләштерелгән сурәтен күз алдына бастыра. Әсәр «Хушыгыз» драмасындагы караш-фикерләрнең үстерелеше, дәвам итүе булып та тора. Белгәнебезчә, әлеге пьесада кайчандыр танылган җырчы булган Миләүшәнең гомере ахырында яшәешенең мәгънәсез булуын, бәхетсезлеген, чын тормышның янәшәдән үтеп китүен аңлауга килүе һәм драматургның укучы-тамашачы белән бергә моның сәбәпләре турында уйлануы үзәктә тора. Автор концепциясендә кеше һәм җәмгыять каршылыгы, сәнгать әһеленә булган караш, рухи бай тормышның нигезен табигать һәм авыл белән бәйлелектә карау мөһим урын алып тора. Гомумән, Миләүшә бәхетсезлегенең сәбәбен җәмгыятьтән, башкалардан эзләү омтылышы өстенлек итә. «Галиябану, сылуым-иркәм»дәге геройлар язмышы бертөрле генә түгел, билгеле. Драматург алгы планга чыгарган хатын-кызларның бәхетсезлеге сәбәбе сөйгән кешеләре белән кавышып гаилә кора алмау рәвешендә чикләнә. Шуңа да төп игътибар аларның рухи дөньясын, хис-кичерешләрен ачуга юнәлтелгән. Шул рәвешле, үткән гомер, яшьлек хаталары, соңарып аңлашу күренешләренә бәйле тормышчан сораулар турында уйлану, бергәләп җавап эзләү пьесаның сюжет нигезен тәшкил итә.

Драматург әсәрнең жанрын «моңсу комедия» дип билгеләгән. Вакыйга-күренешләрдә моңсулык пафосы өстенлек итсә дә, комедиячел каршылык-мөнәсәбәтләр юк диярлек. Пьесадагы геройлар арасындагы яисә һәрберсенең диярлек эчке каршылыгыннан һәм ике буынның әдәбият-сәнгатькә, мәхәббәткә карашларыннан үсеп чыккан конфликт драматик төсмер ала һәм хәрәкәтнең дә шулай үстерелешенә китерә. Шуңа да әсәрне «драма» дип атау уңышлырак булыр. Гомумән, Т. Миңнуллин, интертекстуальлек һәм уен алымнарына нигезләнеп, заман со-

[1] *Хәмид Р.* Татар драматургиясе миллиме? // Казан утлары. – 2002. – № 4. – Б. 155–163.

рауларын алга куйган, укучы-тамашачы белән җитди диалогка этәргән тормышчан пьеса иҗат иткән.

## 3.3. Т. Миңнуллинның соңгы чор иҗатында шәхес концепциясе

Хәзерге татар драматургиясендә барган эзләнүләрнең бер үзенчәлеге булып әдипләрнең реалистик һәм романтик күренешләр үрелеп барган һәм әлеге кысаларга гына сыеп бетмәгән яңа алым-чараларга, шул исәптән шартлы-метафорик сурәтләргә мөрәҗәгать итүе һәм кеше шәхесенә, аның рухи кичерешләренә игътибар арту тора. Соңгы елларда дөнья күргән сәхнә әсәрләрендә яшәешнең әхлакый, социаль-иҗтимагый, милли мәсьәләләре белән бергә, чынбарлыкның аңлап һәм аңлатып бетерү мөмкин булмаган, кешенең көчсезлеге, гомеренең чиклелеге, яшәү мәгънәсе кебек фәлсәфи сораулар да өйрәнү объекты итеп алына.

Т. Миңнуллинның иҗат эволюциясе аеруча шәхес концепциясендә тулы чагылыш таба. Билгеле булганча, әдәби герой бирелешендә авторның дөньяга, чынбарлык күренешләренә мөнәсәбәте, яшәештәге әхлакый һәм фәлсәфи сорауларны аңлауда әдәби-эстетик карашлары чагылыш таба. Тормыштагы вакыйга-хәлләргә гаять игътибарлы драматургның иң уңышлы әсәрләрендәге әдәби образлары – яшәү фәлсәфәсен үзләрендә чагылдыручы олы характерлар, үз язмышларын халык язмышы белән тыгыз бәйләгән милли типлар. «Нигез туздыручылар»ындагы Гарифулла, «Ир-егетләр»ендәге Мәрвән, «Үзебез сайлаган язмыш»ындагы Илгиз, «Ай булмаса, йолдыз бар»ындагы Мәдинә, «Монда тудык, монда үстек»ендәге Саттар, «Әлдермештән Әлмәндәр»ендәге Әлмәндәр, «Әниләр һәм бәбиләр»ендәге Гөлфинә кебекләр эш-гамәлләренең күпләргә үрнәк булуы, укучы-тамашачы күңелендә киләчәккә өмет-ышаныч тәрбияләве белән әдәби барышта аерылып тора. Т. Миңнуллинның XXI гасыр башы иҗатында да әлеге юнәлештәге эзләнүләр белән очрашабыз. Әдипнең «Саташу», «Эзләдем, бәгърем, сине», «Галиябану, сылуым иркәм», «Дивана», Мулла» кебек пьесаларында сюжет-композиция, форма-стиль ягыннан бул-

сын, шартлы яисә фантастик-мифологик күренешләрне ачкан сурәт чараларында булсын – җитди табышларны күрәбез. Драматургны көчле рухлы, нык ихтыярлы шәхесләр күбрәк кызыксындыра, билгеле. Шуның белән бергә, ул язмыш сынауларын уза алмаган, тормыш каршылыкларында буталып калган яисә гомере буе инанган нәрсәләрнең ялган, буш булуын аңлаган геройлар язмышын да җитди өйрәнүгә алына. Аларның катлаулы рухи дөньяларын ачу өчен, әдипнең психологизм алымнарына яисә традицион булмаган хәл-күренешләргә, алым-чараларга мөрәҗәгать итүе дә игътибарга лаек.

Драматургның «Алты кызга бер кияү» моңсу комедиясе әдипнең бөтен иҗатында үзәктә торган кешенең асылы, яшәү мәгънәсе, бәхет турындагы уйлануларының дәвамы булып тора. Бухгалтериядә эшләүче алты хатын-кыз һәм бер ир-егетнең диалог-әңгәмәләрендә яшәешнең гади-гадәти мәсьәләләре турында сүз бара. Әмма һәрбер диалогта, образларның эш-гамәлендә кеше дигән олы затны аңлау, серле дөньясын ачу омтылышы чагыла. Тормыш тарафыннан шактый «кыйналып» та бирешмәгән хатын-кызлар хезмәттәшләре Рәхмәтулла Хөрмәтулловичка булган мөнәсәбәтләренең билгеле бер уен икәнен аңлыйлар. Әмма һәрберсе моның дәвам итүен тели, чөнки алар назга, ягымлы йөзгә, тәмле телгә сусаган.

Эшчән, тырыш Фаягөл тыштан караганда бәхетле кебек, әмма аның гаилә тормышы уңмаган, балалары юк. Шуның өстенә ул иренең үзен яратмаганын, бары түзеп яшәгәнлеген аңлый һәм шуңа йөрәге ярсый. Үзен тыңлый алучы булганга сөенеп, Фаягөл Рәхмәтулла Хөрмәтулловичка бөтен йөрәген бушата: *«...Тик менә үзем яратсам да яраттыра алмадым. Яратып түгел, өйләнергә кирәк булганга гына өйләнгән булып чыкты. Балабыз булмады, дидем. Булмады шул. Булган булса, туң җаны бәлки эрегән булыр иде. Бала булмаганга мин өзгәләндем, аның исе дә китмәде шикелле. Унбиш ел гомер үтте дә китте. Бервакытны әйтә бу – «Синең бала тапмавың әйбәт», ди, югыйсә үзең кебек ямьсез бала табып бәхетсез итәр идең», ди. Тыныч кына әйтә, елмаеп әйтә. Ышынасызмы, Рәхмәтулла абзый? Йөрәгемә боз булып төште шул сүзләр. Бөтен*

*яратуларым нәфрәткә әйләнде. Янына яту түгел, янынnан үтеп китәсем дә килми. Шул килеш ничә ел яшибез бит, Рәхмәтулла абый – җан кисәгем. Кайвакытларда башымны элмәккә тыгарлык булам. Яшәү түгел бит инде бу, Рәхмәтулла абый. (Рәхмәтулланың күкрәгенә башын куеп җылый)»*[1].

Хатын-кызлар арасында иң шаяны, җилбәзәге, көлеп һәм шаярып яши торганы – Гөлчирә. Ул акыллы, чибәр, үткен телле һәм гаять тынгысыз булуы белән аерылып тора. Әмма ул да бәхетсез һәм Рәхмәтулла Хөрмәтулловичка эч серләрен бик теләп бушата. Гөлчирә Фәритне яратып чыга, әмма ире вафатыннан соң, менә хәзер Рәхмәтулла абыйсына гашыйк. *«Син минем җанымны аңлыйсың,* – ди ул аңа. – *Мин күзәтеп торам бит, син хатын-кызның үзләре дә белмәгән серләрен беләсең. Син кеше кыяфәтендәге Хозыр Ильяс бит, бәгырькәем. Шуңа бөтен бәхетсез хатыннар сиңа елышалар»*[2]. Рәхмәтулла Хөрмәтуллович та аны хөрмәт итүен яшерми. Бәхеткә лаек булып та, үз бәхетен таба алмаган җан ул Гөлчирә.

Хәдичә тормыштан ямь тапмыйча яши, ул ялгыз. Әлеге ялгызлык аның бөтен күңелен, яшәү рәвешен биләп алган. *«Яшәве кызык түгел миңа*, – ди ул Рәхмәтулла Хөрмәтулловичка күңелен ачып. – *Яшисем килми генә яшим. Кайвакытларда үкереп-үкереп җылыйсым килә. Юатучы булмаганга җыламый түзәм. Кырык яшь бит инде миңа, һаман бер ялгызым»*[3]. Әлеге гаять тәрбияле, булдыклы хатын һәркөнне өчпочмаклар, пәрәмәчләр пешереп алып килеп, Рәхмәтулла Хөрмәтулловичны сыйлый алуыннан үзенә бер җиңеллек, рәхәтлек, күңел тынычлыгы таба.

Яшь кыз Рузалиянең дә күңеле тыныч түгел. Ятимлектә үскән ул, аңа гомер буе ата һәм ана җылысы җитмәгән. Бүген дә кыз бала әлеге җылылыкны эзли. Шуңа да аңа өлкән яшьтәге хатын-кызлар ана, ә Рәхмәтулла Хөрмәтуллович ата булып тоела, һәрхәлдә аның шулай тоясы килә. Ә менә Нина Васильев-

[1] *Миңнуллин Т.* Алты кызга бер кияү // *Миңнуллин Т.* Пьесалар / кереш сүз авт. А. Габәши-Салихова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 87.

[2] Шунда ук. – Б. 89.

[3] Шунда ук. – Б. 90.

на башкалардан аерылып тора. Татар телен дә ул Рәхмәтулла Хөрмәтулловичның матур, йомшак сөйләменә сокланып өйрәнә башлаган. Аның күңеле дә рәнҗү, кайгы-хәсрәт белән тулы икән. Дүрт тапкыр кияүгә чыгып, өч бала үстерүче хатын тормыштагы иң зур афәт дип аракыны саный. Әллә язмыш кушуы шунда, аның барлык ирләре дә эчкече булып, һәрберсеннән диялек качарга мәҗбүр ул. Шул рәвешле, һәр яктан килгән, матур Нина Васильевна да сызланулы халәттә гомер кичерә.

Т. Миңнуллин яклаган төп идея, беренче чиратта, Рәхмәтулла образы белән бәйле. Ул – яңа образ түгел, атаклы Әлмәндәрнең яңа шартлардагы дәвамчысы. Әлеге образга бәйле сәхнә закончалыкларын белүдә, укучы-тамашачыга эмоциональ тәэсир итүдә авторның осталыгын күрми мөмкин түгел. Вакыйгалар барышында ул кеше кайгысын кайгыртып яшәүче, йомшак күңелле, һәрвакыт елмаеп-көлеп йөри торган, үз тормышыннан канәгать һәм бик тә бәхетле кеше булып кузаллана. Моңа ышанып беткәч кенә, көтелмәгән борылыш ясала – Рәхмәтулла унбиш ел буе паралич суккан хатынын тәрбияләп яши икән. Моны барысыннан да яшереп килгән герой югалып кала. Аннары бу турыда әйткән Нурзидәгә болай ди: *«Кемдә кемнең ни эше бар. Әллә сезнең тормыш тоташ бәхеттән торамы? Бер үтенечем сезгә. Моны миңа сөйләп бер ахмаклык эшләдегез, бүтәннәргә сөйләмәгез. Кемдә кемнең ни эше бар. Кешеләр кайгы белән түгел, шатлык уртаклашырга тиешләр»*[1]. Билгеле, Рәхмәтулла Хөрмәтулловичның әлеге карашы бертөрле генә бәяләнми. Кешеләргә шатлык өләшү рәхәт һәм ул кирәк тә, әмма күңелеңдә онытылмас сызлану хисе булганда ясалма елмаю үзен аклыймы, яисә ул һәрдаим мөмкин хәлме икән? Менә шуның өчен әлеге герой Әлмәндәр дәрәҗәсенә үсеп җитә алмый. Шулай итеп, пьеса, билгеле бер каршылыклардан, ясалмалылыктан котыла алмаса да, укучы-тамашачы күңелендә өмет хисе тудыруы, изгелек аша кеше күңелен сафландыру идеясен яклавы белән гыйбрәтле.

---

[1] *Миңнуллин Т.* Алты кызга бер кияү // *Миңнуллин Т.* Пьесалар / кереш сүз авт. А. Габәши-Салихова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 98.

* * *

Драматург үзенең пьесаларында яшәешнең гаять актуаль мәсьәләләре турында уйлана, борчыла, укучы-тамашачысы белән диалог кора. Гыйбрәтле вакыйга-күренешләр, үзенчәлекле геройлар аша яшәешнең яңа моделен тәкъдим итә. Билгеле булганча, язучы әйләнә-тирә яшәешне кеше тормышы белән тыгыз бәйлелектә чагылдыра. Сурәтләү объекты буларак алынган шәхес үзенең дөньяга карашы, яшәеш кыйммәтләре, яклаган идеаллары белән ачыла. Аның эш-гамәле аеруча үзен яшәгән чор һәм милли сыйфатлары белән билгеләнә, бәяләнә. Шулай итеп авторның субъектив карашы аша дөньяның бер рәвеше ачыла.

Т. Миңнуллин «Дивана» (2006) драмасын язуга шактый озак килә. Үзенең истәлегеннән күренгәнчә, башта Ленин һәм аның татарларга мөнәсәбәте турында пьеса язарга уйлый, әмма язылмый кала. Уй-фикерләрен бары хикәя итеп чыгара. Җәмгыятьтәге үзгәрешләргә нисбәтле, кемнәрнеңдер патша Россиясен идеаллаштырырга омтылуын кабул итми. Драматург фикеренчә, инкыйлаб котылгысыз була, ул Россияне таркалудан коткарып кала. Яңа Ленинны күрсәтүне максат иткән пьесаның нигезенә: *«Дивана – бөтен кешелек дөньясын бәхетле итәргә алынган кеше»*[1], – дигән фикер салынуын билгели ул. Әдип фикеренчә, Ленин идеяләре һәм ул башкарган эшләрнең бер өлешендә уңай якны да күрми мөмкин түгел: *«Таныйбызмы, танымыйбызмы, безне самодержавие дип аталган албасты астыннан коммунизм тәгълиматына корылган халык тигезлеге идеясе тартып алды»*[2]. Яңа гасыр башында илдәге иҗтимагый-сәяси тормышны кабул итми драматург. *«Бөтен кешелек дөньясын бәхетле итәргә теләү идеясе утопия, диваналык булса да яшәячәк. Бер халык та бу җирдә икенчесеннән ким түгел, берсен күтәреп, икенчесен бетерү – әшәкелек дип әйтүчеләр бар һәм булачак. Шулай дип әйтүчеләрне дивана дип атаучылар да аз түгел. Менә нинди уйлар пьеса язарга мәҗбүр итте мине»*[3], – дип яза ул.

[1] *Миңнуллин Т.* Дивана // Мәдәни җомга. – 2008. – 28 февраль.
[2] Шунда ук.
[3] Шунда ук.

Пьесада ике мәсьәлә калку куелган. Берсе – гармониягә нигезләнгән дөнья кору. Кешелек җәмгыятендә андый яшәешкә омтылу хыял буларак һәрвакыт булган. Әлеге теләк бүгенге тормыш шартлары белән дә аңлатыла. Икенче мәсьәлә җанлы һәм җансыз табигать дөньясы, аның уртасындагы авыл белән бәйле. Драматургның соңгы еллар иҗатында урын алган бер үзенчәлек монда да чагылыш таба: ул кешенең сафлыгын-чисталыгын да, гадилек-гадәтилеген дә авыл белән бәйләп карый. Автор әлеге әсәрдә төзегән яшәеш моделенең үзәгендә дә авыл тора. Ул, әдәби мотив буларак, бинар позициядә «цивилизациягә» каршы куела. «Цивилизация» заман эшмәкәре, тупас Ким образында чагылса, «табигать» кочагындагы авыл беркатлы, самими Айсылу образында урын алып, әсәрдә аларның каршылыгы бирелә. Ике бертуган арасындагы каршылык, вакыйгалар барышында кешелек дөньясындагы кыйммәтләр өчен тартыш төсен ала. «Бу – замана кешесенең рухи дөньясы белән матдилекнең бергә-бер көрәше. Бер карасаң, базар икътисады шартларында һәркемнең үзенә симезрәк, тәмлерәк калҗаны эләктереп калырга тырышуын аклап та була кебек – кешедән ким яшисе килми бит. Ә икенче якта – яхшылыкка һәм гаделлеккә, мәхәббәткә balaларча самимилек белән ышану, һәркемне тигез итеп күрәсе килү теләге...»[1] Әсәр геройлары «бер генә дә нормаль кеше» булмаган шәһәрне кабул итмиләр. Авыл үзенең табигате белән дә кешене дәвалау көченә ия. Кешенең табигать белән гармониядә яшәү теләге мәхәббәт хисе белән кушылып китә.

Пьесадагы мифопоэтик эчтәлек аеруча тулы мотивларда ачыла. Аның берсе фәлсәфи һәм психологик планда чагылган ялгызлык мотивы белән бәйле. Драманың төп герое Вил (Владимир Ильич Ленин исеменнән ясалган һәм совет чорында тудырылган миф чагылышы булып тора) шәһәр шартларында үз-үзен тапмаудан, гадел җәмгыять турындагы идеяләрен тормышка ашыру мөмкинлеге булмаудан тилмереп яши, хәтта авыру – дивана хәленә килә. Ул авылда да ялгыз, үз китаплары (Ленин томнары), үз дөньясы белән яши. Ә менә мәхәббәт ке-

[1] *Габәши-Салихова А.* Иҗатында – ил гаме // *Миңнуллин Т.* Пьесалар / кереш сүз авт. А. Габәши-Салихова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 13.

шенең рухи дөньясын ачуга һәм шуның белән психологик халәтен үзгәртүгә сәләтле көч буларак чагыла. Авыл кызы Айсылуга булган ярату хисе Вилнең авыруын җиңә. Кызганыч, шәһәргә киткәч, ул тагын ялгызлыкта кала һәм, авырып, психбольницага эләгә. Спектакльгә язган бәяләмәсендә М. Галиуллина бертуган Ким һәм Вил образларын башкача кабул итүен билгели. «Ким алдап-йолдап, талап хакимияткә килгәннәрне гәүдәләндерсә, – дип яза ул, – Вил, кимнәргә оппозиционер буларак, көч-җегәрен көннән-көн югалта барган интеллигенцияне чагылдыра кебек»[1]. Т. Миңнуллинның герое кыргый капитал шартларында адашкан, шуннан чыгу юлын таба алмыйча дивана хәлендә калган образ буларак, «югалган буын»ның тагын бер тибын тәшкил итә. Шул рәвешле, бөтен әсәрне иңләп үткән сызлану фәлсәфәсе автор караш-фикерләрен конкрет тарихилыктан гомуми, ягъни универсаль яссылыкта карауга, бәяләүгә китерә.

## 3.4. Драматургның сурәтле дөньясында яшәеш кыйммәтләре

Хәзерге татар драматургиясе төрле планда әдәби-эстетик эзләнүләр алып бара. Драматурглар, алдагы чорларның иң уңышлы традицияләренә таянган хәлдә, тормыш-яшәешне бөтен тулылыгында чагылдыруның яңадан-яңа юлларын, алым-чараларын эзлиләр. Сәхнә әдәбияты шартлылыкка, метафора булып килгән күренешләргә, кешенең чиктәш халәтен чагылдыруга, психологизмның «шизоанализ», «җан хәрәкәте» кебек алымнарына бик теләп мөрәҗәгать итә һәм шулар аша чорның үзенчәлекле образын тудырырга омтыла. Туфан Миңнуллин да үзенең пьесалары аша яшәешнең гаять актуаль мәсьәләләре турында уйлана, борчыла, укучы-тамашачысы белән диалог кора. Гыйбрәтле вакыйга-күренешләр, үзенчәлекле геройлар аша яшәешнең яңа моделен тәкъдим итә. Билгеле булганча, язучы әйләнә-тирә яшәешне кеше тормышы белән тыгыз бәйлелектә сурәтли. Сурәтләү объекты буларак алынган шәхес үзенең дөньяга карашы, яшәеш кыйммәтләре, яклаган идеаллары белән ачыла. Аның эш-гамәле аеруча үзен яшәгән чор һәм милли сый-

[1] *Галиуллина М.* «Дивана» ни сөйли? // Мәдәни җомга. – 2007. – 14 дек.

фатлары белән билгеләнә, бәяләнә. Шул рәвешле авторның субъектив карашы аша дөньяның бер рәвеше ачыла. Д. Заһидуллина билгеләп үткәнчә, «әдәби әсәрнең төзелеш һәм эчтәлек тукымасына үтеп кергән дөнья моделе текстны милли мәдәният, иҗтимагый фикер продукциясенә әйләндерә, аның чор һәм милли әдәби процесс белән бәйләнешен ача»[1].

Т. Миңнуллин иҗатының соңгы елларында басылып чыккан яисә төрле сәхнәләрдә куелган «Аерылабыз – хуш инде» (2005), «Алты кызга бер кияү» (2005), «Гашыйк буласым килә» (2005), «Мулла» (2006), «Дивана» (2006), «Син мине күрәсеңме» (2009), «Нәзер» (2010) пьесалары тема-проблемалары, яшәеш мәсьәләләренең милли һәм гомумкешелек кыйммәтләре яссылыгында чагылыш табуы, һәрберсендә үзенчәлекле сыйфатлары белән аерылып торган замандашыбызның характерын иҗат итүе һәм әдип кулланган сурәт чараларының, формаалымнарының төрлелеге, байлыгы, еш кына кабатланмаслыгы белән аерылып тора.

Т. Миңнуллин пьесаларында хәзерге авыл тормышы бөтен каршылыгында ачылып, татар халкының күпгасырлык яшәү рәвеше, гадәт-йолалары, менталь сыйфатлары югала бару өчен әрнү, тирән борчылу чагылыш таба. Тормышка килеп кергән үзгәрешләр, дөньяның классик картинасы үзгәрү, ягъни чынбарлыкның хаос, буталыш, өметсезлек аша кабул ителүе татар авылының үзенчәлекле моделен сурәтләүгә китерә. Татар авылы әдәбиятыбызда һәрвакыт игътибар үзәгендә булды, чөнки гасырлар дәвамында халкыбыз нәкъ менә авыл җирлегендә күпләп яшәгән, үзенә хас яшәү рәвешен корган, милли сыйфатбилгеләрен яклаган һәм саклаган. Шуңа да күпчелек әсәрләрдә һәм башка сәнгать төрләрендә авыл татарның асылын, димәк ки, телен, гореф-гадәтләрен, традицияләрен саклаучы сакраль урын буларак чагыла. Монда һәр кеше кечкенәдән татар рухында, татар моңында тәрбияләнеп үсә. Драматургның «Бәхетле кияү» (1967), «Нигез ташлары» (1968), «Кырларым-тугайларым»

[1] *Загидуллина Д.Ф.* Символические модели мира в творчестве Дардменда // Диалог культур: русско-татарские связи. – Москва-Ярославль: Ремдер, 2005. – С. 98.

(1980), Без бит авыл малае» (1983), «Йөрәк янар өчен бирелгән» (1970), «Уйланыр чак» (1972), «Дилүфрүзгә дүрт кияү», «Иргетләр», «Әлдермештән Әлмәндәр» (1975) кебек әсәрләрендә татар авылы «тормыш бишеге» буларак сурәтләнә. *«Кая гына барсам да, кайда кем булып кына эшләсәм дә, үземне һәрвакыт авыл кешесе итеп хис итәм*, – дип яза Т. Миңнуллин «Хуш, авылым?» исемле публицистик мәкаләсендә. – *Бик күп нәрсәләргә, хәтта илдәге сәясәткә дә беренче чиратта авыл кешесе күзлегеннән карыйм. Вакыты-вакыты белән мин аны идеаллаштырам»*[1]. Татар драматургиясенең күпсанлы әсәрләрендә ул нәкъ менә әлеге сыйфатында урын ала (Н. Исәнбәт, Х. Вахит, Ю. Әминев, Т. Миңнуллин, И. Юзеев, А. Гыйләҗев, Р. Батулла һ.б. иҗаты моңа мисал булып тора).

XX гасыр ахырында татар авылы җитди үзгәрешләр кичерә. Базар мөнәсәбәтләренә бәйле халыкның бер өлеше үзен яңа шартларда таба алмый аптырый һәм бу эчүчелек артуга китерә, икенчеләре исә матди байлыкка кызыгып, рухи кыйммәтләрне санга сукмый башлый. Шул рәвешле авыл кешесе үзе иҗат иткән кануннардан читләшә. Т. Миңнуллинның ике гасыр чигендә язылган «Илгизәр плюс Вера» (1990), «Җанкисәккәем» (1995), «Шулай булды шул» (2002), «Дивана» (2006), «Мулла» (2006) кебек пьесаларында әлеге борчулы хәлләр сурәтләнә. Драматург яшәешнең гаять актуаль мәсьәләләре турында уйлана, борчыла, укучы-тамашачысы белән диалог кора. Гыйбрәтле вакыйга-күренешләр, үзенчәлекле геройлар аша яшәешнең яңа моделен тәкъдим итә. Сурәтләү объекты буларак алынган шәхес үзенең дөньяга карашы, яшәеш кыйммәтләре, яклаган идеаллары, милли сыйфатлары белән ачыла.

Татар авылы бурыч-вазифаларының бер өлешен үти алмый икән, моның сәбәпләре нәрсәдә? Татар авылын үз асылында ничек саклап калырга? Әлеге һәм башка сорауларга Т. Миңнуллин «Мулла» драмасында җавап эзли. Дөресрәге, ул татар авылының түбәнгә тәгәрәве өчен тирәнтен борчыла, әсәр геройларының берсе Вәлиәхмәт әйткәнчә, *«авыл хуҗасы – азгынлык, бо-*

[1] *Миңнуллин Т.* Хуш, авылым? // *Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б. 165.

*зыклык, имансызлык»* булуына әрни һәм бу хәлдән котылу, чыгу юлын, ягъни «авылны дин ярдәмендә яшәтеп, иманга кайтарып буламы?» дигән сорауга җавап эзли.

Ислам дине кыйммәтләре кешелекнең гармониядә – матур, бәхетле, үз-үзе белән канәгать булып яшәвенә хезмәт итә. Р. Фәхретдин үзенең «Гаилә» дигән хезмәтендә болай дип яза: «Адәм улының бәхете дин белән дөньяга бәйләнгән булып, боларны бер-берсеннән аеру рөхсәт ителми, хәтта мөмкин дә булмас. Гәүдә – дөньяда торганда ашау-эчүгә мохтаҗ булганы кебек, рух та дингә мохтаҗ булыр. Диннән башка рухның ләззәте вә рәхәте булмас»[1]. Шуңа да изге Коръәндә кешелекнең чын гамәлләре яклана һәм саклана.

922 елда ислам дине кабул ителгәннән соң, татар әдәбиятының үсеш-үзгәреше Коръән тәгълиматыннан аерылгысыз булып, бу турыда бай фәнни әдәбият тупланды инде. Совет чоры әдәбиятында күпгасырлык традицияләрне бозып, әдәбиятта дини яшәештән читләшү, аны кире кагу күзәтелсә дә, ул барыбер сакланды. Әдипләребез эзоп теле белән, читләтеп, текстның икенче катламында булса да әлеге дини-әхлакый кыйммәтләрне саклдылар һәм мөмкин кадәр укучыга җиткерделәр. Ә инде XX гасыр ахырында, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле, дини тәгълимат кайтып, Октябрьгә кадәрге традицияләр кабат яңара башлады. Хәзерге сәхнә әдәбиятындагы дини-әхлакый һәм фәлсәфи кыйммәтләр, нигездә, түбәндәге мотивларда чагыла: «яңача яшәү омтылышы һәм Коръән тәгълиматы; кеше күңеленең ерак почмагына яшеренгән хис-кичерешләр һәм мәңгелек турында фәлсәфи уйланулар; дөньяви тормыш рәхәтлекләре һәм мәңгелек юлындагы Сират күпере; дини-мифологик традицияләр; пәйгамбәрләр образы һәм изгеләр турында риватьләр һ.б.»[2]

---

[1] *Фәхретдин Р.* Гаилә // Идел. – 2003. – № 2. – Б. 62.

[2] *Закирҗанов Ә.М.* Хәзерге татар драматургиясендә дини һәм фәлсәфи фикер синтезы // Роль Ислама в стабилизации социальных процессов: сборник статей и тезисов II Международной научно-практической конференции, 18 марта 2017 г. / под ред. Р.Ш. Шайхевалиева. – Набережные Челны: Ак мечеть, 2017. – С. 33.

XX гасыр ахырында Т. Миңнуллин дингә караш-мөнәсәбәтен ачык белдерә. Гомере буе кеше күңелен, рухи дөньясын әдәби чараларда ачып, чагылдырып килгән әдип, болай дип яза: *«Җанга таяныч кирәк. Кешегә бит корсак кына бирелмәгән, җан да бирелгән. (...) Кешенең үзе белән үзе генә, вөҗданы белән икәү генә калган чаклары еш була. Алла юк, дип кычкырганнар да үлгән чакта «Алла!» дип үләләр»*[1]. Шуңа да драматургның ике гасыр чигендә язылган пьесаларында яшәешнең катлаулы мәсьәләләре ислам дине өйрәтүләре белән бәйләп карала. Моңа ачыклык кертеп, икенче бер мәкаләсендә: *«Минем өчен изге китап – Коръән Кәрим. Мин үземне мөселман традицияләрендә тәрбияләнгән, хак мөселман дип саныйм, һәм үз баламның, һәм оныкларымның да шул традицияне дәвам иттерүләрен телим»*[2], – дип яза. Кайбер әсәрләрендә ул вакыйга-күренешләргә дини өйрәтмәләрдән чыгып якын килсә, икенчеләрендә яшәешнең әхлакый, фәлсәфи кыймматләре яклanышы рәвешендә бирелә.

«Мулла» драмасы, татар һәм башкорт театрларында уңыш белән куелып, киң җәмәгатьчелекнең югары бәясен ала. Шул ук вакытта әдәби әсәр буларак һәм сәхнәдә уйналуына бәйле режиссерлар шәрехләве фикер төрлелеге китереп чыгара. Әлеге пьесага М. Гафури исемендәге башкорт дәүләт академия театры һәм Әтнә, Минзәлә, шулай ук Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрлары мөрәҗәгать итә. Камал театры коллективы тәкъдим иткән концепциянең җитди бәхәсләргә китерүе спектакль уңаеннан язылган рецензияләрдә чагылыш таба. Ч. Фәрхетдинова пьесага зур бәя биреп, Камал театры уенында заман проблемаларының бөтен кырыслыгында ачылуын, Әсфәндиярне көрәшче итеп күрсәтүне ассызыклап үтә[3]. Г. Җәлилова спектакльгә бәясендә авторның да, режиссерның да төп сораугa

[1] *Миңнуллин Т.* Туган тел нигә кирәк? // *Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – Б. 97.

[2] *Миңнуллин Т.* Кыйбла кайсы якта? // *Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – Б. 273.

[3] *Фәрхетдинова Ч.* Хакыйкатьне чагылдыручы спектакль // Мәдәни җомга. – 2012. – 16 ноябрь.

җавапны тамашачы өлешенә калдыруын билгели. «Әсфәндиярне “ачасы килде”. Бик килде! Әллә шулай уйланылган режиссер алымы иде ул, әллә артык күпкә киткән азсүзлелек булдымы – без мулланың эчке дөньясын күрә алмадык. Ул җиде бик астында калды»[1], – дип, тәнкыйть сүзе дә җиткерә. Г. Тарханова спектакль уңае белән язылган мәкаләсендә Т. Миңнуллин текстының сәхнәдә үзгәртелүен кабул итми. Ул шуннан гыйбарәт: драматург текстында Әсфәндияр яралана, әмма тиздән сырхауханәдән чыгып, үз вазифасына керешә. Режиссер Ф. Бикчәнтәев куйган спектакльдә исә Әсфәндияр атып үтерелә, ахырда аның укучыларының берсе мәчеткә кереп азан әйтә. Рецензент болай дип яза: «Режиссер пьесаның финалын үзгәрткән булып чыкты. Ул мулланы «үтергән». Бу, үз чиратында, әсәрнең төп тукымасына салынган идеяне дә үзгәртүгә китергән. Нәтиҗәдә, яшь мулла Әсфәндияр көчсез шәхескә әйләндерелеп, җиңелүгә дучар ителгән. Аның үлеме авылның тернәкләнүенә ышанычны да юк итә»[2]. М. Хәбетдинова фикеренчә, Минзәлә татар дәүләт драма театры куйган спектакльдә татар авылы ташландык хәлдә күрсәтелә. Автор тормышны бөтен каршылыгында сурәтләве белән шул шартларда яшәүче маргиналь геройларны алга чыгара. Т. Миңнуллин үзе өчен яңа булган «яңа драма» технологиясен үзләштерә[3]. Мәкалә авторы татар авылында үзгәрешләргә омтылыш күрми, пьесада туган җирне зурлау да урын алмаган. Мулла Әсфандияр әлеге авылны яктылыкка илтү вазифасын үтәп бетерә алмый дип саный тәнкыйтьче. Шуңа да спектакль финалы ачык калдырылган, геройларны да уңай һәм тискәрегә бүлү кыен, алар барысы да бер тапкыр инде ялгышкан, ата-баба өчен дин генә булмыйча, яшәү рәвеше дә булган исламнан аерылган[4]. Әлеге фикерләрнең спектакльләрне сәхнәгә куючы

---

[1] *Җәлилова Г.* Ун муллага ялынганчы, бер Алладан сора... // Шәһри Казан. – 2012. – 15 гыйнвар.

[2] *Тарханова Г.* Мулла «персона нон грата» түгел // Мәдәни җомга. – 2013. – 18 гыйнвар.

[3] *Хабутдинова М.М.* Талантом обретенное бессмертие: итоги театральной декады в честь 80-летия Туфана Миннуллина // Татарика. – 2020. – 2 (12). – С. 99.

[4] Шунда ук. – Б. 100–101.

режиссерлар концепциясе белән бәйле булуын искәртеп, аларның бәхәскә урын калдыруын әйтергә кирәк.

Белгәнебезчә, татарның күпгасырлык тарихы гаять каршылыклы булып, анда ил-халыкка фаҗига, афәт алып килгән чор-дәверләр күбрәк урын алып тора. XVI гасыр уртасында рус дәүләте тарафыннан яулап алынганнан соң, татар халкы кичергән михнәт-газаплар берни белән дә чагыштырырлык түгел. Иң яхшы җирләрне тартып алу, олы шәһәрләрдән куу, күпләп юк итү, әсирлеккә алып китү, көчләп чукындыру һ.б. җан әрнеткеч күренешләр татар халкын бик нык тарката, көчсезләндерә. Әнә шундый шартларда татарларны этнос буларак ислам дине саклап кала. Халык диндә өмет-ышаныч, яклау-саклау таба. Шуңа да татарның яшәү рәвеше, йола-гадәтләре, күпсанлы традицияләре дин белән гаять тыгыз бәйле. Совет чоры идеологиясе дини яшәешне юкка чыгарырга омтылса да, ул моңа тулысынча ирешә алмый. Ә инде XX гасырның 90 нчы елларында татар җәмгыятендә дини башлангыч мөһим урын ала. Әмма ул еш кына коры сүзгә, тышкы формага кайтып кала. Шуның бер чагылышы буларак, һәр авылда диярлек мәчетләр салына, әмма әсәр герое эшмәкәр Самат әйткәнчә, *«мулла бар, ләкин тәртип юк»*.

«Мулла» драмасы универсаль мифологик сюжет һәм мотивларга нигезләнүе белән игътибарны җәлеп итә. Әсәр сюжетына шәһәрдә мәдрәсә тәмамлаган Әсфәндияр исемле егетнең авылга мулла булып хезмәткә кайтуы һәм халыкны иманга китерү юлында күп кыенлыкларга дучар булу вакыйгасы салынган. Текстта чынбарлык хәлләрен сурәтләү үзәктә торса да, автор аларны мифологик күзаллаулар белән тыгыз бәйлелектә ике планда ача. Берсе – Әсфәндияр язмышының Мөхәммәд пәйгамбәр тормышы белән охшашлыгына бәйле булса, икенчесе, геройның кыенлыклар аша үтеп үзен табуы, шулай ук герой эш-гамәлләренең традицион көчеш йолаларына туры килүе белән аңлатыла. Әсәрдә ул җәмгыятьтәге, аның бер кисәге булган татар авылындагы дөрес булмаган яшәешне үтеп чыгу, дөресрәге ике төрле яшәеш каршылыгын чишүгә хезмәт итә. Т. Миңнуллин милли мифның бер вариантын тәкъдим итә. Төп

эчтәлегендә ул «үткәнне үзләштерү»гә кайтып кала. Киң планда текст поэтикасында дини миф белән бәйле интертекстуальлек урын алган. Автор камиллек үрнәге булган Мөхәммәд пәйгамбәр мифологемасына нигезләнеп, аның сабырлык, максатчанлык кебек сыйфатларын эчтәлекнең нигез элементлары итеп ала һәм төп герой Әсфәндиярне шулар аша сыный. Билгеле булганча, Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышы гыйбрәтләр белән тулы: ул туганчы ук әтисе сәүдә эше белән киткән җирендә үлеп кала, берничә елдан әнисе дә вафат булып, малай әбисе һәм бабасы кулында тәрбияләнә. Халыкны ислам диненә – иманга китерү юлында күп авырлыклар һәм кыенлыклар күрә, ә инде Бәдер шәһәре янында дәһриләр һәм ышанмаучылар белән сугышта яралана. Әмма ул Аллаһы Тәгалә күрсәткән хак юлдан чыкмыйча, төп максатына бара[1].

Драманың беренче күренешләрендә үк җитди каршылык төенләнә. Ул татар авылы кешеләренең рухи ныклыгы йомшару, әдәпсезлек күренешләре көчәю белән бәйле. Вакыйгалар барышында Т. Миңнуллин моның сәбәпләрен ачуны да алга куя. Аның берсе – төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләрнең үз вазифасын үтәмәве. Пьесада җирле үзидарә җитәкчесе Лемур һәм участок милиционеры Әмир һәрнәрсәгә битараф, күбрәк үз мәнфәгатьләрен кайгыртучы, җитәкчеләр каршында яхшатлы булырга тырышучы кешеләр буларак ачыла. Автор аларга бәяне, беренче чиратта, үз-үзләреннән бирдерә. Әгәр Лемурның чит хатыннар янына йөрүен әйтеп, аның әхлакый йөзен сиздерсә, *«миңа форманы салырга ярамый»* диюче Әмирнең тишек носки детале, гомумән, җәмәгатьчелек тәртибен саклаучыларга бәя булып тора. Икенче сәбәп итеп автор авыл кешеләренең җирдән аерылуын күрсәтә. Вәлиәхмәтнең «үз җирен сатып эчкән мужикта нинди власть» диюе белән килешми мөмкин түгел. Ә инде элекке мулла Сәләхетдиннең *«шәһәр кирәк булгач, төзиләр бит. Авыл белән нишлисең. Җир сукалап интеккәнче, сатасың да аласың ризыкны Америкадан. Монда бер тавык боты ашар өчен ел буе интегәсең. Шәһәрдә саттың да алдың Америка ботын.*

[1] Ислам: Энциклопедический словарь. – М.: Наука. Главная редакция восточной литературы, 1991. – С. 178–180.

*Рәхәтләнеп кимер...»* диюендә ил-дәүләт алып барган сәясәттән ризасызлык та чагыла. Өченче сәбәп буларак авыл кешеләренең ата-бабадан килгән гореф-гадәтләрдән читләшүе, үзара таләпчәнлекнең, бер-берең өчен җавап бирүнең югалуы күрсәтелә. Әнә 17 яшьлек кыз аракы эчә башлаган, авыл мулласы үзе дә хәмердән баш тартмый, күрше авылдагы бер хатын фахишәгә әйләнгән. Авыл егетләре күрше авылга кияүгә чыгучы кызларны үзләре белән йокларга мәҗбүр итә икән. Әсфәндиярнең ике кешегә биргән бәясендә авылның бөтен барлыгы ачыла кебек: *«хайван хәленә төшкән Бәдретдин, ерткыч җанварга әверелгән Вәлиәхмәт абыйлар...»* «Пьеса үзенең үткенлеге, катгый-кырыс дөреслеге, замана вазгыятен аяусыз-рәхимсез сурәтләп бирүе белән һушларны ала, – дип яза А. Габәши-Салихова. – Монда без күрергә күнеккән татар сентиментальлегенең эзе дә юк, мәгәр шыксыз, куркыныч чынбарлыкны фаш итү аша дөньяга яңа караш туа: хәтәрлекнең күзенә курыкмыйча туры карап җиңәргә өйрәнү ул»[1].

Әсфәндияр ятимлектә, әбисе-бабасы кулында үскән. Яшь вакытта закон бозып, яшүсмерләр колониясенә эләгә һәм шунда бер мулла ярдәмендә Аллаһы Тәгалә юлына керә. Яшь муллага авылда күптөрле авырлыклар аша үтәргә туры килә. Беренче күренешләрдә үзенең вазифаларын да төгәл аңлап бетермәгән егет булып күзаллана. Саматның «Авыл хуҗасы син» дигәнен куркып кабул итә, сүзнең авыл кешеләре арасында рухи юлбашчы, әйдәп баручы, юл күрсәтүче булу турында икәнен аңлап бетерми. Вакыйгалар барышында Әсфәндияргә берничә сынау аша үтәргә туры килә. Шул юлда ул үзенең эчке каршылыгыннан котылып, үз-үзен ачык аңлауга, табуга килә.

Т. Миңнуллин яшь мулланы төрле катлам кешеләр белән очраштыра, каршылыкка кертә, нәтиҗә буларак соңгыларының эш-гамәленә бәя бирдерә. Кеше җаны өчен барган тартышта төп каршылыкны сиздереп, беренче күренештә үк вакыйгаларга Вәлиәхмәт килеп керә. Кайчандыр авыл мулласы булган бабасын Себер якларына сөргәннәр икән. Ул шуның өчен авыл ке-

[1] *Габәши-Салихова А.* Иҗатында – ил гаме // *Миңнуллин Т.* Пьесалар / кереш сүз авт. А.Габәши-Салихова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 12.

шеләреннән үч алырга, үзе әйткәнчә, «ясин» чыгарга» кайткан. Аның фикере шактый дәлилле: әнә авылда эчкечелек, азгынлык хөкем сөрә, власть кешеләре берни эшләми, күрше авылда бер хатын фахишәлек итә, һәркайда урлашу... Үзенә ул мондый бәя бирә: *«Юк ул миндә җан. Җансыз бәндә мин. Җансыз җан иясе. Җан дигән нәрсә күптән инде адәм балаларын ташлап качты. Кешеләр Газраилнең килгәнен көтмичә үк җан бирәләр. Җаннарын саталар»*. Аң-белем таратып, Алла тәгълиматын җиткереп, аңлатып яшәгән бабасын ни өчен авылдан сөрүләрен аңлый алмый җәфалана ул. Акыллы кеше буларак, гомере буе үч белән, каргау белән яшәү мөмкин түгелен дә аңлый. Әсфәндиярнең *«Алып ташлагыз күңелегездән үчне. Үч саклау кешене харап итә. Бабагызны куода, мәчет манарасын кисүдә бүгенге авыл халкының гаебе юк. Кешеләр язмышы белән хакимнәр уйный»* дигән сүзләре аның күңеленә, аңына барып җитә. Яшь мулла нәкъ менә сабырлыгы, рухи ныклыгы, кирәк урында физик көче белән Вәлиәхмәткә сабак бирә, бу тормышта иманга килеп, халыкның чын яшәү рәвешен торгызудан башка юл булмавын аңлатуга ирешә. Вәлиәхмәт үч хисеннән арынып җитә алмаса да, Әсфәндиярнең хаклы булуын таный. Соңгы күренештә кызларны яклап чыгуы, Әсфәндияргә киңәшкә килүе, хәтта аны китмәскә чакыруы – Вәлиәхмәт күңелендә барган уңай үзгәрешләр турында сөйли. Әйе, аңа үз-үзен табу җиңел булмас, әмма башлангычы бар.

Әсфәндияр алдында торган тагын бер сынау авыл егетләре белән каршылыгында ачыла. Кызганыч ки, әхлакый идеалларның юкка чыгуы авыл яшьләре арасында әдәпсезлекнең киң таралуына китергән. Алар белән төрмәдә утырып кайткан Эльбрус җитәкчелек итә. Физик көчкә, төркем психологиясенә нигезләнеп эш итүче бу егет Әсфәндияр йөзендә көтмәгән каршылыкка очрый.Үз дигәнен эшли алмагач, ахырда, көчсезлеген танырга теләмичә, кулына утлы корал ала. Әмма аның эш-гамәлләре авыл кешеләрендә бары нәфрәт кенә уята. Иң мөһиме, Эльбрус хәзер яшьләр арасында да, авыл кешеләрендә дә яклау тапмый.

Яшь мулланың өченче сыналуы авыл кешеләре күңелендә ышаныч тудырып, аларны иманга китерү белән бәйле. Безнең

каршыда карт мулла Сәлахетдин, авыл хатыны Мөслимә, үзидарә җитәкчесе Лемур, участок милиционеры Әмир образлары һәрберсе үз йөзе, характеры белән ачыла. Алар белән очрашу-мөнәсәбәттә Әсфәндияр үзе ышанган идеалларны яклап чыга. Боларга егетнең Налимә белән мәхәббәтенә бәйле каршылыклар килеп кушыла. Әсфәндияр әдәпле сүзгә, ихлас вәгазьгә, кешелекле мөнәсәбәткә сусаган кешеләр күңеленә иман орлыгы салуга ирешә. Иң мөһиме, ул яшь буын малайлар-кызлар белән уртак тел таба, аларны Алла йортына китерә. Әсәр ахырында Әсфәндияр шәкерте Илдарның мәчет манарасыннан азан әйтүе – мулла карашларының җиңеп чыгуына, авыл кешеләренең иманлы юлга чыгуына ишарә итә. Хәзер инде Әсфәндиярнең авыл кешеләре белән уртак тел табып хезмәт итүенә дә шик калмый. Моңарчы адашкан халәттә яшәгән кешеләргә Әсфәндиярнең иманлы сүзе күбрәк тәэсир итә, киләчәккә өмет хисе туа. Т. Миңнуллин авылның киләчәген иманлы яшәеш белән бәйләп карый. Әсфәндиярнең түбәндәге уй-фикерләре, автор позициясе буларак, әсәрнең төп идеясен чагылдыра һәм укучы-тамашачыга мөрәҗәгать булып яңгырый: *«Аллам! Адәм балаларын рәхмәтеңнән ташлама! Күгәргән күңелләрен чистарт! Адашкан җаннарга туры юл күрсәт! Иманын югалтканнарга иманын табарга ярдәм ит! Күңелләренә миһербан, мәрхәмәт иңдер! Кылган гөнаһларын ярлыка, уй-фикерләрен, кыласы ниятләрен изге ит! Йа Аллам, йа Хода, йа Тәңрем!..»* Шуңа да халыкның имансызлыкны кире кагуында, әсәр геройларының Әсфәндиярне якларга һәм сакларга алынуында драматургның әхлакый һәм эстетик идеалы чагыла.

Шулай итеп, Т. Миңнуллин драмада дини мифологемадан уңышлы файдаланып, геройның авырлыклар аша үз-үзен табуын һәм шуның нәтиҗәсендә бөтенлекле шәхес булып формалашып җитүен чагылдыра. Шуның белән автор татар авылының яңарышын милли яшәү рәвешен торгызу, дингә нигезләнү белән бәйләп карый һәм укучы-тамашачы күңелендә дә өмет хисе уята.

* * *

Т. Миңнуллинның «Нәзер» трагикомедиясе гаять гыйбрәтле вакыйгага нигезләнүе, халыкчан рухы, милли яшәеш чагылышы белән җәлеп итә. Сюжетына салынган вакыйга түбәндәгедән гыйбарәт: бер үк көнне дөньяга килгән күрше егетләре Хисмәтулла белән Хикмәтулла бер үк көнне өйләнешәләр һәм тиздән сугышка китәләр. Аяусыз сугыш афәте, үлем куркынычы егетләрне бер караганда сәер булып тоелган адымга этәрә. Алар нәзер әйтәләр: *«Әгәр дә икебез дә исән-сау кайтсак, хатыннарны алышып торабыз. (...) Бөтенләйгә түгел, бер атнага».* Хикмәтулланың багучы әбисе әйткән икән: *«Әгәр дә нәзер әйтсәң, нәзереңне үтәмичә гомерең өзелми».* Бу коточкыч мәхшәрдән исән-имин чыгу теләге шундый көчле, Хикмәтулланың нәзергә бик тә ышанасы килә: *«Бәлки безнең дә гомер өзелмәс. Бәлки исән-сау авылга кайтырбыз».* Егетләр исән кала, ләкин аларны гыйбрәтләр тулы ачы да, татлы да язмыш көтә...

Т. Миңнуллин байтак әсәрләрендә урын алган әдәби формага мөрәҗәгать итә: бер катнашучы, булачак вакыйгаларга ишарә итеп, кайберләренә аңлатмалар биреп бара. Бу исә хәлкүренешләрнең тормышчанлыгын арттыра, шуңа да тамашачы аларны чынбарлык буларак кабул итә, геройлар язмышы өчен борчылып утыра.

Сугыштан исән-сау кайткан Хисмәтулла шактый үзгәргән, олыгайган, тыныч, сугыш хәлләре аның ярсуларын да киметкән. Әмма авылчанлыгы үзе белән, әнә бит уйлап та тормыйча Хикмәтулла белән нәзер әйтешүен, хәтта аның мәгънәсен үк хатынына җиткерә. Ә менә хатыны Маһирә исә таш астыннан чыккан хатын-кыз булып алга килеп баса. Аның һәр хәрәкәтеннән, күз карашыннан дәрт бөркелә, ирен ярату, аны иркәләү теләге чагыла. Яшь вакытта *«егетләр төбәлеп карaса да, кытыгым килә иде»* дип үзенең оялчанлыгын искә алган хатын, хәзер инде «*дүрт ел буе пыскып торган учагым кинәт кабынды бит»* дип ире кочагына ава. Хисмәтулла белән күрешергә, ире турында сорашырга дип алар янына Заһирә керү күренеше ут һәм су бәрелешен хәтерләтә. Маһирә ирен сагынудан, күрешү шатлыгыннан «исереп» йөрсә, Заһирә исә сызлану, борчылу,

ирен сагынып көтү һәм бераз булса да өмет хисен саклау теләгеннән туган җан әрнүен баса алмый.

Сугыш беткәннән соң 10 ел үткәч, Хикмәтулланың кайтып төшүе белән вакыйгалар тизләнә, эчке конфликт арта. Ир башта дошман кулына эләгеп, немец концлагерьларында җафа чигә, сугыштан соң аны Магадан ягындагы алтын приискалары урнашкан лагерьга җибәрәләр. Хикмәтулла бик нык ябыгып, авыру хәлендә кайтып егыла. Ул яшәү ямен, гамен югалткан кеше буларак ачыла. Аның өзек-өзек репликалары артында совет системасына ачу, яшьлегенең әрәмгә үтүе өчен үкенү, югалткан сәламәтлегенә әрнү хисе бәреп чыга.

Шактый вакыт үтсә дә Хикмәтулла ныгып китә алмый, хатыны Заһирә исә һаман сула бара. Күршедәге Хисмәтулла да аяктан егыла. Шул вакытта Маһирә ирләрнең нәзерен искә төшерә. Барыш авылындагы юраучы да авыру сәбәбен әйтелгән нәзернең үтәлмәвендә күрә. Ирен яратучы, алты бала анасы Маһирә нәзерне үтәүне таләп итә һәм ирләр хатыннарын бер атнага алыштыра. Нәкъ менә шунда әсәрнең трагикомедиячел асылы ачыла. Бер яктан, ирләрне югалту куркынычы, ничек булса да (!) аларны терелтү теләге һәм, икенче якта, үз ireңне ризалык белән икенче хатын түшәгенә салу... Халыкта бит юкка кына «ир бирмәк, җан бирмәк» дигән гыйбарә яшәми. Шуның өстенә авылдашлар алдындагы оятын да күтәрәсе бар бит әле.

Заһирәнең Хисмәтуллага булган яшьлек хисләре яңара, үзен чын хатын-кыз итеп тоя, ашкын хисләрен тыя алмыйча ярата һәм яраттыра. Маһирә һәм Хикмәтулла очрашуы тагы да тетрәндергеч. Алар арасында якынлык, бер-берсенә тартылу бар, моны үзләре дә яшерми. Яшьлектәге хисләре уянып, Хикмәтулла күңелендәгеләрне әйтә: *«Ярата идем мин сине, Маһирә. Үлеп ярата идем. Әйтеп карадым, аңламадың. Хисмәтулладан бүтән берәүне дә күрми, ишетми идең. Ярата идем. Юлыгызга аркылы төшәргә дә уйлаган идем, Хисмәтулла да дустым иде шул».* Үзенең ачы язмышын сөйләгән ир нәкъ менә ярату хисенең, якын кешеләре белән очрашып аңлашу теләгенең үзенә көч-таяныч бирүен искәртә. Сәламәт ир кеше булмавын белгән хәлдә, җан көеге булып яшәмәс өчен, якыннарын калдырып чы-

гып киткән Хикмәтулланың фаҗигалы төстә вафат булуы хәбәр ителә. Аның фаҗигалы язмышы сугыш афәтенә, Сталин режимына, гаделсез җәмгыятькә ачыну-әрнү булып яңгырый.

Соңгы күренештә Заһирәнең балага узуы билгеле булгач, Маһирә мәсьәләне акыл белән чишә: *«Хисмәтулланы бүлешергә туры килер. Ачуланма, Заһирә, мин аны сиңа бөтенләйгә бирмим. Миңа кочаклап йокларга ир кирәк әле. Сиңа да кирәктер. Син ир рәхәтен күргән хатын түгел. Хисмәтулла, шөкер икебезгә дә җитә. Әнә утыра май ашаган мәче кебек яланып. Минем ачуны китерсә, сиңа куып кертермен. Кача-поса ындыр артлап йөрмәс. Капкаңны көпә-көндез ачып керер. Ярыймы шулай? Нигә җылыйсың? Җылама, мин җыламыйм бит әле. Әллә миңа җиңелме».* Әлеге гыйбрәтле вакыйганың бик күпләргә үз тормышына яңача карарга, яшәеш турында турында кат-кат уйланырга этәрүендә шик юк.

Гомумән, фаҗигалылык һәм көлкелелек күренешләре үрелеп барган вакыйгалар артында әхлакый һәм фәлсәфи кыйммәтләрнең яңа яссылыкта ачылуы белән пьеса төрле уй-фикерләр уята, бәхәсләргә китерә.

### 3.5. Балалар өчен язылган пьесалар

Мәдәни тормышта гаять әһәмиятле урын алып торган театр дөньясы белән танышлыкны кече яшьтән, мәктәп елларыннан башлауның кирәклеге һәркемгә яхшы аңлашыла. Әлеге танышлык, бер яктан, баланың театрга йөрүе белән бәйле булса, икенче яктан, спектакль куелышында бала үзе катнашу яисә иптәшләре уйнаган тамашаларны карау аша бара. Театр залында утырып караган спектакльләрдә яшь тамашачы әлеге олы һәм серле сәнгатьне ача. Шуңа да спектакль нигезенә салынган пьесаның эчтәлеге, вакыйга-күренешләрнең балага таныш һәм аңлаешлы булуы, психологик үзенчәлекләренә туры килүе, акыл сатмыйча гына кертелгән тәрбияви фикер-карашларның чагылышы һ.б. әһәмиятле урын алып тора. XX–XXI гасырлар чигендә балалар өчен пьесаларның шактый күп язылуын билгеләп үтәргә кирәк. Т. Миңнуллинның «Авыл эте Акбай», «Акбай һәм сарык малае», «Акбай нигә күңелсез?», «Интернет Акбай»,

«Гашыйк буласым килә», Р. Сәгъдинең «Гүзәл Аппаксылу», М. Гыйләҗевнең «Патша кәләше», «Кәвеш кигән песи», Р. Мингалимнең «Шүрәлеләр үч алмый», Х. Ибраһимның «Адашкан эт», Г. Каюмовның «Ак баба иле», Ш. Фәрхетдиновның «Алтын алма», «Әкият турында әкият», Х. Җәләйнең «Шәрә бүре», Р. Бохараевның «Тимер борчак», Р. Батулланың «Курчаклы уен», И. Зәйниевнең «Урман club», «Кәҗә, сарык һ.б.» һ.б. пьесалар күпсанлы театр залларында уңыш белән бара. Әлеге әсәрләр беренче чиратта тема-мотивлар төрлелеге белән җәлеп итә. Аларда өлкәннәргә хөрмәт, миһербанлылык, горурлык, үз шәхесеңне яклый белү, туган җиргә, телгә хөрмәт, мәктәп тормышы һ.б. мәсьәләләр төрле алым-формаларда чагылдырыла.

Ю. Сафиуллинның алдагы чорда язылган «Алмазбулат» пьеса-әкияте сәхнәдә иң күп уйналган әсәрләреннән санала. Әкияти сюжет ярдәмендә автор кешелек җәмгыятенең мәңгелек кыйммәтләре турындагы фикер-карашларын укучы-тамашачы алдына куя[1]. Вакыйгалар барышында алар милләт язмышы белән үрелеп, рухи ядкярләр, тел, милли сыйфатлар, гомумән, халык буларак яшәешебез турында җитди уйлануга китерә. Әсәрдә ирек, азатлык идеясе кешенең милли үзаңы уяну белән бәйләп карала. Ю. Сафиуллин татар милләтенә янаган куркынычны ачык сизә һәм аннан котылу юлын һәр кеше күңелендә милләтпәрвәрлек хисе уятуда күрә. Ә ул исә туган тел, туган җир, ата-ана кадере, рухи ядкярләргә, гореф-гадәт, йола һәм традицияләргә тугрылык белән бәйле.

Балалар драматургиясендә уңышлы эшләп килүче Ш. Фәрхетдинов «Әкият турында әкият» (2005) җыентыгындагы әсәрләренә балаларга таныш йорт хайваннары, урман җәнлекләре образларын кертә. Пьесалары нигезен тәшкил иткән Дуслык, Намус, Игелек төшенчәләре я көнкүреш вакыйгаларында, я серле-могҗизалы хәлләрдә ачыла. Әкияти сюжетлар аша автор кешелекнең мәңгелек кыйммәтләрен укучы-тамашачы алдына куя һәм матурлык-яхшылыкның җиңеп чыгачагына ышаныч тәрбияли.

[1] *Миннуллина Ф.* Юныс Сафиуллин драматургиясе: Заман һәм герой. – Казан, 2007. – Б. 45–61.

Р. Бохараевның татар халык йолалары, ышанулары нигезендә язылган «Тимер борчак» әкият-пьесасы үзәгендә яхшылык-явызлык көрәше. Автор Шүрәле, Дию, Су иясе, Юха елан кебек мифологик образларны кешеләр белән катлаулы мөнәсәбәтләргә кертә. Пьесада Мәхәббәт, Гаделлек, Хезмәт, Миһербанлылык кебек изге кыйммәтләр өчен җитди көрәш бара. Мифологик хәл-күренешләр, халык авыз иҗаты әсәрләре, Г. Тукай шигырьләре фантастик һәм чынбарлык катламнарын үзара бәйләп, бербөтен идеягә китерә. Ялган-хыянәт, мәкер кешеләргә күп кыенлык, михнәт, авырлык, күңел газаплары алып килә. Явызлык белән көрәштә яхшылык барыбер җиңәчәк, ди автор.

Балалар дөньясы үзенчәлекләрен тирәнтен аңлап иҗат итүче авторларның берсе – Л. Лерон. Пьесаларында балаларга таныш әдәби дөнья тудырып, геройларының борчу-мәшәкатьләре белән яши, әхлакый сынаулар аша үзләрен танып белергә, шәхес буларак формалашуда ясаган беренче адымнарын бәяләргә өйрәтә. Әдипнең осталыгы яшь укучы-тамашачының акылына, күзаллавына тәңгәл килерлек вакыйга-күренешләрне сурәтләүдә һәм шунда бала урынын ачык билгеләүдә чагыла. Моңа ирешү өчен Л. Лерон төрле юллар, әдәби эзләнүләр аша бара. Берсе – яңа тема-сюжетлар, образлар иҗат итү белән бәйле. Шуның бер чагылышы буларак, «Чәпәләй һәм Тәпәләй маҗаралары» әкият-пьесасында автор йорт җәнлекләре мәче һәм эт, кимерүчеләр төркеменнән булган тычкан кебек тере һәм агач кебек җансыз табигать дөньясы вәкилләре катнашындагы маҗаралы хәлләр тәкъдим итә.

Л. Лерон балалар өчен язган пьесаларында киң таралыш алган халык авыз иҗаты үрнәкләренә даими мөрәҗәгать итә. Әдип, бер яктан, фольклор әсәрләрен заманга яраклаштырып үзгәртеп эшләсә, икенче яктан, аларда урын алган сюжет эчтәлеген, геройларын, төрле мотивларны, детальләрне уңышлы файдалана. Драматургка хас әдәби үзенчәлекне билгеләгән әлеге алымнар берничә максатка хезмәт итә. Беренчедән, автор фольклор әсәрендә киң урын алган яшәү рәвеше, макталган сыйфат-билгеләр аша укучысында туган халкының традицияләренә гореф-гадәтләренә хөрмәт тәрбияли, икенчедән, текст

белән танышканда яисә сәхнәдән караганда укучы фольклор әсәре белән автор пьесасын чагыштыра, уйланулары аша билгеле бер нәтиҗәгә килә. Л. Лерон «Аңгыра сарык җүләре» әкият-пьесасында балаларга фольклор әсәре буларак та, Г. Тукайның «Кәҗә белән сарык» әкияте аша да таныш мотивка мөрәҗәгать итә. Автор һич тә әлеге әсәрләрне кабатламый. Бәрән һәм Кәҗәмил белән Бүретдин, Төлкиназ, Аюлла каршылыгында беренчеләрнең җиңеп чыгуын тасвирлап, баланы үз көченә ышанырга, иң кыен чакларда да чыгу юлын табарга мөмкин, дигән фикергә китерә. «Урмандагы тамаша» да автор үзенең геройлары Тазамат һәм Хыялбай белән бергә укучысын шүрәлеләр, диюләр яши торган дөньяга алып китә һәм Г. Тукайның атаклы «Шүрәле»сендә урын алган бүрәнә һәм бармакларын әлеге бүрәнә ярыгына кыстырган Шүрәленең оныклары Чүрәле, Түрәле, Бүрәле белән очраштыра. Драматургның «Без барабыз бәйрәмгә», «Яңа ел биштәре» әкият-пьесалары бәйрәм рухында язылулары белән кызыклы. Аларда укучыларга яхшы таныш геройлар хәрәкәт итә, вакыйга-күренешләрдә изге гамәл кылу, бер-береңә ярдәм итү, өлкәннәрне тыңлау кебек әхлакый сыйфатлар яклана, һәртөр начарлык кире кагыла. Л. Леронның «Ишегалды» әкияте тезмә формада язылуы белән игътибарга лаек. Автор атаклы әкиятчебез А. Алишның «Сертотмас үрдәк» әсәрендәге мотивны файдаланып, укучыларына яңа эчтәлек, яңа геройлар тәкъдим итә. Күпсанлы йорт хайваннары, җәнлекләре, кыргый җәнлекләр катнашындагы пьесада яхшылык һәм явызлыкка, хөрмәт һәм хыянәткә бәйле әхлакый нәтиҗәләр чыгарыла.

Яшь драматург И. Зәйниевнең балаларга атап язылган «Ак чәчәкләр иле» һәм «Кәҗә, сарык һ.б.» әсәрләре киң танылу ала. «Ак чәчәкләр иле» пьеса-әкияте яшүсмерләр турында һәм яшүсмерләргә атап язылуы, шулай ук әхлакый һәм фәлсәфи эчтәлеге белән җәлеп итә. Без барыбыз да балачак иленнән, уенчыклар иленнән, ул безгә якын, кадерле. Әсәр геройлары да үзләре башлаган уен аша уенчыклар иленә эләгә һәм күптөрле сынаулар алдында кала. Без уен гына уйнамыйбыз, бәлки үзебезнең киләчәкне, язмышны да уйныйбыз икән. Шуларга бәйле

автор яшәешнең җитди мәсьәләләренә алып килә. Әсәр герое Шамил сүзләре белән ул һәрберебезгә, беренче чиратта, олы тормышка атлаучы яшүсмерләргә эндәшә: *«Һәркем эшләгән эшләре өчен җаваплы. Һәркем үз тормышын үзе уйлап чыгара, ничек тели, шулай дәвам итәргә сәләтле. Мөмкин булмаган нәрсә юк, бары тик теләк кенә кирәк. Теләк һәм хыял! Һәркемнең үз язмышы үз кулында».*

Балалар драматургиясе өлкәсендә барган әлеге эзләнүләрне Т. Миңнуллин пьесалары бермә-бер баетып, сан һәм сыйфат үзгәрешенә китерә. Нәтиҗәдә татар театрлары сәхнәләренә яңа пьесалар менә һәм алар балалар аудиториясендә зур кызыксыну уята. Т. Миңнуллинның балалар өчен язылган әсәрләре аншлаг белән бара һәм мәктәп балаларын театр залларына кайтарырга ярдәм итә.

* * *

Балалар өчен театрның әһәмиятен яхшы аңлаган драматург башлангыч чор иҗатында ук «Азат», «Айга сәяхәт» кебек әкият-пьесалар язып, сәхнәгә менгерә. Алар фикер ачыклыгы, акцентларның төгәллеге, әхлак-тәрбия мәсьәләләрнең уңышлы куелышы белән игътибарга лаек. Әдипнең балалар өчен язылган әсәрләре һәртөр идеологиядән азат булып, аның өчен яшь буынның ата-анага, укытучыларга, өлкәннәргә хөрмәте, яшьтән җаваплылык тоеп үсүе кыйммәт. Балалар өчен язылган пьесаларга куелган таләпләр, аларның форма-эчтәлеге турындагы уйланулары аеруча тулы булып драматургның «Без “театр” уйныйбызмы?»[1] язмасында чагылыш таба. Тәнкыйди рух белән сугарылган язмада автор балалар әдәбиятының артка калуы, әдипләр тарафыннан тиешле игътибар бирелмәвенә борчылуын белдерә. 1970 елларда балалар өчен пьесаларның аз язылуын ассызыклап, *«шул азның да шактые пешеп җитмәгән, түбән сыйфатлы әсәрләр»[2]* булуын билгели. Т. Миңнуллин аерып чыгарган кимчелекләрнең берсе булып, тема ярлылыгы, таныш

[1] *Миңнуллин Т.* Без «театр» уйныйбызмы? // Казан утлары. – 1972. – № 5. – Б. 175–178.

[2] Шунда ук. – Б. 175.

вакыйгаларның күпләп урын алуы күрсәтелә. Автор әсәрләрдә бала психологиясенең тиешенчә ачылмавын да билгеләп үтә. Пьесаларның иң йомшак урыны булып әдәби осталык җитмәү, ягъни драма әсәре үзенчәлекләрен, сәхнә законнчалыкларын белеп, аңлап эш итмәү тора дип саный драматург. Болар барысы да пьесаларга заманчалык, тормышчанлык җитмәүгә китерә. Автор әлеге кимчелекләрнең үз әсәрләрендә дә булуын инкяр итми һәм аларны хәл итү юлларын эзли.

Т. Миңнуллинның «Гафият турында әкият» (1976) пьесасы әкияти сюжеты, тәрбияви эчтәлеге белән җәлеп итә. Алгы планга тәрбиясез малайның үз-үзен табуы, эш-гамәлләренә бәя бирү, җаваплылык тою кирәклеген аңлауга килүе чыгарылган. Беренче күренештә Гафият Баязитовның тупаслыгы, әдәпсезлеге белән очрашабыз. Автор аны Әкиятче белән очраштыра һәм бүгенге тормышта әкиятләрнең кирәк булу-булмавы турында бәхәс туа. Өлкәннәр әйткәнне санга сукмаучы Гафиятне төзәтү юлы итеп әкият дөньясы алына. Әкиятче карт сихер көче белән малайны әлеге әкият дөньясына күчерә. Укучы каршында гаҗәеп серле дөнья ачыла. Монда татар һәм рус халык әкиятләреннән таныш геройлар яши: Үги кыз, Шүрәле, Убырлы карчык, Дию, Юха елан, Җен һ.б. Балаларга яхшы таныш хайваннар да хәрәкәт итә: Мәче, Куян, Бүре һ.б. Автор шул рәвешле ике дөньяны чагыштырып карау, нәтиҗәләр ясау мөмкинлеге тудыра. Реаль тормыштагы кебек бу дөньяда да яхшылык һәм начарлык күренеше белән очрашабыз. Әкият геройларының заманчалыгын ачуга, укучыларга якынлыгын билгеләүгә киң урын бирелә. Мисал өчен, әлеге геройлар космосны белә, химия белән дә кызыксына, кайберләре мотоциклда да чаба.

Вакыйгалар барышында Гафият явызлык чыганагы булган Юха елан тәэсиренә эләгә һәм начарлыклар кыла. Аның үз-үзен тотышы, әдәпсез гамәлләре бөтен әкият дөньясын кузгата. Ул хәтта явызлыгы белән танылган Диюнең дә ачуын китереп, аның тарафыннан кире кагыла: *«Син – адәм баласы! Сиңа табигать акыл биргән. Агачларны сындырып, кошларны үтереп, чишмәләрне корытыр өченмени ул акыл? Әкият яратмавың бер бәла, табигатьне саклау турындагы законны да белмисең*

*икән син. Ычкын моннан, урманда эзең булмасын!»*[1] Моның артында табигать законнары булу, тереклекнең шуларга нигезләнеп яшәве, ә инде әлеге кануннарның бозылуы белән бөтен тереклек дөньясына куркыныч тудырылу аңлашыла. Шуңа да Гафиятнең эш-гамәлләре әкият дөньясы геройларына да гайре табигый булып күренә. Шуңа да ул дөньяда яхшылык тарафдары буларак билгеле Былтыр малайның үзләре арасында кала алмавын әйтеп бирә: *«Бар, Гафият, кит урманнан. Син безне белергә теләмәдең, белергә теләмисең. Шуның аркасында уңны сулдан аера белмәдең. Әкиятләрне укып, бездән үрнәк аласы урынга, явызлык кылдың. Кит. Бер сүз әйтмә. Гафу да үтенмә, вәгъдәләрең дә кирәкми!»*[2]

Әкият дөньясыннан куылган Гафият реаль тормышта тагын Әкиятче белән очраша. Хәзер инде ул үзенең ялгышларын аңлауга килә, бик нык үзгәрә. «Әкияти урманда булып, Гафият әкиятләрнең кызыклы сюжетка гына түгел, бәлки тәрбияви көч-йогынтыга ия булуын аңлауга килә. Чөнки аларда халыкның күпгасырлык акылы, әхлагы, яхшылык һәм явызлык турында күзаллаулары тупланган»[3].

Әнә шул рәвешле, пьеса сюжеты малайның тәртипсезлеге, шуның өчен җәза алуы, аннары акрынлап төзәлүгә килүе кебек этапларны үз эченә алган композициягә нигезләнә. Автор аны ике дөньяны параллель сурәтләү белән баета. Әкият дөньясы укучыга бай мәгълүмат бирә, тәрбияви йогынты ясый. Пьеса кеше һәм табигать дөньясы бәйләнешен, табигатьне саклауның мөһимлеген, кешелекнең борынгыдан тупланып килгән әдәп-әхлак сыйфатларына нигезләнеп кенә яши алуын тирәнтен ачуы, укучылар күңеленә эмоциональ йогынты ясавы белән уңышлы.

---

[1] *Миңнуллин Т.* Гафият турында әкият // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 5 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 383.

[2] Шунда ук. – Б. 383.

[3] *Нуреева Г.* Идейно-художественное своеобразие пьесы-сказки Туфана Миннуллина «Сказка про Гафията» // Филология и культура. Philology and culture. – 2020. – №2(60). – С. 210.

«Кайда хаклык, кайда дөреслек» (1976) мажаралы пьесасында 5 сыйныф укучысы Мәсгут, өлкәннәрнең сүзен тыңламыйча, әйләнә-тирәдәгеләр белән каршылыкка керә. Әңгәмәбәхәсләрдән аңлашылганча, каршылыкның төп сәбәбе – Мәсгутнең укыйсы килмәвендә, өлкәннәрнең сүзен тыңламавында, үзенең эш-гамәлләре өчен җавап бирергә теләмәвендә. Әлеге каршылыкка бәйле катнашучылар характерының аерым сыйфатлары ачыла. Үзәктә Мәсгут образы тора, башка геройлар әлеге малайны төрле яклап ачуга, бәяләүгә хезмәт итә. 12 яшьлек малай берни белән дә кызыксынмый, бөтен нәрсәгә битараф. Аңа ярдәм итәргә теләгән Гөлсинәне кимсетә, хәтта кул күтәрә. Укытучылар да, әтисе дә Мәсгут белән уртак тел таба алмый, чөнки ул бик кире, бернәрсә өчен дә җавап бирмичә, үзенчә генә яшәргә омтыла. Зурларның аңа карата куйган таләпләрен дөрес түгел, аны хаксызга рәнҗетәләр дип саный. Шуңа да тизрәк зур кеше булырга тели, аларны янәсе беркем өйрәтеп тормый, эш кушмый, ни дә булса таләп итми. Аны акылга утыртуның, ягъни уй-фикерләренең, теләкләренең дөрес түгеллеген исбатлауның бер генә юлы кала – зурлар роленә кую. Тылсымчы карт кызыклы, гыйбрәтле тылсым догасы ярдәмендә геройларның урыннарын алыштыра.

Вакыйгаларда каршылык капма-каршы якка үзгәреп кабатлана. Укытучы ролендәге Мәсгут башта 5 сыйныф укучысы Шәүкәт белән, аннары әти кеше буларак 12 яшьлек улы Касыйм белән каршылыкка керә. Мәсгут хәзер зурларның үзләре һәм башкаларның эш-гамәлләре өчен җавап бирергә тиешлекләрен аңлауга килә. Шул рәвешле, автор төп идеяне ачуга килә – тормыш-яшәештәге хаклык, дөреслек үз-үзеңә һәм башкаларга карата җаваплылыктан башлана.

Автор геройларның индивидуаль йөзләрен ачуга, бер яктан, бер-берсенең үзара мөнәсәбәте, эш-гамәле аша, икенче яктан, персонажлар сөйләме ярдәмендә ирешә. Мәсгут сөйләме аеруча игътибарга лаек. Әңгәмә-диалогларда кулланган гыйбарәләр, әйтемнәр *(«миңа кысылма, кыстыбый, диярләр»; «җәй бар, кыш бар – ашыгып ни эш бар»; «өйрәтмә, өйрәтүче, диярләр»; «тире җыеп күн эшлим» һ.б.)* Мәсгутнең шактый тапкыр, оста

булуын, теләсә һәм тырышса фәннәрне яхшы үзләштерә алуын күрсәтә. Мөһим урынны шартлы алым алып тора. Әсәрдәге Тылсымчы карт әкияттән алынган, балаларга яхшы таныш, шуңа да ул үтәгән вазифа ачык аңлашыла. Әдәби мисалларга мөрәҗәгать итү дә уңышлы алым булып тора. Ш. Галиевнең Мәсгут исемле малай турындагы шигыре пьеса герое кебекләрнең шактый булуын һәм аларның һәркайда, һәрвакыт бертөрле акланууларын аңлата. Автор тылсым серен укучыларны күздә тотып куллана. Төрле фәннәрдән белемнәрне ачыклауны таләп иткән мәсьәләне Мәсгут кенә түгел, бәлки укучы-тамашачы да чишәргә тиеш була. Пьесада автор кабатлау алымыннан да уңышлы файдалана. Вакыйгаларның капма-каршыга үзгәреп кабатлануы кечкенәләрнең дә, зурларның да үз вазифалары булуын аңларга ярдәм итә.

Шулай итеп, драматург үзең һәм башкалар өчен җаваплылык темасын үзәккә чыгара һәм геройлар арасындагы каршылыклар аша кешенең ирегe-теләге һәм җаваплылыгы арасында төп конфликт калкып чыга. Пьесаның исеме дә тема белән бәйле – тормыш-яшәештәге хаклык, дөреслек үз-үзеңә һәм башкаларга карата җаваплылыктан башлана. Эзлекле рәвештә пьесаның идеясе ачыла – эш-гамәлләре өчен һәркем үзе җавап бирә, шуңа да хаклык-дөреслеккә нигезләнеп яшәргә һәм башкалардан да шуны таләп итәргә кирәк.

Драматург алдагы эзләнүләрендә балалар күңеленә әдәп-әхлак орлыклары салуга хайваннар дөньясының үзенчәлекле якларын ачу, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне сурәтләү аша килә. Әдипнең Акбай турындагы тулы бер цикл пьесалары балалар драматургиясендә үзгә бер күренеш булып тора. «Авыл эте Акбай» (1989), «Акбай нигә күңелсез?» (1991), «Акбайның яңа ел маҗаралары» (1991), «Акбай белән Кыш бабай» (1991), «Акбай, Тәмлетамак һәм Этбүреләр» (1992), «Акбай һәм сарык малае» (1993), «Акбай, SOS!» (1994), «О кей, Акбай!» (1995) пьесаларында хайваннар дөньясының серле, гыйбрәтле яклары ачылып, балалар өчен дә гаять кызыклы һәм бай мәгълүмат бирелә. Автор оста психолог буларак эш итә, сиздерми генә бала күңеленә миһербанлык, туган җирне, телне ярату сыйфатларын

сеңдерә. Әсәрләрдә яшәешнең гаять мөһим мәсьәләләре төрле яктан ачыла. Йорт һәм кыргый хайван образлары тормышчан, гади-гадәти булулары белән җәлеп итә. Автор сәхнәдән балалар белән кызыклы да, гыйбрәтле дә әңгәмә алып бара, бала күңелендәге күпсанлы сорауларга бергәләп җавап эзли. «Киләчәкнең яшь буын кулында булуын аңлаганга күрә, драматург кечкенә дусларына олы-олы хакыйкатьләрне әйтеп калырга ашыга: яхшылык һәм мәрхәмәт, матурлык, гаделлек, кешенең яшәү мәгънәсе нидә – менә бу кыйммәтләрне бала чактан ук күңелгә дөрес итеп сеңдерү зарур»[1].

Драматургның «Авыл эте Акбай» пьесасы аеруча киң танылу алып, күпсанлы театр сәхнәләрендә уңыш белән куелды һәм куелып килә. Әсәрнең курчак театрында куелышы да аның заманчалыгын раслый[2]. Т. Миңнуллинның «Авыл эте Акбай» (1989) комедиясендә хайваннар тормышы сурәтләнсә дә, аларның эш-гамәлләре аша автор кешеләр, аеруча балалар яшәешен күз алдына бастыра. Әсәрнең сюжетына авыл эте Акбай белән мәче Тәмлетамакның шәһәргә барулары, анда урам һәм өй этләре белән төрле мөнәсәбәт-бәйләнешкә керүләре, ахырда аерым юллар белән туган авылга кайтуларына бәйле вакыйгалар салынган. Пьесаның комедиячел конфликты Акбай белән Тәмлетамак арасындагы каршылыкка нигезләнә. Вакыйга-күренешләрдә драматург заманның җитди мәсьәләләрен күтәрә. Мәче Тәмлетамак теләгән «рәхәт, бәхетле яшәү»нең асылын ачарга омтылып, автор авыл һәм шәһәр тормышы, аларның уртак һәм аермалы яклары, табигатьтәге җан ияләре белән кешеләрнең үзара мөнәсәбәте, халкыбызга хас милли сыйфатларның сакланышы һ.б. турында тирәнтен уйлана.

Акбай белән бер йортта яшәүче, һәрнәрсәне алдау юлы белән хәл итүче Тәмлетамак рәхәт, җайлы тормышка ияләшкән:

*Каймак урлап ашап туям,*
*Хәйлә-мәйлә корып куям –*
*Иркәләнеп койрык болгап мияулыйм;*

[1] *Габәши-Салихова А.* Иҗатында – ил гаме // *Миңнуллин Т.* Пьесалар / кереш сүз авт. А. Габәши-Салихова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 12.

[2] *Гатауллина М.* Авыл эте Акбай // Мәдәни җомга. – 2022. – 21 октябрь.

*Хуҗа-фәлән күрмәгәндә*
*Шакшы эшләр эшләсәм дә,*
*Үзем бер дә, беркайчан да буялмыйм*[1].

Әмма моңа гына канәгатьләнәсе килми, эче поша, күңелсезләнә, иркәләнәсе килә. Шуңа да шәһәр мәчеләре тормышына кызыга. Тәмлетемак бөтен нәрсәдән зарлана, кисәтү ясасалар, кычкырыша башлый. Әмма куркак, үзен генә яратучы, үзсүзле мәчене шәһәрдә тиз акылга утырталар. Айдан артык шәһәрдә йөргәннән соң, ул авылга кайтып егыла.

Авыл эте Акбай – башкаларны кайгыртып йөрүче, изге күңелле, *«хәйләсез җан иясе»*. Бүре белән каршылыгында акылы, кыюлыгы, тапкырлыгы ачыла. Ул авыл кешесе кебек гади, гадәти. Тәкәббер, мактанчык этләрне мәсхәрәгә калдыра. Акбай сабыр, тыныч, башкаларга хөрмәт белән карый һәм үз дәрәҗәсен дә саклый белә.

Пьесадагы һәр образга тирән мәгънә салынган. Ерткыч Бүре дә нәселенең корып-бетеп баруына борчыла. Эттән акыллы, бүредән усал ни эт, ни бүре түгел нәмәстәләр урманны баскан икән. Әшәкелекне дә шулар эшли. Ә бит табигатьтә һәр нәрсәнең, һәр затның үз урыны бар. Әлеге тигезлек бозыла икән, табигатькә зыян килә. Бүре әнә шул турыда кисәтә.

Шәһәрдә яшәүче өй этләренең тормышы турында да мәгълүмат бирә автор. Мисал өчен, өй эте Чарлиның кем булуы, нинди булуы җырында ук күренә:

*Өстем бөтен, тамагым тук,*
*Дөньясында бер кайгым юк;*
*Ефәк тасма муенымда*
*Йоклыйм хуҗам куенында*[2].

Әнә шундый рәхәтлектә яшәүче назлы, иркә Чарли тормышы кызыгырлык түгел икән, чөнки үз ирке белән яши алмый. *«Урамга чыктым хуҗам белән»*, – дип 2–3 тапкыр кабатлый ул, үзенең курчак хәлендә булуын ачык аңлатып. Акбайның

---

[1] *Миңнуллин Т. Г.* Авыл эте Акбай // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 5 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 101.

[2] Шунда ук. – Б. 107.

Чарли белән бәхәсе дә кызыклы. Монда автор авыл һәм шәһәр тормышының аермалы якларын, ике төрле яшәү рәвешенә бәйле психологик аерымлыкларны ачып сала. Чарлиның кыланып сөйләшүе артында сәер гадәтләр, табигый булмаган яшәеш күренә. Үзен әллә кемгә санап, башкаларны кимсетүче Бульдогка да Акбай сабак бирә. Урам этләре дә Акбайны башта кабул итмиләр. Авыл этенең тынычлыгы, сабырлыгы, башкаларга хөрмәт белән каравы һәм үз дәрәҗәсен саклый белүе аларны үзара якынайта. Драматург урам этләренең авыр, еш кына фаҗигалы язмышы белән дә таныштырып үтә. Әнә колли токымлы Муйнак хуҗасының кыйнавына түзә алмыйча өйдән качкан. Йолкынган, бер аяксыз, бер күзсез, койрыксыз Сарбай образы да аяусыз тормыш чигенә җиткән, яшәүнең ямен югалткан эт язмышын күз алдына бастыра:

*Өем дә юк минем, оям да,*
*Көне-төне йөрим урамда.*
*Бер кирәксез җан мин дөньяда –*
*Үлсәм әгәр, кая күмәрләр*[1].

Сарбай көчек вакытта авылда яшәгән тормышын сагынып искә ала. Аны ниндидер кешеләр урлап алып китә, ә бераздан урамга чыгарып ата. Ул әнә шулай урам эте булып китә. Күпне күргән, тормышның ачысын-төчесен шактый татыган Сарбайның кешеләр һәм этләр турындагы фәлсәфи фикерләре дә игътибарга лаек, уйландыра: *«Кешеләрне акыллы, диләр, Акбай, балакай, акыллы булгач, нигә болай эшлиләр? Без бит алар хөкемендә. Алар яхшы булса, без яхшы, алар начар булса, без начар»*[2].

Вакыйга-күренешләрдә Акбай үзен көчле рухлы, ышанычлы, сүзендә тора торган, акыллы, көчле, кыю эт итеп таныта. Дүрткүзне үзе белән шәһәрдән авылга алып кайтуы да символик мәгънәгә ия, димәк, аның кебекләр киләчәктә дә бетмәячәк. Ә Тәмлетамакның буш хыялы тормышка ашмый,

[1] *Миңнуллин Т. Г.* Авыл эте Акбай // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 5 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 112.

[2] Шунда ук. – Б. 115.

яшәү фәлсәфәсе чәлпәрәмә килә. Акбай янына кайтуы белән ул үзенең җиңелүен, ә авыл этенең хаклы булуын таный. Әсәрнең төп идеясе нидә соң? Тормыш гел каршылыклардан, бәхәскөрәшләрдән тора. Анда үз урыныңны табып, дөрес яшәү өчен салкын акыл, ихтыяр көче кирәк. Аның нигезе бала чакта ук туган җирендә салына. Пьесаның төп идеясе түбәндәгегә кайтып кала: Тәмлетамак кебек җиңел фикерле, акылсыз, тәрбиясез булмагыз. Үз-үзеңне генә ярату да юньлегә илтми. Акбай кебек акыллы, сабыр, батыр һәм кешелекле, ярдәмчел булыгыз. Тормышта авыр вакытта таянырдай дусларыгыз булсын. Шул вакытта теләгегезгә ирешеп, матур яшәрсез. Гомумән, Т. Миңнуллин тормышчан, ышандыру көченә, гомумиләштерүгә ия булган Акбай образы белән балалар драматургиясенә яңалык алып килә[1]. Авторның бала психологиясен яхшы белеп эш итүе әсәрнең эмоциональ тәэсир итү көчен тагын да арттыра.

Шулай итеп, хәзерге сәхнә әдәбиятында балалар өчен язылган пьесалар тулы бер юнәлеш булып, аның үсеш-үзгәрешен билгеләргә ярдәм итә[2]. Т. Миңнуллин бу өлкәдә дә иң актив авторларның берсе буларак, әсәрләрен кызыклы, мәгънәле итүнең төрле юлларын, алымнарын эзли. Аның пьесаларында укучы-тамашачы да әледән-әле уенга катнашып китә, әсәр геройлары белән бергә сорауларга җавап эзли.

---

[1] *Закирҗанов Ә.* Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – Б. 44.

[2] *Әхмәдуллин А.* Күңелләрне уятыр: хәзерге татар драматургиясе. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б. 219.

# ЙОМГАК

Т. Миңнуллин – XX гасырның икенче яртысы татар драматургиясе үсешенә гаять зур өлеш кертеп, аның тема һәм жанр төрлелегенә, фәлсәфи һәм эстетик эзләнүләренә, сәнгать чаралары белән баюына көчле этәргеч биргән, еш кына әйдәп баручы, юл салучы буларак танылу алган әдипләрнең берсе. Соңгы ярты гасыр эчендәге татар сәхнә әдәбиятын һәм театр сәнгатен аның бай мирасыннан башка күз алдына китерү дә кыен. Драматург 1960 еллар башында әдәбиятка килә һәм иҗат гомерендә 70 тән артык пьеса, күпсанлы хикәяләр, маҗаралы роман, йөзләгән публицистик язма калдыра. Әдипнең әсәрләре унбишләп рус театрында, шулай ук Башкортстан, Мари Эл, Удмуртия, Бурятия, Калмыкия, Дагстан, Осетия, Ичкерия, Казакъстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Эстония, Литва, Латвия милли театрлары тарафыннан сәхнәләштерелә.

Т. Миңнуллин тудырган дөнья сурәтендә, һәр талантлы язучыга хас булганча, Көнчыгыш һәм Көнбатыш әдәбияты, аларның фәлсәфи-эстетик фикере йогынтысы киң чагылыш таба. Әмма бу мәсьәләдә бернәрсә ачык һәм бәхәс уятмый: олы әдип, беренче чиратта һәм өстенлекле рәвештә, үз җирлегебездә, татар драматургиясе традицияләрендә формалашкан милли драматург булып тора. Язучы гомере буе дәвамлы китап яза, диләр. Т. Миңнуллин да үзенең күпсанлы әсәрләрендә, татар милләтенең үткәненә таянган хәлдә, бүгенгесе һәм киләчәге өчен җан атып яши, аның яңадан-яңа сыйфат-билгеләрен ачуга ирешә. Шуның белән бергә, әдип иҗаты үз чорыннан, дәвереннән аерылгысыз. Ил-халык тормышындагы иҗтимагый-тарихи үзгәрешләргә бәйле Т. Миңнуллин иҗатын да өч зур чорга

бүлеп өйрәнү күзәтелә: 1960–1980 еллар, XX гасыр ахыры һәм XXI гасыр башы.

XX гасырның 60–80 нче еллары фәндә әдәбиятның милли нигезләргә кайту чоры (Д. Заһидуллина) дип билгеләнгән кебек, Т. Миңнуллин иҗатында да әлеге дәвер татар драматургиясенең сан һәм сыйфат үзгәрешләре ачык чагылыш таба. Бу чор үзгәрешләре, бердән, «Хрущев җепшеклеге» дип аталган демократик күренешләр, икенчедән, татар драматургиясенең Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, М. Фәйзи, К. Тинчурин, Н. Исәнбәт һ.б.дан килә торган традицияләргә таянуы, өченчедән, репрессияләнгән әдипләр иҗатының халыкка кайтуы, дүртенчедән, рус-Европа әдәбиятларындагы казанышларны актив рәвештә иҗади үзләштерә башлау белән аңлатыла. Т. Миңнуллин, замандаш драматурглары Х. Вахит, А. Гыйләҗев, Ш. Хөсәенов һ.б. пьесаларында урын алган матур башлангычларны үстерә барып, бу чор иҗат йөзен билгеләгән пьесаларын – «Миләүшәнең туган көне», «Нигез ташлары», «Кырларым-тугайларым», «Монда тудык, монда үстек», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Моңлы бер җыр», «Без китәбез, сез каласыз» кебек әсәрләрен иҗат итә. Әлеге пьесалар сайланган тормыш материалы, иҗат юнәлеше, сәнгать чаралары байлыгы белән аерылып торсалар да, аларны авторның төп иҗат концепциясен ачкан тема-мотивлар берләштерә: яңа тип милли геройга йөз тоту; татар авылын яшәешнең үзәгенә куеп сурәтләү; милли яшәү рәвешен, традицияләрен яклау һәм саклау, тормышчан конфликтка нигезләнү һ.б.

1960–1970 еллар әсәрләрендә Көнбатыш, аерым алганда, рус әдәбияты йогынтысы жанр һәм жанр формаларында урын ала. Бу елларда драматург моңсу комедия, сагышлы комедия, социаль драма, лирик драма, публицистик драма, интеллектуаль драма кебек бездә сирәк очраган жанр формаларында иҗат итә. Шуңа нисбәтле аның «Әлдермештән Әлмәндәр», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Дуслар җыелган җирдә», «Яшьлегем-юләрлегем» пьесалары җәмәгатьчелектә киң яңгыраш алулары, бертөрле генә бәяләнмәүләре, төрлечә укылышка урын калдырулары белән танылу ала. Рус-Европа әдәбиятларындагы эстетик

карашлар әлеге чор татар әдәбиятында форма, эчтәлек һәм поэтика өлкәсендәге эзләнүләр белән кушылып китә. Т. Миңнуллин фикер-карашларын укучы-тамашачыга үтемлерәк җиткерү максатында яңа формалар, алымнар эзли. Алар арасында эстетик төшенчә буларак «уен»нан әдәби алым һәм сурәтләү предметы буларак файдалану, образ-символларга актив мөрәҗәгать итү һ.б. бар.

Т. Миңнуллинның XX гасыр ахыры иҗатында традицияләр дәвамчанлыгы һәм сәнгати яңачалык аеруча киң чагылыш таба. Аның беренчесе ачык рәвештә әсәрләрнең форма һәм эчтәлек катламында күзәтелә. Г. Камал «Безнең шәһәрнең серләре»ндә уңышлы файдаланган «тартмалы композиция», ягъни Шәрык әдәбиятында киң урын алган вакыйгаларны оялап урнаштыру, мөстәкыйль күренешләргә бүлү Т. Миңнуллинның «Сөяркә», «Шәҗәрә» кебек пьесаларында уңышлы дәвам иттерелә. Шәрык әдәбиятыннан Урта гасыр татар әдәбиятына үтеп кергән хисакыл көрәше киң җәмәгатьчелеккә яхшы таныш «Илгизәр плюс Вера» да гыйбрәтле гәүдәләнеш таба. Драматург гаилә кору кебек җитди мәсьәләгә хис белән генә түгел, бәлки акыл белән уйлап якын килергә чакыра һәм өч буын язмышы мисалында аның ачык чагылышын күрсәтә. Шәрык әдәбиятыннан ук килә торган бай сурәтләрдән, куе буяулардан, купшы төсмерләрдән, күпмәгънәле символлардан, үзенчәлекле детальләрдән уңышлы файдаланып, аларны еш кына әсәрнең фокусы дәрәҗәсенә куя. «Илгизәр+Вера» драмасының финалында сурәтләнгән ауган тирәк мифологиядән килүче «гомер агачы» мәгънәсен ала һәм ике милләт арасындагы аерымлыкларның, гореф-гадәтләрнең югала баруына ишарә итә. Ялгызлык фәлсәфәсенә нигезләнгән «Эзләдем, бәгърем, сине» драмасында автор файдаланган «Киек Каз Юлы» төшенчә-сурәте авыр хәлдә калган геройлар өчен өмет, үз-үзен табу билгесе буларак мөһим вазифа үти һәм шуның белән әсәрне мифопоэтик яссылыкта бәяләү, шәрехләү мөмкинлеге бирә.

Т. Миңнуллин модернизм әдәбиятына хас алым-чаралардан да читләшми. Бу яктан, «Саташу» драматик хикәясе аеруча игътибарга лаек. Тәнкыйтьтә төрлечә бәяләнгән әсәр геройларында

бернинди универсаль нормалар юк. Алар өчен бәхет төшенчәсе дә бары чагыштырма гына. Автор үз әти-әнисен «Мине нигә таптыгыз?» дип судка биргән Гүзәл исемле кызның эш-гамәлендә гомумән кешелекнең үз-үзен юкка чыгару куркынычын күрә. Әсәр геройлары кара, ялыктыргыч, шыксыз яшәештә үз-үзләрен таба алмыйча, күзгә күренеп тормаган пәрәвез җепләреннән ычкына алмыйча газаплана. Геройлары белән драматург та әлеге халәттән чыгу, кирәк булса хәтта качу юлларын эзли. Әмма юкка... Бу яшәештән качып булмый. Шул рәвешле, сызлану фәлсәфәсе бөтен әсәрне һәм геройларын иңләп үтә. Драмада, реалистик, романтик, модернистик күренешләр үзара кушылып, бүлгәләнгән тормыш сурәте тудырыла.

Алдагы чорларда яшәеш нигезе булып торган, хәтта табынган идеалларының, кыйммәтләрнең җәмгыятьтәге социаль-мәдәни шартларга бәйле үзгәрүе Т. Миңнуллинның XXI гасыр башы эстетик эзләнүләрендә дә урын ала. Каршылыклы, еш кына кара төсләр өстенлек иткән җәмгыятьтә кешенең үз урынын эзләве күренешләрен яңадан-яңа чараларда, сурәт-тасвирларда чагылдыруга килә драматург. Ул, татар драматургиясенең эчке үсеш закончалыкларына таянган хәлдә, Көнчыгыш һәм Көнбатышның аерым казанышларына йөз белән борыла. Шәрыктан килүче ислам кыйммәтләрен яклау һәм саклау мәсьәләсе драматургның «Сөяркә» («Гөнаһсыз гөнаһлылар»), «Төш», «Мулла» кебек драмаларында үзенчәлекле чагылыш таба. Т. Миңнуллин соңгы чор иҗатында актив рәвештә шартлы-символик («Төш») һәм «уен» («Алты кызга бер кияү») башлангычларына, интертекстуальлек алымына («Галиябану, сылуым-иркәм»), кешенең «чиктәш» яисә аңсызлык халәтен сурәтләүгә («Саташу», «Дивана») һ.б. мөрәҗәгать итә. Үзебезнең традицияләрне үстерә барып, эзләнүләрендә Көнбатыш әдәби-эстетик фикерләрен дә уңышлы кушып, үреп бара. Драматургның яңа алымнарга мөрәҗәгать итүе яисә электән килә торган чараларның үзгәртелеп кулланылуы, шулай ук рус-Европадан килүче сурәтләр белән синтезлашып яңа эчтәлеккә омтылуы тормышны күптөрлелегендә, каршылыгында чагылдыру, шуны укучы-тамашачыга җиткерүнең яңа юлларын эзләү

булып тора. Драматургның «Тәнзиләкәй» монодрамасы герое Газинур язмышы экзистенциализм фәлсәфәсенә нигезләнеп ачыла. Автор яшәешнең акыл белән аңлап бетерү мөмкин булмаган яклары барлыгын искәртә. Психологик киеренке халәттәге ир чынбарлык белән хыял чигендә яши, ул саташулы, аңсызлык хәлендә. Бу исә, яшәештәге мәхәббәт һәм нәфрәт, яшьлек һәм картлык, өмет һәм өметсезлек, ышану һәм ялгызлык кебек ике чик арасы рәвешендә күз алдына бастырыла.

Шулай итеп, Т. Миңнуллинның бай һәм күп тармаклы иҗаты, татар драматургиясенең иң уңышлы традицияләрен дәвам итеп, аларны татар милли яшәеше үзенчәлекләрен чагылдырган гыйбрәтле, тормышчан тема-мотивлар, кеше характерлары белән баета. Җәмгыять каршылыкларын, заман проблемаларын ачуның яңадан-яңа юлларын эзләп, драматург реалистик, романтик, модернистик алым-чараларга мөрәҗәгать итә. Яшәешнең әдәби-эстетик кыйммәтләренә йөз тотып, заманча яңгырашлы, гуманистик эчтәлекле әсәрләре татар әдәбияты тарихында лаеклы урын ала.

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

*Арсланов М.Г.* Татарское режиссерское искусство (1941–1956). – Казань, 1996. – 224 с.

*Арсланов М.Г.* Татарское режиссерское искусство (1957–1990). – Казань, 2002. – 272 с.

*Арсланов М.Г.* Тылсым. Татар театры: режиссерлар һәм драматурглар. – Казан: Мәгариф, 2008. – 287 б.

*Арсланов М.Г.* Драматург белән театр дуслыгы // Татарстан яшьләре. – 1976. – 19 окт.

*Арсланов М.Г.* Пафос жизнеутверждения («Старик из деревни Альдермеш». К постановке на сцене ТГАТа им. Г. Камала) // Комсомолец Татарии. – 1976. – 5 дек.

*Арсланов Г.* Бичура һәм кара җаннар // Соц. Татарстан.– 1990. – 4 гыйнв.

*Арсланов Г*. Кишер басуы // Ватаным Татарстан. – 1994. – 26 март.

*Арсланов М.* Туфан Миннуллин драматургиясе // Казан утлары. – 2015. – №8. – Б. 177–178.

*Ахмадуллин А.* Горизонты татарской драмы: Лит.-крит. статьи. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1983. – 216 с.

*Ахмадуллин А.*Г. Татарская драматургия: истоки и проблемы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – 511 с.

*Ахметов Р.* Мулла // Звезда Поволжья. – 2012. – 15 ноября.

Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / мөх.: Т. Галиуллин, Д. Заһидуллина.– Казан: Мәгариф, 2007.– 231 б.

*Әхмәдуллин А.* 1968 елда татар драматургиясе // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б. 16–39.

*Әхмәдуллин А.* Читлектәге кош бәхетлеме? // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б. 262–272.

*Әхмәдуллин А.* Үзе сайлаган язмыш // Дөреслеккә ирешү юлында. Мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – Б. 49–75.

*Әхмәдуллин А.* Дөреслеккә ирешү юлында. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 255 б.

*Әхмәдуллин А.* Туфан Миңнуллин // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 6 т. – Казан: «Раннур» нәшр., 2001. – Б. 405–430.

*Әхмәдуллин А.* Офыклар киңәйгәндә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 239 б.

*Әхмәдуллин А.* Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе. – Казан: Мәгариф, 2007. – 223 б.

*Әхмәдуллин А.* Кеше – дөнья токтасы (Т. Миңнуллинның соңгы чордагы иҗатына бер караш) // Офыклар киңәйгәндә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 66–76.

*Әхмәдуллин А.* Морзалар язмышы – безнең дә язмыш // Офыклар киңәйгәндә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 76–80.

*Әхмәдуллин А.* Хәзерге татар драматургиясенең жанр һәм стиль үзенчәлекләре // Метод, стиль, жанр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – Б. 104–124.

*Әхмәдуллин А.* Ничек сурәтләргә сине, замандаш? – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 151 б.

*Әхмәдуллин А.* Сәхнә әдәбияты һәм тормыш: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 304 б.

*Әхмәтова Ч.* Театрда оча торган тәлинкә һәм башка берни юк // Шәһри Казан. – 1993.– 11 дек.

*Батталова А.Д.* Татар драматургиясендә йорт образыының үсешүзгәреше (1960–2000 еллар): монография. – Казан, 2009. – 132 б.

*Батулла Р.* «Баскетболист» // Звезда Поволжья. – 2002. – 28 февр. – 6 марта.

*Борев Ю.* О трагическом. – М.: Сов.писатель, 1961. – 321 с.

*Бугров Б.* Драматургия: портреты современников. – М.: Знание, 1982. – 64 с.

*Вәлиев Р.* Уйлый торган йөрәк // *Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – Б. 7–12.

*Бугров Б.* Проблемы развития русской советской драматургии на современном этапе (60-е – 70-е годы). – М.: Изд-во Моск. ун-та, 1980. – 160 с.

*Габаши А.* Сотворение чудо («Искал тебя, любимая», ТГАТ им. Г. Камала) // Время и деньги. – 2001. – 9 нояб.

*Габаши А.* Новые открытия Туфана Миннуллина // Казань. – 2008. – № 7. – С. 42–52.

*Габәши А.* Татар драматургиясенең киләчәге өметле («Мулла», «Дивана» спектакльләре турында) // Сәхнә. – 2008. – № 10. – Б. 6–7.

*Габәши-Салихова А.* Иҗатында – ил гаме // *Миңнуллин Т.* Пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 5–13.

*Галиев М.* Туфан булып кара син! // Мәдәни җомга. – 2005. – 19 авг.

*Галиуллина М.* «Дивана» ни сөйли? // Мәдәни җомга. – 2007. – 14 дек.

*Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. – 171 с.

*Ганиева Р.К.* Декадентские мотивы в татарской литературе (первая четверть XX в.) // Милли мәдәният. – 2005. – № 7. – С. 10–16.

*Гареева Н.* Восемь аншлагов в Москве // Татарский мир. – 2013. – № 2. – С.13.

*Гатауллина М*. Авыл эте Акбай // Мәдәни җомга. – 2022. – 21 окт.

*Гилязов А.* Притяжение сцены (К 50-летию Туфана Миннуллина) // Вечерняя Казань. – 1985. – 25 августа.

*Гимранова Д.* Улыбка – это тоже важно... («Четыре жениха Диляфруз» на сцене ТГАТа им. Г. Камала) // Советская Татария. – 1972. – 23 апр.

*Громова М.И.* Русская драматургия конца XX – начала XXI века: учеб. пособие / М.И. Громова. – 2-е изд.испр. – М.: Флинта: Наука, 2006. – 368 с.

*Гыйләҗев А.* Замандашыбыз Әлмәндәр // Соц. Татарстан. – 1978. – 18 апр.

*Гыйләҗев А.* Ябык капканың ачылыр чагы... // *Салихов Д.* Яшьлек хатам – йөрәк ярам: Пьесалар җыентыгы. – Казан: Татар китабы, 1998. – Б. 3–8.

*Гыйләҗев А.* Көндәлекләр (1992–1993) // *Гыйләҗев А.* Сайланма әсәрләр: 6 томда. 6 т.: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре, язылып бетмәгән роман, көндәлекләр, хатлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – Б. 83–255.

*Гыймранова Д*. Театрга гашыйк булыгыз!: драматургларыбызның соңгы еллардагы иҗаты // Казан утлары. – 2003. – № 2. – Б. 124–129.

*Гыймранова Д.* Җиде елдан соң күрешү (Казанда Чаллы Татар дәүләт театры гастрольләре) // Мәдәни җомга. – 2008. – 27 июнь.

*Гуляев Н.А.* Литературные направления и методы в русской и зарубежной литературе XVII–XIX веков: Кн. для учителей. – М.: Просвещение, 1983.

Дуслар җыелган җирдә: Т. Миңнуллин турында замандашлары. – Казан: «Идел» журналы китапханәсе, 1995. – 160 б.

*Дюшен И*. Театр парадокса // Театр парадокса (Ионеско, Беккет и другие): СБ / сост. и автор предисл. И. Дюшен. – М.: Искусство, 1991. – С. 5–21.

Ермилова Е.В. Теория и образный мир русского символизма. – М.: Наука, 1989. – 176 с.

*Җәлилова Г.* Ун муллага ялынганчы, бер Алладан сора... // Шәһри Казан. – 2012. – 15 гыйнв.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская поэзия и проза рубежа XX–XXI веков: эстетические ориентиры и художественные поиски: монография. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2018. – 312 с.

*Загидуллина Д.Ф.* Символические модели мира в творчестве Дардменда // Диалог культур: русско-татарские связи. – Москва-Ярославль: Ремдер, 2005. – С. 98–104.

*Загидуллина Д.Ф.* Татарская литература и национальный театр: одна дорога на двоих // Театр XXI века и вызовы нового времени: материалы Международной научно-практической конференции, посвященной 110-летию татарского театра / под ред. Э.М. Галимовой. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – С. 4–13.

*Закирҗанов Ә.* Заман белән бергә: әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 175 б.

*Закирҗанов Ә.* Яңарыш юлыннан. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 303 б.

*Закирҗанов Ә.* Тормыш учаклары сүнмәсен // Казан утлары. – 1999. – № 7. – 123–128 б.

*Закирҗанов Ә.* Онытырга хакыбыз юк // Казан утлары. – 2000. – № 8. – Б. 132–137.

*Закирҗанов Ә.* Сәхнәдә әдәбиятында – замандаш... // Казан утлары. – 2004. – № 12. – Б. 145–149.

*Закирҗанов Ә.* Рухи таяныч. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 273 б.

*Закирҗанов Ә.* Нәрсә ул гөнаһ? (Әлмәт Татар дәүләт драма театрында «Гөнаһсыз гөнаһлылар») // Шәһри Казан. – 1999. – 12 нояб.

*Закирҗанов Ә.* Туфан Миңнуллинның иҗат дөньясы (соңгы еллар иҗатына бер караш) // Мәйдан. – 2010. – № 9. – Б. 112–123.

*Закирҗанов Ә.М.* Хәзерге татар драматургиясендә дини һәм фәлсәфи фикер синтезы // Роль Ислама в стабилизации социальных процессов: сборник статей и тезисов II Международной научно-практической конференции, 18 марта 2017 г. / под ред.Р.Ш. Шайхевалиева. – Набережные Челны: Ак мечеть, 2017. – С. 32–35.

*Закирзянов А.М., Хабутдинова М.М.* Новое прочтение женской темы в спектакле «Без луны, звезда нам светит» по одноименной пьесе Т. Миннуллина (2015) (реж. Р.Р. Фазлыев) // Филология и культура. Philology and culture. – 2016. – № 1 (43). – С. 198–204.

*Заһидуллина Д.Ф.* Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 255 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф. Заһидуллина, Н.М Йосыпова. – Казан: Казан университеты, 2011. 2 т.: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – 198 б.

*Заһидуллина Д.Ф.* 1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр: монография. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – 383 б.

*Зәйнуллин З.* Зөлфәт Хәким драматургиясе турында уйланулар // Ват. Татарстан. – 1994. – 11 апр.

*Зәйнуллин З*. Афәрин, Туфан! // Шәһри Казан. – 1999. – 9 апр.

*Зубков Ю.* Герой и конфликт в драме. – М.: Сов. писатель, 1975. – 279 с.

*Ибрагимов М.И.* Предисловие // Вахит Х. Первая любовь: пьесы / Хай Вахит; [сост., авт. аналит. ст. М.И. Ибрагимов]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С. 4–12.

*Ибраһим Х.* Хәнҗәр үче // Шәһри Казан. – 1997. – 14 ноябрь.

*Игламов Р.* Рассказать о своем народе (гастроли ТГАТа им. Г. Камала в Свердловске) // Уральский рабочий (Свердловск) . – 1982. – 1 авг.

*Игламов Р.* Не забывайте колыбельную («Колыбельная». К постановке в ТГАТе им. Г. Камала) // Советская Татария. – 1984. – 15 апр.

*Игламов Р.* Крылья даны всем детям человеческим // Известия Татарстана. – 1992. – 22 апр.

*Игламов Р.* В пространстве трагедии // Идель. –1998. – № 2. – С. 44–45.

Ил кайный, фикер көрәшә (А. Гыйләҗев белән әңгәмә) // Казан утлары. –1987. – № 1. – Б. 67–74.

*Илялова И*. «Ир-егетләр» (Г. Камал исем. ТДАТта куелу уңае белән) // Соц. Татарстан. – 1971. – 30 май.

*Илялова И.* Плечо товарища («Мужчины». К постановке в ТГАТе им. Г. Камала) // Театральная жизнь. – 1971. – № 21. – С. 28.

*Илялова И.* Театр им. Камала. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 328 с.

*Илялова И.* Мысли по поводу // Идель. – 1998. – № 8. – С. 36–37.

Ислам: Энциклопедический словарь. – М.: Наука. Главная редакция восточной литературы, 1991. – 315 с.

*Исмәгыйлев Ә.* Комедиянең жанр үзенчәлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 302 б.

*Йосыпова Н.* Хәзерге татар драматургиясендә интеллектуаль тенденция: М. Гыйләҗев // Фәнни язмалар – 2007: җыентык. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2008. – Б. 135–141.

*Йосыпова Н.* Соңгы еллар татар драматургиясе // Хәзерге татар әдәбияты / төз.: Г.Р. Закирова, Л.Ә. Гыйззәтуллина. – Казан: Мәгариф, 2008. – Б. 436–443.

*Лотман Ю.М.* Происхождение сюжета в типологическом освещении // *Лотман Ю.М*. Избранные статьи: в 3 томах. Т. 1. – Таллин: Александра, 1992. – С. 224–242.

*Мәхмүтов Һ.* Татар драматургиясендә трагедия жанры. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1965. – 111 б.

*Мәхмүтов Һ.* «Үзебез сайлаган язмыш» (Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә) // Соц. Татарстан. – 1974. – 23 апр.

*Мәхмүтов Һ.* «Канкай углы Бәхтияр» (Г. Камал исем. ТДАТ сәхнәсендә) // Соц. Татарстан. – 1975. – 25 февр.

*Мәхмүтов Һ.* Иң актив иҗат чоры // Татарстан яшьләре. – 1978. – 30 март.

*Миңнуллин Р.* Бәләкәй чагын сагынучы олы әдип // Шагыйрь генә булып калалмадым. – Казан: Матбугат йорты, 1998. – Б. 189–190.

*Миңнуллин Т.* Без «театр» уйныйбызмы? // Казан утлары. – 1972. – № 5. – Б. 175–178.

*Миңнуллин Т.* Ялгыш төзәтелергә тиеш // Казан утлары. – 2011. – № 4. – Б. 135.

*Миңнуллин Т.* Хәлил әйбәт егетме? // Мәгариф. – 2000. – № 3. – Б. 32–33.

*Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 1 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 20002. – 528 б.

*Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 20002. – 464 б.

*Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 20002. – 447 б.

*Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 4 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 20002. – 415 б.

*Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 5 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 20002. – 480 б.

*Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 6 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 20002. – 480 б.

*Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 7 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 20002. – 448 б.

*Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 8 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 20002. – 479 б.

*Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 9 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 20002. – 447 б.

*Миңнуллин Т.* Сайланма әсәрләр: 10 томда. 10 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 20002. – 447 б.

*Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 383 б.

*Миңнуллин Т.* Утырып уйлар уйладым: Көндәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 367 б.

Миңнуллин Туфан: фәнни-публицистик, документаль-биографик җыентык / төз. Г. Рәхим. – Казан: Җыен, 2015. – 624 б.

*Миңнуллин Т.* Пьеса ничек языла? // Татарстан. – 1993. – № 1. – Б. 117–121.

*Миңнуллин Т.* Татарның бер баласы. – Казан: Рухият, 2003. – 476 б.

*Миңнуллин Т.* Тәнзиләкәй // Казан утлары. – 2005. – № 9. – Б. 45–67.

*Миңнуллина Ф.* Сәнгать – ул җанлы хәтер (Ю. Сафиуллин драматургиясенә бер караш) // Казан утлары. – 2002. – № 6. – Б. 134–138.

*Миннуллина Ф.* Юныс Сафиуллин драматургиясе: Заман һәм герой. – Казан, 2007. – 132 б.

*Миннуллина Ф.Х.* Жанр драмы в татарской драматургии рубежа XX–XXI веков. – Казань: ИЯЛИ, 2019. – 144 с.

*Миннуллина Ф.Х.* Нравственные ценности в современной татарской драматургии // Театр. Время. Герой: сборник V Международной научно-практической конференции, посвященной 50-летию со дня основания Уфимского государственного института искусств имени Загира Исмагилова (31 марта 2018 года). – Уфа, 2018. – С. 136–143.

*Миннуллина Ф.Х.* XX гасыр ахыры татар драматургиясендә шәхес фаҗигасе (Т. Миңнуллин, Р. Хәмид, З. Хәким әсәрләре мисалында) // Тюркский мир и исламская цивилизация: проблемы языка, литературы, истории и религии: материалы IX Международной тюркологической конференции (Россия, Республика Татарстан, г.Елабуга, 13–14 апреля 2018 г.) / отв. ред. Р.Б. Камаева. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. – С. 171–174.

*Миннуллина Ф.Х.* Новые явления в татарской драматургии конца XX – начала XXI вв. // Научный Татарстан. – 2021. – № 2. – С. 78–89.

*Михайлова А.* О художественной условности. – М.: Мысль, 1970. – 335 с.

*Мустафин Р.* Факел внутренней свободы // Татарстан. – 1987. – № 5. – С. 6–7.

*Мөхәммәдиев Р.* Тормыш дәвам итә // *Мөхәммәдиев Р.* Якутлар табыладыр вакыт белән. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – Б. 181–197.

*Мөхәммәдова Г.* Зур драматург та ул // Шәһри Казан. – 1998. – 23 гыйнв.

*Низам Г*. Кем ничек ярата? // Татарстан яшьләре. – 1998. – 14 гыйнв.

*Низамиев Р.* Яшьлекне сагыну // Казан утлары. – 1997. – № 11. – Б. 28–30.

*Нигматуллина Ю.* «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. – Казань: Фэн, 2002. – 176 с.

*Нуреева Г.* Идейно-художественное своеобразие пьесы-сказки Туфана Миннуллина «Сказка про Гафията» // Филология и культура. Philology and culture. – 2020. – № 2 (60). – С. 205–210.

*Павелько С.* Любовь и кровь // Звезда Поволжья. – 2000. – 28 дек.

*Пивоваров Д.* Маленький полюс одиночества // Сов. Татария. – 1990. – 4 марта.

*Рәмиева И.Р.* Рус, татар, төрек әдәбиятларында ханбикә Сөембикә образы. – Казан, 2009. – 244 б.

*Руднев В.П.* Энциклопедический словарь культуры XX века. – М.: «Аграф», 2001. – 608 с.

*Салихова А.Р.* Особенности формирования и развития татарского сценического искусства. – Казань: ИЯЛИ, 2016. – 360 с.

*Саттарова А.* Яңа дулкында // Татар драматургиясе (1980–2000 еллар). Сайланма пьесалар: «Мәктәп китапханәсе» сериясе. Т. XXII / төзүчесе һәм кереш мәкалә авторы А.М. Саттарова. – Казан: ТаРИХ, 2003. – Б. 3–14.

*Саттарова А.* Хәзерге татар драматургиясендә сугыш темасы // Материалы итоговой научно-практической конференции ТГГИ за 2001 год. – Казань: Изд. ТГГИ, 2001. – С. 91–93.

*Саттарова А.* З. Хәким һәм Ф. Бәйрәмова драматургиясенең үзенчәлекләре // Милли мәдәният. – 2001. – № 1. – Б. 63–66.

*Сөләймән С.* Пар канатлар // Мәдәни җомга. – 1997. – 17 октябрь.

*Саттарова А.М.* Современная татарская драматургия: 1985–2000 гг. (Концепция эпохи и героя). – Казань: Гуманитария, 2003. – 150 с.

*Сафиуллин Ю.* Сәхнә әсәрләребез нинди? // Казан утлары. – 2000. – № 2. – Б. 156–161.

*Султанова Р.Р.* История татарского театра в плакатном искусстве. – Казань, 2017. – 352 с.

*Султанова Р.Р.* Сценография татарского театра: основные этапы и закономерности развития (XX – нач. XXI вв.). – Казань, 2020. – 592 с.

Сөембикә ханбикә. Җыентык: Тарихи, фәнни хезмәтләр, бәяннар, әдәби әсәрләр, әсәрләрдән өзекләр. – Казан: Идел-Пресс, 2001. – 279 б.

Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 6 т. – Казан: Раннур, 2001. – 544 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда: 6 т. / фән. мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2018. – 676 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда: 7 т. / фән. мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. – Казан: Фолиант, 2019. – 567 б.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда: 8 т. / фән. мөх.: Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов. – Казан: Фолиант, 2021. – 740 б.

*Тарханова Г.* Мулла «персона нон грата» түгел // Мәдәни җомга. – 2013. – 18 гыйн.

*Усманов М.А.* О Михаиле Худякове и его книге // *Худяков М.*Г. Очерки по истории Казанского ханства. – М.: ИНСАН, СФК, 1991. – С. 3–12.

*Урманче Ф.И.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. 1 т. (А–Г). – Казан: Мәгариф, 2008. – 246 б.

*Фәрхетдинова Ч.* Хакыйкатьне чагылдыручы спектакль // Мәдәни җомга. – 2012. – 16 нояб.

*Фәхретдин Р*. Гаилә // Идел. – 2003. – № 2. – Б. 58–65.

*Фролов В.В.* Бүгенге татар драматургиясе турында сөйләшү (түгәрәк өстәл утырышы) // Казан утлары. – 1984. – № 11. – Б. 166–168.

*Фролов В.* Судьбы жанров драматургии. – М.: Сов. писатель, 1978. – 289 с.

*Хабутдинова М.* Талантом обретенное бессмертие: итоги театральной декады в честь 80-летия Туфана Миннуллина // Татарика. – 2020. – № 2 (12). – С. 91–102.

*Хализев В*. Драма как род литературы. – М.: Изд-во Моск. ун-та, 1986. – 398 с.

*Ханзафаров Н.* Бишек җырын беләсезме? («Әниләр һәм бәбиләр». Г. Камал исем. ТДАТ сәхнәсендә) // Соц. Татарстан. – 1984. – 18 март.

*Ханзафаров Н.* В огне брода нет // Республика Татарстан. – 1997. – 26 нояб.

*Ханзафаров Н*. Татарская комедия. – Казань: Фэн, 1996. – 267 с.

*Ханзафаров Н.* Чәчәкләр һәм күз яшьләре // Ватаным Татарстан. – 1999. – 24 дек.

*Ханзафаров Н*. Драмаларда – күңел дөньябыз // Мәдәни җомга. – 2002. – 15 март.

*Хәбетдинова М.М*. «Төш»тәге серләр (Т. Миңнуллинның «Төш» спектакленнән соң уйланулар) // Казан утлары. – 2015. – № 8. – Б. 169–176.

*Хәйри Ә.* «Шәҗәрә» яки җәмгыятебез көзгесе // Мәдәни җомга. – 1998. – 13 нояб.

*Хәмид Р.* Татар драматургиясе миллиме? // Казан утлары. – 2000. – № 2. – Б. 123–128.

Хәрәкәттә – бәрәкәт (Ә. Закирҗановның М. Гыйләҗев белән әңгәмәсе) // Сәхнә. – 2020. – № 12. – Б. 4–7.

*Шакирова Г.* Драматургия Туфана Миннуллина 1980–90-х г.: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Казань, 1999. – 19 с.

*Шарипов М.* Драматургия Туфана Миннуллина. Проблемы героя и его художественное воплощение: автореф. дис. ... канд. филол. наук. – Уфа, 1989. – 20 с.

*Шарипова А.С.* Татарская драматургия XX – начала XXI вв.: проблема инварианта: монография. – Казань: ИЯЛИ, 2022. – 336 с.

*Шәехов Л.М.* Татар шигъри трагедиясе: монография. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – 146 б.

*Шәкүров С.* Туган туфрак // С. Шәкүров. Пьесалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – Б. 115–146.

*Шәймиев* М. Иң зур бәхет – халык мәхәббәтенә ия булу // Туфан Миңнуллин: фәнни-публицистик, документаль-биографик җыентык / төз. Г. Рәхим. – Казан: Җыен, 2015. – Б. 3–5.

*Шәмсутова А*. «Җан сурәте» // Мәйдан. – 2007. – № 4. – Б. 140–143.

*Шәмсутова А.А.* Туфан Миңнуллин пьесаларында Язмыш мифологемасы // Хәзерге татар әдәбиятында яңараш: фәнни мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – Б. 90–100.

*Шәмсутова А*. Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш: фәнни мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 232 б.

*Юзеев И*. Әлмәндәр гомере телим: Т. Миңнуллинга 60 яшь // Казан утлары. – 1995. – № 8. – Б. 137–138.

*Юзеев И.* Китмәскә дип килгәннәрнең берсе // Казан утлары. – 2001. – № 10. – Б. 45–46.

*Юзеев И.* Кыр казлары артыннан // Сайланма әсәрләр: 5 томда. 3 т. – Казан: Татар. кит. нәшр. 2002. – Б. 207–239.

*Юсупова Н.М.* Система образов-символов в татарской поэзии первой половины XX века: монография. – Казань: Ихлас, 2018. – 312 с.

*Яхин А.* Әдәбият дәресләре: Укытучылар, югары уку йортлары студентлары һәм укытучылар өчен методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2003. – 176 б.

ЭЧТӘЛЕК

Кереш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
1 бүлек. 1960–1980 еллар татар драматургиясендә яңа тенденцияләр һәм Т. Миңнуллин иҗаты. . . . . . . . . . . 25
1.1. 1960–1980 еллар драматургиясендә яңарыш дулкыны . . . 25
1.2. Т. Миңнуллинның драматургиядә беренче тәҗрибәләре. . . 45
1.3. Тормышчан конфликт һәм яңа геройлар . . . . . . . . . 50
1.4. Драматургның яңа жанр формалары өлкәсендәге эзләнүләре. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
1.5. «Әлдермештән Әлмәндәр» феномены. . . . . . . . . . . . 84
1.6. Драматург иҗатында тарихи шәхесләр . . . . . . . . . . 95
2 бүлек. Т. Миңнуллинның XX гасыр ахыры иҗатында әдәби-эстетик эзләнүләр . . . . . . . . . . . . . . . 117
2.1. XX гасыр ахырында социаль-мәдәни шартлар һәм сәхнә әдәбияты үсеш-үзгәреше . . . . . . . . . . . 117
2.2. Т. Миңнуллинның XX гасыр ахыры иҗатында чор һәм шәхес . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 138
2.3. Милли яшәешне сәнгати кабул итүдә яңа алымнар . . . . 156
3 бүлек. Т. Миңнуллинның XXI гасыр башы пьесаларында сурәтләнгән дөнья . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 171
3.1. Яңа гасыр башы сәхнә әдәбияты. . . . . . . . . . . . . 171
3.2. Яңа жанр формаларына йөз тотып. . . . . . . . . . . . 190
3.3. Т. Миңнуллинның соңгы чор иҗатында шәхес концепциясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
3.4. Драматургның сурәтле дөньясында яшәеш кыйммәтләре . 210
3.5. Балалар өчен язылган пьесалар . . . . . . . . . . . . . 223
Йомгак. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 236
Файдаланылган әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241

Научное издание

**Закирзянов Альфат Магсумзянович**

**ДРАМАТУРГИЯ ТУФАНА МИННУЛЛИНА**

(на татарском языке)

Редактор *Л. Г. Шарифуллина*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *А.В. Булатова*

Подписано в печать 22.11.2022.
Печать офсетная. Гарнитура «Times».
Формат: 60×84 1/16.
Усл.-печ. л. 14,7. Уч.-изд. л. 13,5. Тираж 200 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен в Институте языка, литературы
и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20